# казан утлары

11

НОЯБРЬ-1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**11**
НОЯБРЬ
1972

## Бу санда

М. МАЛИКОВА. Адашканга юл кайда! Маҗаралы повесть . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Н. ДӘҮЛИ. Тынгысыз йорт. Поэмадан өзек . . . 58
М. ЗАРИПОВ. Су буенда. Хикәя . . . . . . . 65
Х. САРЬЯН. Туган як моңы. Нәсер . . . . . . 82
Р. ГАТАУЛЛИН. Март-апрель. Шигырьләр . . . 86
С. ШӘКҮРОВ. Туган туфрак. Пьеса . . . . . . 93
Е. УТКИН. Күпләр аны сагынып искә ала. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Кояшым... Шигырьләр . . . 132

ОЧЕРКЛАР

Ф. НАСЫЙРОВ. Үлемне җиңеп . . . . . . . . 134

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

К. НӘҖИПОВА. Хезмәттәшлек . . . . . . . . 141
Ф. ЕРМАКОВ. Хәзинәбез уртак булсын . . . . 152

СӘНГАТЬ

В. ШНАЙДЕР. Кулыңда кинокамера... . . . . . . 154

ЭСТЕТИКА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

К. ГЫЙЗЗӘТОВ. Ленинның чагылыш теориясе һәм художникның активлыгы . . . . . . . . . 161

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Э. НИГЪМӘТУЛЛИН. Жан-Жак Руссо һәм XX йөз башы татар әдәбияты . . . . . . . . . . 167

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. СВЕРИГИН.** Заман һәм тормыш таләбе . . . 177

КИТАП КҮЗӘТҮ

**И. АХУНҖАНОВ.** Кояшлы дөнья . . . . . . . 183

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.** Нур чәчеп туды . . . . . 186
**М. ГАЙНУЛЛИН.** Шиһап Әхмеров . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик, 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор өчен: **Ләбибә Ихсанова**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 9/VIII-1972 ел. Басарга кул куелды 17/X-1972 ел. ПФ 09029. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 86046 экз. Заказ Г-522. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советының нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1972 ел.

## Мәдинә Маликова

# АДАШКАНГА ЮЛ КАЙДА?

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ

### 1



Фажига унтугызынчы февральгә каршы төндә булды. Ә Ниаз икенче көнне иртән бу турыда белми иде әле.

Җомга көн иде. Ул соң гына, кояш шактый күтәрелгәч кенә, йокысыннан торды. Чалбардан гына килеш ишегалдына чыгып, ахылдый-ухылдый кар белән уынды. Күңеленнән төнге бураннан соң көн аязуына, кар чисталыгына, дөньяның сафлыгына сөенде.

Чәй кайнату мәшәкате дә, өстәл янында ялгыз утыру да бүген аның кәефен җимермәде. Югыйсә, ул, әнисе Пермь каласына, кияве белән кызына кунакка киткәннән бирле, өйдә ямь тапмый, ялгызы гына ашау-эчүне яратмый иде. Бүген исә сменасы кич кенә булуга сөенде. Әллә кайчан җыя башлап та, һаман кул житмәгәнгә, тартма эчендә таралып яткан кечкенә радиоалгычның эшен, ниһаять, бетерергә булды.

Ул өстәлне яктыга, ак пәрдәләре ике якка шудырып куелган кечкенә тәрәзә янынарак күчерде. Тәрәзә төбендәге яран гөленең чуар куләгәсе вак шөрепләрне күрергә комачаулый иде. Ниаз гөл чүлмәген бер кырыйга күчерергә үрелгән иде, киң, буш урамнан әкрен генә үтеп барган таныш «Волга»ны күреп, өстәлгә түше белән яткан хәлдә тукталып калды. Шофер Борис та, машина тәрәзәсеннән башын сузып, Ниазларга таба караган. Менә ул машинасын бөтенләй туктатты.

«Очлы күз, мине күреп тә алды»,— дип уйлады Ниаз һәм, кулмәкчән генә килеш, кунакны каршы алырга чыкты. Ул арада Борис кече капканы шыгырдатып ачты, ишегалдына килеп керде.

— Саулыкмы? — диде ул сүрән генә.— Кара, син шәһәр читендә үз йортыңда яшәп ятасың икән. Буржуйлар кебек, ә?

— Әти мәрхүм мирасы,— диде Ниаз.— Авылча тормыш инде. Хәзер мондый өй белән мактанып булмый, дүрт бүлмәле квартир ала кешеләр.

---

Әсәр журнал вариантында бирелә.

— Казан каласының үзендә авылча иркенләп яшәү бер дә начар түгел ул.

Борисның олыгая башлагач та малайларныкыча шомалыгын саклаган түгәрәк йөзе житди, хәтта кайгылы иде. Ләкин аның гадәттәге үйчанлыгына, сабыр-салмак сөйләшүенә күнеккән Ниаз моңа бөтенләй игътибар бирмәде. Борис үтеп барышлый, аны тәрәзәдән күреп, болай гына кереп чыгарга ниятләгән, дип уйлады һәм, туңып та киткәнен сизеп, танышын өйгә чакырды:

— Әйдә, өйгә уз. Бәлеш-мазар белән үк сыйлый алмам сыйлавын, әнинең өйдә юк чагы.

Борис, күн перчаткаларын салып, бер-берсенә шапылдатып сукты да, такта капкага караган хәлдә:

— Кереп тормыйм, рәхмәт,— диде.— Үзең генә киенеп чык та киттек. Сине алырга җибәрделәр.

— Кем? — диде Ниаз гаҗәпләнеп. Ул бүген төштән соң гына эшкә чыгарга тиеш ләбаса, ник кирәге чыкты икән?

— Тикшерүче,— диде Борис теләр-теләмәс кенә.

— Нәрсәне тикшерүче?

— Син ишетмәгәнсеңдер шул әле. Бүген иртән Фидаилне үле хәлендә таптылар.

Дөнья кинәт үзгәрде. Көн артык салкын икән, Ниаз ул салкынның юка күлмәк аркылы кереп, йөрәгенә үк үтеп җиткәнен тойды.

— Кайда? — дип сорады ул.

— Мамадыш трактында. Машинасында.

Борис «машинагызда» диярга тиеш иде. Чөнки Ниаз белән Фидаил икесе бер «Волга»да алмашлап эшлиләр бит. Дөресрәге, эшлиләр иде.

Юлда Ниаз Бористан бу хәлнең ничек булганын җентеклэбрәк сорашмакчы иде дә, ике кулы белән чытырдап баранкага ябышкан, күзләрен соры асфальт юлга текәгән шофер аның сорауларына рәтле-башлы җавап бирмәде.

Таксомотор паркының капкасыннан керүгә, Ниаз үз машинасын — 83—24 номерлы күк «Волга»ны күрде. Аны ишегалды уртасына, нәкъ юл өстенә китереп куйганнар. Машинаның ике як ишеге дә шар ачык. Шофер утыргычының елтырап торган кара күнендә тоныкк таплар күренә. «Кан таплары» дип уйлады Ниаз тетрәнеп. Ул бу машинада күптән йөри, шуңа күрә аңа җан иясенә күнеккәндәй күңеле белән береккән иде.

Ниазны директор урынбасарының кысан һәм шыксыз бүлмәсенә чакырып керттеләр. Каршыдагы өстәл янында таныш түгел бер кеше — тикшерүче утыра иде.

Бусаганы атлаганда, Ниаз таныш кешене очратырга өметләнебрәк кергән иде. Ник дисәң, ул үзе дә милиция эше белән бик кызыксына, армиядән кайтканнан бирле дружинник булып йөри, район милиция бүлегендә эшләүчеләрнең күбесе белән кул биреп исәнләшә иде. Ул институтта уку, судья булу турында хыяллана иде. Әле быел да әтисе озак чирләп вафат булу аркасында гына бу ниятен тормышка ашыра алмады.

Моңарчы, милиция тирәсендә шактый чуалса да, Нияз зур җинаятьләрне ачуга катнашмады. Ул эшләгән эшләр исереп сугышкан егетләрне верып, милиционер кулына тапшыру яки тәрәзә ваткан шук малай-шалайны балалар бүлмәсенә илтүдән узмады.

Хәзер исә, нәкъ менә аның ярдәме кирәк чакта, җинаятьне ачарлык сүз әйтә алмаячагын аңлап, Ниаз эчтән генә уфтанып куйды.

Тикшерүче кара кысалы зур күзлеге аркылы Ниазга бик җитди, хәтта кырыс итеп карады. Бу кеше яшь иде әле, күп булса утыздадыр. Өлкәнрәк, мөгътәбәррәк күренү өчендер инде, президиумга утырырга җыенгандай, бик пөхтә һәм рәсми киенгән: кара костюм, кара галстук,

эк күлмәк. Чәче дә кара, күпереп торган мыегы да кара. Тик болар барысы да аның яшьлегең, бит очларының алсулыгын, иреннәренең кызыллыгын яшерми, киресенчә, тагын да ныграк күзгә ташланырлык итеп күрсәтә иде. Тикшерүче, кыяфәте белән татарга охшаса да, милләте белән рус булып чыкты. Ул, урыныннан кузгалып, Ниазга ак кулын сузды:

— Головин.— Бераз уйлап торгач:— Виктор,— дип тә өстәде.

Ул Ниазны каршысына утыртты да үтә җитди кыяфәт белән сорау артыннан сорау яудырырга кереште.

Беренче күргән кеше белән артык ачылып сөйләшү кыен. Син әйткәннәрне ул ничек анлар бит әле. Өстәвенә, кинәт булган фаҗига Ниазның уйларын чуалткан, дөресен әйткәндә, бераз миңгерәтеп үк җибәргән иде. Алай да ул фикерен җыярга, тикшерүченең сорауларына мөмкин кадәр тулырак җавап бирергә тырышты.

«Мәрхүмне күптән белә идегезме?»

Алар узган елның маенда, Фидаил таксист булып эшли башлагач кына таныштылар, аннан соң да бер-берсенең исемнәрен белүдән узмадылар. Бер машинада алмашлап эшлиләр иде бит, ә алмашынны еш дигәндә атнага бер күрәсең. Үзең белән бер сменадагы таксистлар белән ешрак очрашыла, урамда гына булса да бер-береңә кул болгап узасың, ә монда ул да юк.

«Паркта эшләүчеләр арасында Фидаилнең якын дуслары бар идеме?»

Анысын Ниаз белми. Бу турыда аларның сөйләшкәне булмады. Ниаз аның парктан читтә кем белән булса да очрашканын күрмәде. Фидаил апаларында яши иде бугай; хәер, анысы да Ниазның хәтеренә каяндыр ишетү буенча гына кереп калган. Ул беркайчан да Фидаилнең бусагасын атлап кермәде.

«Ә Фидаил үзе, сезнеңчә, ниндирәк кеше иде?»

Ниаз: «Әйтүе кыен, мин аның кемлеген белмәдем бит»,— диярга авызын ачкан иде — тыелып калды. Тукта, ул бит алмашының кем икәнен бөтенләй үк белми түгел, белә! Беренчедән, Фидаил — армия хезмәте үткән егет. Ә Ниаз солдат боткасы ашаган егетләрнең кемлеген бер чакрымнан танырга өйрәнгән. Фидаилнең яхшы күңелле кеше икәнен сизә иде ул. Икенчедән, Фидаил сүзендә нык торучан иде. Әйттеме — эшли, вәгъдә бирдеме — үти. Барыннан да бигрәк — ул үз эшен, машинасын ярата иде.

Ниаз тикшерүчегә бик ышанычлы итеп:

— Мировой егет иде,— диде.

— Диспетчер әйтүенчә, өченче көнне кич белән, сез линиядән кайткач, Фидаилне телефонга чакырганнар. Кем шалтыратты икән аңа, белмисезме?

— Мин сорамадым, ул әйтмәде.

— Ул көнне сез аның үз-үзен тотышында, сөйләшүендә берәр үзгәреш сизмәдегезме?

Ниаз, Фидаил белән соңгы очрашуны бөтен ваклыклары белән күз алдына китерергә тырышып, шактый вакыт уйланып утырды.

Өченче көнне иртән сәгать биштә, Ниаз эшкә килгәч, диспетчер аңа Фидаил калдырган язуны тоттырды: графаларга бүленгән зәңгәрсу кәгазь битенә бик пөхтә итеп, тигез хәрефләр белән болай дип язылган иде: «Ниаз малай, рессорлар какшый башлаган. Бергәләп карыйк әле. Син кайтуга, мин паркка килеп торырмын».

Дөресен әйткәндә, Ниаз машинага, дөньяның үзенә караган кебек, җиңелчәрәк карый: тәгәрмәче тәгәриме — тәгәри, утыр да чап! Ватылса, янасын бирерләр. Фидаил исә машинаны, баласын артык назлаган ана кебек, өф-өф итеп кенә торучан, хәтта артык вакчыл шофер иде. Нәкъ күз алдына, приборлар калканына Фидаил Америка артисткасы сурә-

тен ябыштырып куйды. Анысы Ниазга бер дә ошамады: ат ялы кебек асылынып төшкән туры кара чәчле, озынча йөзле, оятсыз күзле бу хатын аңа бик сөйкемсез күренде. Ләкин ул Фидаилгә аны-моны әйтмәде, алмашының хәтерен калдырасы килмәде. Тора-бара Ниаз ул сурәткә күнекте, игътибар итмәс булды, ә бик эчен пошыра башласа, ул аны перчаткалары белән каплый да куя иде.

Әйе, машинаны бик кадерләп кенә тота иде Фидаил. Алмашының башка якларын исә Ниаз бик аз белә иде. Ничек яши иде ул? Кемнәр белән аралаша, кемне ярата, нәрсә турында хыяллана иде? Монысы Ниазга караңгы. Елтыр күзле, елмайганда яңак очлары чокыраеп керүчән, бөтерчектәй җиңел гәүдәле, житез хәрәкәтле ул егетнең күңелен белә алмый калды Ниаз. Хәзер менә бу турыда уйлагач, ул үкенеп куйды: кара инде, ничә айлар бергә эшләп, рәхәтләнеп бер гәпләшеп тә утырмаганбыз, ичмаса, дип уфтанды. Фидаил үзе дә тиз генә ачылып китә торганнардан түгел иде, ахры. Авызы ерык булса да, тыгыз тешләре арасыннан артык сүз чыгармый, кеше белән тиз генә аралашып китә алмый иде.

Менә шул Фидаил, өченче көнне кич белән, елтыр козыреклы бүрке астыннан күзләрен очкынландырып, Ниазны парк капкасы төбенә үк чыгып каршы алды. Гадәттәгечә елмайды — тик алмашы белән күрешкәнгә түгел, машинасын күргәнгә ерык иде аның авызы.

Машинаны юу бүлмәсенә керткәч, колга кебек озын буйлы Андрей, шлангны «Волга»ның алгы тәрәзәсенә төбәп, Фидаилне үртәгәндәй кычкырып куйды:

— Тр-р-р, карт алаша!

Карт диярлек тә бар инде: гадәттә 400 мең чакрым юл йөргәч, машина искергән дип, тиешле урынга тапшырыла. Ә бу күк «Волга» 380 меңне чапкан, алай да тәгәрмәчләрендә нык тора әле, яңаларга биргесез!

Фидаил, Андрей кулыннан шлангны алып, машинаны үзе юарга тотынды.

Шул вакыт ишектән:

— Фидаил! Сине телефонга чакыралар! — дигән тавыш ишетелде.

Ул чакта Ниаз моңа әллә ни әһәмият бирмәгән иде. Хәлбуки, шоферларны диспетчер телефонына сирәк чакыралар бит. Ниазның үзен, мәсәлән, ике елга бер тапкыр да телефон аша гараждан эзләткән кеше булмады. Танышлары да шактый, кызлар белән дә йөрми түгел, югыйсә. Димәк, кемдер бик кирәксенеп эзләгән Фидаилне... Ул озак тормады, тиз арада әйләнеп керде һәм, нидер әйтергә кирәк тапкандай:

— Исенә төшкән! — дип, гажәпләнгән кыяфәт белән башын чайкады. Бу сүзләрне әйткәндә Фидаил Ниазга түгел, приборлар калканына ябыштырылган әлеге артистка сурәтенә караган иде.

Шунда, кем ул, ник шалтыраткан? дип төпченеп сораштырасы калган да бит... Хәер, Фидаил аңа җавап биреп торыр идеме икән?

Машинаны профилакторийга кертеп, эстакадага бастырдылар да икәүләп чокырга төштеләр. Рамга сырланып-сырланып боз каткан, аннан пычрак тамчылар тама иде. Шофер күңеленә якын ис — кызган тимер исе, карбид исе — борынны ярып керде.

Ниаз озак азапланмады, Фидаилнең:

— Ну, монда эш күп түгел икән, слесарьлар белән бүген үк төгәлләрбез,— дигән сүзенә сөенеп, өенә кайтып китте.

Ул кичне урам капкасына беркетелгән таблога электр лампочкалары белән: «Һава болытлы, бозлавык»,— дигән сүзләр язылган иде. «Бозлавыгы кыш буе сүнеп тормый инде, анысына күнеккән»,— дип уйлады Ниаз ул чакта. Һава хәлләрен алдан ук әйтеп куялар. Кеше язмышында булачак бураннарны, фаҗигаләрне дә шулай алдан әйтүчеләр булсачы!..

Ниаз сөйләгәннәрне дәшми-тынмый тыңлап утырган тикшерүче Головин:

— Хәтерегезгә төшерегез әле: уйчан, борчулы, дулкынланган төсле түгел идеме ул? — дип сорады.

— Юк, әйтәм бит, гадәттәгечә күңеле көр иде. Шул, телефоннан сөйләшеп чыккач кына: «Исенә төшкән икән»,— дип куйды.

— Ә, бәлки, ул кайчан да булса сезгә берәр танышы турында сөйләгәндер? Яки сез аны кем белән булса да күргәнсездер? Берәр кыз белән дуслашканын белмисезме? Уйлап карагыз әле.

Ниаз башын гына чайкады:

— Юк шул, сөйләгәне булмады. Күрмәдем дә. Бик тыйнак егет иде бит ул, авыл малае. Шәһәргә килгәч, хатын-кызлар белән танышып өлгерде микән, ай-һай...

Тикшерүче өстәлдәге зур кара папкадан газетага төрелгән озынча әйбер алды.

— Сезнең бу нәрсәне күргәнегез бармы?

Ул газета эченнән терсәк буе тимер чыгарып, Ниазга күрсәтте. Тимер шактый юан таяк булып, аның бер башы яссы, зур гына тишекле, тишек тирәләре шомарган, ялтырап тора, ә икенче нечкәрәк башында кечерәк тишек булып, аңа сары каеш элмәк кидертелгән иде.

Ниаз тимергә сәерсенеп карады: аның гомергә дә мондый әкәмәтне күргәне юк иде.

— Шушы кистән беләнме? — дип сорады ул. Аның тавышы кинәт карлыкты.

Тикшерүче, әйе дигәнне аңлатып, башын селекте.

— Без аны машинадан ерак түгел, кар астыннан табып алдык. Ә менә бу — машина идәнендә ята иде.

Головин папкасыннан өр-яңа егерме бишлек акча алды. Аксылшәмәхә төсләр белән бизәлгән кәгазь кисәгендә бер җыерчык та, бер тап эзе дә юк иде. Әйтерсең лә, тикшерүче Головин ак бармаклары белән тотканчы, аңа кеше кулы тимәгән.

— Шофер кесәсеннән чыккан акча түгел бу,— диде Ниаз.— Без акчаны кадерләп йөртә белмибез, тотабыз да йомарлыйбыз, һич булмаса бөклибез.

Головин, Ниаз сөйләгәннәрне әзсенеп булса кирәк, көрсенеп куйды:

— Хәзергә минем башка соравым юк. Берәр нәрсә исегезгә төшсә, я бер-бер шикле хәл булса, шунда ук миңа хәбәр итегез.

Ул блокнот битенә эш адресын, телефонын язды да, ертып алып, Ниазга сузды.

Яңадан ишегалдына чыккач, Ниаз тагын машинасы янына килде. Анда слесарьлар, машина ватылу сәбәпле эшкә чыкмаган яки бүген ялда булса да, бәхетсезлекне ишетеп, паркка килгән шоферлар сөйләшеп торалар иде. Бу юлы Ниаз «Волга»ны ят күзләр алдында бөрешеп торган ятим балага охшатты.

Җыелып торган кешеләрдән сорашып, ул фаҗигале төндә паркта булган вакыйгаларны белде.

Өченче көн кич, Ниаз кайтып киткәч, Фидаил, бик мөһим шәхси сәбәпләрем бар дип, сменасының сәгатен алыштыруны үтенеп сораган. Эшләү дәверендә беренче үтенече булганга, аңа моны рөхсәт иткәннәр. Кичә көндез ул кайларда йөргәндер — анысы билгесез, чөнки машинада рация юк. Шул рациясе булмау аркасында, аны иртәнгә хәтле таба да алмаганнар.

Фидаил тиешле вакытында, ягъни төнге сәгать уникедә паркка кайтмагач, диспетчер борчылган, әлбәттә, тик алай да, берәр аулак урамда ватылып ята торгандыр, дөньяда ниләр булмый дип, үзен-үзе юаткан.

Машина Мамадыш трактында, юл читендә янтайган хәлдә, төн кунган. Төнлә яуган кар аны күмеп китә язган. Ләкин үткән-сүткән кешеләр

аңа якын бармаганнар: кала урамында нинди машина тормас? Сәгать җидедә мәктәпкә барырга кузгалган малай-шалайлар гына яртылаш диярлек карга күмелгән машина янына килгән һәм Фидаилнең җансыз гәүдәсен беренче булып алар күргән...

Ә Ниаз ул кичне өенә кайтты да йокларга ятты. Икенче көнне соң гына торып, шәһәргә чыгып китте. «Дзю-до даһие» дигән ике серияле кинога керде. Көрәшчеләрне, көчле кешеләрне яратканга, бу фильм аның күңеленә бик хуш килде. Ә кич белән ул, берүзе ах-вах килеп, телевизордан хоккей карап утырды.

Нәкъ шул минутларда Фидаил җан биргәндер, бәлки...

## 2

Кеше вафат булгач: «Эх, исән чакта кадерен белмәдек, тегеләй итәсе калган, болай эшлисе калган икән»,— дип үкенү гадәткә кереп киткән. Бу юлы да Ниаз кебек уфтанучылар булды. Ә бит Фидаилнең кадерен белмәгәннәр түгел, бик белгәннәр икән: диспетчер бүлмәсендәге Мактау тактасында, аскы рәттә генә булса да, аның сурәте эленеп тора иде. Хәзер менә шул сурәтне зурайтып, кара тасма белән уратып, ишек өстенә үк элеп куйдылар. Җыелыш саен диярлек, планны арттырып үтәгәне һәм машинаны саклый белгәне өчен, Фидаил макталып телгә алынган, премияләр белән бүләкләнгән. Ун ай бергә эшләү дәверендә ул беркем белән дә телгә килмәгән, аның үзен дә рәнҗетүче булмаган. Сау-сәламәт кешегә, җир җимертеп эшләгән егеткә нинди кадер кирәк тагын?

Парк ишегалдында, ачык һавада тезелеп торган «Волга»лар янында, мәрхүмнең җеназасын үткәрделәр. Фидаилнең гәүдәсе куелган автобус янына парк җитәкчеләре чыгып басты. Халык арасында туктаусыз айкалып шомарган, тирләсен күреп-ишетеп бәгырьләре каткан шоферлар, аягүрә баскан килеш, директорның, партоешма секретареның, актив кешеләрнең Фидаил турындагы җылы сүзләрен тыңладылар. Нотыклар кыска булды, чөнки мәрхүм фани дөньядан яшьли китте, җирдә эшлисе бик күп яхшылыкларын үзе белән алып китте.

Шоферларның кайсы көдрә, кайсы пеләш башларына берән-сәрән кар бөртекләре коелды. Алар күңелдәге кичерешләрен матур сүзләргә төреп әйтеп бирә белмиләр иде. Хәер, аларның йөрәге мәрхүмне кызганып әрнүдән бигрәк, ярсып типте: бу нинди хәл тагын, таксистларга кул күтәрә башладылар! Алар ышануынча, бандит түгел, Газраил үзе дә такси шоферына якын килүдән сак булырга тиеш, чөнки таксистлар бер-берсе өчен утка керергә әзер торалар һәм бер-берсен җәберләүгә юл куймаячаклар. Моны шоферлар үзләре генә түгел, күзенә такси чагылган һәркем белергә тиеш иде кебек.

Шуңа күрә җеназада катнашучыларның күңелендә кемлекләре мәгълүм булмаган җинаятьчеләргә карата нәфрәт хисе кайный, ни дә булса эшләү, үзенең көч-кодрәтен күрсәтү теләге яна иде.

Тынлы оркестр сузып-сузып матәм маршы уйнады.

Оркестр трубаларының җизе тонык кына ялтырый, музыкантларның куллары күшегеп кызарган. Барысының да йөзләре сүрән, тик берсе — замша куртка кигән тук чырайлы егет шушы кайгы, сагыш арасында үзе өчен генә кызык табып елмая. Тиешле чакта ул җиз трубаны кызыл иреннәренә куеп, озак итеп, әче итеп кычкырта, көчәнүдән ак яңаклары алланып чыга, ә трубаны авызыннан алды исә, тагын елмая башлый. Елмайганда бер аскы теше юклыгы күренә. Ниаз аның йөзенә нәфрәт белән карап: «Ах, калган тешләреңне дә кояргa!» — дип уйлап куйды.

Фидаилне туган авылына илтеп күмделәр. Ниаз, аның апасы һәм җизнәсе белән бергә, автобуска утырды. Алдан кызыл йолдызлы обелиск белән чардуган куелган йөк машинасы, аннары автобус кузгалды.

Йола буенча, Фидаилне ирләр генә җирләде, хатын-кыз койманың тышкы ягыннан тавыш-тынсыз гына карап торды. Кыш зиратны бик матурлаган, шомарткан, тигезләгән,— кар астыннан чардуганнарның, ташларның очы гына күренә. Шул саф тигезлектә кар белән буталган күгелҗем туфрак өеме хасил булды, аңа кызыл йолдызлы обелиск белән яшел чардуган куелды. Яңа кабер тирәсендә карт каеннар, өрәңгеләр тын калып торды, соры болытлардан сирәк кенә кар бөртекләре төште...

Исәннәргә зират тирәсендә озак тору авыр. Бу табигый, чөнки кеше күңеле яктыга, рәхәткә омтыла.

Бернич кеше автобуска юнәлде, алар арасында Нияз читтәрәк кенә, күзгә ташланмый гына йөрүче Головинны күрде...

### 3

Шәһәргә кайткач, Нияз, Кольцода машинадан төшеп, беренче троллейбуска утырды. Вагон шыгрым тулган, халык эштән кайта иде.

Троллейбус Тверская тукталышына килеп җитте. Нияз урам ягына карап басып тора иде. Менә каршыдагы биек йортның дүртенче катында, бер тәрәзәдә гөлт итеп ут кабынды, сары пәрдәләр тибрәлеп китеп ачылды, анда кара свитер кигән озын муенлы бер кыз күренде. Кыз үрелеп тәрәзә төбеннән нидер алды.

Ниязга сары пәрдәләр дә, бүлмә түшәмендәге плафон да, озын муенлы кыз да бик таныш сыман тоелды. Троллейбус кузгалып киткәч, озын муенлы кызны кайда очратканы да Ниязның исенә төште, алай гына да түгел, моннан бер ай чамасы элек булган вакыйга аермачык күз алдына килеп басты...

...Унике сәгать буе Казан урамнарында арлы-бирле йөреп, Нияз ул көнне дә шактый ялыккан иде. Дөрес, машина йөртү — күнегелгән эш, күзләр — үткенләгән, кул-аяклар — житезләгән югалтмый, шулай да вакыт-вакыт баш томаланып китә, һаман бер килеш утырганга биләр, җилкәләр катып калгандай була.

Ярый әле, һава хәлләре зарланырлык түгел иде: өстән яумый, аста эреми, томан-фәлән күзне бәйләми. Тик шунысы бар: көн болытлы булганга, бик иртә караңгы төште, ә төнлә йөрү ни дисәң дә кыенрак.

Ниязның сменасы беткән, инде ул яшел утын кабызган килеш туптуры гаражга барып кирәргә ниятләгән иде. Карл Маркс урамын узып, зур фонарьлар белән яктыртылган Ирек мәйданына чыккач, ул кара тун, ак башлык кигән бер кызның кулындагы зур папка белән туктарга ишарәләгәнен күрде. Нияз, тормозларын ачы чинатып, «Волга»ны тротуар кырыена китереп туктатты да артына борылып карады. Әлеге кыз, биек үкчәле ак читекләре белән вак-вак атлап, гәүдәсен туры тотып килә, ашыгырга-йөгерергә исәбендә дә юк. Нияз, әллә ялгыш аңладыммы, аның, бәлки, машинада хәбәре дә юктыр, папкасы ялгыш кулыннан ычкына язып калганга, миңа болгаган төсле күренгәндер, дип тә уйлап куйды.

Әмма кыз машина турына җиткәч туктады, алай да урталай бөгелеп тәрәзәгә карамады, башын чак кына иеп:

— Хәерле кич, Фидаил! — диде.

Зәгыйфь, нечкә тавышыннан Нияз аның яшь кенә кыз икәнен танып алды. Шофер гадәте: күзләр һаман юлда, янында утырган кешегә борылып карарга җай тими, ирексездән кешенең кем икәнен тавышыннан, сөйләшүеннән танырга өйрәнәсең.

Нияз, ишеген ачып:

— Хәерле кич,— дип җавап бирде.— Тик Фидаил түгел, Нияз әле бу.

— Ә-ә, гафу итегез. Бу машинада Фидаил йөри иде бит. Сиксән өч-егерме дүрт... Гафу итегез, ялгыштым, ахры.

— Алай ук ялгышмадыгыз. Мин — Фидаилнең алмашы. Аның сменасы иртәгә.

Кыз, тагын бер кат гафу үтенеп, артка чигенде.

Ниаз машинадан чыкты:

— Ә бәлки, сез кая да булса барырга телисездер? Фидаил янына, мәсәлән. Мин сезне илтеп куя алам.

— Юк, рәхмәт. Мин өйгә кайтам.

— Өегез кайда соң сезнең?

— Тверскойда.

— Миңа юл уңае икән,— Ниаз машинаның арткы ишеген ачты.— Утырыгыз. Танышын юл уртасында ташлап китсәм, алмашым мине мәңге гафу итмәс.

Кичке саран яктыда, шул берничә авыз сүз сөйләшкән арада, Ниаз кызның унсигез-унтугыз яшьләр тирәсендә икәнен, аның бик нәзакәтле, иркә, хәтта аксөяк булуын, хәзерге минутларда нилектәндер бик кәефсез икәнен аңлап алды. Гәүдәсен туры, башын югары тотса да, кызның йөзе моңсу иде. Кыяфәте белән студентка кебек, аның кулындагы зур папкаларга гадәттә нота китаплары салып йөртәләр. Ниазның аны елмайтасы, күңелен күтәрерлек сүз әйтәсе килде.

Кыз арткы утыргычка урнашкач, Ниаз машина ишеген шапылдатып япты да «Волга»ны сак кына кузгатты.

— Консерваториядә эшләр ничек бара соң? — диде ул.

Кыз, сәерсенеп, Ниазның алгы тәрәзә янындагы көзгедә чагылган күзләренә карады:

— Ә сез каян беләсез?

— Музыкант күрсәм, колагым чыңлый минем,— диде Ниаз.— Мин әле, кайсы колагым чыңлавына карап, сезнең нинди инструментта уйнавыгызны да әйтә алам.

Бу кыз җырчы түгел, тавышы зәгыйфь. Кызлар гадәттә скрипкада, виолончельдә яисә фортепьянода уйныйлар. Ә скрипачлар, виолончелистлар уен коралларын үзләре белән сөйрәп йөртүчән.

— Уң колагым зың-зың, дырк-дырк килә,— диде Ниаз,— нәкъ пианино тыңлагандагы кебек. Сез — пианистка.

Ул җитди кыяфәтен саклаган хәлдә көзгегә күз салды: кызның нечкә кашлары йөнтәс ак бүреге астына күтәрелгән иде. Димәк, Ниаз әйткәннәр дөрес.

Ниаз рульне кинәт борды — алар Казанка буендагы борылышка килеп җиткәннәр иде инде. Шофер сөйләгәннәргә авызын ачып, аңымоны абайламый барган кыз утыргычка ауды, бүреге идәнгә үк тәгәрәде. Ниаз боларны күрмәмешкә салышты. Кыз бик кыенсынган кыяфәттә идәннән бүреген алып киде. Тагын кисәк кенә — бу юлы инде уңга борылыш ясап, Казанка күперенә кергәндә, кыз шофер утыргычының артына ныгытып тотынган иде. Ниаз колак очларына аның сулышы бәрелгәнен тойды.

Дамбага керүгә, Ниаз машинасын бөтен көченә җибәрде. Кыз тартылган кыл кебек сагаеп утыра, сүз башларга аның исәбендә дә юк иде, ахрысы.

— Ә мин сезнең исемегезне дә беләм,— диде Ниаз.— Ул «Галин» дигән сүздәге авазларның берсенә башлана.

Әмма кызның шаярып сөйләшергә һич тә кәефе юк иде. Ул кыска гына итеп:

— Юк,— диде.

— Ә, яңгыравыклы авазга башланамыни? Соня, алайса, яки Рая.

— Юк.

— Әә, Зоя!
— Зөлфә,— диде кыз.
— Зөлфия?
— Юк, Зөлфә генә.

Ниазга кызның исеме ошамады... Зөлфә... Зөлфә... Тулы исем кебек тә түгел.

— Фидаилгә Зөлфәдән куптин-куп, чуктин-чук сәламнәр ирештерермен инде, алайса...

Әллә Ниазга гына шулай тоелды, әмма бу сүзләрдән кыз куркынып киткәндәй булды.

— Кирәкми,— диде ул.— Берүк әйтә күрмәгез.
— Нишләп?
— Кирәкми. Ул минем сәламнәремә мохтаҗ түгел.

Монысы инде бөтенләй аңлаешсыз иде. Үзе машинасын куруга туктатты, үзе сәлам җибәрүдән дә баш тарта...

Менә шулай, ярдәмсез җәнлек баласына охшаган Зөлфә исемле бу кызны елмайтып, тешләрен күрү дә насыйп булмады. Тверская тукталышына килеп тә життеләр. «Наратлык» ресторанын узуга, урамда тыгынлык хасил булган — трамвай, троллейбус, автобуслар, йөк машиналары юлны буып торалар. Башта Ниаз аларны, светофорда яшел ут кабынганны көтәләрдер, дип уйлаган иде. Кичке «пик» сәгате — халыкның эштән кайткан чагы, машиналарның күп булуы бер дә гаҗәп түгел. Баксаң, авария булган икән. Аны-моны абайлаганчы, Ниаз «Волга»сы артына да машиналар килеп тыгылды. Ни уңга, ни сулга, ни алга, ни артка кузгалырлык түгел иде. Зөлфә, рәхмәт әйтеп, ишектән чыга башлады.

— Хәзер кузгалырбыз, ашыкма,— диде аңа Ниаз.— Бу кадәр машиналы озак тотмаслар әле.

— Мин кайтып життем инде,— диде Зөлфә.— Рәхмәт сезгә!

Ул житез, матур хәрәкәт белән машинадан чыкты да, шунда ук тураеп, башын бераз артка ташлап басты һәм янәшә торган кечкенә автобус артына кереп китте.

Ниаз күрсендә, кин булса да куркыныч, тынгысыз Декабристлар урамын эченнән генә сүгеп куйды. Арыганлык, ялыкканлык үзен сиздерде, ул бераз хәл алырга дип урамга чыгып басты һәм як-ягына каранды. Шул чак каршы йортның дүртенче катындагы тәрәзәгә күзе төште аның. Гөлт итеп ут кабыну игътибарын җәлеп итте булса кирәк. Зур-зур ике өлгеле тәрәзәдән бүлмә түшәме күренде, шуңа беркетелгән ярым ай рәвешендәге сәер плафон Ниазны гаҗәпләндерде. Менә тәрәзә янына бер кыз килеп басты да ике кулын күтәреп як-яктан пәрдәләрне тартты. Кыз шәүләсе юк булды, сары пәрдәләр аша урамга тоныклык сибелде. Ләкин Ниаз кызны танып өлгергән иде инде: ул Зөлфә иде. Ак башлыгын да салмаган, тун төймәләрен генә ычкындырган. Ул шулай, кулларын өскә күтәреп, башын артка ташлаган хәлендә, Ниазның хәтеренә сеңеп калган иде...

...Шуннан соң Ниаз Фидаилне тиз арада күрмәде, ә соңрак бу очрашу турында аңа сөйләргә онытты.

Хәзер генә ул Зөлфәнең җеназада да күренмәвен хәтерләде. Ә соң ул кыз Фидаилнең һәлак булганын беләме икән? Белмәве-ишетмәве дә бик мөмкин.

Тикшерүче Головин да Фидаилнең танышлары белән бик кызыксынган иде бит әле. Ә Ниаз ул чакта Зөлфә турында әйтергә онытып җибәргән икән. Хәер, бу гаҗәп түгел, аның бит Фидаил белән Зөлфәне бергә күргәне булмады.

...Ниаз халыкны ерып, троллейбусның алгы ишегенә ташланды. Восстание тукталышында төште дә ашыгып кире китте.

«Ул» бүген дә килмәде. Зөлфә, дәрес бетүгә аны консерватория ишеге төбендә очратырмын, дип уйлаган иде. Аның шундый гадәте бар — Зөлфәне дәресеннән көтеп ала да өенә чаклы озатып куя. Кызның өендә аулак чакта — аның әтисе ике елга Польшага китте, әнисе көн аралаш тәүлекләп эшли — алар икәүдән-икәү генә кич утыралар, музыка тыңлыйлар, кофе эчәләр. Зөлфәнең әнисе егетнең өйгә килүенә каршы түгел. Әллә кайларда, кирәк-кирәкмәс урыннарда йөргәнче, күз алдында очрашулары яхшырак, дип исәпли ул.

Аның бу карашыннан файдаланып, Зөлфә ялгызы чагында да егетен өйгә алып кергәли иде. Хәер, аларның мөнәсәбәтләре саф, чиста, егет үзен тәртипле тота, шуңа күрә кыз икәү генә кич утыруны гөнаһка санамый иде.

Бүген шундый кич — өйдә кеше юк. Егет моны белә, шуңа күрә Зөлфә аның килеренә һич шикләнми иде. Ләкин ул бүген дә килмәде. Борынгы бинаның авыр ишеген ачып, таш баскычка чыккач, Зөлфә якягына каранды, шактый вакыт боегып кына салкын, дымлы һаваны сулап торды.

Зөлфәнең ялгызы гына өйгә кайтып китәсе килмәде, бераз икеләнеп торгач, ул актлар залына, симфоник концертка керергә булды.

Оркестр Бетховенның бишенче симфониясен уйный иде. Музыка кызның сагышын көчәйтте генә. Ул, сөйгәнен мәңгегә югалткан кеше кебек, аның йөзен, елмаюын, әйткән сүзләрен исенә төшерде. Бер карaганда ник борчылырга, ник газапланырга?! Аның килмәгәненә дүрт кенә көн, дүрт кенә тәүлек, бүген бишенче... Шулай да Зөлфәнең эчендә ут яна. Сөйгәне берәр бәхетсезлеккә тап булгандыр, яисә гафу ителмәслек хата эшләп ташлагандыр кебек. Ә Зөлфә... аңа ярдәм кулы сузасы, аның белән бергә кайгы-хәсрәт кичерәсе урында, бирелә музыка тыңлап утыра.

Сөйгәне янында булганда гына җаны тыныч Зөлфәнең, ул киттеме — күңеле тынгысызлана башлый. Моның нилектән шулай икәнен ул үзе дә аңлап җиткерми әле...

Оркестр соңгы тантаналы аккордларын уйнагач, кара фрак кигән дирижер залга борылып бөдрә башын июгә, Зөлфә урыныннан кузгалды һәм, алкышлар тәмамланганны да көтмичә, залдан чыгып китте. Читек үкчәләре белән таш баскычка шык-шык басып аска йөгерде: ашыгырга кирәк — «ул», бәлки, өй янында көтәдер. Көтәр-көтәр дә китеп барыр, Зөлфә тагын аны күрми калыр...

Әммa «ул» өй янында да, баскычта да, коридорда да юк иде. Капкараңгы, тып-тын квартирларына Зөлфә үзе генә кайтып керде. Телевизор карыйсы килми, радионың тимер тавышы да эчне генә пошыра. Пианино янына утырырга, кимендә ике-өч сәгать уйнарга кирәк иде — аңа да күңел бармый. Зөлфәнең уң беләге җилкәдән үк сызлый башлады. Соңгы вакытта бу сызлану шактый көчәйде. Укытучы, кулыңны дөрес тотмыйсың, җилкәңнән үк катырасың, ди. Артык күп уйнарга кушмый.

Урамнан трамвай яки авыр машиналар узган саен бөтен йорт тетрәнеп, калтыранып куя. Әледән-әле троллейбусларның ыжылдап тукталганы ишетелә. Күрше квартирдан өзек-өзек пианино авазлары яңгырый:

Күз дә житте, Раинька,
Баю-баю, баиньки...

Бер үк клавишада бер генә аваз белән җырлана торган көзге болытлы көн кебек эчпошыргыч көй.

Бу — күрше малае, ак чырайлы, ябык гәүдәле, сигез яшьлек Вова

пианино янында һәр көнлек жәзасын алып утыра. Ул туктап торган арада әнисенең кычкырганы ишетелә:

— Күзең чәчрәп чыкканмы әллә? Кайсы клавишага төртәсең? Ни язылганын күрмисеңмени?

Вова — өметле малай, тик тырышырга өйрәнмәгән шул әле. Кем белә, бәлки, әнисе тырыштыра торгач, музыкант та булып китәр. Кечкенә чакта Зөлфәне дә әнисе шулай мәҗбүр итеп өйрәтә торган иде. Музыкант була алмаса да, эшләргә, тырышырга, җаваплылык сизәргә өйрәнер малай.

Көз дә җитте...
Көз дә җитте...

Бернинди моңы юк, ә Зөлфәнең күңеле тула.

Ишек өстендәге электр кыңгыравы шалтырады. Зөлфәнең бөтен гәүдәсе кылдай тартылып куйды. Бу ул, бары ул гына булырга мөмкин! Югыйсә, сәгать кичке тугызда аларга кем килсен. Әнисе иртәгә иртән генә кайтачак, аннары ул кыңгырау шалтыратмый, үз ачкычы — кесәсендә.

Ишекне ачарга барган кыз дулкынлануын басарга тырышты: «Юк, тиз генә ачылып китәргә ярамый, үпкәләгәнемне сиздерергә, үземне горур, хәтта бераз тәкәббер тотарга кирәк!» — диде ул үз-үзенә, әмма ирексездән аның күзләре нурланды, ирен читләренә елмаю кунды.

Тик, ишекне ачкач, аның йөзендәге сөенеч билгеләре әкренләп юкка чыкты, күзләре сүрелде. Коридорда ят бер егет басып тора иде...

«Бирредә башка берәүне көтәләр икән»,— дип уйлады Нияз һәм кырыс кына:

— Борчыдым, ахры,— диде.

Зөлфә, ишеккә аркылы баскан килеш, сораулы күзләрен Ниязга текәп, карап торуында булды. «Танымый,— дип уйлады егет.— Кызлар хәтере кыска була шул».

— Минем сезгә бик мөһим сүзем бар иде,— диде ул.

— Тыңлыйм.

Кешенең һәлакәте турындагы хәбәрне менә шулай, аяк өсте генә әйтеп буламыни? Әгәр мәрхүм бу кызның сөйгәне булса? Ә, бәлки, ул шушы минутларда Фидаилне көткәндер?

— Бусага аркылы сөйләшә торган сүз түгел.

Зөлфә, аны тагын бер кат күздән кичергәннән соң, читкә тайпылды:

— Керегез!

Нияз кечкенә, елтыр күзләре белән бер айкауда квартирның нинди икәнен чамалап алды: ике бүлмәле, бөтен уңайлыклары бар. Зөлфә, нечкә беләкләрен күкрәгенә кушырып, аяк өсте генә, Ниязның ни әйткәнен көтеп тора иде. Тик егет аянычлы хәбәрне аның башына органдай итеп кенә әйтә алмады. Бигрәк зәгыйфь, йомшак күренә, егылып китмәгәе...

— Чишенегез, узыгыз! — диде кыз.

Ниязның бензин исе аңкып торган кыска кара туны белән кырыштылган бүрекен шкафка элгәндә, Зөлфә уңайсызланып, хәтеренә төшерергә азапланды: «Кем соң бу, кем?» Үткен карашлы, карлыкканрак тавышлы бу кешене кайдадыр күрде бит ул?

Зал ягына кергәч, Нияз идәнне тутырып япкан аллы-гөлле келәмне әйләнеп узды. Әйе, яшәп карый кешеләр! Бөтен җиһаз затлыдан: телевизорның иң зур экранлысы, радиоланың иң шәбе, пианиноның иң кыйбатлысы. Бер стена киңлегендәге китап шкафы шыплап тутырылган.

Шул җиһаз арасында Зөлфә үзе дә даһи скульптор ясаган гүзәл сын кебек. Мәрмәрдән уеп ясалган, кечкенә башлы, озынчарак йөзле, нәзек-нечкә гәүдәле шушы кызга охшаган сыннарны Ниязның музейларда күргәне бар. Зөлфәнең үз-үзен тотышыннан да таш салкынлыгы

бөркелеп тора кебек иде. Аның әлеге сыннардан аермасы заманча киемендә генә — тар җилкәләрен, кечкенә күкрәкләрен, нечкә беләкләрен кысып торган кара свитерында, бик кыска, бик киң шакмаклы итәгендә, кыска итеп киселгән көлсу чәчләрендә.

Зөлфә Ниазга аптырап карап тора иде. Ялгыз чакта теләсә кемне өйгә кертү ярамый, ләкин... бу таныш кеше булырга тиеш бит! Алай дисәң, аның җилкәләрен җыерып, йоннарын кабарткан карчыгадай текәп карап торуы бөтенләй ят күренә.

Зөлфә кызыл белән тышланган йомшак кәнәфигә ымлады:

— Утырыгыз.

— Минем сезгә Фидаил турында әйтәсе сүзем бар иде,— диде Ниаз.

Фидаил? Зөлфәнең йөзендә гаҗәпләнү чагылды. Нинди Фидаил? Ә-ә, Фидаил! Шунда гына ул Ниазны танып алды. Әйе, әйе, таушалган көрән костюмлы, очлы күзле бу егет Фидаил белән бергә эшли, бер заман ул, машинасына утыртып, Зөлфәне өенә кайтарып куйган иде.

Ниаз кызның йөзендәге үзгәрешне җентеклӛп күзәтеп утырды, тик аның артык пошынганын сизмәде.

— Мин сезне тыңлыйм,— диде Зөлфә.

— Без бүген Фидаилне җирләдек.

Кызда артык каушау сизелмәде. Әйтерсең лә аңа бөтенләй чит кешенең һәлакәте турында сөйлиләр. Ул бераз күңелсезләнгән, гаҗәпләнгән кебек кенә булды. Аннары, сүз булсын дигәндәй, бөтенләй сәер сорау бирде:

— Авырып үлдеме?

Үзе дә утырды, озын-нечкә бармаклы кулларын шакмаклы итәгенә куйды. Ниаз аны текәлеп күзәтә иде: юри кыланамы бу кызый, әллә чыннан бер нәрсә белмиме?

— Юк, авырып түгел. Ул бит сәламәт иде, үзегез дә беләсездер. Аны үтергәннәр.

Зөлфә сискәнеп китте:

— Ничек үтергәннәр?

— Машинасында, сугып үтергәннәр.

— Кемнәр?

— Анысын мин белмим.

Зөлфә дәшмәде, аптыраган кыяфәт белән сүзсез утыруында булды. Аның артык борчылмавы, тынычлыгы соңгы ике-өч көндә күңеленнән күпне кичергән Ниазга бер дә ошамады. Кеше исән чакта, машинасы кулында вакытта урамда тукталып та хәлен белә иде. Ә үлгәч, ник бер яхшы сүз әйтсен, ичмасам! Ниазның кызны тетрәтерлек берәр сүз әйтәсе, аны рәнҗетәсе килде. Кем белә, ул, бәлки, Фидаилнең үлгәнен Ниаздан да алда белгәндер, хәзер юри белмәмешкә салынып утырадыр!

Ниаз, астыртын елмаеп:

— Исән чакта урамда очратканда сәлам бирә идегез, кирәк чакта шалтыраткалап торгансыздыр әле,— диде.

Зөлфә ишек янындагы тәбәнәк тумбочкада утырган ак телефон аппаратына карады.

— Минем үз гомеремдә дә аңа шалтыратканым юк,— диде ул.— Аның телефон номерын да белмим.

Кызның йөзендә курку, хафалану сизелмәде, ул Ниазның сүзләренә гаҗәпләнде генә.

— Алай икән,— диде Ниаз, көрсенеп.— Мин сезне якын танышлардыр дип уйлаган идем. Юкка борчыдым, гафу итегез. Үлгән кешенең беркемгә дә кирәге юк... Аны тизрәк оныту яхшы...

Менә монысын инде Зөлфә яңагына суккандай авыр кабул итте. Аны дуслыкка хыянәт итүдә, якын кешесенең язмышына, хәтта үлеменә

битарафлыкта гаеплиләр. Ул төз аяклары белән келәм чәчәкләренә басты да, болай да юка иреннәрен кысып:

— Сез мине юкка рәнҗетәсез,— диде.— Мин аны бик аз белә идем, бик аз. Үлгәнен дә менә сездән ишеттем.

Зөлфә сәхнәдәге артист кебек кыланыбрак сөйли, әмма, мөгаен, дөресен сөйли иде. Ниаз да урыныннан торып басты, ике кулын да бөгәрләнгән чалбар кесәсенә батырды. Җилкәгә киң булса да, гәүдәсе белән мактана алмый егет — алар буйга Зөлфә белән икесе бер чамада икән.

— Аны күмгәндә шоферлар белән Фидаилнең туганнары гына булды,— диде ул.— Бер танышы да килмәгән иде. Әгәр танышларын белсәгез, аларга да әйтегез.

Зөлфә ярар дигәндәй баш какты. Ниаз сөенечен сиздермәскә тырышты: әһә, димәк, бу кызый Фидаилнең башка танышларын да белә икән!

Ул тагын сорау бирергә дип авызын ачкан иде — кыңгырау шалтырады. Зөлфә, итәген җилфердәтеп, коридорга чыгып китте, ә Ниаз канәфигә кире утырды.

Коридордан матур яңгырашлы ирләр тавышы ишетелде. Зөлфәгә ияреп, озын буйлы, озынча йөзле, туры борынлы бер егет килеп керде. Аның бөтен кыланышыннан, кыяфәтеннән, хәтта чиста-пөхтә костюмыннан ук үзенең чибәр икәнен, кешеләргә (аеруча хатын-кызларга) бер караудa ошавын белгәне сизелеп тора иде. Тышкы кыяфәте белән артык мактана алмаган, хәер, аңа әллә ни әһәмият тә бирмәгән Ниаз чибәр егетләрне гомумән яратып бетерми иде. Өстәвенә, бу кәнфит егет бик вакытсыз килеп керде, сүзне иң кызык урынында өзде һәм тиз генә чыгып китәр төсле дә түгел иде.

— Таныш булыгыз,— диде йөзе сөенечтән алланган Зөлфә.— Бу минем дустым — Атлас.

Ниаз, урыныннан кузгалырга омтылгандай хәрәкәт ясап, теләр-теләмәс кенә кулын сузды:

— Ниаз.

Зөлфә аңа, нишләп утырасың инде, ник китмисең? дигән төсле ятсынып карады. Аның бу шома егеткә баштанаяк гашыйк икәне, Ниазның монда утыруы өчен Атлас алдында уңайсызлануы әллә каян сизелеп тора иде.

Зөлфә егетенә Ниазның бирегә ник килгәнен аңлатып бирергә ашыкты:

— Ниазның дусты һәлак булган бит, Атлас. Һич көтмәгәндә... Шундый бәхетсезлек...

Атлас:

— Ә-ә-ә,— диде.— Әтиеңнең танышларымыни?

— Юк... Без таныш идек... Күптән инде...

Зөлфә кызарынып Ниазга дошмани бер караш ташлады да:

— Без аның белән бала чакта... бергә укыган идек,— дип куйды.— Тегендә, Кабан күле буенда торганда...

— Алай икән.— Атлас радиолага таба борылды.— Кая, әтиең җибәргән пластинкалар мондамы?

— Шунда, тумбочканың өске тартмасында... Син ишетмәдеңме? Бер таксистны үтергәннәр? Менә шул инде.

Атлас, хуҗаларча хәрәкәт белән тумбочка тартмасын ачып, сыгылмалы ак пластинкалар тартып чыгарды да радиоланы тоташтырды. Иелеп басканга, Ниазга аның бик пөхтә тегелгән, тәненә сыланып торган кара чалбары гына күренә иде. Тәти егетнең бөтен кыяфәтендә Ниазны да, үлгән таксистны да санга сукмавы сизелеп тора иде кебек.

Атлас, борылып, пластинканы радиолага куйды. Аннан ямьсез калын тавыш белән сузып-сузып улаган аваз ишетелде.

— Син әйләнешне дөрес куймаган бит,— диде Зөлфә.— Утыз өчкә күчер!

Тыкы-тыкы барабан тукылдавы белән аралаш өзеп-өзеп, чинап-чинап труба уйный башлады. Атлас өйдә кия торган йомшак башмаклар белән («Кара син аны, Зөлфә миңа башмак бирмәгән иде»,— дип уйлады Ниаз) келәмгә такт сугып торды да, карашын түшәмдәге ярты ай төсле плафонга текәп:

— Ах, шайтан, менә бу трубач, ичмасам! — диде.— Ничек күзләре чәчрәп чыкмый. Моны Рифка уйнатып күрсәтергә кирәк.

Ул бары Зөлфәгә генә мөрәҗәгать итә иде.

Бу икәүне Фидаил исемле егетнең дөньяда булу-булмавы тамчы да кызыксындырмый иде, ахры. Аларга чит кеше — Ниаз комачаулый гына иде. Ул Зөлфәнең нервланып кулларын уып торуын күрде дә урыныннан кузгалды. Кыз аны сөенеп озатып калды, артыннан ишекне япканда күзләре белән генә елмаеп та куйды хәтта.

Ниазга Зөлфәнең «бергә укыган идек» дигән сүзләре тынгылык бирмәде. Кем белән бергә укыганын аңлатмакчы булды ул? Ниаз беләнме, әллә Фидаил беләнме? Ниазның аны гомерендә икенче күрүе, Фидаил — авылдан килгән егет, ә Зөлфә, мөгаен, шәһәр кызыдыр, кыяфәте бер дә авылда үскән балага охшамаган. Димәк, ул алдады, егете Атласны алдады. Ялган сүз сөйләгәне кызаруыннан, ык-мык килүеннән үк сизелеп тора иде. Ник алдады ул Атласны, ник дөресен әйтмәде? Ә дөресе ничек? Фидаил белән кайда, кайчан, ничек танышканнар алар, һәм бу танышлык ни дәрәҗәдә булган?

Ниазның башында мең төрле сорау туды һәм аларның берсенә дә җавап юк иде. Мәсьәләгә аз гына булса да ачыклык кертү өчен, кызның ялгызын очратып, озаклап сөйләшергә кирәк иде.

## 5

Нателланы бер күрсәң, гомер онытмыйсың. Кыяфәте белән ул төз сынлы грузинкаларга тартым: иңенә таралып төшкән чәчләре чем-кара, күзләре елтыр-коңгырт, борыны туры, йөзе озынча. Үз-үзен тотышында, холык-табигатендә дә көньяк халыкларына хас кискенлек сизелеп тора. Бу гаҗәп түгел, чөнки аның әбисе грузинка булган, Нателла дигән исеме дә — шул карчыкның мирасы. «Минем кан — җәһәннәм боткасы, җиде буынга хәтле генә тикшереп карасаң да, әллә нинди милләтләрнең өлешен табып була. Шуңа күрә гел кайнап тора ул»,— дип көлә Нателла үзе. Чибәр хатын Нателла, җиләк кебек чагы — аңа егерме сигез яшь. Тик менә гаҗәп хәл, аңа елмаю килешми: яңакларында сырлар хасил була, тигез, ләкин хатын-кыз өчен артык эре тешләре күренә — елмайганда Нателла үз яшеннән олырак сыман тоела. Шуңа күрә ул сирәк елмая, чөнки үзенә ни килешкәнен, ни килешмәгәнен бик яхшы аңлый. Казан урамнарында бер булырлык итеп киенә дә белә ул. Менә бүген дә аның өстендә соры каракүл тун белән башлык, аякларында грузинча фасон белән тегелгән озын кунычлы, ялтыравыклы читек. Күз бәйләнеп килгән сәгатьтә дә Нателланы урамдагы халык арасыннан әллә каян күреп аласың.

Алар Зөлфә белән, алдан сөйләшеп куйганча, «Табигать бүләкләре» дигән кибет янында очраштылар. Нателла үзе генә түгел, дүрт яшьлек улын җитәкләгән иде.

— Өйдә берүзен калдырырга курыктым,— диде ул Зөлфәгә.— Бөтен әйберне ватып бетерде. Өстеннән бикләп чыгып киттем исә, варвар кебек җимерү эшенә керешә! Марсик! Кая киттең, кил әле!

Нателла калын тавыш белән кычкырып сөйләшә иде.

— Марсик! — диде Зөлфә нелеп,— исәнме, Марсик! Нишләдең бүген бакчада? Тагын сугыштыңмы?
— Сугыштым! — диде Марсик, борынын ялан кулы белән сөртеп.
— Ә бияләең кая?
— Һа-а! — диде Нателла.— Аңа бияләй алып туйган инде. Төткәзеп булмый.
Марсикның әнисенә тотынып килгән сул кулы җылы, уңы боздай салкын иде. Зөлфә аны учларына алып, сулышын өрде.
Нателла, башын күтәреп, Ленин урамының аргы ягына юнәлде. Алар шар ачык подъезд ишегеннән керделәр, киң агач баскычтан икенче катка менделәр һәм, сулга борылып, озын коридор буйлап киттеләр. Ике якта — ишекләр, газ плитәләре, шкафлар. Урамдагы кебек салкын, бер-ике шәрә лампочка яна.
Коридорның аргы башына җиткәч, Нателла кара дерматин белән тышланган зур ишек янындагы кыңгырау төймәсенә басты.
Ишекне юан гәүдәле, зур күкрәкле хатын ачты. Аның кып-кыска итәкле чуар күлмәктән булуы Зөлфәгә сәер тоелды. Әчкә кергәч кенә ул аның йөзенә күтәрелеп карады һәм хатын дигәненең унбиш-уналты яшьләрдәге кыз бала икәнен күреп исе китте. Кызның йөзе шома, ак, тик ияк астына сырланып май үскән, ә шешенке кабаклары астына яшеренгән күзләре кырыс һәм күпне белгәндәй тәҗрибәле карыйлар иде.
— Һа-а, Аделаида! Ни хәлләрдә яшисең? — диде Нателла.— Люси өйдә юкмы әллә?
— Әни кайтып җитмәде шул әле.
— Люсиның гадәте шул инде. Без бит телефоннан шушы вакытта очрашырга сөйләшкән идек.
Аделаида, тапкансыз ышаныр кеше, дигән сыман мыскыллы көлемсерәде дә:
— Көтегез, бәлки кайтып җитәр,— диде. Үзе, кыска итәк астыннан юан, шәрә ботларын ялтыратып, бүлмәгә кереп китте. Кунаклар, кысан коридорда чишенеп, туннарын чөйгә элделәр.
Биек, иркен бүлмә ярлы гына җиһазланган: тимер караватлар, иске диван, кызарып-кыршылып беткән кечкенә шкафта биш-алты гына китап. Түр почмакта, язу өстәлендә тонык кына булып телевизор экраны янып тора, тик аңа караучы юк. Паркет идән каралып беткән.
Уртада, аш өстәле янында, тузгыган мамык кебек ак чәчле, кибеп беткән гәүдәле бәләкәй карт күлмәк үткәли.
— Һа-а,— диде Нателла аны күргәч.— Алла ярдәм бирсен, бабакай!
Бабакай акаебрак торган керфексез зәңгәр күзләре белән Нателлага бер генә карап алды да авыз эченнән нидер мыгырданды. Тик бераз уйлап торгач кына Зөлфә аның:
— Берәүнең дә ярдәме кирәкми, кулда көч бар чакта үзем эшлим,— дигәнен аңлады.
— Әллә туйга җыенасызмы, бабай? Яшәреп тә киткәнсез...
— Безнең туйлар узды инде. Чират сезнеке. Ә мин ветераннар кичәсенә җыенам, бүген Совет Армиясе көне бит!
— Бабакай, гафу ит! — диде Нателла, аның янына ук барып.— Котлыйм сине! Син бит ике сугыш ветераны! Зөлфә, күрәсеңме, бу бабакай — гади бабакай гына түгел — Колчакны җиңгән, Гитлерның башына җиткән баһадир бабай бу!
Бабай Нателланың шалтыравык сүзләрен чын-чыннан кәефләнеп тыңлый иде.
— Шул шул, сез, хәзерге яшьләр, тәртип белмисез...
Ишек ачылган тавыш ишетелде, коридорда ах-вах килеп кемдер чишенде, шакы-шокы аяк киемнәрен салды. Бүлмәгә ак йон костюм кигән сап-сары чәчле, бөтерчек кебек җиңел гәүдәле, кәртинкәдәй

чибәр хатын — Люси килеп керде. Кәрә-керешкә артына борылып, итәген карарга кереште.

— Котик типте,— диде ул, яхшы ук кычкырып.

Зөлфә куркынып бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты. Ләкин берәүнең дә Люся сүзләренә исе китмәгән иде: Аделаида китабына төртелгән, бабай утүк табанына чыжлатып төкерде дә үз эшендә булды, Марсик мәче белән булаша. Тик Нателла гына юка иреннәрен җәеп, яңакларын җыерып, елмайган. Ә Люся итәген күтәргән, аның ботында, капрон оек аркылы, зур гына күгәргән тап күренә.

— Менә тагын тап,— диде ул, итәгенә маникюрлы бармагы белән төртеп.— Харап кына итте костюмымны. Бүген генә киеп чыккан идем. Алсу күлмәгемне дә бозды бүген, ресторанда беләгемнән шатырдатып китереп тотты — җиңемдә биш бармак эзе ярылып ята.

— Һа-а, таптың кайгырыр нәрсә! Химчисткага бирерсең,— диде Нателла.

Ә Люся кычкырып еламый гына:

— Химчисткада бозыла ич ул, сузыла, формасын югалта. Чип-чиста йон бит ул, английский йон...

— Котик яңасын алып бирер әле. Аның акчасы буа буарлык... Кая, Зөлфәнең күлмәге әзерме?

Люся, картка карап, тәксе тавыш белән:

— Әти, безгә күлмәк алыштырырга кирәк,— диде.

— Хәзер, якасын гына үтүклим дә кухняга чыгам,— диде карт кабаланып.

— Әти, мин сиңа ничә кат әйттем инде: күлмәкне якасыннан үтүкли башлыйлар!

Карт дәшмәде, ә Зөлфә аның өчен кызарынып, күңеле әрнеп утырды.

Бу йортка Зөлфәнең икенче килүе иде. Аңа әтисе Польшадан үтә күренмәле, алтынсу җепләр белән чигелгән кара тукыма җибәргән иде. Нателла, минем бик яхшы тегүчем бар, сигезенче март җиткәнче ул сиңа күлмәгеңне менә дигән итеп тегеп бирә, дип, Люся янына алып килде. Беренче килүләрендә карт өйдә юк иде.

Нателланың сөйләве буенча, Зөлфә бу гаиләнең тормышын бераз белә иде инде: Люся ательеда тегүче булып эшли, аңа утыз сигез яшь, ул карт әтисе һәм кызы белән тора. Менә берничә ел инде ул Константин, үзенчә әйтсәк, Котик исемле бер кеше белән язылышмыйча гына яши. Өйләнешүне алар, Люсяның әтисе үлгәнче дип, кичектереп торалар. Карт үлү белән, Аделаиданы берәрсенә кияүгә бирәчәкләр, ә квартир аларга калачак...

Нателла сөйләгәннәр Зөлфә өчен сәер һәм аңлаешсыз, икенче бер дөньядагы хәлләр кебек чит иде, шуңа күрә аның йөрәгенә барып җитмәгән иде. Хәзер инде Люсяның әтисе белән тупас, тәксе сөйләшүен, аны бөтенләй санга сукмавын күргәч, бабай өчен бөтен йөрәге белән рәнҗеп утырды. Ул оят эшкә шаһит булган кешедәй кызарынып башын иде, бүлмәдәгеләргә күтәрелеп карарга кыенсынды, урындык аркасына элеп куелган кара пинжәккә күз салды. Пинжәк түшендә алты-җиде орден-медаль ялтырый иде. «Бүләкләрең дә күп икән,— дип уйлады Зөлфә, күңеленнән генә картка мөрәҗәгать итеп.— Заманында батыр йөрәкле кеше булгансыңдыр, мөгаен. Үз балаңның рәнҗеткеч сүзләренә ничек түзәсең?»

Әгәр аларга ачылып китеп сөйләшергә мөмкинлек булса, әгәр Зөлфә сорауларын кычкырып бирсә, карт гаҗәпләнер иде дә елмаеп башын чайкар иде. «И бала, бала! Син күп нәрсәне белмисең шул, сез яшьләр бик рәхәт, бик гамьсез яшисез, безнең баштан ниләр узганны күз алдына да китермисез»,— дияр иде ул. Ул сугышларда күргәннәре, колхоз төзегән елларда ЧКда эшләгәннәре, ерак авылдагы ятим кызга ничек өйләнгәне, аннары гомер буе урыннан-урынга күчеп йөргәннәре, икесе-

нең дә менә шушы рәхәт тормышны төзергә бар көчләрен, гомерләрен багышлаулары турында рәхәтләнеп сөйләр иде. Аның һәр бүләкне алу тарихы мавыктыргыч кыйсса иде. Тыңлаучы табылганга сөенеп, рәхәтләнеп сөйләр иде карт, чөнки аның бу турыда Люсяга да, Аделаидага да иркенләп сөйли алганы юк, яшьләр аны рәтләп тыңламый. Алар: «Вакыты шундый булган аның, хәзер заман бөтенләй икенче»,— дип кенә җибәрәләр, хәтта, син карт инде, күп нәрсәне аңламыйсың, дигән кебегрәк сүзләр дә ычкындыралар иде.

Әйе, заманалар үзгәрде. Алар өйләренә дә кайтып керә алмыйча җан-фәрман тырышып төзегән якты киләчәк менә ул, килеп җитте. Ул киләчәк белән бергә каршыга картлык та килеп басты. Замана дилбегәсе кулдан ычкынды, хәзер инде аны яшьләр тота.

Яшьләр дигәне әллә ничек күзгә күренми генә үсте дә куйды. Һәрхәлдә, карт үзе олыгая башлагач кына дөньяга килгән бердәнбер кызының үсеп буйга җиткәнен сизмирәк калды. Дөрес, соңгы вакытта, үзе пенсиягә чыккач, хатыны да үлгәч, ул кызын тәрбияләргә ныклап тотынмакчы иде дә, ата белән бала бер-берсен аңлаша алмадылар.

Яхшы уку Люсяның кулыннан килмәде. Балигъ булмас борын бала да табып куйды. Болар картның башына сыя торган хәлләр түгел иде. Әмма башны ташка орып булмый бит... Вакыт үтү белән ата кызының кылганнарын гафу итми булдыра алмады. Газапланып уйлый torгач, ул бу хәлләрне үзенчә аклап та куйды: һәр кеше дә укырга сәләтле булмый бит, диде ул. Атасыз бала табучы да дөньяда Люся гына түгел. Элек-электән булган андыйлар. Хәзер әнә, хатын-кыз күп, ир-ат җитми, диләр. Егетләр аз булуга Люсяны гаепләп булмый лабаса! Менә шулай, бер уңга, бер сулга карап, кешеләрдән гыйбрәт алып, үз-үзен юатты ата.

Әле ярый, Люся ул кадәр үк начар булмады, дип уйлый ул хәзер. Һөнәр алды, эшли, баласын да безгә генә ташламады, караштьı.

Бабакай кызының сүзләренә рәнҗемәде, үтүген алды да, күлмәген күтәреп, кухняга чыгып китте.

Бүлмәдә көзге юк иде, шунлыктан Зөлфә яңа күлмәгенең тәнендә ничек торуын күрә алмады, әмма Нателланың йөзе сытылудан тегүченең эше барып чыкмаганын аңлады.

— Люсьена, шайтан кызы! — диде Нателла.— Җиңнәре озын ич!

— Бер дә озын түгел. Куллары озын бит аның. Озын кулга кыска җиң килешми ул,— диде Люся, Зөлфәнең аркасыннан сыпыргалап.

— Ә итәге? Аягы кәкре булганга шулай тигезле-тигезсезме?

Зөлфә кызарынды, ә Люся исе китми генә чүгәләп, аның ике тезе арасында күлмәк итәгенең алды белән артын тәңгәл китерде.

— Алла инде, харап икән! Ике миллиметр!

— Ә түше? Бөрмә дисәң бөрмә түгел...

— Драпировка ул. Хәзер бик модада.

— Карале, ательедагы клиентларыңа да шулай тегәсеңме син?

Люсяның түземе бетте, ахры, ул:

— Натка! Тагын бер сүз әйтсәң, мин сиңа гомеремдә бер әйбер дә текмәячәкмен,— диде.— Гаеп эзләп утырма. Әле бу беренче үлчәп карау гына, тегеп бетергәч, курчак кебек булачак.

Нателла «һа-а» дигән иде, ишек артыннан картның «кхм-кхм» дип тамак кырганы ишетелде.

— Ни булды тагын? — диде Люся кычкырып.

Карт кыюсыз гына:

— Пинжәгемне алырга онытып чыкканмын,— диде.— Алып бирсәңче.

— Кереп ал үзең.

Бабакай пинжәген кигәндә, орден-медальләр тоныкк кына чыңлап куйды. Картның гәүдәсе тураеп, үсеп киткәндәй булды, ул нык тавыш белән:

— Мин тиз генә кайтмам,— диде.— Җыелыш, аннары концерт була

Нателла аның янына барып:

— Егет сез, бабакай,— диде.— Тантаналы җыелышларга йөрү безнең кулдан килми. Җыелыш дигән сүзне ишетүгә минем эчем поша башлый. Зинһар, сак йөрегез, урамда бик тайгак, егыла күрмәгез. Җылы киенегез, салкын тимәсен!

Зөлфәнең күлмәк җиңен типчеп азапланган Люся бармагына энә кадады да ярым пышылдап сүгенеп куйды.

Нателла аны ишетмәмешкә салышты:

— Әле бик нык йөрисез. Егетләрчә. Рәхәтләнеп яшәгез, дөнья матур, дөнья киң.

— Рәхмәт, кызым, ай, рәхмәт яхшы сүзеңә,— дип башын селкеде карт.

Люся артык нык тартып тагын җебен өзде. Звонок шалтырады. Аделаида, ниһаять, китабыннан аерылып, ишеккә юнәлде. Коридордан:

— Әнинең өйдәме, әллә тагын берәр җирдә йөриме? — дигән ирләр тавышы ишетелде.

Менә ул бүлмәгә үк килеп керде. Кыска пальтосының төймәләрен ычкындырган, тулаланып саргайган ак свитеры, шомарган, елтыраган вельвет чалбары күзгә ташланды. Аның ябык йөзен төк баскан, муенында кып-кызыл булып тырналган эз күренә. Бөтен кыяфәте белән ул иясез, әрсез мәчене хәтерләтә иде. Мода мондый хәзер: иске, таушалган кием кияләр. Котик — модный егет. «Замана кушканча» киенә, ә менә аның белән йөри торган хатын журнал тышлыгыннан сикереп төшкәндәй кәттә булырга тиеш, дип саный. Шул чакта инде Котикнын нинди шәп егет икәнен күргән бер кеше әллә каян беләчәк.

— Һа-а, Котик килде,— диде Нателла елмаеп.— Әниең сине исәнләшергә өйрәтмәдемени?

— Натка, ялагайланма! Рифны күргәнем дә юк, күрәсем дә килми! Киен! — диде ул Люсяга.

...Урамга чыгып, саф һава сулагач, Зөлфә үзен саташып уянган кешедәй хис итте.

* * *

Алар «Спутник» кинотеатры янына төшеп, автобуска утырдылар. Арткы ишек янында өелешеп басып торган ирләр Нателланы кочакка диярлек алдылар. Марсикны җитәкләгән Зөлфә исә, аркалары белән борылган егетләрне узып, алгарак китте. Аңа урын бирделәр.

Автобус Ленин дамбасына барып кергәч, Нателла да алар янына килеп басты. Ул тәрәзәгә караган, ләкин шәһәр утларын күрми, башкаларга сиздерми генә, бозы эрегән тәрәзәдәге чагылышына сокланып бара иде.

— Нателла,— диде Зөлфә.— Мин бик күңелсез хәбәр ишеттем бит әле.

— Нинди хәбәр?

— Фидаил, теге шофер Фидаил... үлгән бит. Өченче көн күмгәннәр.

Нателланың йөзеннән кыланчыклык галәмәтләре качты. Ул иелеп, пышылдап:

— Кем әйтте? — дип сорады.

Күзләре кинәт кара пәрдә корылгандай тоныкланып калды. Ни уйлаганын, ни кичергәнен һич белерлек түгел.

— Фидаилнең алмашы әйтте,— диде Зөлфә, Нателланың күзләренә карарга куркып. Ул тезендә утырган Марсикны кысыбрак кочаклады.

— Ә син ул кешене каян беләсең?

— Урамда очраткан идем. Машинасын таныдым да Фидаилдер дип туктаттым.

— Алай икән,— диде Нателла.— Авариягә эләккәнмени?

— Юк. Аны... үтергәннәр,— диде Зөлфә.
— Ничек?
Нателланың йөзеннән кан качты, юка иреннәре бер сызык кына булып калды.
— Анысын сорамадым. Атлас килде дә, сүз бүленде.
Нателла як-ягына каранды: юк, аларның сүзен берәү дә тыңламый. Зөлфә алгы утыргычта ялгызы, аның артындагы ике хатын үз сүзләре белән мавыкканнар.
Нателла тәмам бөгелеп:
— Берни аңламыйм,— диде.— Атлас ни диде соң?
— Бер сүз дә әйтмәде.
— Алай икән,— диде Нателла.— Хәзер тикшерү барадыр инде...
Зөлфә җавап бирмәде. Бу кадәресен ул бөтенләй уйламаган иде. Үтерүчеләрне кулга алмадылар микәнни әле?
Нателла аңа:
— Сер саклый белсәң, ахырынача сакла инде,— диде.— Фидаилне белгәненне берәүгә дә ычкындырма. Юкса, милициягә чакыртып, икебезнең дә узакка үтәрләр. Андый эштән ерак булуың яхшы. Риф алдында да уңайсыз. Зинһар, берәүгә дә әйтмә!
— Әйтмим, әйтмим!
Дөресен әйткәндә, Зөлфә җайлап кына Атласка бу хәлләрне сөйләп бирмәкче иде, уңайлы вакытын гына тапмый йөри иде. Гомумән, Нателланың шәхси тормышы аны шактый ук сәерсендерә: әле ире белән аерылышканына күпме генә, Фидаил белән дуслашып йөрде, аннары менә тагын Рифны якын итә башлады. Ә бит чын ярату гомердә бер генә була, диләр. Нателла исә Фидаилнең үлеменә дә кайгырмый, ахры, бары үзен милициягә чакыруларыннан гына курка. Әгәр шуннан, тфү, тфү, Атлас белән бер-бер хәл булса? Зөлфә өчен яшәүнең мәгънәсе дә калмас иде кебек. Башына шундый олы хәсрәт төшкәндә, милициягә барып сөйләшүдән куркып торалармыни?
Шәһәр кешесенә төрле фаҗигалар турында шактый еш ишетергә туры килә, Зөлфә дә моңа күнеккән. Шуңа күрә дә ул Фидаилнең үлү хәбәрен дә артык борчылмый гына тыңлаган иде. Хәзер үзе Нателланың каты бәгырьле икәнен күреп, Фидаил өчен рәнҗеде. Зөлфә бу турыда Нателлага әйтмәкче дә иде, тегесе Марсикны аның тезеннән тартып төшерде:
— Апаңа кузгалырга ирек бир! Аның тукталышы!
Зөлфә үз турысына кайтып житкәнен сизми дә калган икән. Ул, Нателла белән юньләп саубуллашырга да өлгермичә, автобусның ачык ишегенә ташланды. Ишек төбендә басып торучылар:
— Йокламаска кирәк иде! — дип, аны тиргәп калдылар.

## 6

Виктор Головинның сипкелле һәм сөйкемле хатыны, ясле яшендәге ике кызчыгы күптән инде өй хуҗасының кайтуын көтәләр. Кухняда, зур кунада, ак тастымал астында, әзер пилмәннәр ята. Плитә өстендәге кастрюльдән чыккан пар тәрәзә пыялаларын суландырып бетергән. Суыткычтагы шампан шәрабы күптән инде тешне сындырырлык булып суынган.
Сөйкемле хатын бүген кичке институтка укырга бармады, кызларының интернат-ясләдә куңасы көннәре иде — аларны да алып кайтты. Алар Викторны көтеп арыдылар инде, ә ул юк та юк. Хатын аны көтәргә өйрәнгән, шулай да бу юлы күңеле рәнжи: бүген аларның икеләтә бәйрәм көне: өйләнгәннәренә нәкъ биш ел тулды, аннары Совет

Армиясе көне дә бит! Шушындый бәйрәмдә генә булса да Виктор эштән вакытында кайтсачы! Ах, тынгысыз аның эше, тынгысыз!

Майор Головин исә күптән түгел арып-талып эш кабинетына кайтып керде. Бәйрәмне ул бөтенләй онытткан, хатыны, балалары көтеп утыралардыр, дип башына да килми, чөнки көне буе эш урынында булмады, хатынының телефоннан шалтыратканнарын белмәде. Ул җыелган мәгълүматларны тәртипкә салып, берәр нәтиҗә чыгарырга тырышып утыра.

Виктор, күзлеген салып, соңгы көннәрдә сулып киткән йөзен учы белән ышкый. Дүрт көн үтте, ә тикшерүнең алга киткәне юк әле. Күпме кешене эшкә җикте ул, күпме үзе йөгерде, ә җинаятьчегә илтә торган җепнең очын хәзергәчә таба алмады. Мондый зур эшне ачуда җитәкчелек итүне аңа беренче тапкыр ышанып тапшырдылар. Яшьлек кызулыгы белән ул моны бик тиз башкарып чыгарга омтыла иде. Ләкин бөтен нәрсә, хәтта табигать үзе, җинаятьчеләрнең эзен яшерергә, майор Головинга аяк чалырга тырыша иде кебек.

Җинаять булган урынны кар каплаган. Ә бит машина тирәсендә эзләр күп булырга тиеш иде. Экспертлар әйтүенә караганда, Фидаилне кыйнаганнар, янсә аның кем беләндер бик каты сугышкан булуы мөмкин. Шоферның тәне күгәреп, сыдырылып беткән. Аны чигәсенә суккач, үтергәч кенә кире машинага тыгып калдырганнар. Акчасын алу өчен үтермәгәннәр, юк, аның смена буе җыйган акчасы чалбар кесәсендә калган. Җинаятьчеләр хәтта үзләре дә акча төшереп калдырганнар әле.

Виктор өр-яңа егерме бишлекне өстәлгә чыгарып куйды. Машина идәненә каян килеп төшкән ул? Унтугызынчы февральгә каршы төндә шәһәрдә булган хәлләр арасында бер учреждениенең кассасы талану Викторны кызыксындырды. Бу эш белән капитан Сәлимов шөгыльләнә иде. Виктор әлеге акчаны аңа күрсәтте.

Ул төнне кассадан җиде мең сум акча юкка чыккан. Дөрес, хәзергә, төнлә юкка чыккан, дип үк әйтеп булмый, чөнки кассаның таланганын иртән эшкә соңга калып килгән кассир әйткән. Сейфны ул унсигезенче февральдә көндез үз кулы белән ике ачкычка бикләп киткән, иртән үзе килеп ачкан. Башка беркемдә дә ачкыч юк икән.

Учреждение бинасына ике ишектән кереп була. Урам якта, парадный ишеге төбендә, каравылчы төн куна. Тагын бер запас ишек бар, ләкин анысы гадәттә эчтән аркылы тимер белән бикләнгән килеш тора икән.

Сәлимов әйтүенчә, тикшерүчеләр килгәндә, запас ишек ачык булган, аның аркылы баскыч астындагы складка учреждение өчен кирәк-яраклар ташып азапланалар икән.

Завхоз, мин ул ишекне иртән эшкә килгәч ачтым, аркылы тимере дә урынында иде, дигән. Дөрес, ул да шулай кирәк-ярак артыннан йөреп, эш урынына бераз соңрак килгән булган.

Тәрәзәләр бар да бикле, форточкалар ябык, бинага төнлә кем дә булса кергәндер, дип уйларлык дәлил юк. Бухгалтериядә эшләүчеләр, кичке алтыда дәррәү урыннарыннан кузгалып, барысы бергә бүлмәдән чыгып киткәннәр. Бүлмә ачкычын гадәттәгечә каравылчы янындагы тактага элеп калдырганнар. Кичтән җыештыручы килеп, бүлмәнең идәнен юган. Ләкин ул бөкрәеп беткән җитмеш яшьлек карчыктан шикләнеп булмый.

Кассир да кырык ел буе акча эшендә эшләп, чәчен агарткан олы гына хатын икән. Аның гомерендә бер тапкыр да кырын эшкә катнашканы булмаган.

Шулай да бу юлы бөтен шик кассир хатынга төшә, диде Сәлимов. Моның сәбәбе дә бар. Кассирның сейфта андый зур сумма калдырырга хакы юк. Ул банктан акчаны көнендә тотып бетерерлек кенә алып кайтырга тиеш. Бу учреждениедә һәр айның унсигезендә хезмәт хакы

бирелә икән. Бу юлы акча әләшер чак житкәч кенә, кассир хатынның йөзе көл төсле күгәреп чыккан, күзләре әлҗе-мөлҗе килә башлаган, ул баш бухгалтерга кәефе бик начарланганын, бер минут та урынында утыра алмаячагын әйткән. Бухгалтер ашыгыч ярдәм машинасы чакыртмакчы икән дә, кассир, юк, мин үз врачыма барам, ул минем чирне белә, дип, ашыга-кабалана китеп барган.

Тикшерүченең:

— Врач ни әйтте соң? — дип соравына кассир:

— Мин врачка бармадым,— дип җавап биргән.— Минем эчем авырта иде. Ә бит андый чир белән врачка барсаң, больницага салалар. Өйгә кайтып, синтомицин эчтем, сохари кимердем, кипкән шомырт кайнатып эчтем дә иртән рәткә кердем. Көндез ашханәдә борчак ашы бик тәмсез иде. Ач йөрсәм, хәлсезләнәм дип көчли-көчли ашаган идем,— дип зарланган кассир.

Ашханәне тикшергәннәр, кассирдан башка агуланучы булмаган.

Виктор машинадан табылган егерме бишлекне кассирга күрсәтте. Кайгысыннан ахыр чиккә җитеп йончыган, нервлары тәмам какшаган хатын:

— Безнең сейфта өр-яңа кәгазь акчалар шактый иде,— диде.— Тик миңа монысы тәгаен шуннандыр дип әйтә алмыйм. Акча адәм баласы түгел бит ул, аны чыраена карап танып булмый.

Банкта да бу акчаның нәкъ унсигезендә җибәрелгән булырга тиешлеген әйткәннәр, тик кайсы оешмага икәнен анык әйтә алмаганнар.

Шулай итеп, хәзергә акча үзенең серен ачмады.

Виктор икенче дәлил — кистәнне алдынарак тартып китерде. Күзлеген сөртеп киде дә, лупа аша карагандай, инде ничәнче тапкыр кистәнгә текәлде. Бу тимерне шәһәрдәге таксистларның бөтенесенә дә күрсәтеп чыктылар, ләкин мондый тишекле тимерне күрүче булмаган.

Кызганычка каршы, бер нәрсәдә дә бармак эзләре калмаган иде. Машинаның алгы пыяласында, эчке якта, уч төбе һәм дүрт бармак эзе ярылып ята иде — алар Фидаилнеке булып чыкты.

Виктор, башын ныграк эшләтергә теләгәндәй, мангаен ышкый.

Тагын бер дәлил бар — анысын кулга да тотып булмый. Ул да булса унҗиденче февраль көнендә Фидаилгә шалтыраткан хатын-кыз тавышы. Шул шалтырату белән Фидаилнең сменасын алыштыру арасында бәйләнеш булуы бик мөмкин. Чөнки бу турыда аның туганнары белми дә калганнар. Фидаилне үтерү — бәлки, очраклы хәл дә булмагандыр... Диспетчер: «Ул телефоннан сөйләшкәндә, мин аның сүзенә колак салмадым»...— диде.

Фидаилнең апасы белән әнисеннән башка таныш хатын-кызларын әлегә ачыклап булмады. Ә бит ул шалтыраткан кеше күктә оча торган җан иясе түгелдер, җирдә йөри торгандыр, берәү күрмәсә, берәү күрергә тиеш аны!

Виктор кинәт сискәнеп китте: тынлыкны ярып, бүлмәне генә түгел, буш бинаны яңгыратып, телефон зыңгылдады:

— Өегезгә шалтыраткан идем, ә сез һаман эштә утырасыз икән але,— диде калын гына ирләр тавышы.— Монда бер гражданин килде, сиксән өч-егерме дүрт номерлы такси машинасын унсигезендә төнлә күрдем, ди.

— Кайчан? Кайда?

— Төнге сәгать унда.— Аннары тавыш шәһәр читендәге аулак урамнарның берсен атады.

Виктор унсигезендә Фидаилнең машинасын күргән һәркемнең бу турыда милиция бүлегенә килеп сөйләвен үтенеп, егерменче февральдә үк радиодан игълан бирдергән иде. Аны ишетеп, ике кеше килде, алар Фидаил машинасына утырып йөргәннәр икән. Тик алар сөйләгәннәрдә тикшерүчегә ярдәм итәрлек бернәрсә дә юк иде.

Виктор:
— Хәзер үк ул гражданинны машина белән минем янга китерегез,— диде.
«Гражданин» какча ябык тәнле, сары чырайлы бер кеше булып чыкты. Ул Виктор каршына утырды да башлаган сүзен дәвам иткәндәй:
— Менә шул, күрдем мин ул шоферны,— диде.— Төнге уннар булгандыр, анысын минутлап әйтә алмыйм. Кодаларда кунакта булдык, кайтырга чыккач, трамвайга дип бара идем, күрәм: машина тора. Яшел утын кабызган. Минем хатын, малай янда, кода да озатырга чыккан иде. Теге таксиның шоферы да шунда тора. «Туган,— дим,— һади Такташ урамына илтеп куй әле». «Юк,— ди,— машина буш түгел». «Как так буш түгел? Ә яшел утың ник яна?» «Анысы минем эш»,— ди. Минем кызмача чак, бәйләнеп тә китәр идем — хатын беләктән тартты. Кода да: «Ярар әйдә, ташла»,— дигәч, киттем. Тәки калды шунда яшел күзен яндырган көе.
— Ә сез аның номерын ничек истә калдырдыгыз соң? — дип сорады Виктор.— Төнлә булган эш бит ул.
Әлеге ир пальто кесәсеннән шырпы кабы чыгарды.
— Менә монда язып алдым. Кызган баштан: «Синең безне илтмәскә хакың юк, иртәгә үк мин бу эшеңне тиешле җиргә житкерәм, бу килеш калдырмыйм»,— дип язып алган идем. Ә иртән хатын: «Юк белән булашма»,— диде. Үзем дә суынган идем инде. Кая аның артыннан йөрисең.
— Нишләп соң сез милициягә элегрәк килмәдегез? Радиодан бу турыда егермесендә, телевидениедән унтугызында ук әйттеләр, ә бүген егерме өче бит инде.
— Радионы гел-гел тыңлап тормыйсың бит аны. Телевизорың бигрәк тә. Әле бүген икенче сменада идем, иптәшләрдән ишеттем дә шырпы кабы искә төште. Карасам, ташламаганмын, кесәдә йөри икән. Бәлки, шул машинаны эзлиләрдер дип, милициягә эштән кайткан уңайда гына керүем иде.
Головин бу кешенең исем-фамилиясен, туган елын, торган урынын, сөйләгәннәрен җентекләп протоколга язды. Әһә, унсигезендә төнлә Фидаилнең машинасы кассасы таланган учреждение урамында, хәтта шул учреждениедән ерак та түгел торган икән...
«Ә бәлки Фидаилнең берәр шайкага бәйләнеше булгандыр? — дип уйлады ул.— Иртәгә үк туган авылына барып, аны белүчеләр белән тагын бер кат сөйләшергә, мәрхүмнең нindirәк кеше булганлыгын ачыкларга кирәк».

## 7

Урамда салкын. Агачларны ап-ак сыкы челтәре ураган. Кояш кызарып биш катлы йортлар артына төшеп бара. Зур урамның аргы очын, сихри томан кебек, рәшә каплаган.
Өйдән чыгуга туңдыра-калтырата, ләкин бераз баргач җылынасын, атлаган саен атлыйсы килә, бит очларының кызышканын, күзләрнең үткенләнгәнен,— гомумән чибәрләнеп киткәнеңне тоясың. Дөнья матур, дөнья пакь, яшәү рәхәт, тыгызланып каткан карны шыгырдатып, авызборыннан пар бөркеп, урам буйлап баруы күңелле.
Ләкин Зөлфә бу матурлыкны күрми, аның күңелендә җәрәхәт бар кебек — һич туктамый, онытылмый борчып тора. Бу борчуны кыз күңеленә тынгысыз холыклы, үҗәт карашлы, таләпчән егет Ниаз салды.
Таксист егет Зөлфә янына тагын килде, ачыктан-ачык сөйләшергә тырышып карады. Ул кыздан бу вакыйгага үзенең ачык бер мөнәсәбәтен булдыруны, аның өчен борчылуны, ул гына да түгел, нидер эшләүне таләп итте.

Моңарчы Зөлфәнең көнелендә беркемнән дә яшерен сере юк, ни уйлаганы, ни кичергәне әнисенә дә, Атласка да ачык иде. Хәзер ул якын кешеләреннән нидер яшерергә, хәтта ялган сүз сөйләргә мәҗбүр булды. Атласка Ниазны классташым диде. Чөнки... аның белән урамда очраклы танышуы турында сөйләүне яхшысынмады. Анысын әйтсәң, Фидаил турында озаклап аңлатырга кирәк иде, ә Фидаил белән танышлык — Нателланың сере. Тагын шунысы бар: Ниаз алдында Атласка бу турыда акланганда сөйләп торасы килмәде кызның.

Зөлфә үзенең кичерешләре турында әнисенә дә сөйли алмый, чөнки аның бу танышлыкларын, мөгаен, хупламасын белә иде. Шулай итеп, кыз баланың гомерендә беренче тапкыр әнисеннән яшерен сере барлыкка килде.

Буталды Зөлфә, моңа чаклы якты, бик гади тоелган тормышны аңламас булды.

Озак йөрде Зөлфә, әйтерсең, бара торгач, ул уйларының очына чыгачак. Инде тәмам караңгы төште, утлар кабынды. Зөлфәгә урам фонарьлары яктысыннан төшкән өч күләгәсе берьюлы ияреп бара. Алда бер күләгәсе агарып юк булуга, арттан кыскарагы, карарагы килеп чыга да сукмакка ята.

Игезәкләрдәй бер төсле таш йортлар, күп күзле җан иясе кебек, кайсы якты, кайсы кап-караңгы тәрәзәләре белән карап калалар. Каршы килүче, ашыгып узып китүче кешеләрнең кызда эше юк, һәркем үз мәшәкате артыннан йөгерә.

Зөлфә, уйларына мавыгып, өенә кайтып җиткәнен сизми дә калды. Ишек төбендә генә исенә төште: әнисе аңа ипи алырга кушкан иде бит. Ул кире борылып, «Таң» кибетенә керде. Инде урам аша кире чыгыйм дигәндә, күк «Волга» астына керә язып, артка чигенде. Машина ишеге ачылды, аннан:

— Утырыгыз, илтеп куям! — дигән тавыш ишетелде. Бу — Фидаил машинасы иде. Зөлфәнең тәненә ут капкандай булды, ярым караңгыда машинада мәрхүм егет утыра сыман күренде.

— Син нәрсә, миннән курыктыңмы әллә? — диде Ниаз.— Кил, утыр.

Зөлфә телгә килә алмый тора иде.

— Минем барасы җирем юк,— диде ул, ниһаять.

— Тиз бул инде, монда озак торырга ярамый. Утыргач әйтерсең сүзеңне. Курыкма, ашамам.

Машина эчендә җылы, рәхәт. Кырыс дөньядан, ят кешеләрдән аерылып, чит күзләрдән яшеренеп, ярым-караңгыда икәүдән-икәү генә калгач, Ниаз Зөлфәгә бик якын кеше булып тоелды. Аларны уртак борчу да якынайта иде. Бу егеттә салкынлык, кеше язмышына битараф карап, үз эченә бикләнеп яшәү юк кебек, аның белән иркенләп сөйләшергә, юаныч-таяныч табарга булыр сыман тоелды Зөлфәгә.

Ниаз машинасын Восстание мәйданына таба алып китте. Счетчик йөрәк типкәндәй тигез текелди иде. Берсе дә сүз башламады. Менә Восстание мәйданы, хәзер кире борылырга кирәк иде, ә Ниаз Киров районына юнәлде.

— Туктагыз, кая барасыз? — дип сорады Зөлфә.

— Бераз әйләнеп килик. Безгә сөйләшергә кирәк.

— Сөйләгез, мин тыңлыйм.

Ниаз үрелеп Зөлфә каршындагы тартмадан папирос алды.

— Тартырга ярыймы?

— Үз машинагыз ич, үзегездән рөхсәт сорагыз.

— Болай сирәк тартам мин. Бик дулкынлансам гына. Начар гадәт, күптән ташларга кирәк иде, югыйсә.

Ул, барган көйгә кабызырга тырышып, берничә шырпы сындырды, ниһаять, папирос кабынды.

Урамның сул ягында Нателла йорты торып калды. Аның өч тәрәзәсендә дә ут бар иде.

— Син минем белән ачыктан-ачык сөйләшмисең,— диде Нияз.— Фидаилнең һәлакәтенә дә исең китмәде бугай.

Тагын! Очраган саен Нияз Зөлфәгә бер үк сүзне тукый!

— Ис китеп мин нишли алам?

— Син мине тыңла,— диде Нияз.— Ни дә булса эшләр өчен башта теләк кирәк. Фидаилнең әтисе белән әнисе карт көннәрендә ялгыз калдылар. Син моны аңламыйсың гына, ә ул коточкыч хәл. Ә җинаятьчеләр иректә. Кая монда гаделлек?

— Табарлар әле. Тикшерәләрдер ич.

— Кем белә! Әгәр бар кеше дә синең кебек кире булса, каян табасын аны?

— Кире дип, бу эштә мин берничек тә ярдәм итә алмыйм ич.

— Син мине тыңла. Унҗиденче февральдә кич белән Фидаилгә ниндидер хатын-кыз шалтыратты. Минем күз алдымда булды бу хәл. Шоферны эзләп гаражга бик сирәк шалтыраталар. Шул ук көнне Фидаил диспетчердан сменасын алыштыруны үтенгән. Эшкә чыккач, кире кайтмаган. Кем шалтыраткан аңа, ә?

— Мин түгел,— диде Зөлфә.

— Син түгел. Димәк, башка танышы. Кем ул?

— Соң әллә мине җинаятьче белән таныш дип уйлыйсыңмы?

— Ә син аларны таныйсыңмы? — диде Нияз.— Үтерүченең маңгаена пичәт басылмаган. Ул да ике аяклы, ике куллы. Син менә машинага кердең дә утырдың, ә минем кем икәнемне беләсеңме соң?

Боларны Нияз бер дә исе китмәгән тавыш белән, бик гади итеп әйтте.

Зөлфә өчен исә бу сүзләр коточкыч булып яңгырады. Гомере буе кешеләрдән гел яхшылык кына күреп яшәгән бала, дөньяның салкын җилләрен, каты суыкларын, бозлы яңгырларын, күзгә кырауларын күрми генә, оранжереяда, пыяла астында үскән гөл кебек, саф күңелле җан иясе иде ул. Җинаятьчеләрне китаплардан укып, киноларда күреп кенә белә, намуссыз, кара эчле кешеләрне, «Аккош күле» балетындагы Одиллия образы сымаграк итеп, бик ерак, бик абстракт итеп күз алдына китерә. Ул күзе күргән һәр кешенең яхшылыгына шик тотмый, берәр танышының җинаятькә сәләтле булуын башына да китерми иде.

Нияз сүзләре аны куркытты:

— Борылыгыз,— диде ул калтыранган тавыш белән.— Я туктагыз, мин төшеп калам.

— Син миңа әйтмәдең ич әле!..

— Нәрсәне?

— Фидаилнең танышларын әйтмәдең. Нигә качып йөриләр алар?

«Волга» Аккош күленә таба борылып, йөрешен кызулатканнан-кызулата барды. Иркен һәм буш урамда кеше-кара күренми, киң юлдан зур тизлек белән машиналар гына кара-каршы чаба. Кая ашыга икән алар?

Мотор каты гөрләп эшли, тәрәзә пыяласына бәрелеп, һава сызгыра, лампочкалы телефон баганалары каршы йөгереп киләләр дә артка егылып калалар кебек иде. Менә алар бөтенләй егылып бетте — машина шәһәрдән чыгып, урман юлына барып керде.

— Әкренрәк, зинһар!

Ләкин Нияз бу сүзләрне ишетмәде, ахры. Машина тизлеген һич киметмичә, асфальт юл буйлап үр астына тәгәри, аннары яман үкереп тауга үрмәли иде. Зөлфәнең сулышы кысылды, бөтен тәне тирләп чыкты. Ул үзенең бер чарасыз ят кеше ихтыярында калганын аңлады. Бу егет аны теләсә кая алып китә ала, теләсә нишләтә ала!

Приборлар калканы өстендәге кара перчаткалар идәнгә төште, алар

астыннан актриса сурәте килеп чыкты. Сурәттәге хатын мыскыллы елмая төсле иде.

— Ну, әйтәсеңме?

— Белмим мин, белмим, белмим!

— Болай булгач, мәсьәлә ачык: син җинаятьчене яшерәсең.

— Туктагыз, зинһар, туктагыз. Ялварып сорыйм!

— Ә мин сине яхшы кеше дип уйлаган идем...

Каршыга килгән машиналар җанны өшетеп улыйлар. Аларның тәгәрмәче астыннан күтәрелгән кар алгы пыялага сибелә. Җитмәсә, машинага нидер булды, астан чүкеч белән төйгәндәй, нәрсәседер бик каты шакылдый башлады. «Волга» уңга-сулга чайкалды да каршыга килгән йөк машинасының астына чак кына керми калды.

— Ну, ярый, әйтәм... Туктатыгыз гына...

— Кем?

— Нателла...

Машина, йөрешен әкренәйтеп, юл кырыена туктады. Зөлфә хәлсезләнеп утыргыч аркасына сөялде, аннары, ишекне ачып, әкрен генә тышка чыкты. Йа алла, каты, нык, ышанычлы җиргә басып торулары ничек рәхәт икән! Аягың җиргә тигән саен сөенәсе икән, моңарчы, унтугыз ел дөньяда яшәп, Зөлфә шуны белмәгән!

Ниаз машина астына, алгы тәгәрмәч янына кереп ятты. Аннан аның:

— Амортизатор какшаган,— дигән тавышы ишетелде.

Зөлфәгә машина таралып бетсә дә барыбер иде. «Волга» да, Нателлага биргән вәгъдәне боздырган шофер да аңа күңел кайтаргыч булып тоелды.

Ул читекләре белән тая-тая юл уртасына чыкты да шәһәргә таба баручы йөк машинасына кул изәде. Ул арада «Волга» астыннан чыгарга өлгергән Ниаз, кызның беләгеннән тотып, кире тартты:

— Бала-чага булма. Хәзер кайтабыз.

— Ышанмыйм мин сезгә, ышанмыйм.

— Эх син,— диде Ниаз йомшак кына.— Кешенең кемлеген танырга күптән вакыт бит инде сиңа, күптән балигъ булгансың. Бир әле сумкаңны.— Ул сумканы машина эченә куйды.— Үзең дә җылыга кереп утыр.

— Кирәге бар!..

— Ихтыярың...

Ниаз кесә фонаре кабызып, тагын машина астына шуышты. Юл буйлап ачы җил исә, җәяүле буран каты кар бөртекләрен биткә, тезләргә китереп бәрә иде. Шәһәрдә тыныч иде, монда, ачык җирдә, җил шактый нык сиздерә икән. Зөлфә як-ягына каранды: ике якта да урман, көрткә баткан шәрә агачлар җансыз, кар сибелгәндәй аксыл күк йөзендәге йолдызлар да суыктан дер-дер калтырыйлар кебек. Зөлфәгә әле беркайчан да дөньяның бу чаклы шыксыз күренгәне юк иде. Ул, Ниазга ишеттермәскә тырышып, үксеп елап җибәрде.

Машина астыннан чыккач, Ниаз аның елаганын сизде.

— Ни булды? — диде ул гаҗәпләнеп.

— Берни булмады.

Зөлфә ике кулы белән тезләрен каплады.

— Туңдыңмыни? — диде Ниаз.— Җылырак оек киярга кирәк иде. Әнә машина эченә кереп утыр...

— Кайтыйк,— диде Зөлфә.

— Хәзер. Тик, өйгә кайтканчы, бер кеше янына кереп чыгабыз әле...

## 8

Виктор авылдан туры өенә кайтып, өстен генә алыштырып өлгергән иде. Зәңгәр спорт костюмы кигәч, ул бик гади, кызлары аның тез өстенә менеп, күзлеге, мыегы белән уйнарга, чәчен туздырырга яраталар иде.

— Галя,— диде Виктор хатынына.— Нишләтсәң дә риза, тик ачтан гына үтермә, тизрәк ашарга бир!

Галясы кухнядан үртәп:

— Көт әле менә,— дип җавап бирде.— Без көткәндә бер дә исең китмн. Ярдәм дә итмисең.

— Ач карынга тәнкыйть килешми ул, Галочка. Ашаткач ачуланырсың. Мин сиңа сүз бирәм, бу эшне уңышлы тәгәлләгәч, билләһи...

— Икенчесен тикшерә башларсың,— диде Галя.— Я, килегез, ашыйк.

Виктор, ике кызын җитәкләп, кухняга юнәлде, тик өстәл янына барып житә алмады — алгы бүлмәдә телефон зыңгылдады. Эш урыныннан дежур милиционер шалтырата икән.

— Монда ике кеше килгән иде, сезне сорыйлар,— диде ул.

Галя кухня ишеге төбенә чыгып баскан, аксыл кашларын җыерып, иренә бик җитди карап тора. Викторның да өйдән чыгып китәсе килми. Ул бүген авылдан туңып, талчыгып кайтты. Кич белән телевизордан хоккей карарга, кызларына китап укырга иде аның нияте. Җинаятьчеләр турында уйламаска, бераз башын ял иттерергә иде исәбе. Әнә Галя да күпме вакыт инде бер сызымны булса да эшләп бир, дип ялынып йөри. Һаман сузса, институтта уку эше тау булып өеләчәк. Аңа да авыр, укый, эшли, тормышны алып бара. Әзрәк аның күңелен дә күрергә кирәк бит.

Виктор, бәлки, өйдән үк чыгып китәргә туры килмәс дигән өмет белән, трубкага:

— Ни йомышлары бар икән, сорагыз әле,— диде.

Телефонның теге башында үзара сөйләшкән тавышлар ишетелде. Бер ир кеше аермачык итеп:

— Таксомоторный парктан мин,— диде.— Головинның үзенә генә әйтәсе бик ашыгыч сүзем бар.

Мәсьәлә ачык: ул кеше таксист эше буенча килгән.

Виктор, хатыны ишетсен өчен авыр көрсенеп, милиционерга:

— Машина җибәр,— диде.— Хәзер барам, көтсеннәр.

Ул, Галяның күзләренә карамаска тырышып, кире залга юнәлде.

— Ник кире киттең тагын? — диде Галя моңсу тавыш белән.— Кухняга кер. Машина килгәнче утырып аша, бүлеп куйдым мин.

— Өсне алышырга кирәк.

— Шул килеш барырсың. Эш сәгате түгел, ярамаган тагын.

— Тикшерүченең кыяфәте җитди булырга тиеш, Галчонок... Чиста күлмәк кайда икән?

Виктор хатынының иңнәреннән кочты. Галяның сары бөдрәләреннән үзенә генә хас хуш ис килә иде.

— Мин тиз кайтырга тырышырмын,— диде Виктор.

Бу сүзләрнең юату өчен генә әйтелгәнен, иренең, мөгаен, тиз әйләнеп кайтмасын бик яхшы белә Галя. Ләкин каршы сүз әйтми, шушылай яратып күкрәгенә кысканы, башыннан сыйпаганы өчен ул ирен теләсә күпме көтәргә риза.

Егерме минуттан Головин эш кабинетында иде инде. Аның бүлмәсе кечкенә, Зөлфәгә бигрәк тә тар тәрәзәләрнең тимер рәшәткәле булуы ошамады. Ишектән керүгә, искереп кызара башлаган шкаф, сул якта — зур сейф. Түрдә — язу өстәле, каты урындыклар.

— Өстегезне салыгыз, элеп куйыйм,— диде Головин Зөлфә белән Ниазга. Тик алар, сүзне тиз генә тәгәлләп, чыгып китәргә уйлыйлар иде, шуңа өсләреннән салмадылар. Ниаз тун төймәләрен ычкындырып, бүреген Головинның өстәленә куйды.

Тикшерүче чәчен тарагач, тарагына өреп, күкрәк кесәсенә салды да өстәл янына утырды.

— Сөйләгез. Тыңлыйм,— диде ул.

Головинга яны белән утырган Ниаз аңа таба борылды, ике терсәге белән өстәлгә таянып:

— Зөлфә Фидаил белән таныш булган. Ул аның тагын бер танышын белә,— диде.

Зөлфә, үпкәләгән бала шикелле авызын турсайтып, урындыкның бер кырыенда гына утыра иде. Тикшерүченең текәп караганын күргәч, аскы иренен тешләп, башын иде, аның ике якка таралган туры чәче яңакларына төшеп, битен каплады.

— Кәефегез юк, ахры? — диде аңа тикшерүче.— Ул-бу булмагандыр бит?

Аның үз итеп дәшүеннән Зөлфәнең күңеле тулды.

— Юк...

— Алайса сөйләшик. Ярыймы?

Кыз яшьле күзләре белән тикшерүченең күзләгенә карады.

— Ни сөйлим?

— Фидаил белән кайчан, кайда, ничек танышуыгыздан башлагыз.

Зөлфә башта тотлыга-тотлыга әкрен генә сөйләде. Бераздан ул тынычланды, тавышы да ныгып киткәндәй булды.

Әйе, ул Фидаилне, бик үк якыннан булмаса да, белә иде. Алар үткән җәйдә таныштылар. Зөлфә Камышлы күлдәге пионерлар лагерена эшкә урнашкан иде. Алар Нателла исемле хатын белән бер отрядта эшләделәр. Нателла — педагог, Зөлфә — вожатый. Фидаил берничә тапкыр машинасы белән Нателла янына килде. Лагерьда эшләүчеләргә дә атнага бер ял көне бирелә. Ял көннәрендә Нателланы Фидаил килеп ала, китереп куя иде. Җәе туры килеп, бер тапкыр Зөлфә дә аның машинасында шәһәргә кайткан иде. Нателла Фидаилнең баштанаяк гашыйк булуы турында сөйли иде. Ләкин ай үтүгә ул хатын Риф исемле икенче бер егет белән дуслашып китте. Риф анда йөзү буенча инспектор булып санала иде — лагерьда андый эш тә бар. Аның белән дуслашкач, Нателла Фидаилне бик үк еш китермәскә тырышты. Дөрес, ул араны бөтенләй үк өзмәде, бары Риф белән очрашырлар, дип курыкканга гына шоферны бераз читкә кага иде.

Лагерьдан кайткач, Зөлфә Фидаилне берничә тапкыр урамда гына күрде, бер-ике мәртәбә аның машинасына утырып өенә кайтканы булды. Нателла белән дә Зөлфә якын дус булып китә алмады, алар сирәк күрешәләр.

— Димәк, сез Нателла белән икегез Фидаилне белә идегез? Башка вожатыйлар аны белә идеме?

— Юктыр,— диде Зөлфә.— Ул бит килә дә китә иде. Читтән күреп алган булсалар гына инде.

— Ә Риф?

— Минемчә, ул Фидаилне белми иде.

— Йөзү буенча инструктор, дисез. Физкультура укытучысымы әллә ул?

— Юк. Ул — музыкант.

— Ә ник соң ул лагерьга музыкант булып урнашмаган?

— Анда башка музыкант бар иде. Виталий исемле. Алар өчесе бер лагерьга килергә теләгәннәр. Виталийның хатыны Валя да шунда ук пешекче булып эшләде.

— Кемнәр — өчесе?

— Виталий, Валя, Риф.

— Ә Рифның аларга ни мөнәсәбәте бар?

— Ул Валяларда квартирда тора.

— Нателланың тагын нинди танышлары бар иде?

— Лагерьда эшләүчеләр күп иде инде: смена саен уналты отряд бит.

— Якыннанрак аралашканнарын хәтерләмисезме?

— Рифтан башка — юк.— Зөлфә бераз тынып торганнан соң теләр-теләмәс кенә:— Мин аның тегүчесен дә беләм,— диде.
— Кем ул?
— Люся. Аннары Люсяның дусты Константин белән дә алар яхшы таныш. Константин Рифны да белә.
Боларның барысын да сөйләп биргәч, Зөлфәнең күңеле тынычланып китте. Хәзер аның намусы чиста, йөзе ак. Ул бу ике кешенең күзенә туры карый ала. Бу — кара мыеклы, җитди тикшерүче Нателланың да, Рифның да бернинди гаебе юк икәнен тиз арада ачыклар, гаепсез кешеләрдән шикләнеп, тикшерүченең вакытын алып, Зөлфәнең башын тинтерәтеп йөргәне өчен Ниаз гына гаепле булып калыр. Ул килеп Зөлфәдән гафу үтенер. Зөлфә аңа ачу сакламас, гафу итәр итүен, тик үзенең хаклы булуын, өстенлегеген егеткә сиздерми калмас. Шулай дип уйлады Зөлфә. Һәм бу юлы инде Ниазның күзенә туры карап:
— Нателла да, Риф та, башкалар да — намуслы кешеләр,— диде. Алай да:— Люся белән Константиннан башкалары,— дип өстәми булдыра алмады.
— Алар сезгә ошамыймыни?
— Мин Люсяны ике тапкыр, ә Константинны бер генә күрдем. Тупаслар алар. Ә болай начарлыкларын белмим.
Головинның барлык сорауларына да Зөлфә тартынмыйча җавап бирде, чөнки чыннан да ул танышларының бер начарлыкларын да белми иде. Иң соныннан тикшерүче:
— Ә ник сез минем янга элегрәк килмәдегез? — дип сорады.— Радиодан, телевидениедән без биргән игъланнарны ишетеп килүчеләр булды, ә сез...
— Мин андый белдерүне ишетмәдем. Ниаз әйткәч кенә белдем.
— Сез бу турыда Нателла белән дә сөйләшмәдегезме?
— Сөйләштек.— Зөлфә нервланып тезендәге ак бүрекен бөгәрләде.— Мин әйттем бит инде, ул Фидаил белән танышлыгын яшерә, Рифтан куркам, ди... Әни мине югалткандыр инде, озак йөрдем.
Головин елмаеп:
— Югалтса, безгә килер. Югалганнарны без эзләп табабыз,— диде.— Хәзер, сөйләгәннәрегезне язык та машина белән илтеп куярбыз. Сез бергә кайтасызмы?
— Минем машина монда бит. Үзем кайтарып куярмын,— диде Ниаз.
— Юк, кирәкми,— диде Зөлфә, нык итеп.— Мин троллейбус белән кайтам.
Головин гаҗәпләнеп бер Ниазга, бер Зөлфәгә карап куйды.
— Безнең машина белән кайтуга каршы килмәссез, бәлки? — диде ул.
Зөлфә риза булды.
Саубуллашканда тикшерүче:
— Сезгә бик зур үтенечем бар,— диде.— Бер генә түгел, ике. Сезнең лагерьда вожатыйлар белән җыелып төшкән фоторәсемегез бардыр. Шуны миңа вакытлыча биреп торыгыз. Икенчесе — безнең белән очрашып сөйләшү турында берәүгә дә әйтмәгез, яме? Әтиегезгә дә, әниегезгә дә, иң якын дустыгызга да. Бу бик мөһим. Беркем белән дә бу турыда киңәшмәгез.
— Атлас белән дә,— дип кыстырды Ниаз.
— Кем ул Атлас?
— Зөлфәнең симпатиясе.
— Әйе, сез бу турыда хәзергә үзегез дә онытып торыгыз.
Зөлфәне озаткач, Ниаз белән Виктор кабинетка кире керделәр.
— Ярый, иптәш дружинник,— диде Виктор.— Хәзер сез әйтегез инде: бу кызны каян таптыгыз?

— Ул үзе минем машина янына килеп, Фидаилне сорады. Мин аны өенә кайтарып җибәрергә курыктым, кыз бала, кире уйлар, дидем.

Бу рәвешле сөйләгәч, Ниаз белән Зөлфәнең танышлыгы да, үзара мөнәсәбәтләре дә бик гади, аңлаешлы булып, егет үзе өлгер һәм акыллы булып күренде. Шуңа күрә тикшерүче бу турыда аннан артыгын төпченеп сорашмады.

— Алай икән,— генә диде.— Ә мин бу эшне тикшерү белән сез дә мәшгуль икәнне белми дә идем тагын. Бәлки, көчләрне берләштерербез?

Дөресен әйткәндә, Ниазның җинаятьчене эзләүгә бик катнашасы килә, бу эш белән ул мавыккан иде инде. Викторның сүзләре аның йөрәгенә бал да май булып ятты.

— Сезгә бу кыз белән танышлыкны дәвам иттерергә кирәк булыр,— диде тикшерүче.— Аны күздән ычкындыру ярамас. Нателлага да сукмак табарга туры килер. Гомумән, бу компания белән аралашырга кирәк. Сез иртәгә иртүк миңа шалтыратыгыз әле, аңарчы кайбер нәрсәләр ачыкланыр, без конкретрак сөйләшербез.

Ниһаять, Ниаз да чыгып китте. Ә Виктор Зөлфә атаган кешеләрнең исем-фамилияләрен аерым кәгазьгә язып алды да телефон трубкасын күтәрде.

Зур кала, ыгы-зыгы, шау-шулы көннән соң ял итәргә теләгәндәй, тынып калган. Тикшерүче өстәлендәге кәгазьгә исемнәре язылган кешеләр: Нателла, Риф, Валя белән Виталий, Константин белән Люся, мөгаен, йоклыйлардыр. Иртәгә иртән алар турында бөтен мәгълүмат — кайчан, кайда туган булулары, кайда, кем белән яшәүләре, кайсы оешмада, кем булып һәм кайчаннан бирле эшләүләре, суд җаваплылыгына тартылу-тартылмаулары турындагы мәгълүмат — бәйнә-бәйнә язылып, майор Головин өстәленә куелачак.

Ул кәгазьләр килгәнче үк, телефоннан сорашып, Виктор шуны белде: Нателла исемле хатын кассасы таланган учреждениедә секретарь-машинистка булып эшли икән.

## 9

Диспетчер, сирәгәйгән чәчле түгәрәк башын әле тикшерүчегә, әле Ниазга таба борып, керфексез зәңгәр күзләрен челт-челт йома. Һай, әттәгенәсе, мондый хәл килеп чыгар дип аның башына да килгәне юк иде бит. Көннең көнендә телефоннан йөз кеше белән сөйләшәсең, моннан бер атна элек ишеткән тавышны ничек хәтердә тотмак кирәк?

— Сез тыныч булыгыз, борчылмагыз,— ди Головин.— Уйлап карагыз әле, ул хатын берәр сәеррәк сүз әйтмәдеме? Һәркемнең сөйләшүендә үзенә бер үзенчәлек, башкалардан аерма була бит. Сез аның белән берничә тапкыр сөйләшкәнсез, бәлки, үзенә генә хас сүзе, интонациясе исегездә калгандыр?

— Сөйләшкән дип... Фидаил юк, килмәде әле генә дидем инде.

Головин магнитофон янында утыра. Ниаз кулында бер трубка, диспетчерда — икенчесе. Хәзер Ниаз берничә хатын-кыз белән сөйләшәчәк, диспетчер аны тыңлап торачак, ә Головин магнитофон тасмасына язып барачак.

Ниаз, ашханәгә шалтыратып, Валяны телефонга чакыруларын үтенде. Яңгырап торган нечкә тавыш, сузып:

— Әйе-е-е, мин тыңлыйм,— диюгә, диспетчер башын як-якка чайкады. Юк-юк, бу ул түгел. Ә Ниазга сөйләшүне тәгәлләргә кирәк иде. Ул үзенең өйләнергә йөрүен, туйда уйнар өчен баянист эзләгәнен, ана Виталийны тәкъдим итүләрен әйтте.

— Ю-у-ук,— диде Валя.— Виталий авырып тора, беркая да бара алмый. Сез инде аңа өмет итмәгез, башка кеше эзләгез.

Ниаз кибеткэ, поликлиникага шалтыратты. Э диспетчер, хатын-кыз тавышы ишетүгә, юк, ул түгел, дигәнне белгертеп, түгәрәк башын чайкый торды.

Ниһаять, телефонда Нателла.

— Алло!

— Рәшит Гәрәевич сезгә сәлам әйтергә кушкан иде,— диде Ниаз.

Телефон бераз тынып торды.

— Бу кем сөйли әле?

— Сез мине белмисездер. Мин Тольяттида булып кайттым. Анда Рәшит Гәрәевич белән танышырга туры килде. Ул сезгә әманәт җибәргән иде. Телефон номерыгызны да ул бирде.

— Һа-а, онытмый тагын үзе,— диде Нателла кинәнгән тавыш белән.

Диспетчерның башы астан-өскә хәрәкәтләнә, ул күзләре белән Головинга ишарә ясый: «Шул, шул үзе! Таныдым, аллага шөкер!» Нателланың «һа-а»сы аның хәтеренә сеңеп калган икән.

— Ул әманәтне мин сездән кайчан барып алыйм соң? — диде Нателла.

— Мин әле хәзер эштә. Кич кайтышлый үзем сезгә кереп чыксам, каршы килмәссезме?

— Рәхмәт. Мин кичен өйдә булам.

— Адресыгызны да әйтсәгез...

Диспетчер җылы курткасы кесәсеннән бөгәрләнгән кулъяулык алып, пеләшләнгән маңгаен сөртә.

Ниаз Нателла белән саубуллашып трубканы куйгач, Головин пленканы уйнатып карады. Дөрес, магнитофонга язгач тавыш үзгәрә, янгырабрак ишетелә, һәркемнең үзенә генә хас бер нечкә аһәңе югала. Алай да Нателланың «һа-а»сы диспетчерда шик калдырмый: бу, әлбәттә, ул, Фидаилне таптырып, теңкәгә тигән хатын-кыз.

Диспетчер тикшерүченең тынычлыгына, сөенмәвенә аптырый, хәтта бераз үпкәли дә. Э Викторның башында үз уйлары. Димәк, унҗидесендә Нателла Фидаилгә шалтыраткан, шул ук көнне Фидаил сменасы сәгатен алыштыруны үтенгән. Унтугызына каршы төндә аның машинасын Нателла эшләгән учреждение тирәсендә күргәннәр. Шул ук төнне учреждение кассасыннан акча югалган.

Ләкин Фидаилне үтергән кеше Нателла түгел, чөнки хатын-кыз ир-ат белән ул кадәр каты сугышып, аның тәнен күгәртеп бетерә алмас иде. Монда ирләр кулы уйнаган, кем ул? Рифмы, Виталиймы, Константинмы? Әллә бөтенләй башка кешеме?

Хәзергә Нателладан сорау алып булмый. Ул, әлбәттә, мин Фидаилгә болай гына шалтыраттым, дияр, теләсә нинди сәбәп уйлап табар, чөнки аларның ни сөйләшкәнен белүче юк. Машинаның төнлә аулак урамда торуын да касса талану белән бәйләрлек дәлил юк...

Бүген иртүк Виктор Нателла белән күршедә яшәүче бер гаилә белән сөйләште. Аның бит әле сер саклый алырлык кешеләрен дә сайларга кирәк. «Нателла безнең белән аралашмый, диде күрше хатыны, үзен бик эре тота. Үз чиратында баскычларны юмый, улын рәтләп карамый. Янына ирләр китерә, я улын ялгыз өйдә бикләп, үзе әллә кайда йөри. Шау-шулы мәҗлесләр үткәрә». «Анысы сирәк була»,— диде хатынның ире. «Ире киткәнгә дә күптән түгел бит әле,— диде хатын.— Бичара Рәшит, Тольяттига эшкә барам, дигән булып чыгып китте шул. Андый хатыннан җир читенә качарсың». Алай да Рәшит улын онытмый икән, акчасын-посылкасын җибәреп тора икән.

Виктор Тольяттига да шалтыратты инде, Рәшит Сибгатовның шунда трестта эшләвен белде. Хәзер ул кешенең үзе белән сөйләшеп, күчтәнәчләр мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Вакыт аз, сәгать ун җиткән икән инде.

— Сәгать дүртләрдә очрашырбыз да калганын шунда сөйләшербез,— диде Виктор Ниазга.

...Нәкъ шул минутта Нателла да вакытны карады: аның калын алтын беләзекле кечкенә сәгате унберенче ун минутны күрсәтә иде. А-ах, кичкә хәтле вакыт күп әле. Чәй кайнатырга да иртәрәк. Нателла өстәлендәге язу машинкасына, аның янында чәчелеп яткан бланклы кәгазьләргә нәфрәтләнеп карады. Бөтенесен җыеп алырга иде дә машинкасы-ние белән өченче кат тәрәзәсеннән урамга тондырырга иде.

Нателланың бүлмәсе биек булса да, кысан, караңгы. Бүлмә ишеге ачыла да ябыла — директорны сорыйлар, чөнки аның кабинетына шушы бүлмә аша керешле. Ишектән керүченәргә дә, телефон шалтыраткан-нарга да Нателла бер үк сүзне кабатлый: «Директор районга китте, бүген булмаячак». Аяк астында буталучы халык күп, ә сүз кушар кеше юк.

Тагын ишек ачылгач, Нателла директор юклыгын әйтә башлаган иде. Вера түтәйне күреп, туктап калды. Вера түтәйгә житмеш яшь бардыр инде, аның болай да юка гәүдәсе бер яккарак авышып бөкрәйгән, шиңгән. Алай да ул күк халатын көн дә үтүкләп кия, тиз-тиз атлап йөри, ә жыерчыклы йөзендә шундый кыяфәт, әйтерсең әллә нинди зур бер эш башкара.

Гадәттә Нателла аңа урындыкка караган кебек кенә карый, сүз кушу юк та юк инде ул. «Ник эшләп йөри икән бу корткa? — дип уйлый ул.— Пенсиясе житәрлек бит, югыйсә. Шушы эт куышында идән юып йөрүнең ни тәмен таба икән? Идән юуның да ләззәте бар микәнни?»

Вера түтәй Нателланың мөнәсәбәтен аңлый, ул үзе дә баш бирә торганнардан түгел, ул да бу тәкәббер хатынны күрмәмешкә салыша. Дәшми-тынмый гына төргәктән чиста сөлге чыгарып, ишек янындагы чөйгә элә, андагы керле сөлгене алып чыгарга борыла.

— Сез кайтып китмәдегезмени әле? — ди Нателла кинәт.

— Юк әле,— ди карчык коры гына.

Нателланың бүгенге хәлне кемгә дә булса тизрәк сөйлисе килә. Ул тыела алмый, җыештыручы карчык чыгып киткәнче, әчен бушатырга ашыга:

— Ә миңа бер кеше шалтыратты әле, ирем яныннан кайткан икән. Рәшит миңа бик күп итеп кучтәнәчләр җибәргән, сәлам әйтергә кушкан, бик сагындым, бик күрәсем килә, очып кына кайтыр идем, китеп булмый, дигән. Әшендә тагын күтәргәннәр икән, трест управляющие иткәннәр, эш хакы да арткан, хәзер дүрт йөз сум ала, ди.

Вера түтәй, сөлге белән газетасын кочаклаган хәлдә, ишек төбенә басып, итагатьле кыяфәт белән тыңлап тора.

— Иң матур чагыгызда алай аеры-чаеры яшисе түгел иде,— ди ул, ниһаять, Нателла сөйләүдән туктагач.— Тигез чаклар бер генә була, бергә яшәп калырга кирәк.

— Бик чакыра чакыруын, кил, ди, бүген үк өч бүлмәле квартир алабыз, ди. Шәһәре бер дә күңелемә ошамый шул, Вера түтәй. Ком да таш, яшеллеге юк, рәхәт түгел. Бер киткәч, кире кайтуы җиңел булмас, дим.

Нателла үз сүзләренә чын күңелдән ышанып, дулкынланып сөйли.

— Ул үзе дә анда ике елга гына киткән иде бит. Хәзер бер елы узып та бара инде, бер елга гына түзәсе калды.

— Еллар гына үтсә бер хәл иде, гомер үтә бит, гомер,— диде Вера түтәй.— Ир балаң бар, атасыннан бизә күрмәсен.

Ул чыгып киткәч, Нателла тагын ямансулап кала. Тәрәзәдән күренгән тутыккан калайлар кырыс чынбарлыкны искә төшерәләр. Ә чынбарлык әле генә Вера түтәй тыңлаган әкияткә бөтенләй охшамаган.

Әйе, чибәр иде Нателланың зәңгәр күзле Рәшите, егет солтаны иде. Дүрт ел бергә торганнан соң, ул, Нателладан аерылып, Тольяттида

икенче хатынга өйләнде. Алимент түли, улына әйбер-кара җибәреп тора, ләкин аерылган хатынына бер генә җылы сүз дә язганы юк.

Нателла, сумкасыннан күзге алып, кашын-күзен төзәтә. Көндәшен күргәне юк аның. Ул шушы көзгедә чагылган йөздән чибәррәк микәнни? Кай җире артык икән? Нателла урамнан узса, борылып карамаган кеше юк, үзе сау-сәламәт, теләсә кем белән әңгәмә кора ала — кай җире ярамады Рәшиткә?

Рәшит үзе генә китмәде — Нателланың бәхетен, тормыш җаен алып китте. Лагерьда чакта ярыйсы иде, малай белән икесенең дә тамагы шунда үтә, кибетләр ерак, акча кирәклеге сизелми. Шәһәргә кайткач, нужа басты. Акча санап яшәргә күнекмәгән Нателла кулында Рәшиттән килгән алимент бик тиз эреп юкка чыга торган булды. Сиксән сум эш хакы да, бармак арасыннан аккан ком кебек, коела да бетә, санарга куркасың. Шул куркудан дымланган учыңны алып карасаң, ябышып калган тиеннәрне генә күрәсең. Ә Нателла тирә-юньдә бер итеп киенергә, башны югары тотарга күнеккән. Башны бит аны байлык, муллык югары каратып, терәтеп тота.

Өстәвенә — ялгызлык. Шул ялгызлык бит инде аны, заманында зур гына начальник хатыны булган кешене, үзеннән күпкә яшь, гап-гади шофер малай белән бәйләнергә мәҗбүр итте. Фидаилнең якты күзләре белән хуҗасына караган эт кебек мөлдерәп карап торуы, яратуын аңлатырга сүз тапмый азаплануы, кызлар кебек юктан да оялуы, кызарынып-бүртенеп кияүгә чыгарга тәкъдим ясавы Нателланың күңелен ача иде. «Мин дә төшеп калганнардан түгел,— ди иде хатын, эченнән генә иренә мөрәҗәгать итеп.— Җиләк кебек егетләр миңа гашыйк булалар, минем өчен утка керергә әзер торалар әле». Эч пошу, кимсенү хисе аны сонрак Риф кочагына ташлады.

Нателла, уйларын иңнәреннән селкеп ташлагандай кискен хәрәкәт ясап, урыныннан сикереп торды. Кайгырудан файда юк, каефеңне генә җимерәсең. Чәй кайнатып, кайберәүләрне сыйларга вакыт. Дөрес, кассир карчык хәзер юк, бәлки, бөтенләй эшкә дә чыкмас инде. Ләкин Нателла һәрнәрсәне нәкъ элеккечә эшләп барырга тиеш.

## 10

— Бу кешене кайдадыр күргәнем бар минем,— диде Ниаз...

Анын кулында — бер төркем кызлар-егетләрнең фоторәсеме. Головин бармагы белән төртеп күрсәткән хатын, чекерәеп, туп-туры Ниазга карап тора, аның туры чәчләре иңнәренә таралып төшкән. Кайда күрде Ниаз аны? Бик таныш, хәтта гайрәтне чигереп бетергән йөз бит бу?

— Бу — аларның лагерьда төшкән фотолары,— диде Виктор.

Анысы болай да аңлашыла, чөнки барысы да пионер галстугы таккаңнар. Нателла белән янәшә Зөлфә утыра. Алар артында да... таныш кеше. Кыяфәте бик шәп. Йөзендә елмаю галәмәте, менә-менә көлеп җибәрер дә... аста бер теше юклыгы күренер,— диде Ниазның хәтере.

— Бусы кем? — дип сорады ул.

— Риф.

— Аны да күргәнем бар. Фидаилне күмгәндә оркестр составында иде.

Бер читтәрәк тагын бер таныш — Атлас басып тора. Тик аны Ниаз Головинга әйтмәде. Зөлфә яраткан егетнең тикшерү эшенә бер катнашы да юк иде бит.

— Ә Нателла сезне беләме соң? — дип сорады Виктор.

— Белмим шул,— диде Ниаз.

— Бер сәгатьтән күчтәнәчләр килеп җитәчәк. Куйбышев самолеты һавада инде.

— Нишләп? Куйбышевтан укмыни?

— Рәшит Сибгатов Тольяттида ич. Малайга үз этисе җибәргән күчтәнәчләрне, ә Нателлага үз ире язган язуны тапшырачаклар.

Ниаз сызгырып куйды:

— Ти-из!

— Безнен эштә сонга калырга ярамый. Сәгать алтыларга чаклы Нателланы кайда күргәнегезне исегезгә төшерегез.

Ниаз чыгып машина ишеген ачкан иде, учы белән маңгаена сугып, кире Виктор янына кереп китте.

— Исемә төште,— диде ул.— Нателланың портреты — машинада, приборлар калканында, аны Фидаил ябыштырган иде.

Виктор, бүреген генә киеп, урамга чыкты. Сурәттән Нателла үзе түгел, аңа бик нык охшаган артистка карап тора иде.

...Ниаз кирәкле йортны эзләп тапты. Иөгереп дүртенче катка менде. Менә ул — илле бишенче квартир. Ишек янгагында, озынча ак пластинка эчендә, яшел сәдәф — кыңгырау төймәсе. Ишектә өч йозак тишеге, уртадан пыяла күз «глазок» акаеп карап тора.

Ниаз бармагы белән яшел төймәгә басты — эчтән кыңгырау чыңы ишетелде.

Нателла алгы бүлмәдәге көзге каршына басып, иңнәренә төшкән кара чәчен туздырыбрак куйды, иреннәренә иннек якты. Шуннан соң гына ишек янына килеп, саклык белән глазок капкачын ачты. Аннан соң да ишек ачканчы эчтән чылбыр эләктереп куйды. Ярыктан:

— Сезгә кем кирәк? — дип сорады.

— Сез Нателламы? Мин сезгә көндез шалтыраткан идем.

Тавышына карап, Нателла бу кешене мәһабәтрәк, чибәррәк итеп күз алдына китергән иде. Ә ул карсак гына буйлы, чәчләре маңгаена бөселеп төшкән бер адәм икән. Кыска тун кигән тагын.

Ниазны өйгә керткәч, Нателла ирексездән аның зур кара сумкасына карады. Ниаз сумканы аңа бирде дә залга узды. Бүлмә шәп җиһазланган, әмма чисталык, пөхтәлек җитми иде.

Уенчык машинасын кочаклап, Ниаз каршына дүрт-биш яшьлек малай килеп басты.

— Нихәл, егет, үсеп буламы? — диде аңа Ниаз күз кысып.

Малай авызын ерды — аның өске тешләре череп беткәне күренде.

— Тешләреңне кая куйдың? Сугышып җимердеңме?

— Юк,— диде малай,— конфет ятрканга төште.

— Ә син конфет ашама, кызлар ашасын. Син — егет кеше, ит аша.

Нателла, ашыгып-кабаланып, сумкадагы күчтәнәчләрне өстәлгә бушата иде: аннан алма, әфлисун, лимон, малайга җылы костюм һәм ике пар кечкенә бияләй килеп чыкты.

Марсик өстәлдән әфлисун эләктерде. Нателла нидер көткәндәй Ниазга карап тора иде: юк, бу күчтәнәч кенә аз әле, тагын ни дә булса бардыр, Нателланың үзенә генә аңлаешлы, үзе өчен генә җибәрелгән әйбер булырга тиеш.

— Ә, онытмыйм тагын, Рәшит Гәрәевич сезгә язу җибәрде,— диде Ниаз.

Нателла язуны бик озак укыды. Ул хәтта янында чит кеше басып торганын да онытты. Аның йөзенә нидер көтү, өметләнү билгеләре бәреп чыкты, ләкин өмет чаткылары күзгә күренеп кимеде, сүрелде, сүнде. Хатынның юка ирен читләре кысылды. Ә бит Ниаз белә, язуда нибары өч кенә җөмлә: «Нателла! Марска бераз күчтәнәч җибәрәм, посылка итеп салсам, бозланып катар дип курыктым. Малайның сәламәтлеге ничек? Хәбәр ит. Рәшит».

Нателла, ниһаять, башын күтәрде, ишек төбендә басып торган Ниазны күрде һәм шул мизгелдә аның йөзе алыштырып куйгандай үзгәрде.

Ул, ялчысына утырырга рөхсәт иткән байбичәдәй, мәһабәт хәрәкәт белән кәнәфигә ишарә ясады:

— Узыгыз, утырыгыз! Сөйләгез!

— Әллә ни сөйләр сүз юк инде.

— Сез Рәшит белән күптән танышмы?

— Күптән дип әйтеп булмый. Мин Тольяттига запчасть табып булмасмы дип барган идем. Шоферның эшен беләсез.

Нателла уң кулы белән өстәлгә таянып, сул кулын бөеренә куйган. Аның биле нечкә, аяклары озын икәнен күрми калу мөмкин түгел. Әмма хатынның болай басып торуы Ниазга ошарга теләүдән түгел, гадәте шулай булганга гына иде.

— Рәшит Гәрәевич яхшы кеше икән, миңа бик нык ярдәм итте,— диде Ниаз.

— Кәефе ничек, сәламәтлеге?

Ниаз җавап бирергә ашыкмады. Яхшы, әйбәт дисә, Нателлага аның җавабы ошамаячак иде. Хатын Рәшитнең анда ямь тапмавын, рәхәт күрмәвен, кәефсез булуын, Казаннан, Нателла яныннан киткәненә үкенүен тели иде, билгеле. Ниазның ык-мык итеп торуын ул, Рәшит турында начар хәбәр әйтүдән курка, дип, үзенчә юрады.

— Һа-а, кара әле мин, ачык авыз! Кунакны сыйламыйм да! Рәхим итегез!

Ул өстәлдәге җимешләрне Ниазга тәкъдим итте.

— Юк, кирәкми, рәхмәт.

— Сезне яхшылап сыйлау тиеш иде. Бәлки, кофе эчәрсез?

— Юк-юк, рәхмәт. Мин, кереп кенә чыгармын, дигән идем.

— Хатыныгыз көтәме?

Ниаз елмайды:

— Өйләнеп булмады шул әле.

— Алайса... кичке ашны бергә ашаган булыр идек... Кызганыч, мин белмәдем, әзерләмәдем.

Ниаз аның тел төбен бик яхшы аңлады, аңа шул гына кирәк тә иде.

— Мин сезне үзем чакырыр идем дә, өс-башның рәте юк. Эштән кайтыш кына. Әгәр бу эшне иртәгәгә калдырсак? Сез каршы килмәссезме?

Нателла, ризалыгын белдереп, елмайды.

Ниазның сумкасы өстәл янында калды. Алар икесе дә аны онытуны тиеш таптылар.

## II

— Әйдә өскә менәбез,— диде Зөлфә егеткә.

Лифтның яшькелт ишеге, алар утырганны гына көткәндәй, ачылып тора иде.

Лифт тигез генә гүләп аларны өскә алып менеп китте.

Алар сигезенче катта төшеп, шул читлекнең рәшәткәсе янына бастылар да зур тәрәзәдән аска карадылар. Көн яктысында моннан оргсинтез заводыннан алып тимер юл вокзалына кадәр урыннар бик яхшы күренә.

Хәзер завод та, йортлар да, вокзал да, Идел дә, Казанка да күренми — бар шәһәрне йомшак юрган белән кышкы төн каплаган. Күк гөмбәзе түбәнәйгән, аңа тәмам төшәргә, җир белән тоташырга электр утлары гына ирек бирми кебек. Утлар, утлар, күпме алар? Аклары, сарылары, яшелләре, кызыллары, эреләре, вaклары. Сарылары шакмак-шакмак булып күп катлы йортларның тәрәзәләреннән бөркелә, аклары урамнар буйлап, бер җепкә тезелгәндәй, тәртип белән басканнар, кызыл-яшелләре бер кабына, бер сүнә. Утлар бер ишәя, бер кими, урыннан-урынга күчә, җемелди. Оргсинтез заводларында факелларның

ялкыны ашкынулы йөрәк кебек жилпенеп-жилпенеп яна. Барыннан өстә — күк йөзен ертып, яшел-кызыл утлар жем-жем итә — самолет килә.

Зөлфәнең күп мәртәбә әнә шул утларны күзәткәне бар, тик карап туйганы юк. Менә бүген дә йөрәген телгәләп торган тынгысыз уйларын оныту өчен менде ул монда. Атласның беләгенә иңе белән елышып, басып тора, аның иреннәрендә сизелер-сизелмәс елмаю, күзләре шул утлардан очкын алгандай яктырган.

Яктылык кешегә музыка кебек тәэсир итә, дип сөйлиләр. «Төсле музыка» белән соңгы вакытта бик мавыга башладылар. Ике катлы рамнар аша Зөлфәгә кала шау-шуы ишетелми диярлек, шулай да утлар ана күңел түреннән айкалып чыккан озын, моңлы көй уйныйлар кебек. Ул көй чисталык, сафлык турында жырлый, биеклек алдында баш ию, гаделлеккә, матурлыкка, хакыйкатькә ышаныч булып яңгырый.

Католикларның «Аве Мария» дигән догасы бар. Аны бөек композитор Верди язган. Аны саф сабый тавышы белән Робертино Лоретти жырлый, Мәскәүдәге зур театрның скрипкачылар ансамбле уйный. Шул ике моңны кушсаң, шушы утлар уйнаган көй килеп чыга кебек.

Күпме утлар кабызылган, дип уйлады Зөлфә. Барысы да кешенең йортын, юлын, тормышын яктырту, бизәү-ямьләндерү өчен. Бу утлар яктысында күпме кеше яши! Алар эшлиләр, ашыйлар, ял итәләр, шатланалар, кайгыралар, мәхәббәт утында яналар... Шушы минутларда берәүләр өенә кайтып кереп, балаларын сөя, икенчеләр каядыр ашыга: киногa, театрга, сөйгәне белән очрашырга. Шушы утлар яктысында Зөлфәнең әнисе, акушерка Гөлсинә, дөньяга яңа килгән кешене кулына алып күтәрә. Сабый әле берни белми, күрми, аңламый, әмма ул рәхәт яшәсен өчен дөнья күптән әзерләнгән: шәһәр төзелгән, утлар кабызылган, йортлар жылытылган. Күпме хезмәт куеп, кадерләп, көтеп ала шәһәр сабыйларын! Шул ук утлар яктысында, хезмәт һәм акыл жимешләрен, шәһәрне, утларны исәннәргә калдырып, гомерләрен кичкәннәр үлеп китә... Тик бу турыда Зөлфәнең озаклап уйлыйсы килми. Ул яшь әле, гомере алда, аның яңа туган сабыйга мирас итеп калдырырлык зур эшләр башкарасы бар. Шуңа күрә утлар аңа яшәү турында, киләчәк турында, бәхет турында сөйлиләр кебек тоела. Күпме хис, күпме дәрт, күпме яну-көю синдә, тормыш!

Зөлфәнең иңенә кулын салган Атлас та салкын зәңгәр күзләре белән шул утларга текәлгән иде. Ләкин ул утларның үзләреннән бигрәк, алар арасына поскан караңгылыкны күрде. Күпме лампочка, күпме фонарь кабызылган, күпме көч, энергия сарыф ителә — барыбер шәһәрне төн караңгылыгы баскан. Һәр лампочканың, фонарьның яктысы уч төбедәй түгәрәккә генә төшә. Ул түгәрәкләр кешенең күзен генә сукырайта, алар турысыннан узгач, бакча почмаклары, гараж артлары, вокзал артындагы юллар, чокырлар, ишегаллары тагын да караңгырак, куркынычрак тоела. Шәһәр караңгы, шомлы: жинаятьләр, афәтләр белән тулы. Кемнәрдер кемнедер алдауга план кора, кемнәрдер үч алу жаен карый, кемнәрдер караңгы почмакларга посып яшь түгә. Ишегалларында көчле малайлар көчсезрәкләрне үзләренә буйсындыра: баш игәннәрне канат астына алалар, горурларны кимсетеп, кешелеген таптап тәм табалар. Анда көчле беләкләр, әшәке сүзләр, усал-рәхимсез янган күзләр өстенлек итә.

Ә соң яктыртылган юлларда йөрүчеләр, жылы өйләрдә утыручылар бик әйбәтме әллә? Берәүләр дөнья мәшәкатьләрен, үзенең көчсез, вак адәм икәнлеген онытып тору өчен хәмер чөмерә, икенчеләр шул хәмергә акча табу жаен карый, өченчеләр хатын-кыз кочагына ташлана. Шушы минутларда Киров районындагы караңгы ишегалларының берсендә, авыр адымнар белән, көн буе ресторанга ящиклар ташып арыган, чытык чырайлы ир кеше — Атласның әтисе кайтып килә. Үз

баласына, бердәнбер улына хыянәт итеп, аны чит хатынга алыштырган кара күңелле адәм кайтып килә якты юллардан.
— Искиткеч матур! — диде Зөлфә көрсенеп.
— Нәрсә?
— Төн... Утлар...
— Әйдә, төшик.
Баскычтан җәяү генә төштеләр. Һәр катта Зөлфә борылып тәрәзәгә карый — түбәнәйгән саен утлар әзрәк күренә. Зөлфә күңелендәге тантаналы көй әкренрәк яңгырый. Менә ул, еракка китеп барган җырчы тавышыдай, бөтенләй ишетелмәс булды. Зөлфәнең борчуы тагын әйләнеп кайтты. Ул тәүлек буе инде кичә кич башыннан узган вакыйгалар турында туктаусыз уйлана. Аның әле беркайчан да егетеннән сер яшергәне юк иде. Хәзер аңа Ниазның аны әзәрлекләве турында, машинага утыртып алып китүе һәм Зөлфәнең әйтмим дигән сүзен куркытып әйттерүе турында сөйләргә кирәк. Аннары төнлә тикшерүче кабинетына барып керүен әйтергә кирәк. Атлас Нателла белән Фидаилнең мөнәсәбәтенә игътибар да итмәс, бәлки, ә Зөлфәнең үз-үзен тотуы аңа ошамас. Әгәр, ник утырдың аның машинасына, дисә? Нигә теләсә кемгә кирәк-кирәкмәгән сүз сөйләп йөрисең, дисә? Хәтере калыр Атласның, үпкәләр ул...
Үз ишекләре янына төшеп җиткәч, Зөлфә бияләйләрен салып, тун кесәсенә кулын тыкты. Аннары аптыраган кыяфәт белән папка бауларын чиште дә, аннан нота дәфтәрләре, җыентыклар алып, Атласка тотырды. Баулары асылынып торган папканы әйләндерде, хәтта китап-дәфтәрләрен дә берәм-берәм селкеп карады: ул өй ачкычын югалткан иде.
— Инде нишлибез? — диде Атлас.
— Белмим шул. Әни янына барып кайтырга туры килер микәнни?
Алар ни эшләргә белми аптырап торганда, лифт ишегеннән Ниаз килеп чыкты. Зөлфә белән янәшә Атласны күрүгә аның йөзенә күләгә төшкәндәй булды. Ә Зөлфә, уңайсызлануын Атласка сиздермәс өчен, ишеккә таба борылды.
Аның өйгә керә алмый торганын белгәч, Ниаз кесәсеннән шалтыратып бер бәйләм ачкыч тартып чыгарды. Арадан берничәсе инглиз йозагыныкы иде.
Атлас:
— Кая, бирегез әле, карыйк! — дип, ачкычларны күздән кичерде.— Менә бусы туры килә,— диде ул.— Бу тешен кыскартсаң, бусын бераз гына игәсәң, нәкъ үзе була! Кечкенә генә игәү кирәк.
Зөлфә күршеләрдән игәү сорап алды. Атлас ачкычны игәргә маташып карады. Аны күзәтеп торган Ниазның йөзендә мыскыллы елмаю чагылды: тәти егетнең озын бармаклары тимер-томырны бик җайсыз тота икән. Игәве ычкынып китеп, озынча тырнагына да ялгыш сыдырып алды ул. «Була бит дөньяда булдыксыз адәмнәр,— дип уйлады Ниаз.— Кем булып эшли икән? Әллә укый микән?»
— Бирегез әле,— диде Ниаз.— Тимер кыру — минем һөнәр ул!
— Ә сез кайсы тешен кырырга икәнен беләсезме соң?
Каян белсен аны Ниаз? Гомумән, чагыштыру өчен кулда дөрес ачкыч булмый торып, һич булмаса йозакны ачып, эчен карамыйча, аны белеп буламыни?
— Анысын сез әйтерсез,— диде Ниаз.
Атлас, менә бу төшен, бу төшен, дип, тырнагы белән сызып күрсәтте. Ниаз, кашын-күзен җыерып, машина мае һәм тимер тузаны сеңгән, җәенке, каты тырнаклы куллары белән эшкә тотынды. Әйе, аның кулларын мода журналына төшереп алырлык түгел, машина баранкасы тотарга күнеккән бармаклары да кәкре, ләкин алар шырпы кабы зурлыгында радиоалгычлар ясарлык сизгер һәм оста.

Ул шулай уйлады. Әмма барыбер ачкычны тиешенчә эшләп бирә алмады. Барыбер Атлас җайсыз куллары белән ачкычның бер төшен юкартып, икенче төшен шомартып азапланды. Ниһаять, озын борыны янына ук китереп, соңгы кат күздән кичерде дә, булды бу, дип, йозакны шартлатып ачып та бирде.

Бу шома чырайлы кәнфит егетне мактарга һич күңеле тартмаса да, түзмәде Нияз:

— Мастер,— дип куйды.— Мондыйларны күргән юк иде әле.

Егетен мактаганга Зөлфәнең кәефе килде. Ул ике егет арасында уңайсызлана, дулкынланганын сиздермәс өчен сөйләшергә тырыша иде.

— Аның хәтере яхшы,— диде ул.— Теләсә нинди әйберне бер күрүдә исендә калдыра. Җәй көне лагерьда мин әнинең көмеш беләзеген югалткан идем. Атлас сызымын ясады да нәкъ шундыйны эшләтеп алдык. Әни сизмәде дә.

— Художник, димәк?

— Художник түгел, сызымчы. Ул һәрнәрсәне үз зурлыгында хәтеренә сеңдерә, кичерәйтә алмый.

Атлас, үзе турындагы аңгәмәгә исе дә китмичә, алгы бүлмәнең уртасында, җансыз сындай тыныч кыяфәт белән, керфек астыннан гына карап, басып тора иде. «Сөйләгәнме аңа Зөлфә, юкмы? — дип уйлады Нияз.— Сөйләгәнме, юкмы? Әгәр бу колга безнең тикшерүчегә барганны белсә, ул аны шунда ук Рифка җиткерәчәк. Тик беләме ул, юкмы?»

Зөлфә тунын салды, ләкин егетләрнең берсен дә залга керергә чакырмады. Ул, Ниязны җибәреп, Атлас белән ялгыз калырга ярамаганын бик яхшы аңлый һәм хәлнең болай килеп чыгуына шат иде: хәзер инде серне Атласка сөйләү җаен эзләп интегәсе юк. Ниязны калдырып, Атласны рәнҗетергә дә теләми иде Зөлфә. Өчәүләп кич утыру исә бөтенләй мөмкин булмаган эш иде — чөнки бер-берсен яратмау егетләрнең йөзләренә бәреп чыккан иде. Тик аларның берсе дә алдан хушлашырга ашыкмады.

Шунда Зөлфә үзе дә көтмәгән бер кыюлык эшләде.

— Егетләр, гафу итегез, мин сезне кунак итә алмыйм,— диде.— Ишекне ачып бирүегез өчен рәхмәт. Минем дәрес әзерлисем бар.

Бу сүзләрне ишеткәч, Атлас хәйран калды. Нияз исә сөенде: «Сөйләмәгән, серне чишмәгән!»

Егетләр икесе дә бергә чыгып китәргә мәҗбүр булдылар. Нияз ашыкмый гына, үз дәрәҗәсен белеп кенә, баскычтан алдан төште. Атлас аның артыннан бөтенләй тавышсыз, сиздерми генә атлап килә иде. Аска төшеп җитәрәк, Нияз, әллә теге бөтенләй калып, кире Зөлфә янына менеп китте микән, дип тә уйлаган иде, ләкин борылып карамады, үзенең Атлас белән күпмедер дәрәҗәдә кызыксынуын күрсәтергә теләмәде. Тәти егет аның эзенә басып килә икән, ишектән чыгуга, янәшә килеп басты да:

— Әй, син, фраер,— дип, Ниязга дәште.— Син бу тирәдә артык еш чуала башладың түгелме?

— Кая телим, шунда йөрим. Кешедән сорап тормыйм.

— Сиңа нәрсә, кызлар беткәнме әллә?

Нияз Зөлфәнең бергә укыдык дигән сүзләрен искә төшерде.

— Син әзлә башкаларны. Мин югында йөреп калдың, җитте.

— Яхшылап әйткәнне тыңламасаң, бу тирәдән сине биздерү чарасы табылыр.

— Син нәрсә? Яныйсыңмы?..

Алар шулай әйткәләшеп ишегалды аркылы уздылар. Бетон баганалар, озын муеннарын сузып, неон лампочкалары белән аларны күзәтә иде кебек. Нияз сүзен аста калдырырга да хурлана, бу егет белән бәйләнергә ярамаганын да аңлый иде.

Шуна күрә ул тизрәк аның яныннан китәргә омтылды. Урам аркылы чыгарга да, троллейбуска утырып, өйгә кайтып китәргә. Ләкин ул машина юлына басуга, Атлас аның түн якасыннан тотып алды:

— Син нәрсә, мине озатып, кире кермәкчеме? Юк инде, бергә кайтабыз!

— Кагылма! Ал кулыңны!..

Ниаз кискен хәрәкәт белән якасын Атлас кулыннан ычкындырды. Менә хәзер алар сугышып китәчәкләр иде. Ниаз бу колганы изеп ташларга әзер, җинәсенә дә ышана. Ләкин... тыелырга кирәк. «Ник мине үзе белән алып китмәкче ул?» — дип уйлады Ниаз һәм шунда ук җавабын да тапты: «Зөлфә, бергә укыдык, диде. Димәк, без аның белән бер тирәдә яшәгәнбез булып чыга. Ә бу тугыз катлы йортка халык өченче елны гына күчте. Аңарчы Зөлфә кайда яшәгән?»

Атлас аны үзәккә таба алып китмәкче. Ул беләдер, мөгаен.

— Ярый, беребез дә үпкәләшле булмасын,— диде Ниаз, килешергә теләгәндәй.— Киттек.

Алар кузгала башлаган троллейбусның ишегеннән сикереп керделәр дә шәһәр үзәгенә таба, Ниазлар йортыннан кире якка киттеләр.

## 12

— Слушай, брат,— диде Ниазга Риф.— Әгәр Нателла күңеленә ошаса, бер дә аны-моны уйлап торма. Мин мулла түгел, кеше иреген кысарга җыенмыйм. Үзегез килешәсез икән, миннән хәер-фатиха. Изге сәгатьтә.

Ниаз, Атласны искә төшереп, көлемсерәп куйды. Кеше белән кеше арасы — җир белән күк арасы... Бүген ул Нателланы ресторанга алып бармакчы иде, тик аның артыннан ук Риф килеп керде. Нателла аларны таныштырды. Бераз сөйләшеп утыргач, икесе берьюлы Нателла белән хушлашып, урамга чыктылар да, троллейбуска утырып, шәһәр үзәгенә таба киттеләр.

— Шофер дисең инде, алайса,— диде Риф. Ул иренеп кенә, борын эченнән сөйләшә иде.— Ә машина бармы соң?

— Кирәк чакта машинаны табабыз.

Ниаз аның тук чыраена карап, Головин сөйләгәннәрне исенә төшерде: Рифның әти-әнисе юк, торыр җире юк, даими эш урыны юк, суд җаваплылыгына тартылганы юк. Дөрес, милициягә бик таныш икән үзе, тәртип бозылган тирәләрдә күп чуала, ләкин, тикшерә башлагач, һәрвакыт шаһит кына булып чыга икән.

— Слушай, брат,— диде Риф, Ниазның җилкәсеннән кагып.— Әйдә, бер авылга кунакка барып кайтабыз, ә?

— Еракмы соң?

— Ерак түгел! Егерме чакрымлап кына. Ну, утыз булыр. Минем Виталя дигән дусның кардәше өйләнгән. Кунакка чакыралар, кайта алмыйм! Шунда барып, авылны ду китереп типтереп килсәк, ә?

Билләһи, Ниазга мондый форсатны ычкындырырга ярамый иде! Тик ул сөенгәнен сиздермәскә тырышты.

— Автобус йөрмимени анда? — дип сорады.

— Автобус нәрсә ул! Баргач-баргач, шик белән барырга кирәк! Ну, әгәр кулыннан килми икән...

— Уйлап карарга була,— дип бүлде аның сүзен Ниаз.

— Вакытың булса, әйдә, безгә сугылыйк!

Ниаз риза булды.

Кечерәк кенә бүлмә фанер такта белән икегә бүленгән. Бу якта зал, ә теге якта, ишек урынына элеп куелган эре бизәкле ситсы чаршауны ачып керсәң, мөгаен, йокы бүлмәседер.

Жиһаз бик гади, ләкин яшәү өчен һәрнәрсә унайлы урнаштырылган. Өй хуҗасы, озынча ак йөзле, сирәк чәчле Виталий, түрдә, радиола ында утыра иде. Ул Ниаз белән күрешкәндә кулын җайсыз итеп тка сузды һәм бик итагатьле кеше икәнен күрсәтеп:

— Сезнең белән танышуыма бик шатмын,— диде.

Ә үзе шар ачык зәңгәр күзләрен каядыр почмакка төбәгән — италий дөм-сукыр иде.

Ишектәге чаршау тибрәлеп, аннан ялкын сирпелгәндәй җирән чәчле ш күренде, яңгыравыклы тавыш кунакка сәлам бирде дә кире юкка кты.

— Валя эштән кайтты гына әле,— диде Виталий.

Өй хуҗасы белән чагыштырганда Рифның тазалыгы аеруча күзгә шлана иде. Кыланышы да, модный киеме дә үзенә ятып, килешеп ора. Күпме генә күзәтсә дә, Ниаз аның чиертсәң кан чыгарлык чыраена, йомшак иреннәрендә, шаян күзләрендә шәфкатьсезлек яки вөҗдан азабы кебек нәрсәләрнең чагылышын күрә алмады.

Риф эшенә — «ТАЙ»дагы оркестрда уйнарга ашыга иде.

— Иртәгә Нателланың туган көне, син киләсеңдер бит? — диде ул Ниаз белән хушлашканда.

Ниаз икеләнде:

— Ул мине чакырмады бит!

— Туган көнгә чакырмыйча баралар. Слушай, кил әле! Анда адәми затларның бик кызык экземплярлары була. Хайваннар дөньясы! Зоопарк! Кил, слушай, онытма!

— Сез өстегезне салыгыз да түргә узыгыз,— диде Виталий Ниазга.— Хәзер Валя ашарга хәстәрләр, аңарчы берәр партия шахмат уйнарга була.

Ул радиола куелган өстәл тартмасыннан шахмат алды, аннары бүлмә уртасындагы түгәрәк аш өстәле янына килеп, искиткеч хәрәкәтчән куллары белән урындык аркасын эзләп тапты.

Ниаз шахматны тезәргә ашыкты, ләкин сукыр егет аннан җитезрәк булып чыкты: аның сул кулы такта өстендә йөри, ә уң кулы һәр фигураны үз урынына, тактадагы тишекләргә беркетә иде.

— Өйдә ялгыз утыру кыен,— диде ул.— Бу арада больничныйда әле мин. Бүген балалар концерт куя, мине Валя җибәрмәде. Нишләрләр инде.

— Үз балаларыгызмы?

— Андый байлык юк шул әле. Клубта баян түгәрәге җитәкли идем, шулар концерты.

Сигез-тугыз йөреш ясауга, Ниаз җиңеләчәген сизде. Ул берәр фигураны күчереп куюга, Виталий аны бармаклары белән эзләп таба да шунда ук үзе йөри. Бу дөм-сукыр адәмдә гади кешеләрдә булмый, аларны хәйран калдыра торган ике гаҗәеп сәләт бар иде: берсе — аның сизгерлеге, икенчесе — хәтере. Сукыр күзләр күңелдәге хисләрне чагылдырмый, аларга карап кешенең ни уйлаганын белеп булмый, шулай да Виталий Ниазда ышанычлы, нык, ихтыяры көчле кешедәй тәэсир калдырды.

Ниаз эчтән гаҗәпләнеп утырды: чыннан да бу сукырның Фидаилне һәлак итүгә берәр мөнәсәбәте бар микәнни? Бәлки, бик яхшы артисттыр ул?

Валя кояш кебек якты хатын икән.

Ул чаршау артыннан бизәкле поднос белән ризык алып чыкты.

— Ашагыз, аша,— диде Виталий, Ниазны кыстап.— Безнең Валя ашны тәмле пешерә.

Ниаз Виталийның, күзләре белән почмакка текәлгән хәлдә, бәрәңгене чәнечке белән түгел, кулы белән капшап ашаганына карамаска

тырышты, ләкин күрде, күрми булдыра алмады. Шундый сөйкемле кызның дөм-сукырга кияүгә чыгуы аның өчен аңлашылмас сер иде. Ә табында исә тату гаиләләрдә, бер-берсен яраткан кешеләр арасында гына була торган күңел күтәренкелеге хөкем сөрә иде.

Ниаз сүзне үзенә кирәк юнәлешкә бормакчы булып:

— Риф сезнең туганыгызмы әллә? — дип сорады.

— Туган ук түгел,— диде Валя, кинәт сулпәнләнеп.— Танышыбыз. Әле квартир тапканчы бездә торып тора... Сез чәйгә шикәрне салып эчәсезме, кабып кынамы?

Валя бик оста гына итеп сүзне икенчегә борып җибәрде. Ул Ниазның үзенә һәм Виталийга сәерсенебрәк караганын сизә иде, шуңа күрә иренең дәрәҗәсен күтәрергә тиеш тапты.

— Риф дөньяда җиңел яши. Эшенә дә бик ансат карый. Менә Виталий уйный башласа...

— Валюша, тагын бер ук сүз,— диде аңа ире шелтәле тавыш белән.— Риф теше төшкәнгә генә начар уйный. Сәләтле егет ул.

— Сәләттәмени эш, эчендә җаны булмагач.— Валя Ниазга таба борылды.— Кеше хис белән уйнамаса, музыкада ни мәгънә? Шулай бит?

Аннары хатын быел җәй Одессага барырга ниятләүләрен сөйләде. Виталий андагы күз дәвалау институтында бер тапкыр булып кайткан икән инде, өметләндереп җибәргәннәр икән.

— Ул, мәсәлән, янып торган лампочканың кайсы якта икәнен шәйли,— диде хатын горурланып.

Ниаз белән Виталий авылга бер атнадан барырга килештеләр.

## 13

Музыкада һәр нәрсә матур. Явызлык, дәһшәт, һәлакәт турында сөйләгән әсәрләрдә дә үзенчә бер тирән хис кузгатырлык көч бар. Сагыш та ләззәтле, кайгы-хәсрәт тә татлы музыкада.

Зөлфә бөтен барлыгы, рухы белән шул гүзәллек дөньясында, дөньяның җыерчыкларын, шадраларын шомартып, чистартып күрсәтә торган күзлек кигән кешедәй, хыялый хәятта яши иде.

Ләкин соңгы бер атнада булган вакыйгалар аның тынычлыгын җимерде. Ниаз Зөлфә янына беренче килүендә ук дөньяны бизәп күрсәтә торган тылсымлы күзлекне бәреп ваткандай итте. Баксаң, бәхетсезлек, фаҗига музыкант кыз тирәсендә дә бар икән. Шофер егет йогынтысы аркасында, ул күргән-ишеткәннәренә тәнкыйть күзе белән карый башлады, кешеләрнең язмышы, яшәүнең мәгънәсе турында тирәннәнрәк уйларга мәҗбүр булды.

Ул бу турыда теле белән сөйләп бирә алмас иде. Шуңа күрә бүген кич Ниаз килеп кергәч, аны залга чакырды, кәнәфигә утыртты да, үзе ялтырап торган көрән пианиносы янына килде. Уены белән ул Ниазга борчуларын, икеләнүләрен, шикләнүләрен аңлатырга теләде. Музыка аны юата, авыр уйлардан күңелен бушатырга ярдәм итә иде.

«Чын мәхәббәт кеше гомерендә бер генә килә»,— дип ышана иде Зөлфә. Тик соңгы көннәрдә аның күңеленә житди холыклы, үткен карашлы, туры сүзле, таләпчән Ниаз якын булып китте. Ә бит Зөлфә Атласка булган хисләрен чын мәхәббәт, гомерлеккә сөю дип уйлый иде.

...Үз эченә бикләнеп яшәргә күнеккәнгә, ул Атласка бер күрүдә гашыйк булмады. Пионер лагеренда танышкач, беренче айда аларның мөнәсәбәте гади танышлыктан узмады, Зөлфә егет күңелен үзенә җәлеп иткәнен дә сизмәде. Кичләрен, бала-чагаларны йоклаткач, во-

жатыйлар пионер бүлмәсенә җыелып, икенче көнгә план төзиләр, аннары бөтенесе бергәләп урманда йөргәлиләр иде.

Җылы, айлы кичләрнең берсендә, урман буенда Атлас Зөлфәне култыклап алды да читкәрәк тартты. Шул көннән алар лагерь вожатыйлары арасында тату, күркәм пар булып саналдылар.

Зөлфә Атласның игътибарлы, кайгыртучан, кешелекле булуы турында сөйләргә тели. Бер Зөлфәгә генә яхшы идемени ул? Башкаларның да хәленә керүчән, дустанә мөнәсәбәттә иде Атлас. Зөлфә шундый бер вакыйганы хәтерли: өлкән вожатыйның лагерьдан китүче балаларга бүләк алырга дип әзерләп куйган алтмыш сум акчасы югалган иде. Атлас кесәләрен актарды да бар булган байлыгын — бер унлык белән бер бишлекне өстәлгә китереп куйды: «Зөлфә белән икебездән»,— диде. Шунда ук Нателла биш сум чыгарды, калганнар да хәлләреннән килгәнчә булыштылар. Алтмыш сум ике минут эчендә җыелды...

...Ниаз кызның озын-нечкә муенына кара свитер сыланып торган тар иңнәренә, туп-туры аркасына карап тын гына утырды. Зөлфә әле чәчләрен җилпеп клавишаларга иелә, әле тураеп утыра, әле кулларын як-якка җәеп җибәрә иде. Ул куллар я моңлы-сагышлы, я дәртле авазларны клавишаларга басып түгел, сихри ишарә белән тудыралар кебек иде. Бу нәфис кызчык тылсым көченә ия, ул, пианино янына утыргач, кодрәт иясенә әверелә икән.

Дөресен әйткәндә, Ниазның музыканы аңлау ягы чамалы иде. Фортепьяно диганнәре аның өчен бигрәк тә аңлаешсыз булып, һәр аваз аерым яңгыраган кебек тоела, пианистның нинди көй уйнаганын аңлар өчен, бөтен дикъкатьне җыеп, көчәнеп тыңларга туры килә иде.

Әллә янында ук булганга инде, бу юлы Зөлфәнең уйнаганы аңа нык тәэсир итте. Күңелендә моңсу хис уянды, кемгә дә булса берәр яхшылык эшлисе, я берәрсен юатасы килде. Бу гүзәллек каршында Ниаз үзен көчсез, һөнәрсез, кечкенә кешедәй хис итте...

Йокы бүлмәсендә иренә хат язып утырган Гөлсинә апа да, кызының уйнавын тыңлап, ручкасын күтәргән хәлдә хәрәкәтсез калган иде. Урам яктан троллейбус, трамвайлар тавышы, машиналар гөрелтесе ишетелеп, көйнең агылышын бозалар. Әмма ана баласының кәефе нинди икәнен бармагы белән бер клавишага төртүдән үк белә. Бүген Зөлфә гомер булмаганча дулкынланып, ярсып, күз яше белән елагандай уйный иде. Ни булган аңа? Нинди борчу, нинди кайгы-хәсрәт килгән бала башына?

Гөлсинә апа залга чыгып, кызын кочаклап алырга, чәчләреннән сыйпарга, ничек тә серен сөйләтергә әзер иде инде, әмма кыңгырау тавышы аны алгы бүлмәгә чыгарга мәҗбүр итте.

Ишек төбендә торучы Атласны күргәч, ул йөзендәге канәгатьсезлеген яшерергә дә тырышмады. Гөлсинә апа гомумән бу шома егетне яратып бетерми, ул Зөлфәгә начар йогынты ясар, дип шикләнә иде. Шуңа күрә, кызының борчылуларына, мөгаен, Атлас сәбәпчедер, дип уйлап куйды. Гөлсинә апа өйдә кия торган чуар ефәк халаттан булса да, ак халат кигәндәй эре кыяфәт белән йөри, әйтерсең шул халат та аны башкалардан аерып тора, аның дәрәҗәсен күтәрә иде.

Атлас түбәнчелек белән хуҗа ханымга сәлам бирде дә, өйгә узарга рөхсәт алгач, өстен салды, чәчен тарау өчен көзгегә таба борылды, көзгедәге шәүләсенә күз кысып куйды. Без дә төшеп калганнардан түгел, ди иде аның бу кыланышы. Янында мәрмәр сын кебек чибәр кыз булса, өстәвенә шушылай җиһазланган квартирда торса, Атлас зуррак дәрәҗәгә ирешкәнче, күбрәккә хуҗа булганчы, бик ярап торачак.

Әмма Ниазны күргәч, Атлас келәм читенә сөрлекте. Кичәге бәрелештән соң алар бер-берсенә үч итеп килгәннәр иде.

Нателлага кызыл килешә икән. Челтәрле күлмәгеннән ак йөзенә алсу шәүлә төшкән. Ул, кара чәчен баш түбәсенә өеп, биек прическа ясаган, колакларына бөжра формасындагы алтын алкалар таккан. Кара белән кызыл — ут белән күмер...

— Әйтегез әле дөресен, мин чибәрме бүген? — ди ул Ниазга.

— Чибәр, бик чибәр. Ләкин чын дөресен үк әйтеп бетерергә рөхсәт булса...

— Рөхсәт, тик мине рәнҗетерлек булмасын.

— Мин сезгә сокланам. Ләкин, кызганычка каршы, артык ачык төсләрне мин авыр кичерәм. Күзем чагыла.

— О-о!

— Хәер, мин дә сезнең зәвыгыгызга туры килеп бетмим, шулай бит!

— Һа-а! Зирәк икәнсез!

— Котлыйм! Изге теләкләремне һәм кечкенә генә бүләгемне кабул итеп алыгыз!

Ниаз аңа «Гастроном» кибетеннән алынган кыйбатлы төргәкне сузды. Ал тасма белән бәйләнгән, целлофан белән төрелгән ул бүләк бер шешә аракы, бер шешә портвейн, фарфордан ясалган балерина сурәте һәм балык консервасыннан гыйбарәт иде. Тәҗрибәсез егетнең хатын-кызга мондый бүләк алуы бик табигый.

Залда кеше күп булганлыктан, әллә торшер уты гына янгангамы, гадәттәге шапшаклык сизелми иде. Беренче күзгә ташланган кешеләр — кияү белән кәләш кебек түр башында утыручы Зөлфә белән Атлас булды. Тәти егет киерелеп, кәнәфи аркасына терәлгән, сул беләген Зөлфәнең иңенә салган, Ниазның килеп кергәнен күрмәде дә шикелле, анда берниндн үзгәреш, хәрәкәт сизелмәде.

Ул арада Нателла Ниаз каршына таныш түгел парны китереп бастырган иде инде.

— Костя, якын дуслар өчен Котик.

— Люся.

Актан киенгән, ак чәчле, чытлык хатын кулын, үбәргә биргәндәй, аркасы белән сузды. Ниаз ул кулны шактый авырттырып кысты, әмма тегенең йөзендә елмаю галәмәте тамчы да үзгәрмәде.

Котик дигәне сыек гәүдәле, кечкенә башлы, кырынмаган адәм иде. Вельвет чалбары да, йон свитеры да иске, керле күренә. Шактый ук исерек, ахры, Ниазга аракы пары өреп:

— Андыйларны күргән бар,— дип куйды.

Головин аның турында, җинаятьче өчен гадәти биография, дигән иде. Эчкече ата, караусыз үскән бала, урам тәрбиясе, хулиганнар компаниясе, колония. Белеме — җиде класс, колониядән алып кайткан һөнәре — слесарьлык. Хәзергә заводта эшли, ярамаган эш кылганы әлегә сизелми.

Нателла Ниазны Зөлфәләр янына илтмәкче иде, егет:

— Без таныш инде,— диде.

— Но-о! Бүген үлсәм белми калган булыр идем.

Телекомбайннан дәртле тавыш «Шейх! Шейх!» дип кычкыра башлады. Костя Люсяны биленнән эләктереп алды:

— Әйдә, биибез!

Ниаз килеп керүгә, Зөлфә оялуыннан бөтен тәне белән тетрәнеп куйды. Ул болай да бик уңайсызланып утыра иде: икәүдән-икәү генә чакта итагатьле, тәртипле күренгән Атлас шушы кешеләр арасына килеп керү белән алыштырып куйгандай үзгәрә, әрсезләнә, тупаслана — һич тартынусыз теләнә ни кылса, шуны сөйли, Зөлфәнең башын каерып, ят күзләр алдында үбә, кызның үзенеке икәнен гел сиздереп тора иде. Егетнең бу кыланышлары кызның нечкә күңелен рәнҗетә, пычрата, тик

ул, Атласны кеше алдында кимсетергә теләмәгәнлектән, барысына да төшен кысып түзә иде. Аның бөрешкән кыяфәтен күрүгә, Ниазда кызны исерек егет кочагыннан тартып алу теләге уянды. Ләкин Зөлфә үзе Атласның беләген иненнән алып ташлады да кухняга кереп китте.

— Ни булды, кәефең юкмы әллә? — дип сорады Нателла, аның артыннан кереп.

Зөлфә, күз яшьләренә буылып:

— Уңайсыз миңа, оят! — диде.

— Һа-а! Таптың оят! Нәрсәсе оят? Үз егетең янында утырумы? Монда оялырлык кеше дә юк. Бар да дөнья күргән егетләр. Мин үзем дә шундый!

«Ә мин андый түгел! Түгел!» — дип кычкырасы килде Зөлфәнең, тик телен әйләндерә алмады, хуҗа хатынның кәефен җимерүдән курыкты. Нателла аны йомшак кына итеп иңнәреннән кочып алды, иплән кенә бүлмәгә кире алып чыкты, Атлас янына илтеп утыртты.

— Көйсезләнмә. Компаниянең ямен җибәрәсең... Егетләр, кызлар! — диде ул, бокал күтәреп.— Соңга калып килгән кеше штрафной эчәргә тиеш! Әйдәгез, Ниаз, күтәрегез әле, минем исәнлеккә. Ягез, я. Миңа бәхет теләмисезмени?

Ниаз маңгаена төшкән чәчләрен артка сыпырырга азапланды.

— Бик телим. Тик эчә алмыйм. Иртәгә сәгать биштә сменага чыгасы бар.

— Тамчы да эчмисезмени?

— Аракының исе иртәнгә чаклы бетмәс.

— Ә-ә-ә, сезгә коньяк кирәкмени? — диде Нателла.

— Ю-ук. Менә сухой вино булса...

— Сухой юк шул.

— Атлас йөгереп кенә барып килсен,— диде шунда Риф.

Бар да гаҗәпләнеп аңа карадылар.

— Нишләп Атлас йөгерергә тиеш? — дип сорады Зөлфә.

— Нателла эшләгән акчаны барып алырга иренми бит әле.

Бу шаяруны аңламадылар, берәү дә көлмәде. Ә Риф үзе тыела алмый шаркылдый иде.

— Син, Натка, мине күрмәде дип уйлыйсыңдыр... Ышаныч кәгазең өстәлдә ята иде бит. Эх, сез, сер саклый белмисез!

— Ташла, Риф! — диде Атлас.— Кешегә эчәргә ирек бирмисең. Тот бокалыңны.

Өстәлдә юньле ризык юк икән. Ниаз эчмәде, бер телем колбаса гына чәйнәде.

Котикка аракысы булгач житкән, теш арасына кыстырыр әйбер дә кирәкми. Ул Люсяны изалаудан туктаган, борын эченнән французча «О Париж, о Париж!» дип мырылдый-мырылдый, ялгызы боргалана. Люся пластинкалар актара. Атлас Зөлфәне кысып кочаклап, биегән булып азаплана. Марсик та аяк астында чуала икән, Нателла аңа:

— Улым, мә, конфет суыр! — ди.

— Прә-ни-ек кирәк! — дип шыңшый малай.

— Прәннек юк бит, әнә сыр аша!

— Хайваннар оясы шушымыни? — дип сорады Ниаз янында утырган Рифтан.

— Ә син кара, кара! — Риф башын артка ташлады, тик торшер калфагына бәрелде.— Төртешмә! — диде ул торшерга.— Хәзерге минутларда без җир өстендә түгел, брат. Су асты дөньясын күзәтәбез.— Бүлмә ярым караңгы, һавада дулкын-дулкын тәмәке төтене йөзеп йөри. Чыннан да, үзенне сәер мохиттә итеп тоясың. Риф, чыраена акыллы кыяфәт чыгарып, фәлсәфәгә бирелде.— Әнә Люся — суда йөзгән медуза кебек. Төссез, файдасыз җан иясе. Әйе, бернәрсәгә яраксыз адәм балалары бар шул бездә. Бу медуза суда череп таркалган калдыклар белән

туклана. Аны теләсәң тотып алырга, теләсәң тотып кыйнарга мөмкин — бернәрсә дә сизми ул. Ә аның Котигы — оясындагы кысла кебек. Ул да ялкау, ул да файдасыз, тик оясыннан кыскычларын чыгарып куйган. Үткән-сүткән вак-төяк җан ияләрен эләктерергә генә тора. Нателла исә бөтенләй башка җан иясе. Алар Атлас белән бик пар килгәннәр — буйсыннары, холыклары бер төрле, бер үк аллага табыналар. Тик алар бер-берсен ярата алмыйлар, чөнки үз-үзләрен ихтирам итмиләр.

— Алар су асты дөньясыннан түгелмени?

— Сабыр ит. Су төбендә бик матур чәчәккә охшаган тереклек ияләре бар. Актиния дип атала ул. Алар су агышына буйсынып бик матур чайкала. Тик ул чәчәк түгел, ерткыч хайван. Аның авызына эләккән балык эреп юкка чыга. Нателла — актиния. Ә Зөлфәнең кавалеры — крокодил...

Атлас, башын күтәреп, терсәгеннән чак кына калку Зөлфәне зырзыр үз тирәсендә бөтерә. Үзенә чиксез нәфрәт белән текәлгән Ниазны күрми дә кебек. «Ник яратмыйм мин аны? — дип уйлый Ниаз.— Миңа ошаган кызны ул да яраткан өченме? Юк, әлегә бу күсәк белән бәйләнергә ярамый. Башта җинаятьчене табыйк, аннары!..»

— Ә Зөлфә, синеңчә, алтын балыкмы? — дип сорады ул Рифтан.

— Юк, ул әле су астына төшмәгән. Төшмәс тә. Ул бичара, бу сасык күлдә нинди ерткычлар яшәгәнен белмичә, су ялтыравыгына кызыгып килгән килбәтсез үрдәк бәбкәсе. Үсеп җитсә, мәгъруp аккош булыр иде, тик аны менә шушы крокодил йотачак.

— Ә син үзең?

— Мин күл өстендә яткан төнбоек яфрагы кебек — барысын күрәм, беләм, сизәм, ләкин ни дә булса эшләүне кирәк санамыйм. Нигә катышырга? Әйдә, барсын үз көенә, һәркемнең үз язмышы.

— Ул күлдә миңа нинди урын бирәсең инде син? Үз яныңнанмы?

— Юк, бу күлдә сиңа урын юк,— диде Риф, аның күзләренә уртагандай карап.— Син карчыгага охшагансың, сугыша башларсың кебек. Ну, брат, чукыйсың инде син боларны, ә!

— Ничек чукыйм мин аларны? Карчыга күлдәге җәнлекләрне күрә алмый, чөнки аларны төнбоек яфраклары каплаган ич!

— Һа-а, егетләр, егетләр! — диде Нателла.— Ни серләшәсез сез? Бүген бөтен игътибар миңа булырга тиеш. Күтәрик әле бокалларны!

— Эчегез, миңа карамагыз,— диде Ниаз.— Эшкә чыгасы булмаса, мин дә сездән калышмас идем. Авыз суларым килеп тора.

Һич көтмәгәндә Атлас аның белән килеште:

— Махмырлаган баш белән уникe сәгать машина йөртү кыен шул.

— Ундурт! — дип төзәтте Ниаз.— Ике сәгать төшке ашка бирелә.

Ул борылып Зөлфәгә карады. Зөлфә озын, нәфис бармаклары белән тулы бокалны «тәпиеннән» тоткан иде. Ниаз ул бармакларның тылсымлы көчен, ул куллар талпынуыннан туган серле моңнарны исенә төшерде. «Килбәтсез үрдәк бәбкәсе түгел син, сукыр бер адәм син,— дип уйлады егет.— Шул пианино янында гына чын кеше син, ә тормышта, сукыр Виталийны җитәкләп йөрткән кебек, кулыңнан тотып йөртергә кирәк сине».

Ә Атлас Нателла белән нидер сөйләшә, әллә чыннан да Ниаз өчен «коры шәрабка» йөгермәкче булды микән? Ну, кызык булыр иде.

Ниаз игътибар үзәгеннән ычкынуына сөенеп, алгы бүлмәгә тәмәке тартырга чыкты. Шау-шудан, Рифның фәлсәфәсеннән бераз арынып торасы килде.

Ләкин монда да тынгылык булмады, Нателла килеп чыкты:

— Нишләп ялгыз торасыз? Күңелсезмени? Әйдәгез, чәй кайнатыйк!

Кухняда, чәй куйгач, парлап сигарет кабыздылар. Тәмәке төтененә карап, һәрберсе үз уйларына чумды. Нателлага уйчанлык килешә икән,

ул яшь, чибәр күренә, керфекләреннән төшкән күләгәдә күзләре серле ялтырый иде. Озын, төз гәүдә, нечкә бил. Кызыл сабаклы кара чәчәк.

— Мена тагын бер елга картайдым,— диде Нателла.— Алдагы көннәр ни китерер... Белеп булмый. Алга килми белеп булмый башның ни күрәчәген.— Ул, төтен бөҗраларына карап, көрсенеп куйды.— Берәүләр бәйрәм итә, икенчеләр җан бирә. Минем бер танышым бар иде, таксист. Күптән түгел аны үтерделәр. Ә мин ул көнне бик күңелле уздырдым. Кичтән без Зөлфә белән икәү театрга бардык. Аннан чыккач «ТАИ»га кердем, Риф янына. Ашадык, эчтек, күңел ачтык, сәгать беренче яртыга кадәр ресторанда утырдык. Танышымның үлгәнен кичә генә белдем. Без җан биргәндә дә кайбер дусларыбыз күңел ачарлар. Монда аларның гаебе дә булмас. Шулай бит?

Ниаз тынычлыгын сакларга тырышып, сигаретын суырды, күзләрен кысып Нателлага текәлде. Кызыл сабаклы кара гөлнең чәнечкеләре агулы икән бит! Ул алиби[1] китерә түгелме соң? Үзенә генә түгел, Рифка да бик ышанычлы алиби китерә! Фидаилне үтергән төнне алар икесе дә ресторанда, дистәләрчә күз алдында булганнар.

Шулай ук бу хатын Ниазның кем икәнен белә микәнни? Каян белә ул аны? Юри сөйлиме бу сүзне, әллә аны-моны уйламыйча, очраклы рәвештәме?

Нателла түшәмгә таба күтәрелгән зәңгәр төтен җепләренә карап, моңсу кыяфәт белән басып тора. Тик күзләре генә елтырамый, кара пәрдә коргандай тоныкланган. Ниаз ни дияргә белми аптыраган иде. Бәхеткә каршы, аны уңайсыз хәлдән Люся коткарды — тавыш-тынсыз, кинәт килеп керде дә:

— Ә-ә, сез мондамыни? — диде.— Безгә дигән чәйне эчеп бетерә күрмәгез. Натка, нәрсәгә сөмсерең коелды?

Ниаз, иртәгә иртүк эшкә чыгасын әйтеп, саубуллашырга керешә.

— Яши белмисең,— диде аңа Риф.— Менә мин тамак авыртканга белешмә алдым да эшкә бармадым. Виталийның ангинасы йокты миңа.

Ниаз чыгып троллейбуска утырды. «Юкка вакыт уздырып йөрим, ахрысы,— дип уйлады ул.— Ярый әле, монда килгәнемне тикшерүче белмәде». Ул, Головин кайтуга, аның янына барып, Нателла һәм аның компаниясе янына башка йөрмәячәген әйтергә булды. Тик Зөлфә белән генә араны өзү кызганыч.

Ул Ленинград тукталышында троллейбустан төшеп, үз йортына таба җәяү китте. Урам буш, караңгы, вакыт соң булганга, машиналар да сирәк уза иде. Әгәр ул артына борылып караса, үзеннән илле адым арттарак шулай ук җәяү килгән икенче берәүне күрер иде. Ниаз өенә кереп китгач, әлеге кеше тукталды, кинәт яктырган тәрәзәләргә карап, шактый озак басып торды, бары өйдә ут сүнгәч кенә, кире троллейбус тукталышына таба китеп барды.

## 15

Гараж капкасы янындагы таблога: «Бозлавык, томан»,— дип язылган. Җиңенә кызыл тасма бәйләгән ГАИ инспекторы белән дежур механик линиягә чыгарыр алдыннан күк «Волга»ны тикшерәләр.

— Уңга борылыш! Сулга борылыш! — ди механик Ниазга.— Зур фаралар, кечкенә фаралар!

Аның кушканын үтәп, шофер рульне уңга-сулга боргалый, әле бер утны, әле икенчесен кабыза, тормозларга баса. Инспектор белән механик, зур фонарь тотып, машина тирәсендә йөриләр, чүгәләп тәгәрмәчләрне карыйлар. Бик тырышып эзләгәч, «Волга»ның җитешсезлекләрен

[1] Җинаятьтә гаепләнүче кешенең җинаять эшләгән урында булмавы.

табып булыр, дип уйлый Нияз. Фидаил булса, машинаның һәр какшаган жирен алдан ук күреп, төзәтеп, һәр тузан бөртеген сөртеп-чистартып торыр иде.

Бу юлы «Волга»ның ватык жире табылмады. Аның алгы тәрәзәсенә: «Машина гаражга унтугыз сәгатьтә әйләнеп кайтырга тиеш»,— дип язылган катыргы куйдылар. Механик, чыгарга рөхсәт биреп, кулын болгады.

Машина сөткә чумгандай күгелжем томан эченә кереп китте. Төн караңгы, зур фараларның утлары да, томанны без белән тишкәндәй, юлны начар яктырталар иде.

Иртәнге якта пассажирлар әз булды, күп вакытны Телестудия янындагы тукталышта уздырырга туры килде. Шоферлар — көтәргә күнеккән халык. Нияз да яктырганны сабыр гына көтеп алды. Көн яктысы жиргә таман аша саркып, бик әкрен төште. Ләкин сәгать сигезләргә таман тизлек белән агара, сирәгәя башлады һәм ак сыкы булып агач ботакларына, тимер чыбыкларга, керләнгән карга сарды. Дөнья чистарды, һава корыланды, юылгандай ачык зәңгәр күк йөзе күренде. Кәеф яхшырды, уйлар яктырды, күңелдә өмет, ышаныч хисләре кабынды.

Якшәмбе көн булганга, пассажирлар күп иде. Ниязга бер генә минут та тик торырга туры килмәде. Машина тәгәрмәченә асфальт юл чорнала — шоферның башында бер үк уй урала.

Барлык жепләр Рифка илтә иде. Ләкин, әгәр ул тешсез егет чыннан да сәгать бергә кадәр ресторанда утырган икән, аның Фидаилгә кусәк күтәргән булуы мөмкин түгел. Чөнки мәрхүмне унике тирәләрендә үтергәннәр — врачлар да шулай дигән, кара акыл белән уйласаң да шулай; шофер исән булса, төн уртасына паркка кайтыр иде. Ә Нияз, жинаятьче — Нателла тирәсеннән табылыр, дип ышанган иде. Ул хатын Фидаилгә шалтыраткан, аны сменасын алыштырырга мәҗбүр иткән. Кем өчен? Ник? Нияз бу сорауларга үзе белгәннәрдән чыгып та җавап бирергә мөмкин икәнен сизә. Тик барысын да бер тәртипкә куеп, бер жепкә генә тезеп бетерә алмый иде.

Ул билгеләнгән сәгатьтә гаражга кайтты, аннан җәяү генә Гагарин тукталышына чыкты да беренче троллейбуска утырды. Үз уйларына чумган иде, артына борылып карамады. Хәер, караса да мотоцикл этеп килүчегә игътибар итмәс иде, күрсә дә шикләнмәс иде. Ә теге кеше урамның икенче ягыннан аның троллейбуска утырганын күзәтеп торды, моңарчы ватылгандай сөйрәп килгән мотоциклына менеп атланды. Мотоциклы кеше троллейбусны узмады, тукталыш саен аның артында торды. Троллейбус тәрәзәләре бозланып каткан булганга, аңа берәү дә игътибар итмәде.

Нияз Ленинград урамы тукталышында троллейбустан төште, шактый вакыт тар урамнар буйлап баргач, киң, тыныч урамга килеп чыкты. Бер-берсенә якын салынган биек йортлар арасында сизелмәгән генә, ачык урында каршы жил шактый көчле исә, җәяүле буран себерә икән. Нияз кыска тунының якасын күтәреп куйды да, киез ботинкалары белән машина юлының шомарган бозына жай гына басып, үз көенә атлады. Сул якта — бакчалар, унда — биек койма белән әйләндереп алынган ишегалларында ике генә гаиләлек йортлар. Юлда адәм заты юк. Сирәк очраган зур-зур йөк машиналары яман үкереп, фаралары белән күзне сукырайтып узып китәләр. Ул артыннан төчкерә-төчкерә тырылдап килгән мотоцикл тавышын еракган ук ишетте. «Тагын бер тере мәет,— дип уйлады Нияз мотоциклист турында.— Караңгы диме, бозлавык диме — чабуын белә». Шофер гадәте буенча, мотоциклардан сакланырга күнеккәнгә, ул юл кырыенарак чыкты да, машина эзе булмаса да, жил белән, кар белән ышкылып шомарган бозлы урыннан бара башлады. Аның алдына фара яктысыннан озын күләгәсе төште. Күләгә башта соры гына булса да, торган саен карала, ачыклана бар-

ды. Әллә шул күләгәнең уңга тайпыласы урында нәкъ алдына ятуымы, әллә моторның нәкъ җилкә турысында үкерүеме сискәндерде Ниазны, ул атылган туп кебек кырыйга сикерде — мотоцикл ерткыч җанвардай үкереп, сасы төтен бөркеп, тәгәрмәч астыннан кар сибеп, узып китте. «Исерек! — дип уйлады Ниаз ачу белән.— Үләсен белми, хайван». Ул тагын юлга чыкты, мотоциклның ерак та китми кире борылуын күреп, бер мәлгә сәерсенеп куйды. Ләкин аждаһа авызыннан бөркелгән уттай фара аның күзләрен сукырайтып өстенә килә башлагач, шунда ук аңлап алды: бу мотоциклда аның үлеме иде. Бу аулак юлда булган фаҗигане беркем күрмәячәк. Бәреп егып эшне бетерер дә берәр көрткә тыгып китәр... Җәяүле буран кар өстен шомартып та куяр. Эт белән эзләп тә таба алмаслар — машина тәгәрмәчләре аның эзләрен таптап, резина исе сеңдергән булыр... Мотоциклда исерек түгел, шәфкатьсез дошман утыра иде.

Бу уйлар Ниаз башыннан яшен тизлеге белән йөгереп үттеләр. Дошманның ниятен аңлауга, аның күңеле тынычланып киткәндәй булды, тәне пружинадай кысылды. Вакыт әз иде — ул кулларын тун кесәләренә тыкты — бөгәрләнеп беткән кулъяулык белән бер бәйләм ачкычтан гайре берни юк икән. Ниаз уң кулына ачкычларны йомарлап тотты. «Кил әйдә, кил! — дип уйлады ул мотоциклда утыручыга.— Тик кем белән эш иткәнеңне белеп кил!»

Дошман караңгыда, ә Ниаз уч төбендәге кебек яктыда иде. Шуңа күрә шофер дулкынланганын белдермәскә тырышты, әйтерсең ул берни сизми, үз юлы белән үз җаена атлап бара. Инде мотоцикл аны фара яктысына эләккән куян кебек сукырайтып таптап китте дигәндә, Ниаз яшен тизлеге белән сулга атылды, шул ук вакытта уң кулы белән дошманына кизәнде. Каты эләктерә алмады, бармак араларыннан тырпаеп торган ачкычы белән сыдырып кына калды. Сизгерлеге көчәйгән иде Ниазның — күзләре чагылган булуга карамастан, ул мотоциклда утыручыны таныды.

Шул минутта шәһәр ягыннан машина килгәне күренде. Мотоциклчы борылды да зур тизлек белән поселокка таба китте.

Машина Ниаз янында туктады, аннан Головин чыкты:

— Син нишләп биредә торасың?

— Әнә, Фидаилне үтергән кеше мотоцикл белән китеп бара,— диде Ниаз.

Озак та үтми, җәяүле буран юлдагы эзләрне себереп, шомартып куйды.

## 16

Ишекне ачуга, Зөлфә аның дөнья җимерелердәй куркыныч, аяусыз хәбәр әйтәсен аңлады. Менә хәзер ул авызын ачачак һәм агулы ук кебек сүзләрен Зөлфәнең йөрәгенә кадаячак.

Ниаз аның хәлен аңлады, шуңа күрә чын дөресен туп-туры әйтә алмады.

— Син бернәрсә дә белмисеңмени әле?

— Юк. Ни булды? — дип сорады Зөлфә тавышсыз, иреннәре белән генә.

— Ул эләкте,— дип җавап бирде Ниаз.

Зөлфә «кем?» дип сорамады. Ишегенә япты да ашыгып киенә башлады: «Юк, юк, ялган сөйли Ниаз, ялган сөйли! Хәзер үзем барып күрәм дә дөресен беләм».

Ул өеннән чыкты да Восстание урамына йөгерде.

Ерактан ук күрде — Нателланың тәрәзәләрендә ут юк иде. Зөлфә дүртенче троллейбуска утырды, уйсыз-фикерсез миңгерәп Бауман ура-

мына чаклы килеп җитте, сулышы кысылып, үргә каршы йөгерде. Ленин урамындагы таныш йортка килеп керде. Кыңгырау шалтыратуга ишек артыннан чаштыр-чоштыр килгән тавыш ишетелде. Ишекне бөрешкән карт — Люсяның әтисе ачты.

— Люся өйдәме?

— Узыгыз, керегез, хәерле кич! — дип мыгырданды карт.

Зөлфә коридорга кереп, пәрдәләр арасыннан бүлмә эченә карады. Түрдә, тимер караватта, мендәрләргә аркасын терәп, Аделаида китап укып утыра. Ул кабарынкы күз кабаклары арасыннан Зөлфәгә, мин барын да беләм инде, дигәндәй караш ташлады да тагын китабына иелде.

— Ә Люся кайда? — диде Зөлфә аптырап.

Кунакчыл карт аңа урындык тәкъдим итте:

— Утырыгыз. Юк бит Люся, китте.

Картның бөрешкән авызыннан сүзләр изелеп, сытылып чыга сыман иде.

— Кайчан кайта соң ул?

— Анысын әйтмәде. Барган җиреннән хәбәр итәрмен, диде. Менә инде,— диде карт аптырап.— Олыгайган көнемдә тагын ялгыз калдым, тагын кулымда кыз бала!

— Ничек алай тиз китәргә ниятләде соң әле ул? Мин аны кичә генә күрдем, ул бит бер сүз дә әйтмәгән иде.

— Ул инде атна чамасы, бәлки, китәрмен дә әле, дип йөри иде. Бүген иртән җыенды да чыгып китте. Билеты да юк иде бугай. Хәер, хәзер самолетка билет иркен бит.

— Ә минем күлмәкне кая куйды икән?

Карт, белмим шул дигәндәй, кулларын җәйде.

Зөлфә Нателланың: «Картның үлгәнен генә көтәләр, өйләнешәчәкләр»,— дигән сүзләрен исенә төшерде. Өйләнешә алмадылар, ә карт һаман яши, һаман кирәк әле...

Димәк, Люся киткән. Кем соң хәзер Атласны эзләп табарга ярдәм итәр? Зөлфә егетнең кайда торганын да белми, чөнки гомерендә аның бусагасын атлап кергәне юк, үзеннән адресын сорарга башына да килмәгән иде. Менә хәзер кем ярдәм итәр аңа Атласны табарга?

Риф! Риф! Ул белергә тиеш аны. Зөлфә абына-сөртенә таудан түбән ашханәгә таба йөгерде.

Гардеробтагы карт аның туны белән бүреген алмый аптыратты. «Урын юк!» — диде ул кырт кисеп.— «Бик күрәсе кешем бар иде, зинһар, абый, алыгыз инде»,— дип ялынгач кына, карт: «Юньле кыз бала кирәк кешесен кара төн җиткәч рестораннан эзләп йөрми»,— дип мыгырдана-мыгырдана тун белән бүрекне алып элде дә Зөлфәгә ак пластмасса номер бирде.

Зөлфәнең бу ресторанга икенче генә керүе иде. Бетон белән пыяладан төзелгән бу бинада ашханә ачылуга, алар, әти-әнисе белән өчәүләп, кунакка җыенгандай матур киенеп, төшке аш ашарга килгәннәр иде. Ул чакта Зөлфә үзен чын мәгънәсендә кадерле кунак итеп сизгән иде. Зал иркен, матур, кара-кучкыл агач стеналарга сары җиз тасмалардан урап сурәтләр ясалган. Зөлфәгә бигрәк тә «Былтыр» һәм «Алтынчәч» картиналары ошаган иде.

Җилфердәп торган ак пәрдәләргә Казан күренешләре төшерелгән. Ак чигешле алсу күлмәк кигән яшь, чибәр официанткалар итне дә үтүкләп торган тәлинкәләргә куелган аяклы табаларда китерәләр. Ашъяулыклар шома, ак, озын аяклы фужерлар елтырый иде.

Бүген баскычтан менүгә Зөлфә хәйран калды. Хәтта шундый хозурлыкның да бөтен ямен җимереп, пычратып була икән. Башны миңгерәтә торган шау-шу, тәмәке төтене. Өстәл араларында кызарынган-бүртенгән парлар таптана — бииләр.

Зөлфә залның аргы башына, оркестр янына узарга җай тапмый туктап калды. Буш калган өстәлләрдәге тапланып беткән ашъяулыкларда, тәлинкәләрдә ризык калдыклары, ипи сыныклары, тәмәке төпчекләре ауный. Аракы исе, тәмәке төтене кызның сулышына каба, хәтта крепдешин пәрдәләргә дә шакшылык сеңгән кебек иде. Зөлфәнең каршына күк костюм кигән исерек егет килеп басты да:

— Рөхсәт итегез! — дип кулын сузды.

— Юк, юк! — дип стенага сыенды Зөлфә. Әмма егетнең һаман урыныннан кузгалмыйча, каршында басып торуын күргәч, кинәт тәвәккәлләде: исерекне әйләнеп узды да, биючеләрне аралап, залның түренә китте.

Оркестрның уртасында электр утында күзләрне камаштырып елтыраган саксофонын тотып, Риф утыра. Беркайчан да әле Зөлфәнең аны күреп бу кадәр сөенгәне юк иде. Риф залдагы хикмәтләргә исе дә китмәгән кыяфәт белән, болай да тулы яңакларын бүлтәйтеп, саксофонына өрә. Зөлфәне күргәч, ул күзләре белән елмаеп, керфекләрен кагып, сәламләгәнен белдерде.

Оркестр дәртле көй уйный:

> **Гөлчирәкәй, Гөлчирәкәй,**
> **Зарыктым бер күрергә.**
> **Сандугачны почта итик,**
> **Почта итик**
> **Арабызда йөрергә.**

Карашы ачулы, кыяфәте талчыккан официант тәлинкәләр өеме белән Зөлфәне төртеп узды.

Менә оркестр уйнаудан туктады, Риф шат елмаеп Зөлфә янына төште.

— Килбәтсез үрдәк бәбкәсе,— диде ул тешсез авызын ерып.— Менә көтелмәгән кунак. Хәзер банкет залына алып кереп сыйлыйм мин сине.— Ул узып барган официанткага дәште:— Бик кадерле кунак килде. Банкет залына иң тәмлесен...

— Бер-ике порция ит тапсам гына инде,— диде официантка.

Банкет залы буш иде. Стеналары аллы-гөлле чигешле ак күн белән тышланган. Барысы да бик бай, патша сараендагыча мул. Тик боларның берсе дә Зөлфә күзенә күренмәде. Ул ашыга иде.

— Риф,— диде ул, егетнең күзләренә карап.— Син Атласны күрмәдеңме?

— Ах, ташла әле шуны! Котылганыңа сөен!

Зөлфәнең куркынганы йөзенә бәреп чыкты:

— Нишләп котылганыңа дисең? Ни булды?

Ул арада официантка пар бөркеп торган ике тәлинкә итле бәрәңге, бер шешә шәраб китерде. Риф зур бокалларга шәраб койды:

— Ә син белмисеңмени?

— Нәрсәне?

— Син алар белән шактый якыннан аралашасың бит. Нателла, Котик, Люси, Атлас,— алар нинди акчага типтерә дип беләсең? Миндә нәрсә, миндә иммунитет бар. Ә сиңа ул шайка-лейкадан ераграк булырга кирәк иде.

Атлас турында әйтелгән начар сүзләр Зөлфәне мыскыллый, рәнҗетә иде. Кыз бокалны читкә этеп, урыныннан торды:

— Минем сиңа үтенечем бер генә, Риф. Миңа Атласның адресын бир.

— Әйдә, бу бокалны гына күтәрик инде!

Зөлфә ишеккә юнәлде. Риф аның артыннан куып житте дә беләгеннән тотты:

— Назлы кызларны җенем сөйми! Синең капризларыңа да көчкә

түзеп торам! Мин Атласның адресын белмим, бусагасын атлаганым юк. Аны Виталий беләдер. Ул якын гына тора, кереп чык.
— Теге баянист Виталиймы?
— Шул үзе. Кер, аннан сора. Валя да өйдә хәзер.
— Озат мине...
— Сыйланмыйсың инде, алайса? — Риф Зөлфәнең хәлен хәзер генә аңлагандай карады, аяк өсте генә үз бокалын күтәреп эчте дә официантканы чакырды:— Җый әле боларны.
Ул Зөлфәне култыклап баскычтан төшерде. Читтән караганда гашыйклар кебек — икесе дә яшь, пөхтә, соңгы мода белән киенгәннәр.
Риф Зөлфәнең пальтосын кидергәндә:
— Турысын гына әйткәндә, мин сиңа беркая да барырга киңәш итмәс идем,— диде,— өеңә кайт та тик кенә утыр,— иң яхшысы шул.
Зөлфә, аның үгет-нәсихәтен тыңлап та бетермичә, пыяла ишекне ачып, урамга чыкты. Ә Риф башын чайкады да, гадәттәгечә авызын ерып, ресторанга, саксофонын кычкыртырга менеп китте.
...Валя чәч юып азаплана икән. Зөлфәгә ишек ачканда, ул сул кулы белән җирән кедрәләрен баш түбәсенә өеп тоткан, алсуланган яңаклары буйлап сабынлы су агып төшкән иде.
— Ишек ачык бит! — диде ул, оялчан елмаеп.— Ах, Зөлфә! Нинди җилләр сине ташлады?
— Исәнме, Валя, йомышым төште бит әле.
— Виталенька, Зөлфә килде!
Валя чуар пәрдә эленгән ишектән эчке бүлмәгә кереп китте.
— Сәлам, Зөлфә, бирегә уз,— диде Виталий.— Ни хәлләрең бар? Үсеп буламы?
Зөлфәнең артык озак сөйләшеп торасы килми иде. Шулай да ул ашык-пошык йомышын әйтергә яхшысынмады, Валяның чыкканын көтте, Виталийның сорауларына күңелсез генә җавап бирде. Нинди мәгънәсез хәлдә иде Зөлфә! Иң якын кешесенең, сөйгәненең кайда яшәвен чит кешеләрдән, әллә кемнәрдән сорашып йөри! Нишләп алай булды соң әле? Ник килде ул бирегә? Саташу гынадыр ла бу!
Чуар пәрдә артыннан Валя килеп чыкты. Ак сөлге фонында аның битендәге сипкелләр аеруча чекерәеп күренә иде.
— Ничек безне исеңә төшердең әле? — диде Зөлфәгә, кояш кебек балкып.
— Миңа... Атласның адресы кирәк иде,— диде Зөлфә.— Риф, аның кайда торганын сез беләсез, диде.
Валяның да йөзе бердән җитдиләнде.
— Шулаймыни?
Валя кулларын күкрәгенә кушырып, аның каршына килеп басты, әйтерсең ул ниндидер зур гаебе өчен кызны җавапка тартырга җыена иде.
Зөлфә күзләрен Виталийга, дөресрәге, аның сеңерләре бүлтәеп торган сөякчел, нервлы, хәрәкәтчән кулларына күчерде. Ул куллар астында хәреф урынына төрткеләр ясалган сукырлар китабы ята иде.
Сүзне Валя башлады:
— Ә син үзең аның кайда яшәгәнен белмисеңмени?
— Юк шул,— диде Зөлфә.
— Без сезне якын дуслар дип уйлаган идек. Синдә аның адресы бармы соң?
Валя иреннең исемен әйтеп тә тормады, соңгы җөмләне якын итеп, үз итеп әйтүе белән генә иренә дәшкәнен аңлатты.
— Барын бар да...— диде Виталий.— Минем дә аларга барганым юк. Үзе бер килгәч, авылдан мотицикл алып булмасмы икән, синең танышларың бар бугай, дип, булса хәбәр итәр өчен генә адресын әйткән иде.

Валя алтын төсле сары кашларын җыерып, Зөлфәгә текәлде.

— Яшь әле син. Яхшы кыз үзең. Тыңла сүзебезне, инде югалткансың икән, эзләмә син ул егетне... Шулай бит? — диде ул, тагын тавышын үзгәртеп.

— Әлбәттә, Валюша. Без аңа дөресен әйттик.

— Безгә ул башта ук ошамады,— диде Валя.— Әнә Виталий кешенең кемлеген бер сүзеннән сизә.

— Анысы мин ялгышырмын да,— диде Виталий, хатынының сүзенә йомшак кына каршы төшеп.— Тик бу юлы безнең сизенү дөрескә чыкты. Ул... бәлагә тарган булса кирәк.

Зөлфә тагын егетен яклады:

— Алай булгач, бигрәк тә мин аны эзләп табарга тиеш. Бәлагә таргач кына дусны оныталармыни? Синең белән берәр хәл булса, хатының ташламас иде бит?

Валя беркатлы бала-чагадан мәзәк сүз ишеткәндәй елмайды:

— Без икенче мәсьәлә... Син бит аның хатыны түгел. Һәм була да күрмә. Без сиңа дөресен әйттек, калганы синең үз эшең. Бир адресын, Виталенька...

Валя Зөлфәне чын күңелдән кызганып, ярдәм кулы суза алмавына офтанып, шул ук вакытта үз ире белән горурланып, озатып калды.

Пушкин урамындагы кирәкле йортны тиз тапты Зөлфә, ә менә квартирны табу кыен иде. Ул баз кебек караңгы һәм буш ишегалдында кая барып бәрелергә белми аптырады. Ишекләргә акбур белән генә ниндидер саннар сызылган булса да, берни аңларлык түгел иде. Үч иткәндәй, ник бер кеше күренсен! Бер ишектә яктылык күреп, Зөлфә шунда керде. Яктылык икенче каттан төшә икән, өскә тар, тайгак баскыч белән менәргә кирәк. Ә анда берничә ишек булып, аларның кайсы квартир ишеге, кайсы чоланныкы икәне дә аергысыз иде.

Зөлфәнең бәхетенә каршы, ишекләрнең берсе ачылып, аннан юынтык су тулы чиләк күтәргән юан гына бер хатын килеп чыкты. Кызның соравына ул тупас кына:

— Әйдә күрсәтәм! — дип, суын баскычка чайпалдырып түгә-түгә, алпан-тилпән атлап аска төшеп китте.

Ул чүп базына суны түкте дә кулы белән каршыдагы тәрәзәләргә төртеп күрсәтте:

— Менә. Ишеге теге яктан.

Җирдән әз генә калкыбрак торган тәрәзәләрнең өчесендә дә ут бар иде. Зөлфә буйлы сызыклар төшкән арзанлы пәрдәләрне тишәрдәй булып карады. Белсәң иде: өйдә микән Атлас, юк микән? Өйдә генә булса ярар иде. Аны исән-сау, борчусыз күрү өчен Зөлфә ярты гомерен бирергә әзер иде.

Ул дөм-кара өйалдында баскычлардан төшкәндә чак егылмый калды. Сукыр кеше кебек кулларын алга сузып, бер-ике адым атлаган иде, бармаклары стенага бәрелде. Ул ишек тоткасын табарга азапланып капмаланды.

Ниһаять, каядыр якын гына аяк тавышы ишетелде, сулдарак ишек ачылып, саргылт яктылыкта озын, ябык хатын күренде.

— Әллә кеше бармы соң? — диде ул кискен тавыш белән.

Зөлфә ишек янынарак килде:

— Мин бу?

— Ни эзлисең син монда?

— Атласны. Ул биредә тора дигәннәр иде.

Зөлфә, Атлас күренмәсме дип, ачык ишектән эчкә карады. Көчле яктылыктан аның күзләре чагылды.

Хатын көтмәгәндә мыскыллы төчеләнеп:

— Ә-ә, Атласны эзләп килдеңмени? — диде. Зөлфәне өенә кертергә аның исәбендә дә юк иде, ахрысы.— Кем буласың соң әле син?

Күзе бераз күнеккәч, Зөлфәнең игътибарын җәлеп иткән беренче әйбер — бүлмә түшәменнән асылынып торган зур, шәрә электр лампочкасы булды. Йөз иллеле лампочка өйнең фәкыйрь җиһазын шәрәләндереп күрсәтә иде. Нәкъ менә шул лампочка бередә җан рәхәте тапмаучы, үз-үзләренең дә, торган урыннарының да кадерен белмәүче кешеләр яшәгәнен сөйли иде кебек. Зөлфә, ялгышлык белән кешенең яшерен серен ачкандай, кыенсынып артка чигенде. Ул гомерендә дә Атласын мондый шартларда яши дип күз алдына китерә алмас иде.

— Каян беләсең син аны? — дип кабатлап сорады хатын.

— Ә сез кем?

— Мин аның әнисе.

Менә ничек! Чибәр Атласның әнкәсе менә шушы карачкы кебек ямьсез, усал карашлы, ыржайган тешле хатын икән.

— Ә мин аның танышы,— диде Зөлфә.

Ул үзенең көлке хәлдә икәнен, таныш булу гына кыз кешегә җиде төн уртасында егет эзләп йөрергә хокук бирмәгәнен бик яхшы аңлый иде.

— Танышы-ы-ы,— дип сузды хатын нидер аңлагандай итеп.— Алай булгач, син белергә тиеш инде Атласның кайда икәнен! Танышы, имеш! Көне-төне өеңнән чыгармый яткырасың, тозлы су сипкәндәй иләндерден баламны. Харап иттең, башын ашадың!

Зөлфә, дога кылырга җыенгандай, ике учын күкрәгенә куеп, үзәк өзгеч тавыш белән:

— Ни сөйлисез сез? Ни сөйлисез? — диде.

— Сөйләргә ярамыймы? Ә эшләргә ярыймы? — Хатын аның түп җиңеннән тотты.— Кара, борын асты кипмәгән, нинди туннар кигән, ә? Нинди бүрекләр алган! Акчаны бик күп төшерәсең икән! Йа хода, минем газиз балам шушы өстерәлчеккә тун алып бирер өчен харап булды...

Ул арада янәшә ишек ачылып, аннан карт белән карчык чыктылар. Алар хатынның сөйләгәннәрен сүзсез тыңлап басып тордылар.

Зөлфә ни бер сүз әйтә алмады, ни кузгалып чыгып китә алмады. Ә хатын аны рәхәтләнеп сукте, суккән саен үз сүзләреннән үзе кыза барды:

— Шундый кәнтәйләр ашый ирләрнең башын! Әтисен юлдан яздырганнар иде, инде улын да юкка чыгардылар. Җитмәсә, оялмыйча, йөзеңне ертып минем каршыма килеп басасың. Ычкын моннан, фахишә!..

Бер гөнаһсыз кыз бала — Зөлфә, күсәк белән суктылармыни, башын тотып, чайкалып китте. Хатын авызыннан чыккан пычрак сүзләр аның миендә чүкеч белән төйгәндәй яңгырап тордылар...

## 17

Нателла тикшерүче бүлмәсенә бер генә минутка кергән дә менә-менә чыгып китәр кебек утыра. Хәтта камерада да ул үз-үзен карарга онытмаган, чәчләрен күпертеп, иренен буяп куйган, сигаретыннан коелган көлне кызыл күлмәк итәгеннән озын тырнагы белән чиертеп төшерә.

Ул гаҗәпләнгәндәй кыланып:

— Виктор Павлович! Сез мине нахакка тотасыз,— ди.— Ана бит мин, улымны кем карар?

— Улыгыз караулы, борчылмагыз,— ди Головин.— Унсигезенче февральдә нишләгәнегезне сөйләгез.

— Сөйләдем ич инде! Көндез эштә булдым, кич Зөлфә белән театрга бардым. Аннары Риф янына ресторанга кердем. Ялгызыңа көн саен өйдә аш пешереп булмый. Ресторанга еш керергә туры килә.

— Сез Атлас белән кайчан, кайда таныштыгыз?

— Сөйләгәннәрдер ич инде! — Нателла, Атласның ниләр сөйләгәнен белергә теләгәндәй, тикшерүченең йөзенә туры карап тора.— Мин аның ышанычсыз икәнен башта ук сизгән идем... Камышлы күл пионер лагеренда таныштык без. Һа-а! Мин аңа борылып та карамас идем. Шул бер ягы белән генә ошады ул миңа. Ошады да түгел, гажәпләндерде. Лагерьга кино килгән иде, разведчик турында. Анда разведчик сейф ачкычын сабынга кысып, формасын ала. Атлас миңа: «Разведчик, имеш! Мин ул ачкычка күз генә салыр идем дә кайткач сызымын сызып куяр идем»,— диде. «Шапырынма!» — мин әйтәм. Ә теге бик эре кыяфәт белән миңа карап тора. Шуннан бер яртыга бәхәсләштек. Ул өлкән вожатыйның өстәл ачкычына карады гына, кулына да алмады, миңа сызымын сызып бирде.

Нателла түшәмгә карап сигарет суыра, Головин сабыр гына сүзнен дәвамын көтә.

— Ачкычны сызым буенча Котик ясап бирде,— ди Нателла.

— Ә Котикка сызымны кем бирде?

— Әллә сызым бирү дә гаеп эшме? Мин бирдем. Кызык бит, ул сызым дөресме, юкмы — шуны беләсем килде. Шул ачкыч ярады бит! Бирә бит ходай тәгалә кешегә сәләтне! Нигә миңа бер сәләт тә бирмәгән икән? Мәсәлән, мин җырчы булсам! Һа-а! Хәзерге вакытта сезнең каршыда утырмас идем. Мин сәләтемне юк-барга әрәм итмәс идем! Ә ул, ахмак, алла биргән сәләтен файдаланып, өлкән вожатыйның өстәл тартмасыннан алтмыш сум акча урлады.

— Сез аны үз күзегез белән күрдегезме?

— Күрдем, бәхәсләшкән идек, дим ич.

— Атласның тагын нинди ачкычлар ясаганын белдегез?

Нателла тонык кара күзләре белән тикшерүченең мыегына текәлде:

— Мин Атласка сакчы түгел, ә ул миңа отчет бирергә тиеш кеше түгел. Бу юлы да, сейфыгыздан акча алыйк, дип ул миңа үзе бәйләнде. Мин аңа эш хакымны алырга ышаныч кәгазе генә бирдем. Аның өчен төрмәгә утырырга дигән статья юк.

— Ул сезнең ышаныч язуы белән акча алдымы?

— Алды. Иртүк, эш башлануга киткән иде, кайтты да бүлмә ачкычының да, сейф ачкычларының да сызымын сызды.

— Ә бинага алар ничек кергәннәр?

— Ну, анысы... әйткәннәрдер ич. Мин арткы ишекнең тимерен алып куйган идем, иртән килгәч тагын бикләдем... Кызык тоелды ул миңа. Барыбер булдыра алмаслар, дигән идем. Тормыш болай да әчпошыргыч, андый да кызык булмагач, яшисе дә килми.

— Ә кассир нилектән чирләде икән, әйтә алмыйсызмы?

— Беләсез ич инде... Мин аңа дару салып чәй эчердем. Тәэсир итмәс, дигән идем. Ә ул бик тиз тәэсир итте.

— Фиданлне ник чакырдыгыз?

— Үтерсеннәр дип түгел. Бу ике ахмакның кул астында машина булсын, дигән идем.

— Сез аңа телефоннан ни дидегез?

— Машинаң белән сәгать унга шул урынга кил әле, дидем. Бары шул гына. Килсә-килмәсә, үз иркендә иде, берәү дә мәҗбүр итмәгән. Аны үтерерләр дип минем башыма да килмәде. Ул акчаның тиенен дә миңа кермәде. Алмадым. Аның яртысын Люся алып качкан бит. Аһ, Виктор Павлович, тормыш катлаулы да соң, ә? Син яхшылык эшләргә тырышасың, ә ул начарлык булып килеп чыга.

...Котик — Головинга бик аңлаешлы тип, андыйлар һәр тикшерүче кулыннан күп узган. Котик барысын да ачыктан-ачык сөйләп, үзенә тиеш җәзаны йомшартырга тырыша.

— Дус-иш үтенеп сорагач, ачкыч ясап бирдем шул, гражданин тикшерүче. Ник дип сорап та тормадым. Ә унсигезендә Атлас миңа сумка алып килергә кушты. Ул минем сумканы алып, бер ишектән кереп китте, мина көтеп торырга кушты. Озак та тормады, чыкты. Урамда буш такси тора иде, шуңа утырып киттек.

— Сәгать ничәдә киттегез?

— Унберләр булгандыр.

— Машинада кайсыгыз кая утырды?

— Атлас алга, мин артка. Ну, мин карыйм, гражданин тикшерүче, теге эт җан сумканы миннән ерак тотарга тырыша. Ә ул бит минем сумка! Сез дә бит үз сумкагызны әллә кем кулына биреп җибәрмәс идегез, шулай бит?

Котик, тәк баскан озын муенын сузып, өстәл аркылы Головинга карый. Соравына җавап алмагач, сүзен дәвам иттерә:

— Мин сумканы алмакчы булдым. Ә теге сволочь бирми! Сумка ачылып китте дә эченнән акча чәчелде...

Котик тирләгән маңгаена ябышкан төссез чәчләрен артка сыпыра.

— Шуннан нишләдегез? — дип сорый Головин.

— Ну, минем исәп тизрәк машинадан чыгып ычкынырга инде. Ә теге сволочь — Атлас: «Давай, ди, Мамадыш трактына!» Ну, мин полный ход барган машинадан сикереп төшеп кала алмадым.

Котик урындыкта мәче кебек боргалана.

— Сез, гражданин тикшерүче, шоферны мин үтердем, дисәм дә, ышанмас идегез, шулай бит? Мин «юеш эш»ләргә каршы. Ну, теге шофер да ишәк төсле кире адәм булып чыкты. Мамадыш трактына житкәч, «тукта» дибез, ә ул туктамый. Атлас хәтта: «Сумкадагы акчаны өчебезгә бүлешербез»,— дип тә әйтеп карады. Ә теге тыңламый, һаман бара! Ә бәлки безне милициягә тапшырмакчы булгандыр? Мин үзем милициягә барырга каршы түгел, әмма аны уйлап эшләргә кирәк.

Котик керләнгән свитер якасын тартып куя.

— Ну, мин шоферның кулын тоттым, ә теге сволочь, Атлас, тормозга басты. Мин аның бер җирен авырттырмадым, ә ул, башы белән бәреп, минем иякне җимерде.

Котик сакал үскән кечкенә ияген тотып, авызын як-якка кыйшайтты.

— Билләһи дип әйтәм, гражданин тикшерүче, иң күбесе миңа эләкте. Алар машинадан чыгып сугыша башладылар, ә мин аермакчы идем...

Виктор тимер кистәнне күрсәтте:

— Ә бу кемдә иде?

— И-их, гражданин тикшерүче! И-их! Мин андый нәрсә күтәреп йөримме, ә? Шуның белән харап итте дә инде эшне Атлас — эт җан!

...Атлас һәр сүзне келәшчә белән тартып чыгаргандай авырлык белән әйтә. Атлас — студент, дөрес, беренче курста гына әле. Ул унике яшьтә чакта әтисе икенче хатынга өйләнеп, элекке гаиләсен ташлап чыгып киткән. Ә малай әнисе янында үскән. Аның бөтен кыяфәтеннән, салкын күзләреннән карашыннан буш, шәфкатьсез күңелле кеше икәне сизелеп тора.

Тикшерүче сорауларына ул кыска-кыска җаваплар гына бирә.

— Фидаил белән күптән таныш идегезме?

— Беренче күрүем иде.

— Бу тимерне каян алдыгыз?

— Виталийлар ишек алдындагы чанадан.

— Ник алдыгыз?

— Хулиганнар очраса, үз-үземне яклар өчен.

— Фидаилгә ни өчен суктыгыз?

— Белмим. Хәтерләмим. Ул үзе мине буып үтерә язды.

Атлас бөкрәеп утырган, карашын идәннән алмый.

— Сезнен мотоциклыгыз бармы?

Атлас кинәт башын күтәреп, салкын күзләренен карашы белән тикшерүчене чәнчеп ала, анын уң яңагында тырналган эз күренеп китә:

— Кызганыч, мин ул фраерның сезнең кеше икәнен башта белмәдем. Әгәр сизгән булсам...

Котик та, Атлас та бу фаҗигане очраклы булган хәл, бер бәхетсезлек итеп күрсәтергә тырышалар иде. Әйтик, кеше урамнан барганда өстенә багана ауган кебек. Ләкин асылда моның алай түгел икәнен Виктор бик яхшы аңлый иде. Алар бөтен тормышлары, дөньяга карашлары, кыйблалары белән капма-каршы кешеләр булганнар. Бер машинага утыргач, алар бәрелешми кала алмаганнар һәм ул бәрелеш аяусыз булган.

* * *

Җир йөзенең бөтен керен, карасын капларга, үкенечле үткәннәрне хәтер күзеннән яшерергә теләгәндәй, ябалак-ябалак кар ява.

Эре кар бөртекләре алгы пыялага килеп ябыша, эри, аларны «дворник» та чистартып бетерә алмый.

Ирек мәйданы аша узганда, таныш кешене күргәч, Ниазның йөрәге сулкылдап куйды. Автобус тукталышына баручы Зөлфә дә, кинәт нидер сизенгәндәй, артына борылып карады. Таныш машинаны күреп туктады, йөзе белән мәйданга борылып, Ниазның килеп житкәнен сабыр гына көтте.

Аның турысына житкәч, Ниаз тормозларга басарга омтылды — ләкин басмады. Шул секундта ул Зөлфәнең иңенә кулын салып оятсыз елмайган Атласны, аннары кулы белән машинасын сөеп торган нурлы йөзле Фидаилне күз алдына китерде һәм Зөлфә белән икесенең арасыннан бу кешеләрнең кулагәсе мәңге китмәячәген аңлады. Ул яратуы хакына Зөлфәнең хатасын да, ялгышуын да, адашуын да гафу иткән булыр иде. Әмма солдат йөрәге аны — иң саф, иң изге хисләрен жинаятьчегә багышлаган кешене — беркайчан кичерә алмаячак иде.

Зөлфә, машинаның кечерәйгәннән-кечерәя барган кызыл утларына карап, ялгызы басып калды.

## Нәби Дәүли

# ТЫНГЫСЫЗ ЙОРТ

ПОЭМАДАН ӨЗЕК

I

О, матбугат йорты,
Сиңа бер карасам,
Искә төшә яшьлек чакларым.
Еракларлан калган хатирәләр
Уйландыра мине,—
Ул көннәрне истә сакладым.

Син өр-яңа идең,
Бауман урамында,
Мең тәрәзәң белән балкыдың.
Син, беренче кабат ишек ачып,
Безне яктылыкка,
Биеклеккә, алга чакырдың.

Ул вакытта мин дә
Матур егет идем,
Егермедән яшем узмаган.
Мине кызлар өзелеп сөя иде,
Ләкин курка идем,
Курка идем үзем кызлардан.

Буем кыска иде,
Чәчем озын иде,
Шигырь тулы папка култыкта,
Үзем теләп ирегемне бирдем,
Үзем теләп килдем
Поэзия дигән «коллыкка».

Чәчем озын иде,
Чөнки белә идем,
Такташ, Туфан озын чәчләләр.
Шагыйрь даны белән кызыктырып,
Алар мине, алар
Бу тынгысыз йортка дәштеләр.

Елмайдылар алар
Мине очратканда,
Кайгыларын яшереп еракка.
Язмышыма алдан бәхет юрап,
Каптырдылар мине
Ычкындырмый торган тозакка.

Урамнарда салкын,
Сап-сары көз иде.
Минем әле язгы чак иде.
Күкрәгемдә әле йөрәк түгел,
Ләкин йөрәк төсле
Гел яңгырап торган чаң иде.

Мине әле беркем,
Беркем белми иде,
Тын авылда туган идем мин.
Беренче төн Казан вокзалында,
Йортсыз мәче кебек,
Кача-поса кунган идем мин.

Әйдә, белмәсеннәр,
Анда ни эшем бар,
Мин исемсез әле бүгенгә.
Иртә әле миңа кайгырырга,
Шагыйрьләргә исем
Кайзакытта үлгәч бирелә.

Бер нәрсәм юк иде,
Акчам да юк иде.
Ярлы диеп ләкин уйлама:
Бозылмаган яшьлегем бар иде,
Тотылмаган гомер,
Мин әр-яңа идем дөньяда...

— Менә биек баскыч,
Атла югарыга,
Эзләп килгән изге түреңә.
Бер карт мишәр мине тотып алды:
— Тукта,— диде,— парәм,
Башыңнан сал ишек төбендә.

Сәлам бирү кирәк
Бире кергән чакта,
Без бит монда постка куелган.
Төскә-башка чибәр күренәсең,
Точно әйтәм сиңа,
Төшеп калган, ахры, культураң.

Бу бит школ түгел,
Кибет-мибет түгел,
Дом печать бу, энем, беләмсең?
Адаштырган сине хыялларың,
Точно әйтәм сиңа,
Адресыңны белеп киләмсең?

Бу йортта бит, ылан,
Шуткы тәгел сиңа,
Буш кылынсаң бик тиз тыярлар.
Ак кәгазьгә кара хәреф белән
«Пешмәгән бу» диеп
Мир алдына язып куярлар.

Бүлмә саен утыра
Зәһәр редакторлар,
Үтә үткен күзлек кигәннәр,
Шул күзлектән карап тикшерсәләр,
Эссе мунча кереп,
Тирләп чыга монда кергәннәр.

Бер караса тагын
Рецензентлар сиңа,
Бер минутта куяр бәяңне.
Монда, энем, китап чыгаралар,
Ә син әле бик яшь,
Ашыйсың бар әле бәрәңге.

Бер караса тагын
Главный дигәннәре,
Нәрсә чыгар синнән, кем белә?
Үзеңне син фил дип санныйсыңдыр,
Ә бу йортта кинәт
Әйләнүең мөмкин чебенгә.

Вот, браток, монда
Эшләр ничек тора,
Ни буласын алдан белмәссең.
Так что, син уйла,
Адашырга туры килмәсен.

— Юк, адашмам, абый,
Тирән шахталарда
Кап-караңгы юллар узган бар.
Адаштыра икән мине хыял,
Әйдә, адаштырсын,
Мин үземне юлда кызганмам.

Барган кеше ләкин
Бер адашмый калмас,
Эзләгәндә үзенең йолдызын.
Мин хыялга зәңгәр җилкән корып,
Шул йолдызга карап
Әйләнермен әле җир йөзен.

Кунак булып түгел
Бире килүләрем,
Син бу түрне миннән тарсынма.
Дәүлине син әллә белмисеңме,
Менә бит мин, менә,
Басып торам синең каршыңда...

Абый миңа озак,
Озак карап торды,
— Кемнәр,— диде,— монда булмыйлар.
Шаир диеп бар да авыз ача,
Мескен аналардан
Кемнәр генә җиргә тумыйлар.

Чорт беләме Дәүли,
Вәли дигәннәрне,
Хоть буа бу монда алардан.
Кучат булып кайсы кычкыра да,
Кинәт тынып кала,
Гайрәтләре катмый яңадан.

Бер карасаң гаҗәп,
Зур умарта кебек,
Кызыктыра бу йорт халыкны.
Көне-төне керә-чыга кешеләр,
Ну, например, әйтим,
Килгән кебек балга бал корты.

Кортларның бит була
Төрле-төрлеләре,
Аларга да чиннар бирелгән.
Кайсылары бире бал китерә,
Кайсылары балны
Элэктереп оча биредән.

Ачуланма, ылан,
Шаир булмасам да,
Тик тормый шул минем дә телем.
Хотя миңа акча түләмиләр,
Зато, телне чарлыйм,
Обязанность шундый бит минем.

Сиңа кирәк, значит,
Точно бишенче[1] кат,
Шаирләрнең анда дөньясы.
Яраталар алар биеклекне,
Ләкин сандугачның
Бик түбәндә була оясы.

Бишенче кат биек,
Ике атлап кына,
Очып кына мөмкин менәргә.
Ләкин әле ап-ак чәчләр кирәк,
Җыерчыклар кирәк,
Мин бит инде шаир дияргә...

Дөрес әйткән идең,
Булдыклы карт мишәр,—
Бусагада сакта торучы.
Бу юлларны язган минутларда
Искә төштең кинәт,
Мин гомергә сиңа бурычлы.

---

[1] Сугыш елларына кадәр Язучылар союзы бишенче катта иде.

Еллар, еллар үткән,
Син юк инде күптән,
Ә мин исән, куам дөньяны.
Айга барып, айдан кайтыр идем,
Әгәр сузып куйсам
Мин бу җирдә узган юлларны.

Ә син әле һаман,
Һаман истә минем,
Беренче кат миңа очрадың,—
Бу йортта син мине каршыладың,
Мәрхәмәтле кеше,
Җиңел булсын кабер туфрагың.

II

О, матбугат йорты,
Сиңа килеп керсәм,
Кайтам кебек узган көннәргә,
Нур бирдең син минем күзләремә,
Яктылыгың өчен
Нәрсә белән сиңа түләргә?

Гади генә мин дә
Сөйләп китим әле,
Синең хакта, үзем турында.
Беркайчан да язып бетермәслек,
Әйтеп бетермәслек
Истәлекләр яши уемда.

## Беренче истәлек

Кайсы көнне чыктым
Дөнья юлларына,
Бәхетемне эзләп табарга?
Кошлар да бит шулай бер вакытны,
Канатлары үскәч,
Оялардан китеп тарала.

Мин дә китеп бардым,
Юл капчыгын асып,
Таң туганда җирне кызартып.
Читән башларында иске чүлмәк,
Хуш, авылдаш, диеп,
Карап калды мине озатып.

Тиздән инде минем
Туган авылымны
Танып булмас туган җиремдә.
Гаҗәп түгел безнең заман өчен,
Тормыш киң юл сорый,
Тау очраса — тауны җимерә,

Ә нишләргә миңа?
Әллә еларгамы,
Югала дип узган гомерләр?
Бетә диеп бабам нигезләре,
Онытылыр диеп
Атам-анам яткан каберләр?

Торасымы туктап
Кабер яннарында,
Язган сүзне укып ташларда?
Соңгы сәлам әйтеп бу тарихка,
Безгә насыйп булган —
Яңа тарих җирдә башларга.

Әйе, мин дә киттем,
Бәлки, бер кайтканда,
Шәһәр булыр авыл урнында.
Каберлекләр булмас сыкранырга,
Музейларда кебек
Кеше ятар көмеш урнада.

Еллар уза бирә,
Сулар аккан кебек.
Яңа ярга килә авыллар.
Булды микән кайчак океаннарда,
Тугыз баллдан артып,
Җан тетрәтеп узган давыллар?

Юк, җан гына түгел,
Хәтта җир тетрәде,
Төньяктагы бозлар сизгәндер,
Коммунизм дигән аваз белән,
Кызыл байрак белән
Яңа гасыр җиргә килгәнен.

Шулай кирәк иде.
Искелеккә — тар-мар!
Яңа туа авыр газапта.
Революция:
Тарихны,
Кеше гомерен,
Кешенең акылын,
Канын, йөзен, тәнен тазарта.

Өйрәтте ул безне
Мылтык тотарга да,
Ашамый да, эчми чыдарга.
Без җигелдек корыч «бишьеллыкка»
Илне ярлылыктан,
Кайгылардан тартып чыгарга.

Шулай кирәк иде.
Яңа чор каршында
Кирәк иде йомшап калмаска.
Авылларга килде эшче дуслар,
Авыл егетләре
Юл тоттылар ерак Донбасска.

Урак белән чүкеч
Кул алышты шулай,
Авыл белән шәһәр кавышты.
Иске дөнья белән сугышырга
Атакага чакырып
Хәбәр салды гудок тавышы.

Бирешмәдек ялган,
Кара коткыларга,
Төнне узып, көнгә атладык.
Явыз телле дошман авызларын
Корыч, тимер коеп,
Цемент белән сылап каплаладык.

Эшләдек без ярсып,
Ару-талу белми,
Җиңнәр белән йөздән тир сөртеп.
Иртә белән гудок тавышында
Ленин васыятьләрен
Йөрәгебез белән ишетеп.

Ә мин каләм алдым,
Бәлки, шул иртәдә
Башлангандыр тормыш юлларым.
Белми идем әле ул каләмнең
Авыр чүкечләрдән
Авыррак корал булганын.

Ләкин белә идем,
Хезмәт солдатлары
Атакага барган чакларда,
Барабанчы белән янәшәдә
Байракчылар кебек
Шагыйрьләр дә кирәк сафларда.

Кирәк иде икмәк,
Кием кирәк иде,
Кирәк иде тормыш үзе дә.
Күмер, тимер һәм бәрәңге белән,
Корал белән бергә
Кирәк иде шагыйрь сүзе дә.

Шул сүзне без койдык
Йөрәк ялкынында,
Кан җылысын бирдек ул сүзгә.
Мең тәрәзәң белән балкып тордың,
О, матбугат йорты,
Тимерчелек булдың син безгә.

**Марсель Зарипов**

# СУ БУЕНДА

хикәя

1



Ул көнне Ягъфәр иртән иртүк идарәгә барырга җыенды. Башта көн дә киеп йөри торган кыска сырмасын, аның өстеннән каты брезент плащын, итеген, күн тышлы колакчын бүреген кигән килеш кенә барырга уйлаган иде. Ләкин иренә кырыс булып күренергә тырышкан, чынлыкта исә ягымлы гына өйрәтеп-төзәтеп торырга күнеккән хатыны бу юлы да аны битәрләргә тотынды:

— Бу кыяфәтең белән кеше күзенә ничек күренмәкче буласың? Ичмасам, чиста күлмәгеңне, пинжәгеңне ки.

— Туйга бармыйм ич. Бәйрәм көн дә түгел.

— Туйга булмаса, председательнең үзе янына барасың.

— Таптың сүз, кем соң ул председатель? Кыз кеше түгел, кочаклашып үбешәсебез юк...

— Үбешмәсәң, эш турында сөйләшәсең бар. Бу синең туең-бәйрәмеңнән болайрак...

— Бәлки син медальне дә тагарга кушарсың?

— Анысын да так. Урлаган нәрсә түгел бит. Сатып алынган нәрсә дә түгел. Җиңү хөрмәтенә бирелгән бүләк.

Ягъфәр хатынының сүзен уйлап бер мәл тын торды, хатынын хаклы дип тапты һәм өстен алыштырырга тотынды. Башта вак-вак төймәләр тезелеп чыккан кыек якалы чиста күлмәген, аннары мон-нан биш ел чамасы элек алынып та берничә тапкыр гына иңенә эленгән пинжәген киде. Учларына төкергәләп торды да пинжәгенең кирегә бөкләнә төшкән якасын рәтләштергәләп куйды, йомшак каз канаты белән җилкәләрен сыпыргалап алды, кыш буе киеп йөреп күнегеп беткән бүрек урынына шактый ук уңган хәрби фуражкасын киде. Бөтенләй икенче төс керде Ягъфәргә. Яз төсе, бәйрәм төсе. Ул инде шул килеш чыгып китәргә үк җыенган иде, әмма әле апрель ае гына булуын, урамда суык җил икәнен уйлап плащ киде. Сугыш беткәннән соң военкоматка, военкомның үзе янына махсус чакыртып тапшырылган бүләген — «Германияне җиңгән

өчен» медален дә такмакчы иде, ләкин аны кайда куйган булуын һич хәтеренә төшерә алмады, озаклап эзләп торасы килмәде һәм шул килеш, медальсез генә барырга булды.

Ягъфәргә илле яшьләр, типсә тимер өзәр чагы, ә менә саулыгы аркасында беренче группа инвалид булып йөри. Шуңа колхозда эше юк дисәң дә ярый: бригадир да, председатель дә наряд биреп борчымыйлар аны. Ләкин Ягъфәр намуслы кеше. Колхоз җирендә яшим, шунда терлек-туарымны — кәҗәмне, бәтиләре белән өч сарыгымны көтүгә йөртәм, егерме биш сотый бакчага бәрәңге утыртам икән, димәк, мин үзем дә колхозга файда китерергә тиеш дип саный. Шуңа күрә һәр елны язга чыгу белән идарәгә эш сорап килә. Чәчүлек орлыкны сакларга дисеңме, тракторлар янына су ташыргамы, чәчелгән кукуруз орлыкларын чүпләргә өерләре белән ябырылучы кара каргаларны куып торырга дисеңме — берсеннән дә баш тартмый Ягъфәр, җитәкчеләр кая куйса, шунда бара, эшнең төшемлесен эзләми, колхозга файда булсынга йөри.

Кырлар инде кардан арчылган, апрель кояшы астында буланып яталар, шулай да сабанга чыгарга иртә әле. Тракторчылар, техниканы әзерләп-җайлап бетергәннәр дә, кырга чыгар сәгатьне көтеп, машина янында тәмәке төтәтәләр. Тополь агачларындагы бүрек-бүрек ояларыннан кара каргалар кычкырганы ишетелә, читән асларыннан, кое бурасы төпләреннән яшел чирәм бәреп чыккан. Терлек әле көтүдә түгел. Авыл халкы чиратлашып үзләре көтәргәме, әллә көтүче ялларгамы икәнен һаман хәл итә алмый, шуңа күрә малтуар урамда каңгырып йөри. Йоннары коела башлаган арык гәүдәле сыерлар йорт нигезләренә елышканнар, кояшта кызыналар, әнә тыкрыкта бер әрсез тәкә сарык тирәсендә бөтерелә...

Табигатьне чолгап алган бу түземсезлек Ягъфәргә дә күчте булса кирәк, ул иркенрәк сулыш ала башлады, каны кайнап, йөрәге яшьләрчә җитез тибәргә тотынды. Бу тибеш Ягъфәрнең нәкъ баш түбәсенә куелган плексиглас пластинка турысында көчлерәк, ешрак булып сизелә иде. Ягъфәр, тирә-яктагы төрле буяулардан, язгы иртәнең хуш исләреннән исерү шатлыгын тойган хәлдә, урам буйлап бара бирә. Менә ул адымнарын юри акрынайтты, иртәләрен председатель бүлмәсендә була торган гадәттәге ыгы-зыгы басыла төшсен әле дип, ашыкмый гына бара. Ул председатель кабинетына ничек килеп керәчәге, ничек итеп сүз башлаячагы, ярым шаяртып, ярым җитди итеп председательгә:

— Гвардия рядовой Шамгунов алгы сызыкка килеп басты. Аны төп юнәлешкә куегыз! — дип, хәрбиләрчә итеп кулын чигәсенә куячагы турында уйлады.

Ә Баһрамов, аларның председательләре, һәрвакыттагыча эше муеннан булса да, аны шатланып каршы алачак, мактап та җибәрәчәк:

— Син, Ягъфәр, молодец, ичмасам. Наряд биргәнне дә, чакырганны дә көтеп ятмыйсың,— диячәк.

Хәер, Ягъфәр үзе дә аптырап тормаячак, күзен дә йоммыйча:

— Халкыма хезмәт итәм! — дип чатнатып җавап бирәчәк.

Баһрамов җайлы кеше ул. Утыз меңче булып килгән иде. Эшен белә, кешеләргә ягымлы. Белеме дә зур: укымаган китабы юк. Аның тырышлыгы аркасында колхоз аяктан егылмый калды. Баштарак ул Ягъфәрне чәчкечләр янына ат белән орлык ташырга куя торган иде. Ә ашлыкның машинадан туп-туры чәчкечкә сала торган җайланма уйлап табылгач, аны су ташу эшенә күчерде. Узган язда исә бөтән бер эш тапты: бәрәңге каравылларга куйды. Хатын-кызлар бәрәңгене чиләкләр һәм кәрзиннәр белән чокырдан алып чыгалар да утыртыр алдыннан бераз кояш җылысы алсын өчен ише-

галдына сибәләр. Ягъфәр исә, кулына тал чыбыгы тотып, терлекләрне, казларны куып тора. Бер өйрәнеп киткәч, авыр булмады тагын, бәрәңгене һич кенә дә әрәм иттермәде. Бәлки председатель быел да бәрәңгегә куяр.

Идарә йортының коридорында буш һәм тын иде. Тик әрсез бер тавык кына бик җитди кыяфәт белән ике ишек арасында таптана, әледән-әле бусага асларына башын тыккалап карый иде. Ягъфәр бик вакытлы килүенә шатланып куйды. Башта күпне күрергә теләүче әлеге тавыкны пыраклатып куып чыгарды, фуражкасын салды һәм, уч төпләренә төкереп, чәчен сыпырырга тотынды. Ләкин чәчләре инде сирәгәйгән, алар аша аксыл җыерчыклар челтәре белән кискәләнгән баш түбәсе аермачык күренеп тора иде.

Эш Ягъфәр көткәнчә барып чыкмады. Хәрбиләрчә рапорт бирергә дә, председательнең мактау сүзләрен ишетергә дә насыйп булмады аңа.

Ул кабинетка килеп кергәндә, председатель әле яңарак кына колхозга райком җибәрүе буенча килгән партком секретаре белән сөйләшеп утыра иде. Ягъфәрне күрү белән урыныннан торып, аның каршысына килде.

— О-о, Шәмгунов! Әйдә, өйдә, рәхим ит. Гомерең озын булыр, синең турыда гәп кора идек.

Ваһрамов, Ягъфәргә тәкъдим итәргә теләп булса кирәк, эскәмиягә тотынган иде, нигәдер кире уйлады, ияк кагып кына ишарә итте:

— Утыр, Ягъфәр абзый!

Ягъфәр утырды, өстәлгә җәелгән постауның тузанын сөртеп, шунда фуражкасын куйды. «Уңай туры килде әле бу, кешесе дә күп түгел, председательнең дә кәефле чагы бугай»,— дип уйлап алды.

— Менә яз да җитте, Ягъфәр абзый,— диде Ваһрамов.— Сизәсеңме, елның иртәсе бит бу...

— Сизәм. Бөтен тереклек уянган. Яз килү минем өчен дә бәйрәм бит ул,— диде Ягъфәр, аның сүзен җөпләп. Һәм артык тартынып тормыйча, иркенләп сөйләшергә урын калдыра торган бу «бәйрәм» сүзен бик тә вакытлы кыстырып җибәрүенә эченнән шатланып куйды.

Ләкин нәкъ менә шул «бәйрәм» сүзеннән соң секретарь урыныннан кузгалды һәм тәмәкесен кабызырга тотынды.

— Я, ярый, мин киттем, агитаторларны эшкә кушарга кирәк. Плакатларын, листовкаларын хәстәрли башласыннар,— диде дә чыгып китте. Ә Ваһрамов кәгазь кыстыргычны алып, ашыкмый гына турайтты да шуның белән кара савытын чистартырга, аннан ниндидер йомычка кисәкләре, үле чебеннәр казып чыгарырга тотынды. «Әй, җүнсезләр, тәмәке төпчегенә тикле кара савытына салалар бит!» — дип зарланып алды.

«Председатель кара савытында үлгән чебеннәр эзләргә тотындымы,— бу хәерлегә түгел инде, тартәгә тибәчәген көт тә тор! — дип уйлады Ягъфәр, юлының уңмаячагын сизенеп.— Эх, комиссарны чыгармыйчарак торырга, аның янында сөйләшергә кирәк иде...»

Кара савытының төбендә берни дә калмады булса кирәк, председатель казынуыннан туктады.

— Беләсеңме, без нәрсә дип сөйләштек, Ягъфәр абзый? — диде ул, ниһаять.— Сиңа утыз хезмәт көне язарга булдык.

— Тиктомалгамы?

— Ник алай булсын. Тиктомалга чуан да чыкмый диләр бит. Сиңа рәхмәт йөзеннән. Колхоз өчен күпме хезмәт түккән кеше бит син. Иң кыен чакларда эштән баш тартмадың, хаста кеше бит мин.

булдыра алмыйм, дип тормадың. Ә хәзер инде сине борчып тормас-ка булдык. Эшче көче җитәрлек. Ә син ял ит, балыгыңны тот... Бакчаң өчен дә кайгырма. Бүтәннәрнекеннән иртәрәк тә сөреп ташларбыз, утын китертербез, мал-туарыңа азык бирербез.

Ягъфәр, кинәт бөтен барлыгын биләп алган кайгысын яшерә алмыйча, көрсенеп куйды. Баһрамов моңа бик нык гаҗәпләнеп:

— Әллә син канәгать түгелме, тинтәк балыкчы? Миңа аена илле сум пенсия бирсәләр, тынымны да чыгармыйча тик ятар идем әле. Җәннәт бит: эш дип баш ватасы юк, беркая чакырмыйлар, беркем сукми-тиргәми. Ә монда, кем әйтмешли, өстән басалар, өстән кысалар. Э-э-х!

— Нәрсәсенә шатланыйм мин моның? Мин бит сездән хезмәт көне сорарга килмәдем. Әнә бер чукрак бабайга бир син аны, миңа бирмә.

— Ул ниткән бабай тагын? Фронтта яраланган солдатыбызның да хәленә кермәскә без... Әллә син су ташый торган арбаңнан мәтәлеп төшеп, тагын имгәнмәкче, мине бөтен район алдында хурлыкка калдырмакчы буласыңмы? Юк инде, рәхмәт, Ягъфәр абзый, анысы булмас!

Ягъфәр нинди генә авыр көннәрендә дә үзен кызгандырасы килмәде, ул гына да түгел, кызгана башласалар, кычкырып елап җибәрер хәлгә җитә иде. Бик кирәк чакларда да инвалидлык биргән хокуклардан файдаланганы булмады, кибеткә кергән чакларында башкалардан узып прилавка янына тыгылмады — бер пачка тоз алу өчен дә юри чиратка баса иде. Шәһәрдә булган вакытларында трамвайга утырса-нитсә үзен, сау-сәламәт кешеләр, яшьләр белән беррәттән, өлкәннәргә, алгы ишектән керүче балалы хатыннарга урын бирергә күнектерде. Ә монда, туган авылында, баксаң-күрсәң, аны бөтенләй исемлектән сызып ташлаганнар, сабыйларның да кулыннан килә торган юк-бар эшне дә кушарга теләмиләр, бүтәннәргә комачау ясап, аяк астында буталып йөрмәсен дип, болай гына хезмәт көне язмакчылар...

Хәзер үк, идарә бүлмәсендә үк Баһрамовка үзең минем хәлгә төшсәң иде син, менә шунда аңлар идең, дип әйтәсе килде Ягъфәрнең. Ләкин шул вакытта телефон шалтырады. Районнан шалтыраталар иде булса кирәк. Председательнең «әйе, әйе, эшләрбез», дип түбәнчелек белән вәгъдә бирүләренә, әле сыерларның сөтне кимүе сәбәпләрен тәфсилләп аңлата башлавына, әле терлек азыгының җитешмәвеннән, болында үләннең булмавыннан зарлануына карап, Ягъфәр монда үзенең артык икәнен һич хатасыз шәйләп алды. Баһрамов, телефон трубкасын иңбашы белән колагына кысып, читчотлары мунчалаланып беткән куен дәфтәренең битләрен кабаланып актарырга, ниндидер кәгазьләр эзләргә тотынды.

— Председательнең эше дә майлы ботка түгел шул. Әнә бит ничек тинтерәтәләр үзен,— дип уйлап алды Ягъфәр сүрелә барып. Кешеләргә, һәртөрле җан иясенә карата йомшак күңелле булган Ягъфәр бүтән вакыт булса Баһрамовны һичшиксез кызганган, «ну кыздыралар да соң үзеңне, ходай түземлек кенә бирсен!» — дип җор сүз белән аны юатырга тырышкан булыр иде. Ләкин бүтәннәргә карата нечкә күңелле булып та үзен кызгануларын һич ошатмый торган бу кеше менә хәзер председательне шулай әрепләүләреннән, аның гаепле кеше төсле акланып торуыннан үзенә күңел юаткыч бер ләззәт тапкандай булды. Ягъфәр Баһрамовның телефоннан сөйләшеп бетерүен дә көтеп тормастан, фуражкасын киде дә, саубуллашырга юри онытып, тантана иткән кеше кыяфәте белән усал елмаеп чыгып китте.

Көн аяз, кояшлы булырга охшый иде. Ягъфәр бу язгы якты көндә аеруча каралып күренгән йортлар янынннан атлаганы хәлдә эш сорап таң тишегеннән идарәгә ашыгуы өчен үзен битәрләүдән туктамады. Шунда берочтан: «Ничек дип йөрәккә кадый бит, ләгънәт! Хезмәт хакы язачакбыз, имеш!» — дип, председательне дә үчекләп алды. Һәм ачуын тыя алмыйча, кемнеңдер ава башлаган читәненә төкерде.

Өйгә кайткач Ягъфәр хатыны белән сөйләшеп эчен бушатмакчы, аңа председательнең мәгънә белмәс бер хайван-бәндә булып чыгуын әйтмәкче булган иде, ләкин Фәйрүзәсе иртән үк фермага эшкә киткән иде. Үзе дә сизмәстән, ул көзге каршына килеп басты һәм, карый торгач, председатель белән икесе арасында охшашлык тапкандай булды. Бер үк төсле кысык күзләр. Бит сөякләре бер чамарак калкып тора, яңаклары эчкә баткан. Тик Ягъфәрнең чәче инде коелып бетә язган, ә председатель куе кәдрәләре аркасында бүреген кия алмый интегә. Мондый охшашлык Ягъфәрнең ачуын тагын кабартып җибәрде, шуннан соң ул түзмәде, көзгедәге шәүләсенә кашын җыерды. Билгеле инде, үзенә түгел, әлеге теге председательгә охшаган кешегә. «Тукта әле,— диде Ягъфәр шул ук кешегә, инде яз булуы, тиздән мал-туарны җәйләүләргә чыгарыр чакның җитәчәге, менә шунда инде председательнең, теләсә дә теләмәсә дә, аның яныңа балык сорап киләчәге турында уйлап.— Күрсәтермен мин сиңа тиктомалга хезмәт көне язуның ни икәнен! — Ул аягүрә басып, көзгене җиңе белән сөртеп алды.— Менә шунда исеңә төшерермен мин синең. Эх, медальне юкка тагып бармаганмын! Фронтовиклар белән ничек сөйләшергә кирәклеген белер идең...»

## 2

Врачлар инвалидлык кәгазе биргәннән бирле Ягъфәр балык тоту белән мавыгып китте. Кама буеннан менмәс булды. Балыкка ул җәен колхоз эшенә чыккан көннәрендә, көзен елгада, су өстен тутырып, үзенә бертөрле кыштырдаган тавыш чыгарып, бәстән аксыллаңып торган зил акканда һәм кыш буе тик ятудан ялыккан Кама эре-эре боз кисәкләрен ярсый-ярсый ваткан, сәке асларында йомырка өстендә утыручы җанкәйләрен сагынып яр буенда каңгырып йөрүче ата казлар бу бозларның бер-берсенә бәрелеп шатыр-шотыр килүеннән куркышып читәнгә елыша торган вакытларында гына төшми кала иде. Мондый чакта Ягъфәргә тыныч су өстендә дә әйләнергә торган җәлпәк төпле көймәсе белән Камага чыгу турында уйларга да юк. Әмма суның кимегәнен, тынычланганын көтеп ятарга да тәкате калмый Ягъфәрнең. Ул бар булган җиһазларын ала да фронтта тез тиңентен аяксыз калып, агач аяк белән йөрүче күршесе Фатихларга керә. Фатихның бакчасы артында язгы ташкын вакытларында түбәсенә тикле су астында кала торган кара мунчасы бар. Ягъфәр мунча түбәсенә башта җиһазларын, плащын ыргыта, аннары үзе менә, аяксыз дусты Фатихка менәргә булыша. Менә шуннан алар икәүләшеп балык тота башлыйлар. Балык әйбәт каба. Болганчык суда алабугалар, шыртлакалар шактый еш чиртә, аратирә зур-зур корбан балыклары да эләккәләп куя. Мунча янындагы читән буена ирләр, хатын-кызлар, яшь-җилкенчәк җыела. Түбәгә кунаклап алган Ягъфәр кармак сабын тартып кына тора, һәм ул тарткан саен су эченнән тыпырчына-тыпырчына балык атылып чыга. Ягъфәр тоткан бер балыгын кармактан ычкындырып ала да, әйләнеп карап тормыйча гына, иңбашы аша артка таба атып бәрә. Бала-чага шашынып чыелдап кычкырырга тотына, ә олкәннәр, аны

юри үчекләп: «Эх, мать якасына, Ягъфәр, мич башында яткан кілеш кенә кармак саласы кала сиңа хәзер!» — диешәләр.

Ягъфәр боларның берсен дә ишетми, язгы салкынның акрынлап бөтен тәненә сеңә баруын сизми, тик кич җиткәч кенә бавырларына тикле туңганын аңлый, җәй җитми торып су буена аяк басмам дип үзенә үзе сүз бирә. Әмма икенче көнне шул ук хәл яңадан кабатлана.

Җәй җитүгә елга тынычлана, элекке эзенә төшеп, салмак кына, вәкарь белән генә ага башлый, Фатихның мунчасы яр буеннан ерак бер җирдә, бакча уртасында торып кала. Ягъфәр күздән үк көйләп калдырган җәлпәк төпле көймәсен чыгара.

Каракош авылында балык тоту киң таралган кәсеп түгел, күпләр аңа мәзәк итеп кенә, бала-чага эше итеп кенә карыйлар. Олыларның беркадәресе ферма тирәсендә, машиналар тирәсендә көнетөне кайнашканга балык тоту белән онытканда бер, хозур өчен генә шөгыльләнә. Икенчеләре исә кармакларын, суалчаннарын, бүтән җиһазларын вакытында хәстәрләп куярга өлгерми кала. Ягъфәр исә алар аяк киенгәнче су буена төшеп тә утыра.

Каракош — дүрт йөзләп хуҗалыгы булган шактый зур авыл. Шулай да мондагы халык бер-берсенең хәле белән хәбәрдар булып яши. Ягъфәр дә кемнең өендә кайчан туй булачагын, кемгә көтелмәгән җирдән кунаклар килеп төшкәнен әллә кайдан белеп өлгерә дә, нәкъ кирәк вакытта килеп, йодрыгы белән шул йортның тәрәзәсен кага башлый:

— Әй, кунакларны ни белән сыйламакчы буласыз? Көлдә пешкән бәрәңге беләнме?

Тегеләрнең җавап биргәнен дә көтмичә, тәрәзәне тартып ача да, саңаклары селкенеп торган тере балыкларны шалт итеп тәрәзә төбенә китереп сала.

— Шыртлака белән кушып пешерсәң менә дигән шулпа чыга судактан. Кыздырыйм дисәң, кара балык белән карасьтан да әйбәте юк. Сомны исә тозлап какларга кирәк... — дигән була.

Өй эчендә зык куба: «О-о, менә хәзер балык шулпасы мәтәштерәбез!» — диешәләр. Хуҗа кеше һәм кунаклар, стаканнарын тотып, Ягъфәр янына ашыгалар:

— Әйдә, җибәр берне, Ягъфәр.

— Юк, эчмим мин...

— Әйдә, әйдә, капла... Тавык кына эчми хәзер...

Аңарга стакан сузалар, төрлечә кыстап карыйлар. Ягъфәрнең эчеп җибәрәсе, балык исе сеңгән учларын иснәп торасы, хәмернең башка китеп, күңелгә вәсвәсә салуын сизәсе, кунакларга кушылып кычкырып җырлыйсы, иртәгесен үзеңә урын таба алмый йөрерлек булып бер исерәсе килә. Ләкин ул, ике төрле уйларга урын калдырмый торган бер катгыйлык белән, аракы кебек агуны инде күптән авызына алмавын, күрәләтә торып сәламәтлегенә зыян китерергә теләмәвен аңлата башлый.

Ягъфәр үзенә авылда ничектер югарыдан торыбрак, кызганыбрак карауларын да, аның балык тоту белән мавыгуын җир сөрергә, терлек карарга, чын ир кешенең генә кулыннан килә торган бүтән эшкә сәләтсез булганга ирексездән сайлап алган бер шөгыль итеп кенә санауларын яхшы белә. Моны Ягъфәр авыр кичерә, гарьләнә, аның каравы, эчәсе килүен басар өчен үз-үзе белән көрәшкән, таза-сау ирләр дә кайчак каршы тора алмастай бу азгын теләкне авызлыклаган минутларда ул үзен бүтәннәр төсле үк көчле кеше итеп сизә, алай гына да түгел, тормыш тоткасы булган чын эш белән мәшгуль, ихтирамга лаек бу кешеләрдән үзен өстен итеп саный башлый иде.

Яз җитеп, җир өстендә чирәм борын төртә башлау белән, Ягъфәрнең өенә председатель үзе килә. Монысы инде бөтен авылда сирәк була торган хәл, ни өчен дисәң, гадәттә председатель кирәк кешене үзе янына йомышчы малай аркылы чакыртып ала. Ә менә Ягъфәр исә мондый игътибарга гадәти бер нәрсә итеп карый. Ул берни булмагандай самовар яңартырга тотына, идән астыннан марттa ук тотып каклап куйган корбан балыкларын алып чыга. Председатель балыкның майлы кабыргасын кимереп куя. Ягъфәр исә тәмәке белән дус булмаганга балык артыннан чәй йотып җибәрә. Аның күңелен ләззәтле дә, шатлыклы да түземсезлек били башлый, әмма ул моны сиздермәскә тырыша, председательнең сүз башлаганын көтә.

Менә, ниһаять, Баһрамов урыныннан кузгала, бер мәл чалбарын каккалап тора, бер корбан балыгын алып кесәсенә тыга һәм болай сүз ара сүз чыгып кына әйткәндәй:

— Савымчыларны җәйге лагерьга чыгарабыз,— дип куя.

Ягъфәр, бу эшне хуп күргәндәй, ияк кага.

— Вакыт инде. Җәй җитте, үлән чыкты.

— Эссегә китсә, терлекне арлы-бирле куып йөртүдән генә дә ни тикле сөтне югалтабыз.

— Сыерларга кыен, әлбәттә. Куып йөртүдән дә мәгънә юк,— ди Ягъфәр, председательнең сүзен җөпләп.— Җан иялəре бит...

— Зур эш бу,— ди председатель.— Шул уңай белән бәйрәм сымак бер нәрсә мәтәштерергә исәп. Халык җаваплылыкны да сизсен, үзләренә игътибарны да күрсен. Син, әйдә, бер-ике җөенне чамала инде. Тозлап-каклап куй. Кулыңнан килә ул синең.

Баһрамов килгән саен Ягъфәр аның янында үзен эрерәк, хәтта кырысрак та тотарга сүз биреп куя. Ләкин һәр очракта ничектер онытылып китә, шатлыгыннан үзен-үзе белештермичә, күзен дә йоммый ялганлый башлый. Янәсе, җәен ул Ягъфәр өчен чүп тә түгел. Менә председатель ярдәмгә бер кеше генә бирсен, ул көймәсенә мотор куячак та Астраханьга барып җитсә җитәчәк, иллә мәгәр артель өстәленә әсәтернең менә дигәнен, элек патшалар табынына куела торганын китереп салачак.

Әсәтер балыгын тотып алып кайту түгел, күрә дә алмаячагын Ягъфәр үзе дә яхшы аңлый, шулай да бер башлагач ул инде сөйләүдән туктый алмый, әсәтерне көймәгә ничек тартып чыгарырга кирәк икәнен, аңардан күпме кара икра алып булуын, аның күпмесен тозларга мөмкин икәнен тезеп китә, тузга язмаганнарны әйтеп ташлый, аннары үз ялганыннан үзе үк кызара. Шул тикле кызып китә Ягъфәр, үзен-үзе туктата алмас хәлгә җитә, үзе уйлап тапкан уйдырмага үзе ышана башлый һәм, балаларча беркатлылык белән, аның бу ялганнарына бүтәннәр дә ышаналардыр дип уйлый.

Председатель, шайтан, хәйләкәр кеше. Ягъфәрнең бу гадәтен яхшы белә. Тегенең әсәтер дигәннәренә һич исе китми аның.

— Я, ярый, әсәтере чәнчелеп китсен. Дәүләт балыгы ул, валютага китә. Аның өчен сиңа да, миңа да шундый эләгер, гомереңдә шыртлакага кул якмаслык булырсың,— ди председатель, шундук, сиздермәстән генә тегеңә салам кыстыра:

— Өч потлы җәен алып кайта алсаң, шул җиткән. Син каклаган җәен булганда әсәтерең бер якта торсын...

Ягъфәргә шул җитә кала. Дөресен генә әйткәндә, ул Баһрамовның әсәтер турындагы уйдырмага ышанмавы белән канәгать: ялган ачылмыйча калачак. Шулай да моны сиздерми, көрсенгән була:

— Ярый инде алайса,— ди ул.— Җәене булыр анысы.— Андый сыйга ләек өстәлегез генә булсын.

Икенче көнне иртән үк Ягъфәр эшкә тотына. Башта буадан ямьяшел гөберле бакалар тотып кайта да салкын сулы тирән чүлмәккә тутырып куя. Шуннан соң гына кармакларын ала да кеше-кара йөрми торган урын эзләп китә һәм җан-фәрманга тыпырчынган зур мыеклы симез балыкны ярга тартып чыгармый торып әйләнеп кайтмый. Өсте-башы ләмгә буялган, пычранган килеш туп-туры дусты Фатих өенә барып керә, бер-ике атнага дип тегенең мунчасын сорап ала да шунда күрәзәлек итә башлый. Беренче башлап ул җәенне берәр килолы кисәкләргә бүлеп чыга, аларның итен иткә, кылчыгын кылчыкка аера, аннары итенә тоз сибә дә әлеге кисәкләрне — берсе янына берсен — агач мичкәгә сала, өсләреннән түгәрәк такта белән каплап, авыр нәрсә белән бастырып куя. Шулай бер атна үтә. Җиденче көнгә китте дигәндә, Ягъфәр мичкәдән тозланган кисәкләрне алып, мунча эчендәге киштәләргә элеп чыга, эчтә җил уйнап торсын өчен тәрәзәләрне ача, ләүкә өстендәге чүпрәкне тартып чыгара да мичкә ягарга тотына. Аның ягуы да үзенчә: утын агачларын әле бөтенләе белән мичкә тыга, әле тартып чыгара, ул арада булмый, утка махсус киптерелгән ниндидер хуш исле үлән яфраклары ыргыта. Әледән-әле өенә дә кайтып килә... Ягъфәрнең бу мәзәкләренә инде күнегеп беткән Фәйрүзәсе аны табын янына чакырып карый, әмма тегесе кулын гына селти: янәсе, тәмам бәйләндең ич. Шуннан соң инде Фәйрүзәнең дә түземе бетә, ләкин ул бүтән хатыннар кебек тавыш куптармый, тиз генә өенә керә дә бер савытка токмачлы кайнар аш яисә буланып торган бәрәңге сала һәм әлеге мунчага йөгерә. Ягъфәр аны бусага төбендә каршы ала, ашамлыгын кабул итә дә үзен кире куа башлый. Ләкин Ягъфәрнең дулкынлануы хатынына да күчеп өлгергән була, ул аяк очларына гына басып мунча алдына керә, төтен тулы бүлмәгә башын гына тыгып, ни өчендер шыпыртлап:

— Тиз буламы инде? — ди.

— Озакламый була,— дип, шулай ук шыпырт кына җавап бирә Ягъфәр. Аннары хатынына карата күңелендә рәхмәт хисе уянганны сизеп, өстәп куя: — Өч көннән...

— Барып чыгар микән соң?

— Чыкмый диме соң? Искитмәле булачак!

Ягъфәренең шатлыгына шатланудан Фәйрүзәнең дә күңеле почмаклана, ул елмаеп үк җибәрә, ә аның бу елмаюыннан Ягъфәргә тагын да рәхәтрәк булып китә, ул үзен бүтәннәрнең кулыннан килми торган эшне башкаручы аерым бер кеше дип хис итә башлый.

Атна ахырына төтеннән тәмам каралып беткән, аягына да басып тора алмастай арыган Ягъфәр, өенә кайтып, өстен чишенә һәм изелеп йокыга талыр алдыннан хатынына:

— Председательгә әйттер, җәенне алырга кеше җибәрсен...— дип әйтергә генә өлгерә.

Шуннан соң нәрсә булачагын ул барып карамаса да яхшы белә. Председатель Ягъфәр каклаган балыкны алачак та урман уртасында савымчылар, көтүчеләр өчен мәҗлес сыман бер нәрсә оештырачак. Районнан да кешеләр чакырачак. Халык утырышып беткәч, ул беренче булып үзе торып басачак, стаканын күтәрәчәк, үтә күренмәле булыр дәрәҗәгә җиткереп каклаган балыкны чәнечкесе белән элэктереп алачак, аны яктыга куеп бер мәл сокланып карап торачак. Шуннан соң гына җәйләүдәге кешеләрнең яхшы эшләвен теләп, аларны көчләрен кызганмаска чакырып тост күтәрәчәк. Бүтәннәр дә эчеп җибәрәчәкләр, ашарга тотыначаклар һәм, әлбәттә, табында итеннән-маеннан дисеңме, колбасасыннан-консервасыннан дисеңме, сый-хөрмәтнең мул икәнен бөтенләй онытып, әлеге хуш исле каклаган балыкка ябырылачаклар. Мәҗлесне түгәрәкләргә ва-

кыт житкәч, председатель, кунакларга берәр кисәк балык тоттырып, мактанып алачак:

— Безнең колхоз маркасы бу, янәсе. Ягъфәр шайтан эше. Җәен генә булса да, әсәтерең бер якта торсын. Чын сихерче ул безнең Ягъфәр, билләһи!..

Өенә кайтып, ачулы-гарьле килеш көзге алдына утырган Ягъфәр менә шулар турында уйлады. Бу юлы үзе янына килгән председательне ничек каршы алачагын бөтен ваклыклары белән күз алдына китерде. Ягъфәр, әлбәттә, сер бирмәячәк, берни булмагандай, Баһрамовны каклаган корбан балыгы белән сыйлаячак, хәл-әхвәл сорашачак, төрле юк-бар турында сөйләшәчәк, ә менә сүз иң мөһим, иң кирәкле нәрсәгә килеп төртелгәч, күзен бераз кыса төшеп, кискен генә башын чайкаячак. Җитәр инде, балык тоту дигән нәрсә белән арасын өзде Ягъфәрегез, ул хәзер бүтән пенсионерлар төсле тыныч кына яши башларга исәп тота,— диячәк.

Ягъфәр көтелмәгән бу сүзләрдән председательнең тамагына кылчык кадалуын, аның чәчәлеп йөткерә башлавын күз алдына китерде һәм көлеп җибәрде...

Менә фермадан Фәйрүзәсе дә кайтты. Ягъфәрнең идарәгә эш сорап барган булуын белгәнгә, ул аны өйдә туры китерүенә гаҗәпләнде, ә картын көзге каршында күргәч бөтенләй аптырап калды. Ягъфәр башта ялганларга, «чәнчелеп китсеннәр эшләре белән, бармаска булдым»,— дияргә уйлаган иде, ләкин хатыны алдында беркайчан да икеле-микеле сөйләгәне булмаганга моны булдыра алмады, идарәгә нинди уйлар белән барып керүен, Баһрамовның нинди әшәкелек эшләвен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Юләрләнеп йөрисең шунда, әтисе,— диде хатыны.— Безгә, ике бөртеккә күпме кирәк соң? Син пенсия аласың, мин, биргәненә шөкер, эшлим. Җитмәгәнмени безгә...

Ул бу сүзләрне ачулангандай итеп әйтә, ә үзенең тавышы йомшак, ягымлы.

— Беләсең син, юләрләнеп, имеш... Кеше арасында буласым килә минем, аңлыйсыңмы син шуны? Су өстендәге маяк төсле гел бер ялгызым бит...

— Юләрләнеп шул... Кирәгең бар иде синең аларга, ул кешеләргә... Миңа ярый инде — шундый язмышны үземә үзем сайлап алдым. Ә бүтәннәр синең белән газапланырга теләмиләр шул. Эшләгәнең бер тиенлек булса, мәшәкатең биш сумлык бит синең...

Ягъфәр хатын-кыз нәселен начар белә. Озын һәм авыр тормыш юлында аңа очраган хатын-кызларның беренчесе һәм соңгысы шул Фәйрүзә булды. Шуңа күрә булса кирәк, ул хатыныннан бернәрсә дә яшерми, күңелендә туган иң нечкә хисләрне, иң яшертен уйларны да аңа сөйләргә күнеккән, хәтта үзе өйдә булмаганда да аның белән гәп корып йөри, андый очракларда да Фәйрүзәсе менә шунда, каршыда гына аны тыңлап утырган төсле җитди итеп сөйләшә. Шулай итсә аның уйлары ачылып киткәндәй була, хыяллары ничектер канатлырак була башлый, дөньяга карашы җитдиләнә.

Сүзенең ахырында Ягъфәр хатынына председательне ничек кабул итәчәген, аңардан ничек үч алачагын да әйтеп салды. Балык тотулар бетте инде хәзер, диячәк ул аңа, алай гына да түгел, бөтен йорт-җирне сатып чишмә һәм коедан битәр суы булмаган урынга күчеп китәргә исәп бар, диячәк. Бүтәннәр эссе чүлдә дә үлмиләр, суны төштә күреп булса да яшиләр, без дә үлмәбез, диячәк.

Хәер, күчеп китү турында ул болай гына, ачуы килүдән генә

әйткән иде. Ә менә иренең һәр сүзен чынга алырга күнеккән хатыны бу юлы да аңа ышана калды, хәтта шатланып та куйды.

— Үлмәбез әле,— диде ул, иренең сүзен җөпләп. Тик ни өчендер Ягъфәргә сәерсенеп бер мәл карап торды.— Син өйдә кайнашырсың, мин эшкә керермен. Юкса, котым алына шул елга буена төшеп китсәң, көймәң-ниең белән агып китәрсең дә кире кайтмассың, әҗәлең шул елгада булыр дип ут йотып утырам.

Хатыны нindидер гаебе бар кеше төсле, Ягъфәргә карап елмаеп куйды, һәм аның йөзендә яшереп булмастай чая бер шатлык балкый башлады. Ягъфәр хатынының авыр еллар, олы һәм кече кайгылар сөреме белән өртелгән ягымлы күзләренә карап торды, ул күзләрдә кабынып киткән шатлыкны бөтен күңеле белән аңлады. Һәм кинәт аның бөтен барлыгын коточкыч бер уй биләп алды: «Күр әле мине, үзе турында гына уйлый торган «мин-минлекле» җанны, шул елга-балык аркасында, шул нәләт төшкән мавыгуым аркасында күпме газап чиккән бит минем хатын!» Ягъфәр Фәйрүзәсе белән гомер иткән елларын, үзен нәни баладай караган хатынына менә шул изгелеге өчен балык тоту хирeслегеннән бүтән бернәрсә дә бирә алмавын, алай гына да түгел, шул хирeслек аркасында аны гел хәсрәт эчендә тотуын күз алдына китерде. Менә хәзер шулар өчен хатынынnan гафу үтенәсе, аны иркәлисе, назлыйсы килде Ягъфәрнең. Ләкин ул моны булдыра алмады, өметсез бер кыяфәт белән кулын гына селтәде.

## 3

Чыннан да, моңа кадәр Ягъфәр аны чын-чынлап белмәгән икән ләбаса, өйдә аның үзенең теләкләре һәм омтылышлары гына өстенлек иткән икән, шушы көнгә тикле ул янәшәсендә шундый ук теләкләре, омтылышлары, ихтыяҗлары булган тере кеше яшәвен, аның бу теләкләре белән исәпләшергә кирәклеген уйлап та карамаган икән. Гомер буе, Фәйрүзәсен белә башлаганнан бирле, менә әлеге, бүгенгe сөйләшүгә кадәр гел шулай булган икән.

Ә Фәйрүзә аның күңеленә беренче тапкыр сугыш вакытында, зур газапларның һәм зур батырлыкның башлануы булган коточкыч җәйдә килеп кергән иде. Ул көнне авыл халкы армиягә алынганнарны озата иде. Озатучылар да, сугышка китүчеләр дә бер-берсен соңгы тапкыр күрүләре бик ихтимал икәнлекне яхшы аңлыйлар, шуңа күрә һәркемнең күңелен нindидер тантаналы кайгы биләгән. Басуда иген өлгереп килә, арыш башаклары җиргә иелә башлаган. Сугышчыларны озатырга чыккан халык басу капкасы янына җыелды. Үзенең булачак хатынын, Фәйрүзәсен — ялан аягының балтырлары тырналып беткәнгә булса кирәк, яклаучысыз калган нәүмиз бер ятим төсле генә булып күренгән Фәйрүзәсен — Ягъфәр әнә шунда очратты. Ул аның кем кызы икәнен дә белми — буй-сынында дисеңме, бите-күзендә дисеңме әлеге игътибарны җәлеп итәрлек бернинә булмаган озын торыклы мондый үсмерләр азмыни авылда! Шулай булса да һич кичекмәстән сугыш эченә барып керәсе, җитлегеп җитмәгән әлеге чандыр кызны ил өстенә килүче куркынычтан саклап-ярлыкап каласы килде Ягъфәрнең, нәкъ менә шул минутта ул үзен көчле-куәтле кеше итеп, немец җәберләргә теләгән һәркемнең яклаучысыдай хис итте, берәр ягымлы, җор сүз әйтеп, кызның күңелен күтәреп җибәрәсе килде аның. Бөтен халык алдында Ягъфәр Фәйрүзә янына килде дә нindидер зәңгәр чүпрәк катыштырып үрелгән кыска толымнарыннан сыйпады.

— Син курыкма бер дә. Күрәмсең, фашист өстенә ни тикле кеше бара. Мәскәве дисеңме, Казаны, Ташкенты — бөтен ил күтә-

релде бит. Дәррәү китереп суксак, фашист дигәнеңнең көле күккә очар...

— Ә мин курыкмыйм,— диде кызый, бер дә исе китмичә генә, ә үзе, куе кашларын күтәрә төшеп, рәхмәт хисе тулы ягымлы күзләрен сирпеп аңа бер мәл карап торды.— Исән йөреп, сау кайтыгыз...

Ул тагын нидер әйтергә теләгән иде булса кирәк, ләкин Ягъфәр аны шундук онытты, гармунчыга кушылып, бар көченә җырлап җибәрде.

Менә шул гына. Алар арасында бүтән берни дә булмады: сөешүяратышу да, кочышу-үбешү дә. Ягъфәр аны исенә дә төшереп карамады дисәң, хәер, инде сугышның өченче елында, һич истә-оста юк чагында Фәйрүзә аның төшенә керде. Нәкъ печән өстендә Ягъфәр Каманың хатын-кызлар гына су кerә торган бер тын култыгына барып чыккан икән. Караса, баеп баручы кояш нурына чумган су эченнән ниндидер алсу төскә манчылгандай булып әлеге кызый чыгып килә, имеш. Ягъфәр, кызның ялангачлыгыннан оялып, тиз генә куаклар арасына яшеренә, күзләрен йома икән. Шулай да аның йомры күкрәкләре очында кара кучкыл булып торган ике төерне, иңбашына төшеп торган юеш чәчләрен, калак сөякләренә бөрчек-бөрчек булып утырып калган су тамчыларын аермачык күрә икән.

Иртән Ягъфәр күңеле моңарчы булмаган ниндидер татлы да, шатлыклы да сагыш белән тулган килеш уянып китте. Бередә, рәхимсез сугыш эчендә, тикмәгә түгел, кешелек табигатенең иң изге, иң югары билгеләмәсе буенча йөрүен, үзе өчен булудан битәр, халык иминлеге өчен кан коюын искиткеч ачык һәм кискен итеп аңлагандай булды. Икенче көнне шундый яңа хис белән ул атакага барды, дошман окопларына якынлашканда ни өчендер төнлә күргән төшен тагын хәтерләргә тырышты, ләкин хәтерендә берни дә калмаган иде. Менә шунда ул яраланды. Еөтен барлыгын биләп алган ярсуга бирелгән хәлдә, ул баштарак каскасының түбәсен снаряд кыйпылчыгы тишкән булуын да сизмәде, бер кызган килеш һаман дошман окопларына таба йөгерүендә булды, бөтен көченә: «Ә-ә-ә!.. Нәсел-ыруыгызны...» дип кычкыруын белде, тик бераздан гына, үзе дә сизмәстән, каядыр читкә янтая баруын абайлап, коты очты...

Шул көннән соң Ягъфәр ел буе госпитальдә ятты һәм Каракошка инвалид булып кайтты. Врачлар аның нәкъ баш түбәсенә плексигластан уч төбе кадәр ямау салдылар. Шуннан соң ул баш очындагы әлеге ямауның сәгать йөрүе төсле һәрвакыт тик-тик-тик итеп сугып торуын ишетә торган булып китте.

Ягъфәр госпитальдән буш өйгә кайтып төште. Үзе исән булса да бар нәрсәгә битараф булып, бер нәрсә белән дә кызыксынмыйча, баш түбәсендәге плексиглас ямауның торган саен сирәгрәк, зәгыйфьрәк тибүен сизгән хәлдә, көннәр буе урамга карап тәрәзә каршында утырды.

Фәйрүзә, аның хәзерге хатыны, бушап калган бу өйгә нәкъ менә шундый көннәрнең берсендә килеп керде. Кыюсыз һәм һәрнәрсәдән өркүчән яшь-яшь бу кызга, хәер, Ягъфәрнең сүнеп барган йөрәгенә тормыш өрү, шатлык, җиңеллек китерү ансат булмады. Бәхеткә каршы, Ягъфәр күңелендәге җылылык бөтенләй үк сүнмәгән, көл астында калган очкындай, кабынып китәр сәгатен көтеп, күмелеп кенә торган булган икән. Күп айлар үткәннән соң ул күңел түрендә зәгыйфь кенә, кыюсыз гына булып ниндидер теләк кузгала, уяна башлавын сизде. Ул күкрәгенә тормыш өргән фәрештәнең кем булуын аңлап, хәлсез куллары белән аның тыгыз һәм җылы җилкәсеннән сыйпады...

Сугыш бүләк иткән чирдән бөтенләй арындым, баш түбәсенә ямау салганга кадәрге хәлемә кайттым дип уйлады Ягъфәр. Хәзер аның тормышы ике яртыга бүленгәндәй булды. Беренчесе беленер-беленмәс ак тап булып хәтернең теге ягында калды, ә икенчесе ул теге упкын эченнән чыккан, Фәйрүзә җилкәсенә кулын салган көннән соң башланды. Аңа җан керде, ике ел чамасы тракторчылар арасында хисапчы булып эшләп йөрде, сабый бала төсле тормышны, табигатьне үзе өчен өр-яңадан ачты, юк-бар гына нәрсәгә дә — үлән арасында дөньясын онытып сайраган чикерткәләргә, урамдагы тузан өстендә борчак бөртекләре төсле сикергәләгән яңгыр тамчыларына, җәйге җилдә тирбәлеп утырган үлән сабакларына гаҗәпләнеп карап тора торган булды, бала чакта кичергән шатлыкларны яңадан кичерде. Тормыш аның өчен ниндидер бер кызык нәрсә булып китте, ул чыннан да бу якты дөньяга яңа килгән кешедәй яшәи башлады.

Әмма снаряд кыйпылчыгы аңа шактый нык бәргән булган икән. Кисәк-кисәк хәтере югала торган булды Ягъфәрнең. Бүген язганнарны иртәгә оныта, кәгазьдәге саннарның кайдан килүен исенә төшерә алмыйча, мәгънәсез караш белән шуларга текәлеп тик утыра. Эш гаугага кадәр барып җитте. Тракторчылар я бер көнгә бүтән чакларда ай буе ала алмаган кадәр акча эшләгән булалар, я ай буе эшләп тә бухгалтерия аларга түгел, алар бухгалтериягә тиеш булып чыгалар. Ягъфәргә теләсә дә, теләмәсә дә пенсиягә китәргә туры килде.

Тума-тумыштан ялгызлыкны җене сөймәгән егет үзенең эшкә яраксыз булып калуын бик авыр кичерде, елга бер генә тапкыр булса да «бүтәннәр төсле булу», башкалар белән эшкә чыгу аның өчен чын бәйрәмгә әверелә иде. Каракош халкы аның эшкә яраксызлыгын күрмәмешкә салыша. Ләкин Ягъфәр күзсез түгел бит ул, кызгануларын бик яхшы күрә. Әмма ул түзә, кеше алдында моны сизмәгән-белмәгән булып кылана, бүтәннәрнең аңа игътибарлы булуларына шатлангандай итә. Тик көчле-куәтле елга киңлегенә чыгып, ташып аккан дәрья кочагында калгач кына ул йөрәкне әрнетеп торган бу кимсетүле хистән арына башлый, үзен тирә-юньдәге табигать белән тоташ итеп, иксез-чиксез галәмнең кечкенә генә булса да бер кисәкчәсе дип хис итә иде.

Баштарак ярыйсы гына барса да, көннәрнең берендә ул су өстендә көймәдә килеш аңын югалтты. Аны очраклы рәвештә узгынчы балыкчылар күреп, өенә алып кайтып салдылар. Ул мондый өянәкнең һәр минутта кабатлануы ихтимал икәнен яхшы белә, үзе генә түгел, аның аркасында Фәйрүзәнең дә иза чигүен аңлый, ләкин элеккечә яшәвен дәвам итә: җәйләрен су өстендә үткәрә, ә кыш җитте исә, баш түбәсендәге ямауны күрсәтер өчен врачлар янына йөри. Фәйрүзәсе, аны үзен генә җибәрергә куркып, фермадан сорап китә дә больницада шәфкать туташы хезмәтен үти башлый. Ягъфәрне больницада күптән белгәнгә артык сузып тормыйлар, операция урындыгына утырталар. Врачлар аңа операцияне ни өчендер, йөрәге өчен куркып булса кирәк,— наркозсыз гына ясыйлар. Ягъфәр инде мондый чактагы авыртуларга да, үзе тирәсендә кайнашкан врачларның борчылып пышылдауларына да игътибар итмәскә күнегеп бетте. Операция ясаганда ул бүлмә ишеге төбендә куркынып басып торучы хатыныннан күзен алмыйча утыра. Үзе өчен аеруча кыен булган бу минутларда Фәйрүзәсе белән булган бөтен тормыш юлын көнен көненә күз алдына китерә, теге басу капкасы төбендә булган беренче очрашу-сөйләшүдән башлап менә шушы операция урындыгына килеп утырганга тикле булган һәр вакыйгане да тәфсилләп уйлый, Фәйрүзәнең көн саен аңа ничектер бүтән-

чәрәк, йомшаграк, ягымлырак, игътибарлырак була баруын исенә төшерә, шундый кешелекле уңган хатынга тап булуына шатлана һәм үзенең бу изгелеккә шундый ук изгелек белән җавап бирә алмавы, аны хәтта ана булу кебек бик табигый бәхеттән дә мәхрүм итүе өчен пошына башлый иде. Бер ятим бала алып үстерергә иде, ичмасам. Лэкин ничек үстермәк кирәк соң аны? Ягъфәрнең үзенә сабый бала тәрбиясе кирәк ләбаса! Менә шуңа аның йөрәге әрни, һәм врачлар пычагы тиюдән булган авырту бу әчке әрнү, күңел сыкравы алдында бөтенләй чүп кенә булып тоела иде. Менә шул әчке сызлануын басар өчен ул больницаны тутырып:

— Күр әле син, Фәйрүзәкәй, нишләтәләр алар мине! Өр-яңадан дөньяга тудырмакчылар бит! — дип кычкырып җибәрә.

Иртәгесен иртән палатага курчак төсле ап-актан киенгән врач керә дә, үз итеп, Ягъфәрнең караваты читенә килеп утыра, аның күзенә карамыйча гына, марля белән бәйләнгән башына салкынча кулын куя.

— Ну, көч тә бар үзеңдә! — ди ул.— Бирдең безнең кирәкне кичә, бик нык әйттең. Сакламыйсың син үзеңне. Кара аны, бөтенләйгә монда калырга туры килмәсен...

Врачларның шундый игътибары Ягъфәргә ошый, күңел әрнүе бераз басылгандай була, шулай да ул йөзенә ачулы төс чыгарып:

— Бик кирәгегез бар иде. Минем ихтыярда булса, сезнең якка борылып та карамас идем,— диган була.

Фәйрүзәсе алдындагы гаебен чын күңелдән таныган Ягъфәр, больницадан чыккач, врачлар кушканча гына көн итәргә, елганы күрмичә бөтенләй тора алмас булганда гына яр буена бер төшеп менәргә дип, үз-үзенә сүз бирә. Лэкин мондый тормыш аның өчен чын газап була башлый, төннәрен йокысы кача, шулай да биргән вәгъдәсен үтәр өчен бөтен күңелен билгән вәсвәсәдән котылмакчы булып, тәмам интегеп бетә һәм, каршы торып булмый торган бу көчкә буйсынып, кача-поса елга буена, көймәсе янына төшеп китә.

Баштарак болай итү аңа бик тә уңайсыз иде, лэкин еллар үтү белән ул үзе үк уйлап чыгарган бер теориягә ышана башлады: бу дөньяда кеше өчен иң мөһим нәрсә, иң зур хакыйкать төрле чир-хасталыкларга яраклашуда түгел,— алай булса тормыш дигәнең зәгыйфь тән, көчсез-кодрәтсез рух рамкалары белән чикләнер иде. Кеше күңеле өчен иң зур ләззәтләрнең берсе үз табигатеңне иң зур афәтләргә, бәла-казаларга, авыру-сырхауларга каршы көрәшкә җайлаштырудан, шуларга каршы торырга күнектерүдән гыйбарәт. Чөнки дөнья дигәнеңнең зурлыгы-көчкенәлеге барыннан да элек кешенең аны үз карашы, эшләгән эшләре белән үлчи-чамалый белүендә.

## 4

Ягъфәр үзен биредә, Каракошта түгел, кайдадыр бүтән бер җирдә, бөтенләй елгасы-суы булмаган урында яши итеп күз алдына китерде һәм хатынына артыгын лыгырдап җибәрүенә үкенеп куйды.

— Әллә көчләп әйттерделәрме сине, тел бистәсе?!

Ул үзен тирги-тирги, әйткән сүзеннән ничек тә кире кайтырга, күчеп китү турында артык кызып китүдән генә әйтеп җибәргәнмен, дип, хатынына аңлатыр өчен сәбәп эзли башлады.

Бер тапкыр да бала тапмаган бүтән хатыннар төсле, аның Фәйрүзәсе дә тән һәм йөз чибәрлеген саклаган, төсе-бите белән дә, буесыны белән дә ун-унбиш елга яшьрәк күренә. Эшкә уңган, житез хәрәкәтле Фәйрүзә мондый көннәрне дә Ягъфәренә бернинди эш

калдырмый иде, ә бүген исә бөтенләй бөтерелеп кенә йөри. Ягъфәр бакчада җир казымакчы булып карады, ләкин көрәге майлы кара балчыкка батып калды, чиләкләргә барып тотынган иде, алар тумтулы булып чыктылар. Кардан арынганнан соң кибеп тә җитмәгән ишегалды да чип-чиста килеш тора иде...

Ул арада хатыны өй эшләренә тотынды — самоварын, кашыкаягын катык белән чистартып куйды. Фәйрүзәдәге күтәренкелек Ягъфәргә дә күчте, ул да мендәр-ястыкларны, юрганнарны кояшка чыгарып элеште, тузаннарын каккан булды. Аннары хатыны базга төшеп бәрәңге алып менде. Ягъфәр дә, кулына пычак алып, аңа булышмакчы булды. Алар икәүләшеп бәрәңге әрчеделәр. Фәйрүзәнең пычак тоткан кулы бәрәңге өстеннән күз иярмәс тизлек белән йөри, бәрәңге кабыгы юка гына озын киң тасма булып бөтәрләнеп төшеп кенә тора. Ягъфәр дә сер бирмәскә тырыша, ләкин аныкы барып чыкмый: пычак бәрәңге кабыгын ите-ние белән умырып ала, ә кабык Фәйрүзәнеке төсле бөтерелеп барасы урынга сынып-сынып төшә иде. Ягъфәрнең моңа ачуы чыга, шуңа ул каударлана-ашыга башлый, ләкин аңа карап эше рәтләнми.

— Ашыкма шул тикле, бөтен йомшагын кабыкка чыгарып бетерәсең ич,— диде аңа Фәйрүзә, икенче бәрәңгесен әрчергә тотынып.

— Ашыгып ни файда инде. Сине барыбер куып җитеп булмый. Әнә бит бармакларың ничек тигез йөри!

— Ә син куып кара, бәлки җитәрсең дә...

— Маташып торасы да юк...

Гаҗәеп хәл, әллә шул сүзләрдән, әллә бүтән сәбәп аркасында, Ягъфәр кинәт тынычланып китте, пычагы бәрәңге өстендә җитезрәк йөри, иң мөһиме — әрчелгән кабык юкарак һәм тигезрәк булып чыга башлады. Күңел яктысы йөзенә чыккан, бәйрәмчә балкып торган Фәйрүзәсенә караган килеш, Ягъфәр хатынының шатлыгы аның да шатлыгы була баруын, моңа кадәр аның йөрәген тырнап торган кайгының бик вак бер нәрсә генә булып калуын торган саен ачыграк аңлый барды.

Кайгы яисә зур шатлык Ягъфәрдә гел яр буена төшү, елгага чыгу теләген уята. Бүген дә шулай булды, ләкин ул иң башта хатыны турында уйлады, биргән вәгъдәсен искә төшерде һәм, өзәргә булгач берьюлы өзәргә кирәк, дип тыелып калды.

— Бүтән аны борчымыйм,— дигән катгый карарга килде Ягъфәр.— Бәлки төн җиткәч тагын бер генә, соңгы тапкыр гына көймәдә әйләнеп кайтырмын да шуның белән вәссәлам.— Һәм ул, кыен хәлдән чыгу юлын табуына, шундый акыллы да, хәйләкәр дә карарга килүенә шатланып, тынычланып калды...

Ягъфәр бик зирәк йоклый. Көндезге борчулардан тәмам арып, изрәп йоклап яткан хәлендә дә ул хатынының йокыга китүен сизде һәм, урыныннан торып, киенергә тотынды. Ул һәрвакыттагыча саклык белән, шылт иткән тавыш та чыгармыйча, бернәрсәгә сугылмыйча-кагылмыйча җыенды. Шулай да инде өйалдына чыгам дигәндә генә аны хатынының тавышы туктатты:

— Син кая болай, Ягъфәр?

— Болай гына... чыгып керәм әле. Бөркү монда, ничектер тын кысыла...

Ягъфәр шулай дип чыгып китмәкче иде дә тагын туктады. Ул хатынының нидер сизүен, ялганының тотылуын аңлады, Фәйрүзәнең аны әрепли башлавын, үпкә белдерүен көтте.

Хатыны торып утырды, кинәт, яшь кыздай оялып, юрганын күкрәгенә каплады. Иртән булган сөйләшүне онытмаган икән, кинәт сорап куйды:

— Кая күченербез икән без, Ягъфәр?

— Кая дисеңме? — Мондый сорауны бөтенләй көтмәгән Ягъфәр кинәт каушап калды.— Район үзәгенә, әлбәттә...— диде.

— Нигә, Казанга, яисә бүтән бер шәһәргә дә ярый. Култыклашып йөрербез. Безнең алай йөргән дә юк бит әле.

— Әйе шул. Мин сине әләктереп алырмын да, әй, китәрбез, мин сиңа әйтим!

— Хәзер ирләр түгел, хатыннар култыклый инде. Телевизордан күрсәтteләр.

— Шулаймыни? Менә бит без синең белән авылда торып ничек артта калганбыз.

Ягъфәр үзенә-үзе ачулана, шуңа күрә хатыны белән ничектер ярым шаяртып сөйләшә, ләкин Фәйрүзәсе әллә моны аңламый, әллә аңламаган булып кылана, һаман үзенең такылдавын белә иде:

— Ә син култыклашып йөри дә белмисең әле. Безнең икәүләп йөргәнебез юк лабаса. Син һаман үзең генә. Шул больницага барганда гына инде. Менә ничә ел бергә яшибез, үзең белән елга буена да алып төшкәнең юк,— дип, ул Ягъфәренә ягымлы гына итеп үпкә белдереп алды. Ә Ягъфәргә шул да җитә калды, кызарынды, уңайсызланды, бит урталарының ут булып януын сизде.

— Әйдә, хәзер алып төшәм!

— Әйдә.

Төн тымызык иде, баш өстендә еракта-еракта йолдызлар җемелдәшә, ә аларның таңгы нурлары җир өстенә ерак галактикаларның күгелҗем томанын алып килә лэр төсле тоела.

Ягъфәр Фәйрүзәнең көймәгә кереп утыруын көтеп торды да үзенең мамык сырмасын ыргытты. «Аякларыңны төребрәк утыр, туңарсың»,— диде һәм көймәне ярдан этеп җибәрде дә, үзе менеп утырды.

5

Су өсте тын иде. Елга төн буе дулкыннарын уйнатып арыган да хәзер инде иркенләп ял итә. Шулай да дәрьяның көче, киңлеге күңелләрдә ниндидер җилкенү уята. Яктыра башлады. Яр буенда акрынлап каралҗым куаклар, ялгыз йорт менеп кунаклаган текә калкулык беленә башлады. Баш өстендә күк гөмбәзенә сагаеп кына иртәнге шәфәкъ канат җәйде. Елга уртасында су өсте тигез, каракучкыл, ә текә яр буенда югарыдан искән җилдән саклап торучы калкулык ышыгында томан эленеп тора. Суга тоташкан җирдә томан аксыл-күгелҗем, югарыга таба акрынлап алсу төскә манчыла бара, һәм ерактан иртәнге яктылыкта су өсте тәтенләп янып тора төсле. Куаклар арасында, әлерәк кенә алар кузгалып киткән урында ниндидер бер кошчык, тынычлыкны болай вакытсыз бозуына уңайсызлангандай, тыелып кына, кыюсыз гына тавышын сынап карады, аннары бар көченә сайрап җибәрде. Күз ачып йомган ара да үтмәгәндер,— бу тавышка икенчесе, өченчесе кушылды, һәм дөньяда менә шушы елгадан, шул кошлар чыр-чуыннан гайре берни дә калмаган төсле тоела башлады.

Ягъфәр, көймәсен чак кына кыеклап агымга каршы тоткан хәлдә, күгелҗемләнеп күренеп торган каршы як ярга таба ишүен белде. Иренең сырмасын иңенә элгән Фәйрүзә көймәнең койрыгында тын да алмый утыра иде. Ул кинәт ни өчендер шыпыртлап:

— Тиздән чия бөре ачачак,— дип куйды.

— Алмагачлар чәчәк атачак, аннары икмәк өлгерәчәк,— дип өстәде Ягъфәр һәм хатынының мондый сизгерлегеннән, аның уйларының юнәлешен аңлый белүеннән күңеле нечкәреп тынып калды.

Алар су чупылдавын, дулкыннарның салмак кына шаулашуларын тыңлап, бу авазларны бозмас өчен тын гына утырдылар. Аннары Фәйрүзә түзмәде: «Нинди рәхәт!» — дип тирән сулап куйды һәм кулын суга тыкты.

— Эх, теге вакытта юкка гына тәрбиягә бер малай алмадык,— диде Ягъфәр.— Яшь чагында аякка бастырган булыр идек әле.

— Кызый әйбәтрәк.

— Малай ышанычлырак инде анысы.

— Алайса, берьюлы икене: бер малай, бер кыз...

— Кайдан аласың андыйларны? Язмыш дигәнең балаларны шулай парлап ятим итәр дисеңме?

Әйләнә-тирәдәге бар нәрсә: киң җәелгән су өсте дә, яр буйлары да ал төскә керде. Өстенә бөркелгән бу мул яктылыктан каушап калган маяк гаҗәпләнүеннән хәтта күзен дә кысмас булды. Елга уртасыннан зур ак пароход йөзеп бара, аның койрык ягында, аста алсу төскә кереп су кайный иде.

Ягъфәр пароходларны яратмый, аның палубаларындагы бәйрәмчә киенгән эшсез пассажирларны аксөякләр дип саный, тик берьюлы берничә баржаны этеп баручы, зур-зур салларны тартучы буксирлар турында гына ихтирам белән: «Менә болар чын эшчеләр, ичмасам, күпме йөк тартып баралар!» дип уйлап кала. Ул пароходның бушап калган палубаларына, пәрдәләре төшерелгән тәрәзәләренә карап торды да, бар көченә: «Уяныгыз, торыгыз, йокы капчыклары! То-ры-гыз!» — дип кычкырып җибәрде.

Ләкин аның тавышы бик зәгыйфь булып ишетелде, киң күкрәкле гайрәтле елга бу тавышны, еракка җәелергә бирмичә, шундук йотып җибәргәндәй булды. Пароход та, Ягъфәргә һәм аның кычкыруына һич тә игътибар итмәстән, канатлы коштай очып үтеп китте. Җәлпәк төпле көймә көчле дулкыннар өстендә чайкалып калды. Ягъфәр ишкәкләрен ычкындырды да, бөтен тәнен-мускулларын йомшартып, көймәдә утыра бирде. Бу минутта ул язмыш дигәнең кешегә бүләк итә алган рәхәтлекләрнең иң-иң зурысын кичерә иде. Чыннан да бәхетле иде ул бу мәлдә. Яр буенда яңа салынган нарат бүрәнәле йортлары, җил-яңгырлар каралткан өйләре белән чуарланып торган әнә шул туган авылы барга, аның җанына да, тәненә дә ял бирә торган менә бу елга барга, рухи яктан аңа бик якын булган сөйгән хатыны менә шулай каршысында утырып торганга ул бәхетле иде. Ягъфәр белән никадәр иза чиксә дә, аның Фәйрүзәсе сулмаган, киресенчә, еллар үтү белән аның хатын-кыз мөлаемлыгы отыры арта төшкән иде. Ягъфәрнең иркәләүдән азынмаган күңеле хәзер нечкә бер сагыш белән тулып ташый, җил-салкыннан өшегән җир кояш җылысын көткән төсле, назлауга сусый иде. Менә әгәр хәзер аңа Фәйрүзәсе: «Әйдә, Ягъфәр, ташлыйк бар нәрсәне, мине кулыңа күтәр дә алып кит шул су өсләтеп!» — дисә, ул ике дә уйлап тормас, бәхетеннән бөтен дөньясын онытып, күтәреп алып китәр иде. Ягъфәрнең күңелендә бу минутта хәтта бүген аны хезмәт кешеләре арасыннан миһербансыз рәвештә сызып ташлаган председательгә карата да үч-ачу калмаган иде. Баш түбәсендәге плексиглас ямау да, врачларның әледән-әле аның башына ремонт ясаулары да нечектер юк нәрсә генә булып тоелдылар. Ләкин шулай да бу минутта аның өчен каршысында утырган Фәйрүзәсенә карап торудан, аның сулышын ишетүдән, бер сүз дә әйтмичә генә аны уйлаудан да зуррак ләззәт юк иде. «Менә бит ниндиләр бездә хатыннар! — дип уйлады Ягъфәр.— Алтын хатыннар. Алар булмаса безнең ир-ат халкы беткән булыр иде. Чын әгәр — харап булыр иде».

Ягъфәр турылыклы булганы, яратканы өчен хатынына бернәрсә белән дә җавап бирә алмавына гомере буе газапланып, үз арала-

рында бүтәннәрнеке кебек чын сөешү-иркәләшүнең булмавына күңеле әрнеп яшәде. Сукыр кеше түгел бит ул Ягъфәр, күрә: сарыф ителмәгән табигать көченә буйсынып хатынының таза-сау тәне ничек сагышланганны да, Фәйрүзәнең назлау-иркәләү яратучы йөрәгенең шул ук көчтән ничек вәсвәсәләнүен дә күрә... Хатыны алдындагы менә шул ирексез гаебен аңлагангамы, хәзер нәкъ Фәйрүзә теләгәнчә эшләргә, бар нәрсәгә кул селтәп, елга буеннан бөтенләйгә күчеп китәргә карар итүе Ягъфәргә аерата бер рәхәтлек бирә иде. Бу карар аның үзенә карата булган ихтирамын арттырды, ул үзүзенә олырак һәм көчлерәк булып күренә башлады.

* * *

Икенче көнне Ягъфәр төш күрде. Алар йорт-җирләрен сатканнар икән дә Каракоштан күчеп киткәннәр икән. Бу юлы да бәхет дигәненең аларны әйләнеп үтмәгән, өйләрен ярыйсы гына бәягә сатып, яңа җирдә дә әйбәт кенә йорт-җиргә тап булганнар икән. Фәйрүзә район үзәгендә йон тетү фабрикасында кабул итүче булып эшкә кергән, ә Ягъфәр көнозын өйдә. Район үзәгендә елга-мазар юк, халык суны колонкалардан гына ала, шуңа күрә ул тәүлегенә унар сәгать йоклап, врачлар кушканча гына тормыш итә башлаган икән. Ягъфәр бу графикны бозмаска тырыша, ләкин шунысы бар: төн җиттеме, төшенә әллә нәрсәләр кереп интектерә икән. Үзе йоклый, ә үзе бакча артында гына елганың дулкын какканын, кояшның су өстен алсу төскә мануын, бер-бер артлы ак пароходлар үтеп торуын күреп-ишетеп ята икән... Ул да булмый, һич истә-оста юк чагында, аның янына колхоз председателе килеп чыга. Бүлмәгә кереп утыра да кайдандыр Иделнең иң түбән агымыннан көтү-көтү булып килүче әсәтер балыклары турында, бүтән тузга язмаган нәрсәләр турында сөйләргә тотына, шунда сүз арасында гына яңа җәйләүләр оештыруларын бер-ике сүз белән генә әйтеп куя. Ягъфәр исә берни дә белмәгән-аңламаган булып күренергә тырыша, ә үзе кунагын чәй эчәргә кыстый-кыстый, район үзәгендәге тормышны мактарга, моңа кадәр юләр булып авылда яшәгәнмен дип үзен үзе сүгәргә тотына...

Председатель чәй эчеп туйганнан соң чокырын әйләндереп каплый, сый-хөрмәте өчен рәхмәт әйтә-әйтә, аңа карап көрсенеп тора да: «Юкка күчтең син монда, тинтәк балыкчы!» — дип китеп бара...

Ягъфәр әле уянып киткәч тә моның төш кенә икәнлегенә ышанырга теләмичә, тын да алмыйча ятты. Аннары аңына килде, үзен чолгап алган кара стеналарга, түшәмгә күз төшерде, кабат йокыга китәр алдыннан председатель турында ачу белән, нәфрәтләнеп уйламакчы булып карады, ләкин күңелендә ачу булса да, җанга рәхәтлек китерми иде ул...

## Хәсән Сарьян

# ТУГАН ЯК МОҢЫ

НӘСЕР



Карта битләрендә аның сурәте кеше йөрәгенә охшап тора. Ул — Башкортстан, минем туган җирем. Йөрәктәге кан юллары шикелле, аның туфрагын да бик күп елгалар сугарып үтә. Шуларның иң өлкәне, халкыбызга иң якыны — былбыл моңыдай гүзәл Агыйделдер.

Агыйдел!

Бармы безнең чын татар җырларында синнән дә күп җырланган гайре бер елга!..

Әгәр дә мин елына бер сиңа кайтып, чабатасыз малай чагым кебек, иртә таңда салкын чыклар ярып буйларыңны бер әйләнмәсәм, чык суыдай ак суыңда сары сагышларымны бер басмасам, бабамнарның сөяге түшәлгән җылы туфрагыңа битем куеп орынмасам,— мин үземне башка җирдә, хәтта Казанымда да бу тикле дә нык ватанлы тоймас идем.

И иртәләрең ак томанлы Ак Иделем!..

Мин Агыйделнең түбән карасаң йөрәкләр купмалы Төбә яры читендә басып торам. Миннән бик түбәндә, кызыл яр тирәли, кыелып-кыелып кәрәшәләр очып йөри. Дөнья моннан капыл киңәеп, күз кабагыдай ачылып китә: уң ягымда зәңгәр дымдай рәшәләнеп, офык өстенә Йолдыз-Тау уелып төшкән; сул ягымда — Питер тавы, аның очлы борыны Агыйдел аръягындагы Кызкала тавына төбәлеп каткан төсле. Моннан ике йөз ел элек империяне дер селкеткән Пугач явы Казанны алмага барышлый бу җирләрдән дә яңгырап үткән. Алар әнә шул Питер тавы өстенә урнашканнар. Әби патша гаскәрләре исә аларга каршы Идел Эченнән[1] килгән булса кирәк: нәкъ Питер тавы турысына — уйсу япан җиргә хәзерге спорт сарайларыннан да зуррак итеп, камалы бүректәй түгәрәк тау өйгәннәр дә шуның артында һөҗүмгә көч туплаганнар. Әүвәл таудан тауга атышканнар дип сөйлиләр. Белмим, ул ераклыктан туп атышулары бәлки өеп тау ясаулары шикелле бер риваять кенәдер, әмма ләкин каты сугыш булуы хак. Әби патша гаскәрләре Агыйделне

---

[1] Безнең як халкы Агыйделне күп вакыт Идел дип кенә йөртә, шуңа күрә аның унар чакрымга җәелеп, язларын су астында кала торган әрәмәле, болынлы түбән ягын элек-электән Идел Эче дип әйткәннәр, ә таулы биек ягын Кыр Ягы диләр.— Автор искәрмәләре.

кичеп, авыр һөҗүм белән Питер тавы төбенә үк килеп җиткән: шулай булмаганда Пугачев егетләре болай да текә борын очына, иңеннән-иңенә чокыр казып, җирдән нығытма өймәсләр иде (ул өемнәр бүген дә машинадан биек). Шуннан бирле бу тауны, үзен Петр III дип игълан иткән Пугачев «исеме» белән, Питер тавы дип йөртәләр.

Идел Әченең көнчыгыш тарафында тагы, аяз көннәрне күгелҗем рәшә сирпеп, ә яшенле яңгыр килгәндә кара-кучкылланып яткан иләмсез зур ике әүлия зираты бар. Боларын исә Алыпның агасы Бисрәк батырдан калган диләр: Агыйделне атлап чыккач, чабатасын салып, туфрагын кагып киткән, имеш... Калган җирләрдә ерак тау тезмәләренә кадәр болын да әрәмә, болын да әрәмә: Күгәрчен, Акман, Каттарлау, Чәгерче болыннары... Алардан әчкәре — язын су басмас чикләрдән авыллар, бүлем-бүлем урманнар башланып китә: Чумар, Мәнәк, Кәлтәй урманнары... Һәр тарафта күпме кавем гомер кичкән чын табигать. Тик ул хәзер әүвәлгечә тын гына түгел: инде бу төбәкләргә дә тимерле бетоны, БелАЗлары белән зур санагат килеп керде. Әнә теге Кызкала тавыннан ары, Нугай, Кырым-Сарай якларында инде шаулатып нефть чыгаралар; ялкынланып янган утлары төн буена соргылт күк йөзендә нәҗәгайдай уйнап тора...

Мин Агыйдел буйларының искитмәле ямена карап, миңа кадәр уникe буын элек болгар угланы Гәрәй бабабызның яр-юлдашы, карендәш-якыннары белән Казан йорты Масрадан баш бирмичә чыгып киткән, арлар[1] иле аша ике Идел кичеп, бу җирләрдә торак тапкан чагын гүя үзем күргәндәй күз алдына китерә алам... Борынгы Чулман белән Ак Идел килеп кушылган бер кыйтга. Кеше кулы тимәгән урманнар, киекле болын-тугайлар. Кичә-көнлек бу тараф, кичәкөнлек ул тараф җирләрдә чын кышлак кормыйча башкортлар (истәкләр) ыругы гына быел монда, ярен анда җәйләп-кышлап йөри. Ыруг җирләре күп, хәтта чикләре дә мәгълүм түгел: болын-тугайларында елкылдап чапкан елкы көтүе; елга-күлләрендә балык, кондыз; карт юкә, имән куышларында кыргый корт балы... Башкорт инде Болгарын белә, Казанын белә. Алар аша ул дин алган, хәреф алган, алардан күреп иген игү эшенә дә ихлас бирә башлаган. Ул Болгарның үсүенә дә, һәлакәтенә дә шаһит. Бәлки шуңадыр, болгар дигәндә күңеле дә япандай киң, иркен...

Ә чынлап уйласаң, кемнәр генә килеп сыенмаган башкорт иленә! Бату ханның исәпсез-сансыз бәни әсфарлар кавеме[2] баскыныннан соң Дәште Кыпчак бетеп — кыпчагы, Бөек Болгар җимерелеп — болгары агылып килгән; Аксак Тимер белән Туктамыш хан арасындагы яман кыргыннан соң икенче кабатка янә болгар агылган; инде Казан җиңелгәч, егерменче йөзгә кадәр тукталмаган өченче агым килә. Башкорт инде бу агымны туктата да алмый,— я үзе буш җирләргә күчеп китә, я тел берлеге, дин берлеге аркасында килгән беренә өлеш чыгара. Ул шулай Гәрәй бабабыз белән карендәш-якыннарын да үзенә сыендырган. «Танып тамагыннан алып Ак Иделнең түбән тарафы ике якка таралмыш сулары, койгучы елгалары, тугай-камышлары, арка вә яланнары илә сезгә булыр; суларыннан кондыз, урманларыннан киек тотарсыз...» дигән. Гәрәй бабаларыбыз яңа ватанда нигезе болгардагыча һиммәт кышлак йортлар корып, башкорт белән ут күрше булып, өйләнешеп, кыз бирешеп, «Идел буйлары вә урманларында бал корты илән, суларында кондыз, камасы илән, яланларындагы йөкерәк төлкү, сусар-

---

[1] Удмуртларны элек ар дип атаганнар.
[2] Сары тәнле халык, сары раса.

ларыйна сунар кылыб, сука илән җир сөреб, иген игеб гани улганлар...» Башкорт туфрагында нәсел шулай башланып киткән.

Пугач явыннан күп алда, инде җиденче буын Акман бабабыз, Болгар иленнән[1] яңа гына килгән Апанай (Әпәнәй) гаиләсе белән туганлашып, янә мөселман диненә чыккан бер мари кешесен алып, Идел Эченнән Кыр Ягына — иген уңдырышлы җирләргә күчеп утырган. Төрле юллар, ысуллар белән башкортның үзеннән, я ак патшадан башкорт җирләрен алу-алмауларына, ягъни бары тик җирле-җирсез булуларына карап, безнең нәселдә дә уникe буын дәвамында башкорты булган, типтәре булган. Ләкин, нинди генә рәвешкә кермәсеннәр, алар үзләренең асыл болгарлыгын иман кебек саклаганнар (чөнки татар исеме татар халкына унтугызынчы йөз ахырында гына ныклап йога башлый); нәсел башын Казан йорты Масрага, бик борынгысын Болгарга илтеп бәйли торган булганнар. Безнең телебез дә, йөзебез һәм моңыбыз да үзебезчә калган. Гәрәй бабамнар белән бергә күчеп килгән марилар безне әле һаман «суаз» ди. Ә суаз яки суар — болгарның бер кабиләсе булган. Рәхмәт онытмауларына.

Ә сезнең «Казанны яу алган көй»не ишеткәнегез бармы? Минем — бар. Ул көйне безгә анам ягыннан туксан яшенә җитеп үлгән бабам уйнаган иде. Тик мин аны ике генә кабат ишетеп калдым. Кайгылы сугыш чоры иде. Берсендә сугышта ирләре, уллары үлгән сагышлы аналар җыелып үтенгәч уйнаса, икенче кабатында тең үзе генә моңланып уйнады: өченче улының да үлү хәбәре килгәннән соң иде монысы. Йөзендәге бер сырын да кыймылдатмыйча, яшьсез генә уйнады-уйнады да: «Җитәр, күп уйнасаң, көйнең дә төсе уңа» дип, үзедәй карт венский тальянын сандыкка салып куйды. Казан моңы шулай, бабамның хәсрәт тулы йөзе сыман, күңелемә уелып төшсә дә, авызымнан көй булып чыга алмады. Тиздән бабам үзе дә бу дөньядан кичте,— шулай итеп моңын йөрәгемә салды да көен үзе белән мәңгегә алып китте...»

Мин Агыйделнең түбән карасаң башлар әйләнмәле Төбә ягы өстендә басып торам. Миннән бик түбәндә, иң аста, эссе җәйдә кимеп, ярлары ачылып беткән Агыйдел ага. Ага да ага, ага да ага... Синең суларың белән генә дә буш диңгезләр тулып түгелгәндер инде, Агыйдел! Ярларың да, кеше гомере сыман, кителеп-кителеп кенә юыла тора, юыла тора... Пугач явын бастыргач, башкорт иленең Салаваттай асыл ирләрен асып, күпме дар агачы агызганнар синнән, Агыйдел! Алар сал өстендә җил-дулкынга чайкала-чайкала акканнар да акканнар, акканнар да акканнар — гел бер таба, гел түбән таба...

Ләкин егерменче йөз башында кинәт, агымга каршы юл ярып, Агыйдел буйлап, яңа гасыр авазын салган Владимир Ульянов узып киткән. Мин басып торган ярга да карап узган ул Ленин... Соңыннан аңа меңнәр, миллионнар ияргән...

Агыйдел!

Синең ак суыңа халык азатлыгы өчен бу җирләрдән дә кәрәшеп үткән Чеверев, Чапаев каһарманнарының да каны коелган бит!.. Аклар афәте дә үткән моннан. Нәкъ менә мин басып торган яр читенә бастырып, күпме коммунистны атып киткәннәр аклар. Ул шәһитләр каны да синең суыңда бит, Агыйдел! Бәлки ярың да шуңа кызылдыр...

И газиз аналарыбыздай күпне күргән Агыйделем!..

---

[1] Хәзерге Татарстан җирен башкортлар 19 йөзгә кадәр Болгар иле дип йөрткәннәр.

Бу сугыш елларында без этиләребезне пристаньнан туры фронтка озатып җибәргәч, тыннарыбыз бетеп шушы ярга менә идек тә, соңгы кабат карап калырга теләгәндәй, пароходның куе төтене Йолдыз-Тау зәңгәрлегенә эреп югалганчы карап тора идек. Китте дә утка керде, китте дә утка керде безнең этиләр...

Агыйдел!

Мин синең бүгенге тыныч, иркен-рәхәт, якты ярыңда басып торам. Миннән бик түбәндә, кызыл яр тирәли, уйнап-уйнап кәрәшәләр генә очып йөри. Илгә иш булган Илешем басуларында да, болгар бабаларыбыз шикелле, иген игүдән башканы белмәгән, теләмәгән халкым эшли — Илем данын үстерәләр. Тик мин әле үткәннәрне уйладым. Чөнки бүгенгенең берсе дә төче камырдан гына әвәләп ясалмаган,— урак өстенең монарланып кызган һавасында битләргә ягылып үткән җепселдәй, барыбызның да бик ерактан өзелмичә килгән тамыры бар, тик без аны белмибез генә. Хуп, бик ерактан килгәнен күбебез белмәсен дә ди, анысы тарихка калсын ди, ә якынын барыбыз да җитәрлек микъдар беләбезме соң? Инде бабайлар гына түгел, этиләребез дә, кайтмаска китеп, җәйге сулар кебек саега, бетә баралар. Ә бер уйласаң, шушындый да шаулы гасырыбызның кырык елы эчендә генә дә алар гомеренә нәкъ өч сугыш, өч революция туры килгән!.. Без шуларны белергә тиешме? Тиеш! Алар кабызган революцион ут, каннан канга күчеп, безнең йөрәкләрдә дә яна. Һиһаять, без бөек бәрелешләрдә алар яулап, безнең кулга тоттырган бөек бәхетнең, Икмәкнең кадерен белү өчен дә үткәннәрне белергә тиеш. Алар кигән чабатаны сөйләгәндә дә чырай сытып түгел, ә күңел колагын салып, чабатага ихтирам белән тыңларга тиешбез...

Мин Агыйделнең еракларга төбәлеп торган Төбә яры өстендә битләремне астан искән җылы, дымлы, чәчәкле болын җиленә куеп басып торам. Күз күреме җирләрдә болын да эрәмә, болын да эрәмә; ә шулар эченнән, ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап, Агыйделем ага.

Агыйдел!

И минем туган җирем — уникe буын буена сулап туймаган сулышым!..

Февраль, 1972.

## Рәдиф Гатауллин

# МАРТ-АПРЕЛЬ

### «Уел»

Х. С. га

Күпне күргән сиксән яшьлек әби
Бер җырлады безгә «Уел»ны;
Күзләр коры иде, тавышындагы
Яшьләр гүя җанга коелды...
Агыйделнең көләч ярларында...
Шатлык иле — Илеш ягында,
Тарих, бәлки, безгә очрагандыр
Аһәңнәре, моңы сагында?
Уел алды гүя йөрәгеннән
Еракларда килгән сагышны —
Агыйделнең үзенә охшап акты
Халык моңы, җаны, тавышы...
Җилләр исте... батыр ирләр үтте,
Илләр үтте кичеп уемнан;
Ил язмышы йөрәкләргә безнең
«Уел»лары белән уелган.
Бар булганы белән халык җаны
Яшеренгән шушы моңнарга...
...Ятим моңнар, ятим җырлар булмас
Халык яшәгәндә, ил барда.
Озата барыр киләчәккә шулар...
Онытып буламыни үткәнне? —
Заман — үзгә, тормыш — үзгә, яңа,
Ә чын җырлар — иске, күптәнге...
Искә төшереп гүя гамьсезлектә
Онытылган изге уемны;
Җаны белән бөек типтәр әбие
Уятты бер уйда «Уел»ны,
Моң уятты уйда...

●

Тормышының борчу, низаглары
Һаман ача иске ярасны;
Аерылулар — җанның җәрахәте,
Нечкә җанда алар — дәвамлы.

Югалтулар, авырлыклар хисе
Баетадыр җырга шагыйрьне? —
Ә кемгәдер кыйммәт җыр әҗере,
Фаҗигаңнең алтын яңгыры...

Ваклыкларын күреп яшәешнең
Канатлары сынса күңелнең;
Ятим күңел белән яшәсәк тә,
Ятим итмик инде шигырьне...

Бурычларың искә төшереп дөнья
Искәртсә дә һәр көн җаныңны,
Түләү өчен гомерең җитмәсә дә,
Киләчәк бер аклар шагыйрьне,
Җырда танып матур җаныңны!

## Биек йолдызларга

Үпкәләмим — бик биектән карап
Көлгән йолдызларга.
Һич кинәм юк — миңа югарыдан
Караган кызларга...
Очрашырга мине чакырса да,
Килмәде гүзәлләр,
Минем хисләремнән көлке эзләп
Кинәнде гүзәлләр.
Күзем бәйләп, юри уен өчен
Ташладылар суга.
Бата язгач, салам сузды алар
Миңа тотынырга...
Ләкин һаман кимемәвен күреп
Мәҗнүн хисләренең,
Минем дуслар белән китте алар,
О, бу истә минем!
Суындыммы хәзер? Күзем ачып,
Үзгәрткәндер вакыт?
Белмим... искә алу шул чакларны
Шатлык миңа, бәхет.
Мин ихтирам саклыйм ул көннәргә,
Яшьлек, шашкын хискә.
Алар — кабатланмас җырлар иде,
Газап түгел һич тә.
...Юк, үпкәм юк сезгә, мәхәббәттән
«Дәрес» биргән кызлар.
Элеккечә янсын, көлеп янсын
Биектә йолдызлар.

●

Карлар яуды, яуды карлар,
Беренче карларым.
Карлар яуды. Ник аларга
Мин каршы бармадым?
Тәрәзәдән карадым.

Кар эреде, тагын яуды...
Аклыкны яраттым.
Карлар яуды — юлларымны
Күмсәләр — тараттым...
Бакчага кар аттым...

Карлар яуды — бураннары
Сыерчык, карганың...
Карга күмелеп, нәрсәмнеңдер
Мәңгегә калганын
Мин хәзер аңладым...

...Карлар ява, гомер бара...
Белсәм дә, карганмыйм.
Бер көн аяз күңелем аша
Соңгы кат карармын.
...Явыгыз, карларым!

●

*30 март, 1972*

Туган көнем. Тагын бер яшь артты,
Тагын тойдым вакыт үткәнне...
Шушы вакыт әллә хыялыма
Кагылмыйча читләп киткәнме?
Кара, аның һаман яль-яшь чагы,
Сабый акылы — бөтен булганы,
Ул һаман да, әнием! — диеп, башын
Итәгенә куя дөньяның...
Хыялның да, бәлки, туган көне? —
Мәҗлесебез... эчми исерәм,
Йолдызларын санйым, энҗеләренең
Исемнәрен искә төшерәм.
Киңлек-биеклекләр — аның йорты,
Чиксезлекләр — барыр юллары,
Ай-кояшка кабынып мәхәббәте,
Йолдыз итеп яза җырларын.
Чынбарлыкка — тормыш, кануннарга
Иярәшмәс төсле иде ул,
Иңнәрендә барысын күтәрергә
Әзер иде, көчле иде ул;
Юлга фатихасын алган көннән
Менде җирдән өскә, яктыга...
Чакырсам да, кире кайту кая,
Догаң нәрсә аңа, бәддогаң.
Үзенә остаз хәким, хөр җаннарның
Әйтерсең лә бер-бер варисы —
Тәгълиматын җыя — таныш аңа
Хыялстан иле тарихы.
Тугачтан ук коенып үскән гүя
Оптимизм күлләрендә ул,
Кагылмаган ләкин төнбоекка —
Пессимизм гөлләренә ул.

Чиге кая ышанычка юлның,
Башынияр мәллә үлемгә?!.
Ихтыярын — атын иярләгән,
Кояшларга юлы — бүген дә...

Хыялымны котлый туган көнем...
Саный сәгать вакыт үткәнне.
Хыял...
Яшьтәшемме, туганыммы?
Мәңге ять-яшь калыр бүтәнме?

...Тагын бер яшь артты... Туган көнем...

## Дөнья бит...

Әйтерсез,— кемнәр ул,
Сорарсыз — ул кайда?
...Казанда, «көчекләр»
Өргәннәр Тукайга.
Тукайга!
Йолдыздан көнләшеп,
Түбәннән өргәннәр.
Иснәнеп яманын,
һау-һаулап йөргәннәр
Заманның этләре! —
Өргәннәр ал-арттан,
Газеттан өргәннәр,
Болактан, почмактан...
Тик Тукай көчлерәк
Яндырган йолдызын;
Ул янган — саф, якты,
Төнен һәм көндезен,—
Халкымның йолдызы!
Булган бит заманнар,
Булган бу — Казанда...
Бер гаҗәп хәл кебек
Бу — безнең заманда.
Максатлар — бер, уртак,
Теләкләр кояшлы...
Йолдызга урын күп,
Күгебез — колачлы.
Гайбәткә урын юк,
Дөньябыз түгәрәк:
Бәхетебез карлары
Күбәләк, күбәләк...
Тукайга тиң булыр
Юк болай юклыкка,
Шагыйрьгә, әдипкә
Юк бугай кытлык та.
Этләргә бәхәскә
Урын юк бугай да...
Дөнья бит:
Кайвакыт
Өрәләр шулай да...

## Сәлам

Салават премиясе лауреаты
Нәҗар Нәҗмигә

Уралларга барсаң, туктал, болыт,
Уфаларга туктап сәлам әйт:
Ат өстеннән үрелеп кенә сине
Тартып алыр, бәлки, Салават.
Уралларга барсаң, җил, күреп кит,
Узаманнар рухы сәламәт.
Җыр укларын, ирлек җәяләрен
Иленә мирас иткән Салават...
Яманатлар түгел, дан атлары
Халык улларына әманәт.

Шагыйрьләренең сабантуе, бәлки,—
Уфаларда күпме азамат! —
Үз кулыннан бүләкләрен бирер
Баһадирларына Салават.
...Халык күңеледәй ак сөлгеләр,
Ак сөлгедәй күңел — аман, ак...

Уралларга барсаң, туктал, болыт,
Уфаларга, җилкәй, сәлам әйт! —
Атта җилеп, Тукай бәйрәменә
Килеп китсә иде Салават,
Сәлам әйт!

●

Хыялымда минем Кояш яна,
Яна алтын Кояш! —
Шул кояшның эссе нурларыннан
Җаным мәңге туймас.
Хыялымда алтын Кояш, тоташ
Ак алтыннан койган.
Йөзен тирәләгән алтын чәчләр,
Битен алтын юган.
Алтын Кояш яна, алтын бәхетем,
Якты көнем — кичем;
Алтын нурлар белән алтынлана
Өнем минем, төшем.
Ул — бүлмәмдә китапларга төшә,
Өстәл, кәгазьләргә...
Уйламастан җылы бирә — суык
Фикер, вәгазьләргә.
Шатлыгыма кучә, уйларыма,
Юлларыма бага.
Ничә еллар шулай яна-яна
Минем белән бара.
Хыялымда алтын Кояш яна,
Яна табӱ — Кояш;
Әрсезлегем, ялгышып та, аңа
Кул сузарга кыймас.

●

Нәрсә әйтим баш бирмәгән ярсу
Толпар атларыма?! —
Тагын кайтам менә — язларыма,
Мөслим якларына.
Оныттырып дөньям, гамь-шөгылем,
Җан канатым — шул ат,
Нигә һаман шунда каера әле,
Ярсып, шашып, дулап?
Нигә анда кайту? Хәзер миндә
Башка мәшәкатьләр.
...Улыма калсын хәзер ярсу атлар,
Шашкын мәхәббәтләр.

Кичтем күптән хис-моң Рубиконын,
Нәрсә кирәк тагы?
(Инде ыргып үтәлмәссең, Ыкның
Ташып аккан чагы!)
Анда — хыял кызы... Күңелемдә
Элеккечә калсын!
Ул кабызган йолдыз яна һаман,
Элеккечә янсын,
Нигә карау хыял аръягына,
Үткән кире кайтмас,
Үткәннәрнең урамы тын инде,
Йортлар күзен ачмас...
Тик, ни әйтим — тыңламыйча чапкан
Тойгы атларыма?
Тагын кайттым (ничәнче кат) языма,
Мөслим якларына.

●

Кал җырымда, апрель булып кал син?! —
Якты таңдай син бер балкыдың,
Мартта туган җаным шунда белде
Апрельгәчә дөнья салкынын.
Апрель булып килдең, юк, май түгел
Мәңге миңа апрель булып кал;
Мәңге шулай якты булсын кичләр,
Сабый яшьле булсын болытлар,
Апрель булып кал син! —
Бөреләрнең
Тик ачылган чагын, саф чагын,
Каеннарның суы ташыган мәлен
Күзләреңдә мәңге сакларсың,
Апрель булып кал тик!—
Ташкын сулар
Күңелеңдә калсын — шул килеш,
Төенләнгән килеш торсын сорау,
Юк, кирәкми җавап, чишелеш...
Апрель килеш...
Беләм, табигатьнең
Үзгәрмәгән юк бер мизгеле;
Тукталу юк сиңа, алда көтә
Яшьлек — яшел урман шикелле.
Көмнәргәдер хәзерләнгән бәхетең
Елап ашыктыра майларга...
Юк, туктатып булмас бугай аны,
Күңелең синең әллә кайларда,
Ләкин миңа апрель булып кал син,
Минем өчен — апрель булып кал?
Җырларымда синең Кояш яна,
Елау катыш көлә болытлар...

Кал җырымда, апрель булып кал син!

●

Хәл белергә килеп чыктың безгә,
Озын булган юлың,
— Арыгансың, ял ит, апа, диеп,
Урын бирде улым.
Без утырдык аннан тып-тын гына;
Сүзләр — күптән беткән.
Белдек шуны: тормыш сөюдән дә
Мәшәкатьле икән.
Истәлекләр тавын кузгатмадык,
Кары ишелер төсле! —
Таудан түбән төшүе дә авыр,
Тормыш — бездән көчле...
Чылтырап торган сулар кебек сүзләр
Әллә кая, тынган,
Кайчак иелеп кенә су аласы
Бик килсә дә шуннан,
Кипкән барысы — күзгә чыкмый яшь тә,
Бирелсәң дә хискә.
...Чишмә — тау астында, сирәк очрый
Менгән саен өскә...

Хәл белешергә килгән идең безгә,
Кайтыр юлың ерак.
— Караңгыга калам, китим,— дидең.
Мин озаттым...
Авыр истәлеген
Озатып кайтты йөрәк...

●

Кая ашыгасың? Зур юлыңның
Бәлки, башында син,
Карурманнар очрар, көчең сакла,
Кая ашыгасың?
Кашка атлар, алмачуар атлар...
Меңдең кайсына син?
Теләкләргә тизрәк җитәргәме? —
Кая ашыгасың?
Алда таулар, сикереп үтәрсеңме? —
Тукта, ярсынма син! —
Түгел Рәсүл — бөркет канатлы ир,
Түгел Кайсын да син,
Кая ашыгасың?
Исемең яздың тимер дага белән
Кыя ташына син;
Ир-егетләр җырын җырла шуннан,
Кая ашыгасың?
Алда — диңгез, кырмыскадай нәни
Аның каршында син;
Корабың көт, йөзеп чыгалмассың,
Кая ашыгасың?

Дөнья — чиксез, табалмассың ахырын,
Һаман башында син...
Ул ашыкмый, кабаланмый,
Ә син
Кая ашыгасың?

## Сәет Шәкүров

# ТУГАН ТУФРАК

ДРАМА ӨЧ ПӘРДӘДӘ

КАТНАШАЛАР:

Галина (Галимә)
Арслан Ахъяров
Игорь Валерианович
Сабира түти
Зарифа карчык
Маргарет (Мәрьямбану)
Курка Сөләйман
Хәйдәр
Мәликә
Юнусов
Гариф
Илдус
Тәнзилә

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Июнь ае. Сабира түтиләр ишегалды. Кичкырын. Урам буйлап Гариф солдат гармун тартып җырлап килә.

Безнең авыл чокыр-чакыр,
Чокыр башы тыкырык;
Исән булсам, бер кайтырмын,
Дошманны тар-мар кырып.

Өйдән Сабира түти йөгереп чыга.

Сабира. Кайсы ул анда? Оныгымны уята бит!

Киртә буена Гариф килеп туктый.

Гариф. Исәнме, Сабира түти! Менә без дә кайттык.
Сабира. Гариф, сау гынамы, улым, кайчан кайттың?
Гариф. Бүген. Иртә белән генә. Кая, киртә аркылы гына булса да бер үбим әле үзенне.
Сабира. Нигә киртә аркылы, әйдә, өйгә кер. Кунагым булырсың.
Гариф. Арслан да кайткан диме?
Сабира. Кайттылар, кайттылар. Әле шушы арада гына кайттылар.
Гариф. Чакыр әле, солдатларча бер кочаклашып алыйк әле үзе белән.

Сабира. Казан аслык кына коры-сары алып кайтыйм дип, кечкенә арба белән урманга киткән иде.

Гариф. Демобилизованный солдат арба тартып йөрергә тиешмени, понимаешь? За что воевали?!

Сабира. Аты юк бит колхозда...

Гариф. Айгырын бирсен Күркә Сөләйман. Менә хәзер мин аның барып якасыннан алам да тарантасыннан сөйрәп төшерәм, рессорлы тарантасына имән ботагы төяп кайтам урманнан.

Сабира. Алай ярамый.

Гариф. Ә нишләргә соң миңа? Сабира түти, син әйт, нишләргә? Әнием 1942 елның салкын кышында... ачлыктан шешенеп...

Сабира. Сөйләмә юкны, илдә кеше ачтан үләмени? Тәрбияләдек әниеңне, бөтен авыл белән тәрбияләдек, нишлисең, авыруы көчле булды шул.

Гариф. Менә кайтып төштем ялгыз йортка. Тәрәзәләре ватылып беткән, ипи шүрлекләренә кадәр тузан баскан. Ә ул, председатель кеше, тәрәзәләрен генә булса да кадаклатып куя алмаганмыни солдат йортының... Барып йонын гына тузгытыймчы шул күркәнең...

Сабира. Ярамый, балам, син бит акылсыз егет түгел.

Гариф. Разведчик. Күрәсеңме бу орденнарны?.. Дан орденнары болар, дан! Тагын берсен алсам, полный кавалер була идем, офицер! Ә хәзергә әле сержант кына. Арслан өйләнеп кайткан диме?

Сабира. Әйе, улым. Бик чибәр, бик акыллы килен алып кайткан үземә. Оныгым да бар.

Гариф. Украинаданмы?

Сабира. Әйе, шуннан.

Гариф. Шәп алар, украинкалар. Ә икмәкне ничек пешерә алар?! Исе борынны ярып керә.

Сабира. Икмәкне үстерә белгән кеше пешерә дә белә шул, улым.

Гариф. Кырык дүртенче елны оборонада торганда минем дә бер украинкам бар иде. Әсхәпҗамалыма хыянәт итәсем килмәде. Кайтсам... Ул анә кияүгә чыккан.

Сабира. Табылыр әле, улым. Әсхәпҗамаллар белән анә урам тулган, тик менә Гарифулла балакайлар гына сирәк кайта. Сугыш беткәнгә ай ярым узды.

Гариф. Калдылар шул, Сабира түти, сугыш кырында күп калдылар. Ярый, мин Арслан янына соңрак килермен әле. Яна бит, йөрәк яна...

Гармун тартып, урам буйлап җырлап үтә.

Безнең авыл чокыр-чакыр...

Сабира. Аллага шөкер, авылга тереклек керә башлады. Тукта әле, Илдус балакаем уянганчы, кичә Галимә киленем алып кайткан кузгалакны эшкәртеп куйыйм әле. *(Өйгә кереп аннан бер алъяпкыч кузгалак алып чыгып, болдырга утыра да кузгалакның яфракларын сабагыннан аера башлый.)*

Күрше ишегалдында — Зарифа карчык тавышы.

Зарифа. Ти-ти-ти... Ти-ти-ти...

Сабира. Тавыкларың кунаклагандыр ич инде, Зарифа түти, нәрсәгә бимазалыйсың?

Зарифа Менә бер яшь этәчемне таба алмыйм, сезнең лапас тирәсендә түгелме икән?

Сабира. Бар, әнә кара, үзем дә рәтләп аера алмыйм мин чебиләремне.

Зарифа. Анда кереп йөрмим инде, иртән торып чыгар әле, теге як күршеңә үк кереп кунакламаган булса. Һай, сине, Сабира күрше,

киленем кайтты дип, бер дә тик ятмыйсың, кара, никадәр кузгалак җыеп кайткан.

Сабира. Кирәк бит.

Зарифа. Әллә бүген колхоз эшенә дә бардың инде?

Сабира. Бармыйча, миңа каенана булырга иртә әле.

Зарифа. Кунакларыңны кузгалак шулпасы белән сыйларга булдыңмыни?

Сабира. Юк, каз бәбкәләренә ул.

Зарифа. Синең каз бәбкәләрең юк бит.

Сабира. Минеке булмаса, энә, теге як күршенеке бар.

Зарифа. Киленең кая? Бүген күренми. Әллә, кайтып җитмәс борын, ул да колхоз эшенә китте ме?

Сабира. Юк, районга китте.

Зарифа. Шул кадәр җиргә... Җәяүме?

Сабира. Айгырга атланып.

Зарифа. Кайсы айгырга?

Сабира. Яшел айгырга.

Зарифа. Җирән айгырга димәкчесеңдер. Аның кара айгырына Күркә Сөләйман үзе генә утырып йөри. Ә менә җирәнен вак-төяк йомышка биргәли бугай. Әмма район хәтле җирдән әйләнеп кайтырлык түгел ул җирән айгыр. Хәле юк, ава.

Сабира. Ә безнең яшел айгыр аумый.

Зарифа. Ә... Самоход дигәнен әйтәсеңдер әле. Бик укымышлы нәрсә күренә килене, самоходларга гына утырып йөри, берәр нәчәллек булырга киткәндер әле районга.

Сабира. Начальник түгел, укытучы ул. Ронога китте.

Зарифа. Кайсы авылда укытачак?

Сабира. Үзебезнең авылда.

Зарифа. Татар балаларын укыта алыр микән, безнең кеше түгел диләр бугай килененне.

Сабира. Нишләп безнең кеше булмасын, үзебезнең кеше, саф мөселман.

Зарифа. Аныс мөселман ук түгелдер инде, аның татары да мөселман түгел хәзер.

Сабира. Ә минем киленем саф мөселман. *(Шаяртып.)* Амин итә, дога кыла.

Зарифа. Кит әле, көлмә әле, Сабира күрше.

Сабира. Чын әгәр. Әле үземнән намазлык таптырып теңкәмә тиде. Намаз укыйм, ди.

Зарифа. Синең үзеңә дә юк инде ул намазлык, намаз кешесе булмагач.

Сабира. Бар иде. Намазлыкларым күп иде минем, Зарифа түти. Әле нинди генә чиккәннәре бар иде.

Зарифа. Соң?

Сабира. Күп укыдым мин намазны сугышның беренче елларында. Иремнең үлгән хәбәре килде, шушы Арсланым хәбәрсез югалды, ә мин һаман укыдым. Аннан уртанчысы үлеп, кечесеннән дә хәбәр туктагач, укымас булдым. Барлык намазлыкларымны оекбашларга алмаштырып бетердем дә, улларымның исән калган иптәшләренә адреслап, фронтка посылка җибәрдем.

Зарифа. Аныс инде барыбыз да хәл кадәренчә җибәреп тордык. Менә мин дә, картым вафат булгач, туның, толыбын, киез итекләрен, хәтта бияләйләренә кадәр җибәрдем. Тик менә намазлыкны гына ташларга ярамый. Бигрәк тә картайган көндә...

Сабира. Кем белә, картайгач, бәлки, без дә утырырбыз намазлык өстенә. Ә хәзергә вакыт юк. Кулда көч барында эшләргә кирәк, Портны, колхозны аякка бастырырга кирәк.

Зарифа. Болай булгач, бастырырсыз инде, алла боерса. Киленең дә бик унган күренә... Малаең да, әнә, «уфалла» тартып кайтып килә. Без әле кунак, дип тормыйлар, кайткан көнне үк тырыша башлыйлар. Кечкенәдән тырыш булдылар шул синекеләр...

Сабира. Шулай инде, керәстияннең тормышы тырмашып бара бит ул, Зарифа түти. *(Зарифа читән аша үз ишегалдына чыгып китә. урам яктан, утын төягән кечкенә арба тартып, Арслан кайтып керә. Сабира түти аны каршы ала.)* Кайтасыңмы, балам, тукта, тукта, үзем ачам капканы!.. Әбәү лә... Бигракләр дә күп төягәнсең. Ярар, аудар шунда.

Арслан. Галимә кайтмадымыни әле?

Сабира. Кайтып җитмәде шул әле, балакаем. Нишләптер озаклады. Әллә кайтышлый бүген дә Чаптырган чишмәсенә тукталган инде.

Арслан. Чаптырган чишмәсенә? Анда нишли?

Сабира. Кузгалак җыя. Кичә дә әнә никадәр җыеп алып кайткан иде. Ашы бик тәмле була икән аның, жиренә җиткереп пешергәч. Ә син юына тор. Комган да, сөлге дә лапас астында.

Арслан *(кесәсеннән газетага төргән бер кечкенә шешә алып бирә)*. Менә, моны алып кереп, шкафка куеп тор әле, әни.

Сабира. Бу нәрсә бу?

Арслан. Лесхоз кибетеннән алып кайттым.

Сабира. Әй, бала, авырлыкны шушы нәрсә белән юарга өйрәнәсеңмени инде? Сиңа килешми ул.

Арслан. Юк ла, үземә түгел.

Сабира. Кемгә?

Арслан. Сөләйман абыйга, шулпа янына дәшеп алырга кинәш иткән иде Хәйдәр.

Сабира. Майларгамы?

Арслан. Йоласы шул ди бит.

Сабира. Юк, улым, бездә андый йола юк, булмады да. Безнең йортка кергән нәрсә түгел бу, син аны үзең яхшы беләсең. Шулай булгач, алып та кермим, шкафка да куймыйм. Әнә, Илдус уянды бугай... *(Кузгалакларын җыеп өйгә кереп китә. Икенче як күрше ишегалдыннан Маргарет түтинең җырлаганы ишетелә.)*

Җыр:

И пока за туманами
Видеть мог паренек,
На окошке у девушки
Все горел огонек...

Маргарет *(җырлый-җырлый, ике ишегалдын урталай бүлгән койма янына килә)*. Нихәл, чибәр егет? Кайтканыңа ни гомер, читән аша ияк кагып кына исәнләшкән буласың. Өемә бер кереп утырыр идең, күрер идең... Минем ише солдаткаларның хәлен сез дә белмәгәч... Кулыңда нәрсә ул?

Арслан. Арба майларга дип алып кайткан идем

Маргарет. Ярамыймы?

Арслан. Әни ярамый ди.

Маргарет. Синең әниең нәрсә белә ул. Кая, китер монда, үзем майлап күрсәтим.

Арслан. Мә, ал! *(Читән аша шешәне Маргарет түтигә бирә.)*

Маргарет. Әйдә керик.

Арслан. Кая?

Маргарет. Өйгә.

Арслан. Үзең генә майла инде, Маргарет түти.

Маргарет. Монда аз, җитмәс дисеңме? Курыкма, минем өйдә

тагын бар. Солдатка дигәч тә син мине... Аттестатлы солдатка ла мин. *(Пышылдап кына җырлап күрсәтә.)*

...И у детской кроватки тайком... *(Арслан бер сүз дәшми борылып китә башлый.)* Тукта, тукта, алай бик эре кыланма. Мә, хеть, акчасын ал. *(Кесәсеннән утызлык акча чыгарып суза. Арслан аның акчалы кулын этәреп, шешәне тартып ала, озак итеп шешәгә карап тора.)*

Арслан. Йоласы шул дидемме әле мин? Нинди түбәнлек. *(Шешәнең башын түбән ия, аракы җиргә ага, бушаган шешәне читән аша томыра.)* Чирканыч хәтта. *(Китеп китә.)*

Маргарет. Фу, кыланышы. *(Өенә борыла.)*

Урам яктан Маргарет түти коймасы буена Күркә Сөләйман килеп баса.

Сөләйман. Маргарет!

Маргарет. Күреп килүеңме, сизеп килүеңме? Борының, шайтан!

Сөләйман. Күрмәдем дә, сизмәдем дә. Иртәгә кибәк суыртырга дәшүем.

Маргарет. Кибәкне әнә теге бозаудан суырт инде син.

Сөләйман. Аңа кибәк дуверять итә алмыйм. Кибәктә җурна бар.

Маргарет. Кибәк җурнасы белән генә юмаламакчы буласыңмыни инде син мине?

Сөләйман. Юк ла инде, эшкә кушабызмы сине, кушабыз, даже үзем килеп дәшәм.

Маргарет. Шул гынамы?

Сөләйман. Нәрсә шул гынамы?

Маргарет. Эшкә дәшәргә генә йөрисеңмени син минем яныма?

Сөләйман. Сабыр, сабыр...

Маргарет. Бик күп сабыр иттем инде мин, шул җомыкый хатыныңны ташлап чыга алмагач...

Сөләйман. Балалар да бар бит анда.

Маргарет. Алайса, шул кәкре сыйраклы балаларыңны гына кочаклап ят инде син, яме? Минем яныма больше килеп йөрмә. Әнә хәзер демобилизованный солдатлар көн саен кайтып тора. Тотам да йортка кертәм берсен.

Сөләйман. Тукта инде, үпкәләмә инде, җаный. Йортны ташлап чыгу, йортка керү алай капылтын гына эшләнми бит ул.

Маргарет. Мин артык көтә алмыйм, вакыты шундый. Я шушы атнада күчеп киләсең минем йортыма бөтен манаткаларыңны алып, я булмаса...

Сөләйман. Ярый, ярый, әнә, кемдер килә.

Урамнан чалгы күтәреп килгән Мәликәне күрә.

Сөләйман. Иртәгә эшкә, Маргарет килен, менә шул! *(Мәликә каршына төшә.)* Тукта әле, кызым, тукта әле, син бүген кайда идең?

Мәликә. Кычыткан чаптым.

Сөләйман. Кайда?

Мәликә. Урманда.

Сөләйман. Мин хәзер генә шуннан кайттым, чалгың белән берике селтәнгәнсең дә качкансың.

Мәликә. Аланлыктанмы? Ул ачык аланлыктагы кычытканны чапмадым мин.

Сөләйман. Ә каян чаптың?

Мәликә. Урман эченнән, агач күләгәсеннән.

Сөләйман. Җүләр, чүпрәк баш. Аланлыкта кычыткан котырып үскән, чалгың белән кереп күмелерлек, күләгәдән кычыткан җыеп йөреп, кайчан тутырмакчы буласың син ул базны?

Мәликә. Алан кычытканы силоска ярамый, картайган, ди, урман күләгәсендәге яшел кычыткан әйбәт, ди.

Сөләйман. Кем әйтә?

Мәликә. Мин аланда чапканда урманнан Арслан абый килеп чыкты. Шул әйтте.

Сөләйман. Арслан? Кайсы Арслан?

Арслан *(лапастан чыгып, киртә буена килә)*. Мин ул, мин әйттем.

Сөләйман. Син? Ә син кем соң? Бригадирмы, әллә...

Арслан. Кем булса да барыбер түгелмени, файдалы киңәш әйткәч.

Сөләйман. Миңа, энем, киңәш кирәкми, миңа күләм кирәк, тонна кирәк, план кирәк. Ничә тонна силос салырга план бирелгәнен беләсенме соң син?

Арслан. План дип кешеләрнең хезмәтен бушка түгәргә ярамый бит инде. Булгач, яраклы силос булсын.

Сөләйман. Силосның аның беркайчан да яраклы булганы юк, язын барыбер тирескә чыгарып түгәбез без аны.

Арслан. Аннан чәчү өстендә атларны арканга асып куябызмы?

Сөләйман. Тукта әле, син нигә кайтып кермәс борын руководство эшенә кысылып, әнтәгәнизм таратып йөрисең. *(Мәликәгә.)* Бригадир кая, Хәйдәр кая дим мин сиңа?!

Мәликә. Хәйдәр абый да шулай диде.

Сөләйман. Нәрсә диде?

Мәликә. Силос базына фәкать яшел кычыткан гына тутыр, диде.

Сөләйман. Телеңә салынма! Бар, иртәгә базың тулган булсын.

Мәликә. Юк инде. Мин алай хезмәтемне җилгә җибәрә алмыйм. *(Китә.)*

Сөләйман. Әнә күрдеңме? Синең әнтәгәнизмыңның җимеше.

Арслан. Агроном була торып, шул нәрсәгә күз йомып кала алмыйм бит инде мин, Сөләйман абзый.

Сөләйман. Миңа, энем, агроном кирәк түгел, колхозга кайткансың икән, әнә, кәнүшнине принимать итеп ал. Кунюх бул. Бастыр аякка әнә шул, үзең әйтмешли, арканга асып куйган атларны. Ә әнтәгәнизм... Ни, ни, ни!

Арслан бер сүз дәшми ишегалдына кереп китә.

Сөләйман *(Маргарет капкасына килә)*. Маргарет, кая, шкаф астында берәр нәрсәң юкмы, юкса, бу укымышлылар күбәеп китте колхозда.

Маргарет. Чыннан да, нигә кайтканнар алар шундый җирне ташлап бу караңгы авылга? Берсе агроном, берсе укытучы. Анда эш таба алмаганнармы? Әллә эзләрен җуярга кирәк булганмы? Кем белә аларның оккупацияләнгән җирдә нишләп йөргәннәрен? Сак кылан!

Сөләйман. Курыкма, Сөләйман абыең йоклап ята торганнардан түгел ул. Мин алар кайткан көнне үк районда булдым инде. Кирәкле кешеләргә хәбәрне салып куйдым. Чәпчи алмаслар. *(Өйгә кереп китәләр.)*

Урам яктан велосипед белән Галина кайтып керә. Каршысына Арслан чыга.

Арслан. Кайттыңмы? Арыгансыңдыр. Иөрмә. Шул кадәр җиргә йөрүдән нинди мәгънә бар?

Галина. Өзеп кенә әйтми бит алар берсе дә: «Менә карарбыз, менә хәл итәрбез, бераз көтегез...» — диләр.

Арслан. Кайттык, күрдек, житәр. Әнине алырга да китәргә кирәк.

Галина. Кая?

Арслан. Кире Украинага. Эшләми ятып булмас бит монда.

Галина. Синме соң моны сөйлисең? Кайтып төшкәч, җирне ятып үпкән кеше? Туган туфрагыңны?!

Арслан. Туган туфракка күз яше түгел, тиремне тамызыр өчен кайттым бит мин. Ә миңа кичә район җир бүлеге агрономы тыныч кына ял итәргә куша. Хәзергә вакантный урын юк, булгач үзебез чакыртырбыз, ди. Я, әйт, ял итеп ята торган вакытмы соң хәзер?

Галина. Чыннан да, нигә сон әле без икәүләшеп район юлын таптыйбыз. Тотарга да иртәгәдән үк колхозга эшкә чыгарга.

Арслан. Кем булып? Мин агроном, ә миңа конюх булырга кушалар.

Галина. Хезмәтнең кайсы да бер түгелмени?

Арслан. Бер. Ләкин бит мин үз белгечлегемдә күбрәк файда китерә алам.

Галина. Димәк, бүген колхозга агроном түгел, конюх кирәгрәк.

Арслан. Кем әйтте. Бүген басуда булдым, йөрәк әрни. Басу минем ярдәмне көтеп, елап утыра. Ә мин ат көтүе көтәргә тиеш.

Галина. Атсыз басуны эшкәртеп булмый бит, Арслан. Техника сугышта кырылды. Атлар аякларын сузалар... Нишләргә?!

Арслан. Әйе... нишләргә?

Сабира чыга. Арслан өйгә керә.

Сабира. Кайттыңмы, кызым?

Галина. Кайттым, әнкәй. *(Өйалды чоланына кереп өстен алмаштыра.)*

Сабира. Озак йөрдең, кызым, арыгансыңдыр. Әллә бүген дә Чаптырганга тукталдыңмы?

Галина. Әйе, әнкәй, Чаптырганга тукталмыйча китә алмыйм мин хәзер.

Сабира. Әле кузгалак күп иде бит.

Галина. Кузгалак җыймадым, чишмәсеннән су эчтем. Битемне юдым, хәл кереп китте. Бик тә шифалы су. Ә капчыкта кузгалак түгел, әнкәй, он.

Сабира. Он? Каян алдың?

Галина. Районнан. Паек бирделәр.

Сабира. Паек? Әллә эшкә урнаштыңмы?

Галина. Урнашачакмын. Көзгә. Әле бит мәктәпләрдә каникул. Ә паегын менә бирә тордылар.

Сабира. У-у-у... Бигрәкләр дә күп, авыр булгандыр. Ничек тарттырдың шул кадәр җирдән?

Галина. Авыр түгел, әнкәй, пот ярым монда. Минем машинам тарта ул. Артыгын да. Илдус нихәл, әнкәй?

Арслан. Ул Чаптырган чишмәсе каян исеңә төште синең? Ничек барып таптың аны?

Галина. Әнкәй алып барып күрсәтте. Үзең тегендә чакта һаман шул Чаптырган белән хыяллана идең бит. Хәтта төшеңдә дә кемнәрнедер тиргәп ята идең. Чаптырган болынына көтү кертkәннәр, чишмәсенең буасын җимерек хәлгә китергәннәр дип. Хыялланмаслык та түгел икән шул. Теге син сөйли торган карама төбеннәнургылып-ургылып чыга... Кара әле, Арслан, нигә аны Чаптырган чишмәсе дип атаганнар?

Арслан. Күрмәдеңмени, буасына куелган колашасыннан ул гел шулай чаптырып агып тора. Шуңа Чаптырган кушканнар.

Өйдән Илдус тавышы: әбием!

Галина. Бар әле. Илдус нидер сорый.

Арслан. Хәзер, улым. *(Өйгә кереп китә.)*

Күрше ишегалдында Зарифа карчык күренә.

Зарифа. Ти-ти-ти! Кай җәһәннәмгә дөмекте икән?! *(Киртә буена килеп, Галинага.)* Здырастый!

Галина. Исәнме, әбекәй.

Зарифа. Маяныкы куркы-малайкы невидал?

Галина. Нәрсә соң ул куркы-малайкы, әбекәй?

Зарифа. Беләм... Бу безнеңчә бик күркәм сөйләшә икән ич. Куркы-малайкы дигәнем, тавык малае була инде. Безнеңчә — әтәч. Өйгә кайтып кунакламый торган бер җүнсез әтәчем бар минем. Шуны эзләп гаҗиз булам кичкә керсәм.

Галина *(кесәсеннән конфет чыгарып бирә).* Мә, әбекәй, кереп чәй эч тә йокла. Ә әтәчең кайтыр ул, кайтыр. Үз нигезендә үскән әтәч идеме соң?

Зарифа. Нәрсә соң бу?

Галина. Конфет, күчтәнәч.

Зарифа. Һай, рәхмәт. Бу арада гел «шулкөй» белән эчеп, бер генә дә авызкайларымның тәме юк иде. Әтәчем үз нигеземдә үскән иде үсүен. Чуар тавыгым басып чыгарган иде. Йомыркасын гына күршедән алган идем.

Галина. Шуна күрә биләмче әтәч булгандыр инде ул.

Зарифа. Биләмдә генә булса, кайтыр, алла теләсә. Сезнең, әнә, теге як күршегездән шикләнәм мин. Бигрәкләр дә комсыз бәндә. Шушы сугыш башлангач, икуиренный булып абыйсы йортына кайтып төшкән иде. Абыйсы сугышта үлде, җиңгәсе Майбәдәрне урман кискәндә агач басты. Бу җүнсез алардан калган алма кебек ике баланы детдомга илтеп бирде дә, әнә, ни тикле йортка, никадәр малга хуҗа булып калды. Типтереп ята. Кеше тапкан мал кызганычмыни ул?

Галина. Ярый, әбекәй, мин керим әле, улым көтәдер. *(Өйгә кереп китә.)*

Зарифа. Башыма шом салдың бит әле, балакай, кеше йомыркасы белән. *(Каршы як читәндә Маргарет күренә.)* Әллә суеп ашарга инде мәлгуньне.

Маргарет. Сөякләрен тапсаң... Яшь әтәч сөяге бит ул авызга керү белән эри дә китә.

Зарифа. Аның каравы, йоны кала. Бик тиз тыгыла аның йоны тамак төбенә.

Маргарет. И пока за туманами...

Зарифа. Томан, томан. Син үзең томана. Ә ул әнә синнән җүнлерәк булып чыкты. Маржа булса да.

Маргарет. Маржа булырга аңа иртәрәк әле. Культура җитми. Яулыгын арттан бәйләп куйган. Чеп-чи татар. Донбасс татарыдыр ул, тегеләр ягында калган.

Зарифа. Синең бу якта калуың белән кемгә файда соң? *(Өенә кереп китә.)*

Арт яктан чүмеч тотып Сабира кайта.

Маргарет. Кәҗәнне саудыңмыни, Сабира түти? Бигрәкләр дә аз икән сөте. Чүмеч төбендә генә. Булмаса, минем сыерымны да кереп сау әле. Бер чүмечен үзеңә алыр идең. Ишәйдегез бит инде сез хәзер *(Галина чыга.)* Сразы өч тамакка арттыгыз.

Сабира. Безгә шунысы да җитәр.

Маргарет. Иртә белән дә савылмыйча көтүгә киткән малкаем, ишек төбендә мөгрәп тора.

Сабира. Сыер сава белмим инде мин хәзер, оныткан.

Галина. Әнкәй, син бар, кер, аш әзер, ашый торыгыз. *(Сабира кереп китә.)* Әйдәгез, үзем савып бирим сыерыгызны. Сөтегез өчен түгел. Сөт алмыйм. Мал кызганыч.

Маргарет. Әйе шул, сезнең исемегез ничек була соң әле, чибәр ханым?

Галина. Галимә.

Маргарет. Юк, чын исемегез дим?

Галина. Әгәр анам телендә әйтәсегез килә икән, Галина. Тагы да тутырыбрак әйтергә теләсәгез, Галина Максимовна, фамилиям Ахъярова.

Маргарет. Юк, мин Галочка дип кенә йөрермен инде сезне.

Галина. Галочка — чәүкә баласы дигән сүз бит ул, Маргаретта ханым.

Маргарет. Алайса, мин «күгәрченем» диярмен. *(Икесе дә Маргарет ишегалдына кереп китәләр. Маргарет өеннән Сөләйман чыгып, урамнан үтеп барган Хәйдәрне дәшеп ала.)*

Сөләйман. Бригадир! Син кая барасың, понимаешь, нәрәд закытында.

Хәйдәр. Мин нарядны биреп бетереп киләм инде.

Сөләйман. Кемнән алдың нәрәдне?

Хәйдәр. Кенәгәгә язып калдыргансың бит.

Сөләйман. Әйе шул, точно. Только ни, ни... Миллиметр да отклонение булмасын!

Хәйдәр. Сөләйман абый, бу Арслан мәсьәләсен хәл кыласы иде бит.

Сөләйман. Ә менә анысын мин хәл кылмыйм инде, бигайбә. Район җир бүлеге хәл кыла. Пука колхозда эшләп торсын, диелгән бит.

Хәйдәр. Колхоздасын колхозда. Ләкин кырчылык бригадасына куярга иде, бригадир итеп.

Сөләйман. Синең урынгамы?

Хәйдәр. Әйе, минем урынга. Ул агроном кеше. Миңа караганда күбрәк файда китерәчәк.

Сөләйман. Агроном штаты безнең колхозда юк. Безнең агроном район җир бүлегендә. Аннан, әнә, МТСта бар агроном. Алар акка кара белән язып төшерәләр. Фәлән көнне, фәлән сәгатьтә, ноль-ноль минутта, фәлән җиргә фәлән нәрсә чәчәргә! Мин башбаштаклыкны терпить не могу! Ә син шул кычыткан агрономының фәлсәфәсенә карап, минем приказны отменить иткәнсең.

Хәйдәр. Ул белемле кеше. Фән нигезендә...

Сөләйман. Белем, энем, монда нипочем, житәкли белергә кирәк. Әнә кәнүшнидә эшләп күрсәткән белемен. Фән нигезендә рацион уйлап тапсын атларга. Калорий-малорий... Бу минем үз сүзем түгел, аңладыңмы?

Хәйдәр. Синең үз сүзең булганы да юк.

Сөләйман. Бар, сөйләп кара үз сүзеңне, ничә көн торырсың икән бригадир булып.

Хәйдәр. Аның хатыны да, көзгә кадәр колхозда эшләп торам, ди. Укытучы кеше. Тавык фермасына учетчик кирәк анда.

Сөләйман. Помыркадан тавык өйрәттерергәме? Булмый. Иртәгәдән силос чокырына куй. *(Китә.)*

Маргарет *(коймa аркылы)*. И пока за туманами...

Хәйдәр. Томан шул, томан. Үз авылымны танымыйм мин хәзер.

Маргарет. Һәм кешеләрен дә.

Хәйдәр. Кешеләрен танийм, ләкин аннан ни файда?

Маргарет. Танымыйсың шул менә, танысаң бер кереп чыгар идең, хотя бы. Үз бригадаң членына.

Хәйдәр. Сиңа бригадир нәрсәгә? Председатель үзе кергәч.

Маргарет. Фу, дорфа. *(Өенә китә.)*

Хәйдәр Арсланнар капкасы төбендәге эскәмиягә утыра. Тәмәке төрә. Капкадан Арслан чыга. Капка баганасына сөялә.

Хәйдәр *(янына урын күрсәтеп)*. Утыр.

Арслан. Арымадым.

Хәйдәр *(янчыгын бирeп)*. Мә, көйрәт берне, ичмасам, тәмәке янсын.

Арслан. Өйрәнмәдем инде мин ул нәрсәгә. Авыррак вакытларда да. *(Акрын гына Хәйдәр янына килеп утыра.)*

Хәйдәр. Мөнә авыррагын да күргәнсең бит.

Арслан. Күрдем, ләкин бирешмәдем. Рухым сынмады минем. Авыр яра алып чолганышта калдым. Менә шушы Галиналар хуторына килеп чыктым. Мине үз кешеләре итеп кабул иттеләр, миңа ышандылар. Минем артымнан утка-суга ташландылар... Ә монда, үз авылымда... Туган туфрагым мине кабул итми.

Хәйдәр. Ни сөйлисең син? Бер Сөләйман әле туган туфрак була алмый. Монда без бар.

Арслан. Гафу ит, йөрәк әрни бит... Китәргә иде.

Хәйдәр. Китсәң, без дусларың әрниячәк. Туган туфрагың әрниячәк!

Галина. Мин дә шулай дим аңа.

Арслан. Ә? Син дә мондамыни әле? Нигә чыктың? Тунасың бит. Һич булмаса, иңбашыңа җылы кофтаңны салып чыгар идең. Теге яшел кофтаңны. Кичкырын салкынча бит. Әнә, кырау төште, утыр, үзем алып чыгам. Әнә, Мәликә дә безнең янга кич утыра килгән. Әйдә, утыр, Мәликә. *(Өйгә кереп китә.)*

Галина Хәйдәр янына эскәмиягә утыра. Мәликә бер читкә чирәмгә чүгәли.

Галина. Әйе... Безнең хутор халкы Арсланга үзенә ышанган кебек ышанды. Шундый авыр хәлендә дә дошманга бирелмәгән батыр совет солдаты аларда өмет чаткысы уятты. Кырык икенче елның салкын кышы иде. Берәү тәрәзә шакый. «Җылынып кына чыгыйм әле, анакай...» Бусагадан түше белән шуып керде. Ач, авыру... Язга кадәр идән астында ябып асрадык, дәваладык. Көндез идән астында, төнен янәшә хуторларга йөреп үзенә иптәшләр туплый. Язын, полицайлар, каратель-ләр тынгы бирми башлагач, кечкенә генә бер отряд булып оешып урманга күчтек. Аннан зур отрядка — Коржик отрядына кушылдык. Коржик — командир, ә Арслан — разведка начальнигы. Безнең район немецлардан азат ителгәч, Коржик райком секретаре булды. Һич кенә дә кайтарасы килмәгән иде безне монда Коржикның.

Хәйдәр. Ә хәзер кайтканыгызга үкенәсеңме?

Галина. Юк, үкенмим, анда бит минем беркемем дә юк. Без партизан отрядына киткәч, әниемне атканнар, йортыбызны яндырганнар. Ә монда — Арсланның туган җире, әнисе... Ул авылын бик сагынды. Әнкәйне дә ялгыз яшәтеп булмый. Иремнең туган җире — минем туган җирем. Шулай булгач, нишләп үкеним.

Хәйдәр. Авыррак туры килә бит менә.

Галина. Ә кайда җиңел? Бу сугышның шаукымы байтакка барыр әле... Менә нәрсә, бригадир, син мине иртәгә Мәликә белән бергәләп силос хәзерләргә куй. Юк, юк, шулай кирәк. Мин эшләми тора алмыйм. Силос хәзерләүдә минем тәҗрибәм бар. Узган ел үземнең класс балалары белән без байтак силос хәзерләдек. Ә нинди силос булды әле, хуш ис килеп тора.

Мәликә. Галина җанкисәгем!.. *(Аны кочаклап ала.)*

Арслан чыга.

Арслан. Мин синең кофтаңны тапмадым, Галимә. Син аны бүген иртән районга киеп киткән идең түгелме соң?

Галина. Эзләмә син аны. *(Түбән очтан гармун, җыр ишетелә.)* Әнә җырлый да башладылар.
Хәйдәр. Ай да калка.
Галина. Син тегендә гел шушы көйгә җырлый идең.
Арслан. Кайчан?
Галина. Кичләрен елга буенда, мина ишеттермичә, акрын гына. «Туган илнең саф җилләре истә, һаман да истә...» дип. Мин камышлар арасыннан күзәтә идем.
Арслан. Булмаганны.
Мәлика. Ә ул монда, безнең янга килә.
Хәйдәр. Ат белән урам әйләнә. Тарантаста.
Арслан. Кем ул?
Хәйдәр. Бу бит безнең Гариф. Председатель тарантасында, вот солдат! Төшмә инде, төшмә тарантасыңнан.
Гариф *(арттан)*. Да ну, к черту!
Хәйдәр. Кая җибәрәсең аны үзен генә.

Култык астына гармун кыстырып, Гариф керә.

Гариф. Күркә Сөләйман тотып тугарыр әле. Сәлам демобилизованный солдатларга!
Арслан. Исәнме, Гариф, сау кайттыңмы?
Гариф. Дөбердәтеп, шыгыр-шыгыр... Күкрәгемә өч сары тасма тагып.
Арслан. Полный кавалер диимме?
Гариф. Булмый калды. Икәү генә. Мин сиңа бүген килгән идем, ә син, понимаешь, «уфалла» тартып йөрисең, партизан башың белән. Әнә тарантаста ташырга кирәк утын.
Хәйдәр. Ул тарантас сиңа ничек эләкте әле?
Гариф. Күркә Сөләйманны бәреп төшердем дә утырдым. Әле, өстәвенә, кибеткә алып кереп сыйлады үземне. Бер ярты алды. Синен хатын дигән нәрсә шушымыни инде? Кая, күрешик. Гариф Сабиров, гвардии разведчик. Чибәр, чибәр хатының. Минем дә Әсхәпҗамал шәп иде. Көтмәгән бит, кияүгә чыккан. Күрше авылга. Әле шуннан кайтышым. Әй, түрләреннән гармун белән сыздырып уздым, атылып капка төбенә чыккан, яулыгын да ябарга онытКан башына. Капка баганасына сөялеп калды шул Әсхәпҗамалың. Айгыр җиленә чәчен җилләтеп. Менә шулай була ул. Чукынсын шунда Әсхәпҗамалы, чык мина хатынлыкка, Мәликә. Җимерек йортта ялгызым гына яши алмыйм бит инде мин.
Мәлика. Бик чыгар идем дә, Гариф абый, минем бит сугыштан кайтасы Низаметдиным бар.
Гариф. Хәбәрсез югалган диләр түгелме соң аны?
Мәлика. Югалса да көтәм әле мин аны. Бәлки, бер кайтыр әле.
Гариф. Көт инде, көт, мин синең өметенне кисәргә теләмим. Әйдәгез, егетләр, яшь вакытларны искә төшереп, бер урам әйләник әле.
Хәйдәр. Чыннан, Арслан, бер җилләнеп алыйк әле.
Арслан. Килешер микән?
Хәйдәр. Килешкәнен-килешмәгәнен кем сорап торган аның хәзерге вакытта. Күңел бит ул йомшара да белә. Җырлыйсы килә, кычкырып-кычкырып җырлыйсы килә.
Галина. Бар, Арслан, җырла, күкрәк тутырып җырла бер сагынып кайткан җырыңны. Җәйге айлы кич җыр сорый ул.
Хәйдәр. Ә син безнең авыл кешеләрен начарга санама, Галимә. Әйбәт алар. Менә шушы айлы кич кебек саф алар. Алар җырлый да беләләр, әрни дә беләләр. Ә Күркә Сөләйманнар алар бик аз. Аз һәм вакытлы.
Гариф. Чәйбез без аны, Күркә Сөләйманын!..

Хәйдәр. Әнә, айны бер ертык болыт каплады. Ә күпмегә дисең? Айны мәңге каплый ала торган болыт юк ул.
Гариф. Точно.
Хәйдәр *(Гарифка)*. Тарт, дустым, гармуныңны. Безнең яшьлек әле узмаган. *(Гариф гармун тарта, Арслан белән Хәйдәр, бер-берсенең иңбашларыннан алып, гармунчыга каршы басалар һәм урам буйлап җырлап күздән югалалар.)*

Без әүвәле йөргән чакта
Киң урамнар тар иде,
Киң урамнарны тарайтып
Йөргән чаклар бар иде.

Галина белән Мәлика аларны капка баганасына сөялеп озатып калалар. Маргарет түти үз капка баганасына чыгып сөялгән.

Маргарет. Авыл авыл инде, некультурно. Айлы кич дип, акырып урам әйләнә, имеш.
Галина. Шигърият бу, Мәрьямбану ханым!
Маргарет. Во-первых, Мәрьямбану түгел, Маргарет диләр миңа. Мар-га-ре-та! Во-вторых, яшел кофтаңны районга алып барасы түгел иде синә, миңа гына кертергә иде. Мин күбрәк биргән булыр идем паек онын.
Мәлика. Мәрьямбану, җир бит.
Маргарет. Син нигә һаман миңа бәйләнәсең?
Мәлика. Бәйләнмим. Сабый балалар хакы болай да бугазыңа шеш булып чыгар әле, вакыты җиткәч.
Маргарет. Минем артым чиста. Мин шәһәребезгә беренче бомба төшүгә үк эвакуироваться иткән кеше. Оккупациядә калмадым!
Мәлика. Анда синең кебекләрне калдырмыйлар да, әрәмтамак. *(Маргарет капкасын каты итеп ябып кереп китә.)*
Галина. Кирәкми, Мәликә. Бәйләнмә шуның белән.
Мәлика. Әйт әле, Галимә, син Арслан абыйны яратып чыктыңмы?
Галина. Бик. Аны бит яратмаска мөмкин түгел. Аны минем әнием дә бик яраткан иде. Без разведкага гел бергә йөрдек.
Мәлика. Ә улыгыз Илдус кайчан туды?
Галина. Илдус инде безнең районны немецлардан азат иткәч, узган җәй, үзебезнең хуторда туды.
Мәлика. Әйт әле, дустым, мин сиңа гел шулай дип кенә йөрермен, ярыймы? Синең Арслан абыйга кадәр яраткан егетең бар идеме? Әйтик, үзегезнең авылда?
Галина. Бар иде.
Мәлика. Чибәр идеме?
Галина. Бик.
Мәлика. Нигә соң аны ташлап Арслан абыйга чыктың?
Галина. Күрәсең, минем Арсланга булган мәхәббәтем, соң булса да, көчлерәк булган.
Мәлика. Ә ул егет ни исемле иде?
Галина. Игорь.
Мәлика. Ул да сезнең партизан отрядында идеме?
Галина. Юк, аның белән бергә ун класс бетердек. Мин үзебезнең хуторда укытучы булып калдым, ә ул институтка китте.
Мәлика. Син Арслан абыйга чыккач, аны бүтән күрмәдеңме?
Галина. Күрдем. Әле без монда кайтыр көннәрдә генә ул демобилизацияләнеп безнең хуторга кайтты. Офицер. Зур галим булачак ул, искиткеч сәләтле егет.
Мәлика. Күрәм, син хәзер дә әле аны оныта алмыйсың.
Галина. Ничек кенә булмасын, беренче мәхәббәт. Юк-юк та, бер кытыклап куя.

Мәликә. Әйе шул, менә мин дә Низаметдинымны һич оныта алмаячакмын, мәңге яратачакмын мин аны, мәңге көтәчәкмен.

Галина. Ә мин көтә алмадым инде Игорьны. Һәм үкенмим. Шулай да, шәүләсе күңелгә шик салып йөрмәсен дип, ул хуторга кайтып төшү белән үк, Арсланны тизрәк бире кайтырга ашыктырдым. Шулай яхшырак булыр... Онытырга җиңелрәк булыр, дидем.

Мәликә. Оныт инде син аны, дустым, сызып ташла йөрәгеңнән.

Галина. Әгәр ул онытырга вакыт бирмәсә? Ара-тирә, кайтып, үзен искә төшереп торса?

Мәликә. Мондамы, безнең авылгамы?

Галина. Ышанма анар. Ул шундый сәер кеше. Бик сагынса, килер дә төшәр, кунак булып.

Мәликә. Монысы инде бернинди законга да, шәригатькә дә сыймый. Хәзер үк хат яз үзенә, андый җүләрлекне эшләмәсен.

Галина. Хат язып кайдалыгыңны белгертсәң, иртәгә үк килеп төшәр ул, җүләр.

Мәликә. Юк, юк. Хат та язма, исенә дә алма! Ялгыз калырга тырышма син, дустым. Һәрвакыт безнең белән бул. Әнә, кайталар. Арслан абыйлар урам әйләнеп кайталар. Әйдә шулар янына! *(Галинаны кулыннан алып, гармунга каршы җырлап китә.)*

Кайтыр әле, кайтыр әле,
Кайтыр әле гүзәлем;
Ай күтәрмен, ел күтәрмен,
Гел күтәрмен, түзәрмен.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Бер ел вакыт үткән. 1946 елның апрель ахыры. Шул ук декорация. Вакыт иртә. Пәрдә ачылганда, капка төбенә атка атланган Сөләйман килеп туктый.

Сөләйман. Тыр-р-р... Шельма. Тукта! Ну, бу айгырны! Хуҗасының адресы алмашынганын һаман белми бит. Һаман иске йортка тарта. Маргарет, Маргарет дим! *(Террасага Маргарет чыга.)*

Маргарет. Кычкырма шул хәтле, җаный, синә килешми ул, солидный кешегә.

Сөләйман. Мин район кадәр җирдән кайтып җиттем, понимаешь, ә син йокыңнан айный алмыйсың.

Маргарет. Айгырыңны нигә монда алып кайттың, берәр малай илтеп кайтыр иде шунда конюшнига.

Сөләйман. Малай-шалайга тоттыра торган айгырмыни ул, понимаешь.

Маргарет. Баскан урынында биеп, капка төбен измә ясап бетерә.

Сөләйман. Ә как же! Биеп тормагач, председатель айгыры да булмый ул. Кая, Арслан өйдә микән, кычкыр әле.

Маргарет. Үзең генә кычкыр инде, җаный, аның теге карачкы карчыгы бер сүзгә биш җавап бирә.

Сөләйман *(ике ишегалдын бүлгән койма буена барып кычкыра)*. Арслан, Арслан дим!

Маргарет. Акрын кычкыр, өйдә кеше йоклый, уятасың.

Сөләйман. Ничек кеше? Нинди кеше?

Маргарет. Юлаучы.

Сөләйман. Председатель йортына юлаучы кертәләрмени кунарга?!

Маргарет. Рус егете ул, татарча белми, кая барсын?

Сөләйман *(тәрәзәгә якын килеп)*. А мая какой дело!

Маргарет. Чәпчемә инде, жаный, врач егет ул. Бәйтерәк больницасына барышы. Мунча ягыйммы?
Сөләйман. Мунчаны кертеп кайтардылар...
Маргарет. Кайда?
Сөләйман. Бюрода. Арслан, Арслан дим!

Арсланнар өеннән Сабира чыга.

Сабира. Ни бар?
Сөләйман. Син Арсланмыни? Арсланга дәш.
Сабира. Йоклый ул.
Сөләйман. Как то ест йоклый?
Сабира. Шулай, йоклый. Тәүлек буе конюшнидә дежур торып кайтты да йоклый.
Сөләйман. Уят, әнә минем айгырны конюшнигә илтеп кайтсын.
Сабира. Уятмыйм.
Сөләйман. Ышту?
Сабира. Конюшнигә ат куып йөрергә малай-шалай түгел ул сиңа.
Сөләйман. Анысы дөрес. Арслан молодец ул. Атларны аякка бастырды бер ел эчендә. Бүген бюрода да мактадылар үзен. Ә киленең кая?
Сабира. Киленем бригада хатыннары белән пристингә симәнә орлыгы алып кайтырга китте. Яшь баласын калдырып.
Сөләйман. Мөгаллимә кешегә симәнә ташып йөрү кирәкми иде инде. Тем более яшь баласын калдырып. Мин бит аңа бармаска куштым.
Сабира. Синең өчен түгел, колхозыбыз өчен йөри. *(Кереп китә.)*
Сөләйман. Ул нигә шулай дорфа сөйләшә минем белән? Әллә аңа күрше булуым ошамыймы?
Маргарет. Алар бар да шулай. Синең бертуган сеңелең Әсмалар белән бергә укмашып алганнар да...
Сөләйман. Әсмага ни калган алар белән, понимаешь?
Маргарет. Синең әйбәт торуыңнан көнләшә. Тегеләрне — төп йортында калган балаларыңны кызгана, имеш. Абыйсының шул чир өереннән котылганына рәхмәт әйтәсе урында.
Сөләйман. Балаларны карарга минем анда улым — демобилизованный солдатым кайтты. Йорт-җир, мал-туар, никадәр курма калды аларга.
Маргарет. Алар аны беләмени!
Сөләйман. Бар, мунча як. Күп итеп, төтене күккә күтәрелерлек булсын. Бөтен авыл күрсен. Шартласыннар, понимаешь!
Маргарет. Ярый, жаный. Бар, син кереп ашап ал да ятып тор. Аныңчы мунча да булыр, яртым да бар...
Сөләйман. То-то! Нуменклатурный булсын. *(Өйгә кереп китә. Урамнан Зарифа карчык үтеп бара.)*
Маргарет. Зарифа түти, Зарифа түти дим, мунча гына ягып бирмәссенме?
Зарифа. Бирермен, бик әйбәт итеп, ташына табык тизәге салып.
Маргарет. Анысы ни өчен?
Зарифа. Пары әйбәт була аның, яшь бикәчләр өчен. Яңыгыздан үткән саен җаным өши, шул балаларны уйлап.
Маргарет. Сөләйман балаларын әйтәсенме?
Зарифа. Сөләйман балаларының әниләре уңган хатын иде, аларны ач-ялангач итмәс, аллаһы боерса. Менә бу нигезнең үз хуҗаларын әйтәм әле, Майбәдәр балаларын.
Маргарет. Алар-да ач булмас. Детдомда балалар ач булмый.

Зарифа. Анысы ач түгелдер, шәт, иншалла, хөкүмәт ач итми ул. Тик менә үз нигезләре була торып, чит җирдә тилмереп яшәүләренә генә җаным әрни. Дәү үскәннәрдер инде балакайларым, эшкә ярарлык булып киләләрдер.

Маргарет. Әйе шул, Харисы утын ярырлык, Халисәсе су ташырлык булгандыр.

Зарифа. Тагын бераз үсә төшсеннәр инде. Синең өчен түгел, үзләре өчен эшли алырлык булсыннар. Аннары кайтартабыз без аларны, аллаһы боерса, бөтен авыл белән. Тамга җыеп. *(Китә башлый.)*

Маргарет. Мунча якмыйсыңмыни инде, Зарифа түти?

Зарифа. Әнә, айгырыгыз ычкынып качты.

Маргарет. Шайтан икән!..

Зарифа. Анысы авылдан чыгып китмәс, күркәнне сакла син, күркәнне... Очып китмәсен! *(Китә.)*

Маргарет. Син үзең күркә, хәзер кабарынып ябышырга гына тора.

Урам як капкадан Сабиралар ишегалдына Хәйдәр керә.

Хәйдәр. Өйдәләрме? Сабира түти, Арслан өйдәме?

Сабира. Ял итә иде, торды микән, хәзер дәшәм. *(Китә.)*

Арслан чыга.

Арслан. Ә, Хәйдәр, кайттыңмы? Нәрсәгә чакырганнар, кем чакырган?

Хәйдәр. Иптәш Юнусов.

Арслан. Кем ул?

Хәйдәр. Яңа килгән зональный секретарь. Бюродан соң бер сәгать минем белән сөйләшеп утырды. Эшләр шәптән түгел. Язгы чәчүнең өзелү куркынычы бар.

Арслан. Өзмибез, атлар аякка баса, анысын мин үз өстемә алам. Бераз концентрат запасым да бар... *(Күз кысып, пышылдап.)* Н. З. Ә силос, малай, менә дигән. Ямь-яшел, хуш ис аңкып тора. Бигрәк тә Мәликә белән Галимә хәзерләгән чокырда...

Хәйдәр. Галимә бүген дә симәнәгә киттеме?

Арслан. Әйе.

Хәйдәр. Иөртмә аны андый авыр эштә. Үз итеп кенә әйтәм, син хатынсыз, балаларыбыз укытучысыз кала болай булса. Ташлый да китә. Биллаһи, ташлый да китә, сине дә, безне дә.

Арслан. Китми. Җиргә ябышкан ул. Ашарына бирмә син аның, ә җирдә — туфракта казынудан аерма.

Хәйдәр. Әнә Иске Арышның Бүтәкә Гыймраны бер сары чыпчык алып кайткан иде Кишиневтан. Уеныгыз уен түгел, арба тартып уйныйсыз дип, утын төягән «уфалла»сын урман кырыена ташлаган да киткән дә барган, ди.

Арслан. Андыйга ак юл. Ә мин Галимәләр силосының һәр чокырыннан анализ алып лабораториягә җибәргән идем, рецептын сорап язганнар, колорийность — иң югары процент. Әле кайчан гына күтәртә торган атлар хәзер утарга чыгып уйнаклап йөри башладылар. Чәчүне җиңәбез алар белән, җиңәбез. Менә симәнәне дә вакытында ташып бетерсәк...

Хәйдәр. Тик менә Сөләйман гына аяк чала. Игенчемени ул, итче бит. Бернәрсә белмәгән башы белән... Минем төбәк басуына бодай чәчтерми.

Арслан. Нигә?

Хәйдәр. Район агрономы тары чәчәргә план төшергән, тары чәчәсең, ди.

Арслан. Тары җиремени ул! Исбат итәргә кирәк, агрономның үзенә барырга кирәк.

Хәйдәр. Булдым. Анысы Сөләйманнан да кирерәк. «Каян алдың ул теорияне?» — ди.

Арслан. Алайса, карап торып колхозны эштән чыгарырга юл куябызмы шуларга?

Хәйдәр. Юк, куймыйбыз. Иптәш Юнусовка мин синең фикерләреңне, тәкъдимнәреңне аңлаттым. Ул синең белән бик кызыксына. Хәтта дилбегәне сиңа тапшыру турында хыяллана.

Арслан. Син нәрсә?

Хәйдәр. Тукта, нигә дип шулай ялынны тырпайттың әле?

Арслан. Син нәрсә сөйләгәнеңне белеп сөйлисеңме?

Хәйдәр. Бик белеп. Анда басуда җир елый. Синең туган туфрагың елый. Син — шул туфракта туып-үскән агроном.

Арслан. Беләм. Син миңа вазифамны сөйләмә. Мин дә елыйм... Бөтен йөрәгем белән елыйм.

Хәйдәр. Күз яше белән туфрак сугармыйлар, көрәшергә кирәк, дисең бит син үзең.

Арслан. Әйе, көрәшергә, моментны ычкындырмаска, инициативаны үз кулыбызга алырга. Әгәр язгы чәчүне кулдан ычкындырсак, аннан тагын ел буе сыкрап йөрергә кала. Көрәшергә, ләкин белеп. Акыл белән, тактика белән. Болай кинәт алырга ярамый.

Хәйдәр. Сөртенербез дисеңмени?

Арслан. Дилбегәне миңа тапшыру турында сүз булырга тиеш түгел. Сөләйман кулына карта бирергә ярамый. Ул, шуннан файдаланып, үзенең козырен чыгарып салачак. «Ахъяров — карьерист, Ахъяров, үзе председатель булу өчен, минем тырнак астыннан кер эзли» һәм башкалар... Ә районда аның яклаучылары күп.

Хәйдәр. Соң нишләргә?

Арслан. Әйдә хәзер телефонга. Иптәш Юнусовтан безне бүген үк үзенә кабул итүен сорыйбыз. Аннан, үзебез белән Гарифны алабыз да, өчәүләп районга. Мин иптәш Юнусовка үзем исбат итәрмен. Иртәгә үк гомуми җыелыш җыярга рөхсәт алырбыз һәм көн тәртибенә — синең кандидатураң.

Хәйдәр. Минем кандидатурам? Ә син нәрсә? Кыяклыйсыңмы?

Арслан. Юк ла инде, колхозчылар сине ярата лар, оештыру сәләтең бар...

Хәйдәр. Бар, ләкин... киштә сай!..

Арслан. Калганы өчен син борчылма. Мин сиңа бөтен яктан ярдәм итәрмен. Якындагы бер-ике ел гына әле безгә зур нәрсә бирмәячәк. Киләчәкнең перспективасын зур масштабка корырга кирәк. Ә моның өчен урта белемле агроном булу гына җитмәячәк. Димәк, миңа институтка китәргә кирәк.

Хәйдәр. Быел укмы? Шул инде, кәкре каенга терәтеп китмәкче буласың син мине.

Арслан. Юк, курыкма, мин сине быел ук ташламыйм әле. Безгә хәзер колхозны бу коточкыч хәленнән чыгарырга кирәк, синең позициянне ныгытып, сиңа төпле юнәлеш биреп җибәрергә кирәк. Аннан Галимә дә заочныйның өченче курсында гына.

Хәйдәр. Шул инде, Галимә очныйга күчә, аның артыннан син.

Арслан. Күчми. Читтән торып бетерә. Аннан мин укырга китәм. Шунсыз булмый. Монда бит әнкәй, балалар... Я, ярый, болары — киләчәк эше. Ә хәзер, әйдә иптәш Юнусовка. Вакыт көтми. Әнә ничек кыздыра. Бер-ике көннән — чәчүгә!

Маргарет *(өеннән чыгып коймага килә)*. Һай, һай! Сез нәрсә, яшертен идарә утырышы уздырасызмы?

Х ә й д ә р. Әйе, мена синең купме кар тотуың, басуга күпме ашлама чыгаруыңның очына чыга алмый идек.
М а р г а р е т. Чыктыгызмы соң?
Х ә й д ә р. Чыктык шикелле, әйдә, Арслан. *(Китәләр.)*
М а р г а р е т. Ташу суын үлчәгез, ташу суын. Мин тоткан кар гөрләвек булып ташу суына күчте.
З а р и ф а. Сөләйман кая? Күркә Сөләйманга кычкыр. Әнә айгыры урам бетереп чабып йөри.
М а р г а р е т. Нигә Сөләйман? Әнә, конюхка әйт.

Урамның икенче башыннан Гариф килеп чыга.

Г а р и ф. Кычкырма Сөләйманга. Мин аның айгырын тотып бәйләдем инде. Ул яшь бикәче белән бикәчләп ятсын шунда. Ә мин айгыр белән иртәгә сукага чыгам. Арслан, Хәйдәр, туктагыз, туктагыз! *(Алар артыннан йөгерә.)*

З а р и ф а китә. Террасага И г о р ь чыга.

И г о р ь. Хәерле иртә, апа.
М а р г а р е т. Иртә, иртә. Йокың туйдымы соң? Ял итә алдыңмы, кандала таламадымы?
И г о р ь. Арылган, тоймадым.
М а р г а р е т. Арыгансыңдыр шул. Шул кадәр җирдән язгы саз ерып, җәяү... Бераз җир кипшергәнне көтәсең калган.
И г о р ь. Эш көтми бит, апа. Анда бер авыруны...
М а р г а р е т. Шулай шул, авыру көтми. Менә үземнең дә кыш буе басуда кар тотып билләрем кузгалды. Бөерләрем чәнчеп авырта. Син, булмаса, бер-ике көн ял ит, мунча керерсең. Аннан тарантас җиктереп картымның айгыры белән генә илтеп куярбыз.
И г о р ь. Рәхмәт, апа.
М а р г а р е т. Монда район врачлары бернәрсә дә белмиләр. Печатьфәләнең бардыр ич.
И г о р ь. Рецепт бланкаларым бар.
М а р г а р е т. Мин үзем дә шәһәр кешесе. Ленинградтан. Комсостав хатыны идем мин. Әле менә узган көз генә Германиядән үлгән хәбәре килде иремнең. Меңнән артык аттестат кына ала идем мин. Акчам күп аңысы, хәзер дә...
И г о р ь. Суык тидерә бит инде балакай.
М а р г а р е т. Кемне әйтәсең син?
И г о р ь. Әнә, күрше ишегалдында бер чибәр малай... Әле кибәркипмәс җирдә ялан аяк йөгереп йөри.
М а р г а р е т. Әй, авыл балаларына чуртым да булмый аларга.
И г о р ь. Әбисе тотмакчы була, ул тоттырмый. Кара, кара ничек йөгерә? Ни исемле ул?
М а р г а р е т. Илдус.
И г о р ь. Нәкъ үзе, бөтенләй үзе.
М а р г а р е т. Нәрсә дисең син?
И г о р ь. Юк... ни... кем малае ул дим... шундый чибәр?
М а р г а р е т. Әнисеннән сорарга кирәк.
И г о р ь. Әнисе кем соң аның?
М а р г а р е т. Мондагы түгел ул, күршебез партизанлыкта йөргәндә ләктереп кайткан. Хәзер модада бит ул: кайсы полячка, кайсы француз, кайсы итальянка сөйрәп кайткан була. Үзләре ымлашып сөйләшәләр...
И г о р ь. Болар дамы?
М а р г а р е т. Юк, бу Галимә дигәннәре безнеңчә яхшы белә аңысы.
И г о р ь. Кем диден?

Маргарет. Безнең авылда Галимә диләр, үзләренчә Галина була инде.

Игорь. Галя...

Маргарет. Нәрсә диден?

Игорь. Юк... ни... улы дим, ничә яшьтә инде?

Маргарет. Ике тулган, өченче яше ди. Тагы бер кызы бар, анысының әле бишенче генә ае.

Игорь. Анысы ни исемле?

Маргарет. Тәнзилә ди бугай...

Игорь. Тәнзилә... Матур исем. Таня... Танюша...

Урамнан, кыр казлары кебек тезелешеп, хатын-кызлар үтә. Алар арыган, ләкин күңелләре көр. Иңбашларына капчык белән симәнә орлыгы күтәргәннәр. Игорь аларны ерактан күреп ала.

Игорь. Бу нинди тамаша?

Маргарет. Май бәйрәме демонстрациясенә репетиция ясыйлар.

Игорь. Аңламыйм?

Маргарет. Симәнә орлыгы алып кайталар.

Игорь. Ерактанмы?

Маргарет. Пристаньнан. Тезелешеп баралар, тезелешеп кайталар. Ул ерак түгел, унсигез чакрым гына.

Игорь. Атлар юкмыни?

Маргарет. Атларны чәчү алдыннан ял иттерәләр. «Уфалла» тартып булмый, пычрак. Берничә урында ташу ерып чыгасы бар. Үзләре шулай хәл кылдылар. Собраниедә, кул күтәреп. «Инициативная бригада» ди.

Игорь. Молодцы!.. Ничек киләләр! Әйтерсең арымаганнар да.

Маргарет. Арытырсың аларны. Әле аларның шул килештән телләрен әйләндереп председательне сүгәргә көчләре җитә. Имеш, ни өчен колхозны симәнәсез калдырдың? Белмиләр алар үзләренең гектары-гектары белән урылмаган игенне кар астында калдыруларын.

Игорь. Әллә ашлык кар астында калды?

Маргарет. Шулай да бер бригаданыкын әнә теге арттан кызулап килә торган укытучы хатын, менә шушы күрше карчыкның килене Галя — Галимә, көн-төн басуда кунып, җыйдырып бетерде бетерүен... Ә менә ике бригаданыкы калды. Калды шул, калды...

Игорь *(Галяны күреп)*. Ул!

Маргарет. Кемне күзлисең? Күзлә, күзлә. Араларында шактый гына чибәрләре бар. Бигрәк тә әнә шул укытучы хатын. Ул төзегән инициативная бригада инде бу. Язгы каникул вакытында, ял итәсе урында, үзе дә җәфа чигә, кешегә дә тынгы бирми. *(Китә.)*

Игорь. Галя... Галина... Менә нинди икәнсең син!!. *(Урам аша үткән ерганакны аркылы чыкканда, аягы таеп, Галина пычракка егыла.)* Егылды, егылды бит! *(Игорь үзен-үзе онытып койма аркылы урамга сикерә дә ерганакта яткан Галинага ташлана.)* Галя, Галина!

Галина *(тәгәрәп киткән капчыгына шуыша)*. Орлык... Орлык чәчелмәсен!

Игорь. Галя! Бу мин бит, мин, Игорь!..

Галина. Капчык, капчык ярылды бит! Мә әле, шушы бияләй белән капчыкның ярыгын томала.

Игорь. Галина, әллә танымыйсыңмы?

Галина. Таныйм. Менә бит орлык чәчелде. Җый. Бөртеге дә калмасын, җый! *(Үзе учына бөртекләп чәчелгән орлыкны җыя. Урамнан йөгереп Арслан һәм Хәйдәр килеп җитәләр.)*

Арслан. Галимә, ни булды?

Галина. Чаптырган чишмәсенә туктап, иптәшләремнән калган

идем. Куып житим дип кызуладым да, хәл китте, егылдым. Капчык амбарга...

Арслан. Хәзер, хәзер. *(Җирдәге капчыкны ала һәм Игорьны күреп аптырап кала. Мәликә Галимә артыннан кире борылып килә.)*

Галина. Бу... Игорь инде, Игорь... Шушы үзе инде.

Арслан. Нишләп монда? Әйдәгез өйгә, өйгә керик!

Галина. Юк, юк, син бар, капчыкны... Капчыкны иптәшләрдән калдырма. Игорь китмәс әле ул, китмәс! Хәйдәр, син дә бу орлыкны... *(Учындагы орлыкны Хәйдәрнең итәгенә сала.)* Игорь, сал син дә учындагын. Бар, Хәйдәр, шунда капчыкка куш. Арслан, барыгыз инде!..

Мәликә. Юк, юк, бармасын. Арслан абый, син барма, син кал, мин үзем... Без икәү, әйдә, Хәйдәр абый.

Капчыкны күтәреп Хәйдәр белән Мәликә китәләр.

Арслан. Галимә, әйдә, кунакны өйгә...

Игорь. Юк. Мин сезгә кунак булып килмәдем.

Арслан. Кая, күрешик әле бер, дусларча, солдатларча... Кочаклашып!

Игорь. Теләмим.

Арслан. Нигә? Без синең белән тегендә... Украинада да таныша, күрешә алмадык.

Игорь. Бик кызганыч. Бәлки, шунда — урында мәсьәләне хәл кылган булсак, Галина мондый коточкыч хәлгә калмаган булыр иде.

Галина. Нинди хәлгә?

Игорь. Кара кыяфәтеңә... Ялан аяк язгы кар суын ерып... Пычрактан үрмәләп бөртек чүпләү...

Арслан. Шул җиргә төшкән бер бөртектән җирдә тереклек башланып киткән...

Игорь. Сез миңа әкият сөйләмәгез. Һәм ничек сез бу хәлне көлеп уздыра аласыз? Бу — шәфкатьсезлек, бу — каты бәгырьлелек. Шуның өчен сез аны бирегә алып кайттыгызмыни?

Галина. Игорь... беренче күргән кеше белән болай сөйләшү...

Игорь. Әдәпсезлекме? Гафу сорыйм. Ләкин кем генә булмасын, минем хәлдә...

Арслан. Әйдәгез, өйгә керик, урамда мондый әңгәмә алып бару килешми...

Ашыгып Гариф керә.

Гариф. Арслан, райкомнан иптәш Юнусов килеп төште. Хәзер үк идарә әгъзаларын җыйнарга куша.

Арслан. Шул арада? Менә бу кавалеристларча. Бая без аңа үзебез бармакчы булып шалтыраткан идек. Пычрак ерып килеп йөрмәгез, хәзер үзем килеп җитәм, дигән иде. Син бар, Хәйдәргә әйт, идарәне җыйсын.

Галина. Ә син?

Арслан. Мин бит идарә члены түгел.

Гариф. Юк, ул беренче сине чакырды.

Галина. Син бар, әтисе, бар.

Арслан. Менә бит, кунак белән тагын утырып булмады.

Галина. Ул китми әле, китми. Ә сезнең эш ашыгычрак.

Гариф. Сөләйман абзый!

Крыльцога Сөләйман чыга.

Сөләйман. Нәрсә бар?

Гариф. Иптәш Юнусов килгән, идарәгә чакыра.

Маргарет. Мунча кермәгән әле ул.

Гариф. Какой-такой мунча хәзер, киттек тизрәк. *(Китәләр.)*

А р с л а н. Сез, Игорь, сөйләшеп чәйли торыгыз, мин озакламый кайтырмын, гафу сорыйм, вакыты шулай.

Арслан китә.

Г а л и н а. Әйдә, ишегалдына керик. Менә, безнең төп нигез шушы була инде. Утырыйк.

И г о р ь. Утырасым да килми хәтта. Син аңла, Галя, бу синең төп нигезең була алмый. Синең төп нигезең тегендә, кояшлы Украинада.

Г а л и н а. Син нигә кайттың? Кунак булыпмы? Кунак булсаң, тыйнак бул.

И г о р ь. Юк, мин кунак булып кайтмадым. Мин сине алырга кайттым.

Г а л и н а. Без синең белән бу турыда сөйләшкән идек инде. Хәтереңдәме, без монда китәр алдыннан. Һәм син бу мәсьәләне бүтән кузгатмаска сүз биргән идең. Кайтсаң, фәкать кунак булып кына кайтырга сүз биргән идең син минем яныма.

И г о р ь. Аңлыйсыңмы син?.. Мәхәббәт бит ул!..

Г а л и н а. Сугыш аерып кына калмады. Сугыш күпләрне күпләр белән кушты да. Күпләргә икенче ил, икенче тел, икенче туфрак та бирде. Һәм менә нәтиҗәдә мин...

И г о р ь. Шушы караңгы почмакка килеп баттың, үз иркең белән, үзең теләп, шулаймы?

Г а л и н а. Әйе. Мәхәббәт фәкать ирекле була ул. Үзем теләп яраттым, үзем теләп аның иленә кайттым.

И г о р ь. Һәм син мондагы кешеләр белән уртак тел табармын, шушында яши алырмын дип уйлыйсыңмы?

Г а л и н а. Ә мин таптым инде. Уртак тел дә таптым, дуслар да таптым. Күрдегез никадәр алар? Алар белән без бу син әйткән караңгы почмакны гөлбакча итәчәкбез. Син безгә тагын бер ун елдан кил, Игорь, ярыймы?

И г о р ь. Син монда тагын ун ел яшәмәкче буласыңмы?

Г а л и н а. Мин монда үлгәнче яшәячәкмен.

И г о р ь. Ә Днепр, ярларыннан ташып аккан Днепр.

Г а л и н а. Безнең Кама буйлары да искиткеч. Бозлар ага, бозлар... Менә шушы өй кадәрле бозлар...

И г о р ь. Ант итәм, сине сихерләгәннәр.

Г а л и н а. Әйе, мине мәхәббәтем, балаларым сихерләде.

И г о р ь. Димәк, синдә миңа карата мәхәббәт булмаган. Синең миңа биргән антың ялган булган.

Г а л и н а. Теләсәң ничек гаеплә син мине, Игорь, ләкин барыбер мине...

И г о р ь. Димәк, кайтмыйсың?!

Г а л и н а. Юк.

И г о р ь. Ярар. Мин үзем Казанга, профессор Вишневский клиникасына күчеп киләм. Үзем булмаса, шәүләм синең үкчәңә басып йөрер.

Г а л и н а. Хыялый...

И г о р ь. Көл, көл! Син минем мәхәббәтемне аяк астына салып таптадың, инде хәзер көләсең. Көл. Шәфкатьсез син, вөҗдансыз син, каты бәгырьле кеше син.

Г а л и н а. Кая барасың? Әнә этиебез дә кайта. Өйгә керәбез.

И г о р ь. Юк, кирәкми. Мин аңа күренмим. Мин аны куралмыйм. Мин сезнең өегезгә аяк басмаячакмын. *(Йөгереп Маргаретларга кереп китә. Урамнан ашыгып Арслан кайта, Галина йөгереп килеп аның кочагына ташлана.)*

Г а л и н а. Арслан! Арсланым минем... Син нигә шулай...

А р с л а н. Гафу ит мине... Минем күңелемә ниндидер бер шик... шом

дип әйтимме? Кинәт кулларым калтырый, буыннарым дерелди башлады. Иптәш Юнусовтан рөхсәт сорап, синең янына ашыктым... Ул кайда?

Галина. Син кайтканны күргәч, күршеләргә кереп китте. Кызык, сәер кеше ул дип сөйли идем бит үзенә...

Арслан. Ник кайткан ул? Кем янына?

Галина. Арслан!.. Синме соң бу?

Арслан. Син мине гафу ит. Мин көнчелекнең нәрсә икәнен белми идем. Мин синең минеке генә булуыңа ышанган идем. Шуңа синә тиешенчә игътибарлы була алмаганмындыр. Һәм менә хәзер арабызга өченче берәүнең килеп керүе...

Галина. Арслан...

Арслан. Һәм ул өченче берәү — синең беренче мәхәббәтең.

Галина. Арслан дим!..

Арслан. Әйе. Ул хәзер дә сине ярата һәм ул моңа лаек та... Шулай булгач...

Галина. Шулай булгач, син минем ирем, син минем балаларымның әтисе һәм син мине...

Арслан. Үлемнән коткардың, шулаймы? Һәм шуның өчен... Юк, бу безне бер-беребезгә бурычлы итми. Дөрес, син мине коткардың. Ә мәхәббәт? Мәхәббәт кайсы якта? Мәхәббәт кем ягында дип сорыйм мин синнән? Җавап бир? Икебез алдында да җавап бир... *(Маргаретлар крыльцосына бара башлый.)*

Галина *(аңа ташлана)*. Юк, юк, барма. Чакырма син аны. Шулай яхшырак. Син хаклы. Арага өченче берәү килеп керсә генә мәхәббәт ярларыннан чыгып ташый икән ул. Арага өченче берәү килеп кергәндә генә мәхәббәтне югалту куркынычы килеп туа икән ул! Ә мин мәхәббәтемне югалтырга теләмим. Теләмим... теләмим... Теләмим!

Арсланны кочаклап, өйләренә сөйри.

Ут сүнә.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Беренче пәрдә белән икенче пәрдә арасында берничә ел вакыт узган. Колхоз идарәсе. Председатель бүлмәсе. Пәрдә ачылганда бүлмәдә берәү дә юк. Бераздан арыган, тузанга баткан Арслан кайтып керә. Аның артыннан, тузаннарын кага-кага, Юнусов керә. Арслан, кулындагы чыбыркысын урындыкка ташлап, тәрәзә төбендәге графиннан бер стакан су алып, дәшми-тынмый, Юнусовка суза. Юнусов бер тынсыз эчеп, стаканны кире Арсланга бирә. Арслан үзенә бер стакан салып эчә дә, башындагы фуражкасын өстәлгә ташлап, тәрәзә янындагы урындыкка килеп утыра.

Арслан. Я?..

Юнусов. *(Дәшми.)*

Арслан *(ян тәрәзәнең рамына йодрыгы белән бәрә, тәрәзә ике якка ачылып китә)*.

Юнусов. Җилли, яңгыр булыр.

Арслан. Яңгыр астында калып чередеме, кыягында килеш, кызудан көеп куырылдымы — барыбер түгелмени?

Юнусов. Ә син тәрәзә рамыннан алма ачуыңны. Кояшта көяме, яңгырда черимме,— анысын күз күрер. Башта покоска егарга кирәк.

Арслан. Ектык инде. Ектык та, киптердек тә... Печәне печән генәме? *(Килеп түр тәрәзәне ача.)* Әнә кара... пожар сарае алдында...

Юнусов (*Арслан янына түр тәрәзәгә килә.*)

Ишектән Сөләйманны җитәкләп Галина керә.

Ә менә бу яңалык... Синең өчен. Үзең генә уйлап таптыңмы бу нәрсәне?

Арслан. Юк, иске дуслар ярдәм итте.

Юнусов. Димәк, шәп юлга баскансың... (*Ирония белән.*) Мактауга лаек! Монда бер 25 центнер булыр.

Арслан. Әле бу өч йорттан алып чыкканы гына.

Галина. Бөтен авылның печәнлеген, түбәсен актарып чыксаң, печән чабып, печән җыеп торасы да юк. Ферма малларына рәхәтләнеп бер кышлык җыеп алырга була. Нигә, шулай җиңелрәк ич?

Арслан. Көләсең?

Галина. Көлмим, чынлап әйтәм. Әнә анда авыл башына чыгып кара әле. Менә Сөләйман абзый басу капкасы төбенә тагы бер богыл өеп куйган.

Юнусов. Печәнме?

Галина. Чүп үләне. Кипкәч барыбер печән була инде ул.

Сөләйман. Знамо!

Галина. Каян килсен. Әнә, председатель приказ биргән, ә Сөләйман абзый утаудан кайтучы хатын-кызларның култык астына кыстырган үләннәрен бушаттырып тора. Бушатмасалар, таягы белән сыртларына менеп төшәргә дә күп сорамый.

Юнусов (*Арсланга*). Бу нәрсә була инде?

Галина. Әле минем кукуруз утап кайтучы укучы балалар кулындагын да бушаттырасы иде. Ничектер, ялгыш, таягы минем кулга кучеп калды.

Сөләйман. Шүрләдем. Мондый зәһәрлекне Галимә килен күзләрендә беренче күрүем минем, честно слово. Утызлап укучы баланы үләннәре белән үткәреп җибәрдем. Җавабын менә директорлары үзе бирсен.

Арслан. Ә сиңа чүп утаучы хатыннарның чүп үләннәрен алып калырга диган приказ булдымы?

Сөләйман. Булмаса... Кипкәч барыбер печән була ул, дип үзе әйтеп тора бит мәктәп директоры.

Арслан. Юк, син әйт, сиңа шундый приказ булдымы? Булдымы?

Сөләйман. Әнә кешеләрнең теземдәге печәннәрен дә ат белән кереп төяп алып чыгабыз бит — законно. Ныклабрак карасаң, шул чүп үләннән печән булган бит инде ул да.

Арслан. Ул — болын печәне. Колхоз болыныныкы.

Сөләйман. Ә мин — рядовой кыр сакчысы. Миңа кырныкы больше касается.

Арслан. Моннан соң чүп утаучы хатын-кызларның үләненә тимәскә.

Сөләйман. Миңа нәрсә? Үзең хуҗа. Бөтен болыныңны ташып бетерсеннәр шунда миңа димәгәе... Халык ул, бер слабинаңны сизеп алса... (*Тыштан Хәйдәр ишекне ача.*)

Хәйдәр. Әйдә, әйдә... Әйдә, кер монда.

Ишек төбендә Гариф күренә.

Гариф. Керәм, монда керергә дип килдем дә инде мин.

Арслан. Ни бар?

Хәйдәр. Менә Гариф... Кичә дә эшкә чыкмаган иде, бүген дә...

Гариф. Иртәгә дә чыкмыйм... Берсекөнгә дә, аның берсекөненә дә!

Арслан. Утыр әле, Гариф. Ни булды? Нигә тартәгә тибәсең?

Гариф. Ни булганын син үзең белергә тиеш. Понимаешь, ни өчен сайлап куйдык соң без сине? Шуны да аңламагач...

Юнусов. Утыр иптәш, тынычлан. (*Кесәсеннән папирос чыгарып.*) Тартасыңмы?

Гариф. Эчәм дә мин, салып бирсән.

Арслан. Я, кызма, кешеләрчә генә аңлашыйк әле. Кичә нигә дип эшкә чыкмадың?

Гариф. Базарга бардым. Теләче базарына... Сыерымны саттым, актык сыерымны! Аңлыйсыңмы син, крәстиян баласы? *(Хәйдәргә төртеп.)* Ә ул миңа печән чабарга куша. Чапмыйм мин аны, нигә чабыйм, чапканын төяп алып чыгып киттегез бит инде. Бер иманага шул житмимени?

Арслан. Ул — колхоз печәне.

Гариф. Ә мин кемнеке соң? Нәрсә белән туйдырырга тиеш мин ул балаларны, сөт тә булмагач? Ипи беләнме? Хатын белән икебезгә меңнән артык хезмәт көнебез бар, ә җилпучта бер умачлык он юк. Бүген печән чап, иртәгә печән чап... Ә өч көннән уракка. Илле генә грамм булса да аванс бирәсеңме соң син ул хезмәт көненә? Бирмисең бит. Бирмисең. Эх, Арслан! Арслан! Өченче ел председатель итеп сайлаганда ике кулымны күтәргән идем мин сиңа. Бөтен өметем синдә иде. Ярый, былтыр уңыш булмады, ә быел!.. Кара ул арыш басуын! Дугалы ат кереп күмелә. Башак исе борыныңны ярып керә. Ә беләсеңме син? Исе генә кереп кала бит ул ипинең безнең борынга. Әй, нигә сөйләп торырга, сез аны үзегез белмисезмени? Беләсез. Бик яхшы беләсез. Ләкин сезне безнең хәл кызыксындырмый. Сезгә планны-заданиене тутырырга кирәк. Арттырып тутырырга кирәк. Сезгә дан-шөһрәт кирәк. Орден кирәк! Ә колхозчы түзәр ул. Түзәр. Юк инде... Мин артык түзә алмыйм. Менә мә, кабул итеп ал!

Арслан. Нәрсә бу?

Гариф. Гариза. Китәм. Авылдан, колхоздан китәм. Тәрәзәләрен кадаклап кына түгел, йортымны сатып. Нигез-торыгы белән сатып! Олы улымны ФЗУга илтеп бирәм, төзүче булырга. Таш йортлар салыр, ичмасам, шәһәрдә, монда җимерек йортта черегәнче.

Галина. Идриснеме?

Гариф. Идрисне булмый, кемне булсын. Минем иң олы улым шул ич.

Галина. Идрис әле яшь, аны ФЗУга алмыйлар. Аннан соң без бит синең белән сөйләшкән идек...

Гариф. Нәрсә дип? Балага туган туфрак исе сеңдерергә дипме? Ә нәрсә бирә ул туган туфрак дигәнегез безгә? Әнә минем күрше Исмәгыйль малае... Былтыр киткән иде... Быел гармун куныччлы хром итек киеп кайткан. Ә минем малаеның гармун куныччлы хром итек киясе килмимени? Килә. Бик килә!

Галина. Их, Гариф абый...

Гариф. Нәрсә? Әйбәт укучымы? Аның кечкенәсе дә — Зәйтүнәсе дә начар укымый иде.

Галина. Бик әйбәт укый ул Зәйтүнә хәзер дә.

Гариф. Анысын да шәһәргә илтеп бирәм. Магазинда эшләүчеләргә, бала карарга. Авызын тутырып бер туйганчы икмәк ашар, ичмасам. Шәһәр икмәген. Монда үсми бит ул ипи дигән нәрсә, шәһәрдә үсә. Ә үзем, хатынымны җитәкләп, өйдә калган ике кечкенәмне култыкка кыстырам да шахтага китәм. Гаризама кул куйсаң да, куймасаң да китәм. Вербовать итәләп китәм. Менә шул. Беттеме сүзегез? Бетсә, бигайбә.

Чыгып китә, бар да тынып калалар.

Сөләйман. Менә... халыкка слабина бирүнең эрезультаты...

Арслан. Чыгып кит!

Сөләйман. Китәм, китәм *(ишектән, түзгып, Мәликә килеп керә)*. Менә тагы берсе, якаңнан алырга килде.

Мәликә. Аның түгел, синe якаңнан алырга килдем әле мин.

Сөләйман. Мин прсидәтел түгел, минем якага ябышып ерак бара алмассың.

Мәликә. Ә син һаман да әле безнең бугазга ябышып, безнең каны эчеп яшәмәкче буласыңмы?

Сөләйман. Осторожно, гражданка. Тол хатыннар заманы узды хәзер. Аннары соң син тол хатын да түгел, тол кыз гына бит...

Мәликә. Күзләрен генә чокып чыгарыймчы шул чыбыркы сабы белән. *(Сөләйманга ташлана.)*

Сөләйман. То-ты-гыз! *(Идәнгә, урындык артына яшерена.)*

Галина *(Мәликәне кочаклап ала)*. Мәликә дустым, кирәкми, тынычлан!

Мәликә. Нигә ул минем ансыз да әрнегән җәрәхәтемә тоз сала?

Сөләйман. Тер-рор! Көпә-көндез, идарәдә террор ясый башладылар! Кемгә? Долженостной лицога! Ни өчен? Һаман да шул колхоз эше артыннан җанын да, аякларын да кызганмыйча чапкан өчен! Товарищ Юнысов, син өченче генә булсаң да, секретарь кеше, сведитель булырсың, прокурорга барам.

Мәликә. Бардың инде син, күп тунадың безнең тирене прокурор исеме белән.

Арслан. Мәликә, кызма әле, иплэп кенә аңлатып бир. Ни булды?

Мәликә. Кичәдән бирле ун баш казымны лапасында ябып асрый. Кичә бардым шушы идарә язуы белән, бирмәде. Бүген бардым шушы язуны тотып... Хатыны Мәргәрит капкадан да кертми. Күсәк белән өстемә ташланды.

Арслан. Нигә бирми?

Мәликә. Идарә язуың белән бәдрәфкә бар, ди. Ун баш казга биш дистә йомырка сорый.

Арслан. Ун баш казга биш хезмәт көне күләмендә штраф тотылган. Ә йомырка ни өчен?

Мәликә. Үзләре тыгынырга. Идарәнең штраф язуын карап та тормыйлар алар. Каз башына биш йомырка, бозавы ябылса, ун йомырка, ә сыерың ябылса, сразы өч дистә чыгарып сал.

Сөләйман. Чыгармассың малларыңны колхоз басуына, чыгарып саласың килмәсә, карарсың.

Арслан. Басуга чыгарган өчен без идарә карары нигезендә штраф салабыз. Ә йомырка ни өчен дип сорыйм мин синнән?

Сөләйман. Төкерә ул синең штраф язуыңа. Хезмәт көне нәрсә соң ул? Һавадагы торна. Былтыр, 150 грамм биреп, выговор алдың бит. Быел анысын да бирә алмыйсың. Ярты уңышың МТСка түләү өчен житми, калган яртысы белән заданиеңне каплый алмыйсың. Ә хезмәт көненә нәрсә? Шымытыр. Белмимени аны колхозчы? Ул әллә кайчан исәпләп чыгарган инде. Бөтен хезмәт көнен штрафка алып бетерсәң дә исе китми аның. Ә менә бер мәртәбә йомырка китереп түләсә, икенче мәртәбә бозавының койрыгына ябышып йөри ул, казларын су буена арканлап куя.

Мәликә. Арканлап та котылып булмый бит сез үҗәтләрдән. Хәсбикамалның тау башына арканлап куйган бозавының казыгын йолкып алып кайтып япкансың. Минем алда күз яше белән ике дистә йомыркасын түләп алып китте. Ә минем ана казның тәпиенә күтәрмәле чабата бәйләгән иде. Мәргәритең чабатасын су буенда кисеп калдырган.

Арслан. Хатының эштә түгелмени?

Сөләйман. Ничек эштә булмасын? Көне буе ындыр басуыннан казлар куа. Үзем ерак басудан эре хайван куам. Өстәвенә, эреләндерәм дигән булып, Укмас колхозын кушкан булдың. Синең ул аксак алашаңа атланып кына бер полявой бөтен басуга өлгерәме?

Арслан. Хәзер үк Мәликәнең казларын биреп җибәр дә хатыныңны монда алып кил.

Сөләйман. Шушы язугамы?

Арслан. Әйе, шушы язуга. Хәйдәр, шушы өч көн эчендә кемнән күпме йомырка алган, бөтенесен хуҗаларына кире кайтарып бирергә. Бар, үзең тикшер, бер генә данәсе дә калмасын.

Мәлика. Ә тагын бер мәртәбә «тол кыз» сүзен ишетсәм, җир битендә бер генә бөртек сакалыңны да калдырмыйм мин синең.

Сөләйман. Әйдә, Хәйдәр, үзем генә бармыйм мин. Бу хатын...

Мәлика. Нәрсә?

Сөләйман. Белмим инде нәрсә диярга дә хәзер сине. Хатын дисәм хатын түгел, кыз дисәм...

Мәлика. Күп теләңә салынма, күркә токымы. Әйдә, Хәйдәр абый, үз-үземә ышанмыйм мин хәзер бу иблис белән ялгызым гына барырга. Я берәр тыкрыкта буып ташлармын да җавап бирәсе булыр.

Мәлика, Хәйдәр, Сөләйман чыгып китәләр.

Юнусов. Әйе...

Арслан. Әйе шул менә!.. Мине барыннан да бигрәк Гариф мәсьәләсе борчый.

Галина. Әгәр дә бу юл белән барсаң, йортларын-нигезләрен сатып авылдан качучы бер Гариф кына булмаячак.

Арслан. Ә нинди юл белән барырга? Бармы ул икенче юл? Менә син, Юнусов, райком секретаре, әйт, бармы?

Галина. Бар, юллар күп, максат бар. Шул максатка һәрбер кеше үз җирлегеннән чыгып үзенә уңайлы юлны сайлап барырга тиеш.

Арслан. Барып кара. Былтыр бер адым атладым бит инде мин үз юлым белән. Шунда ук китереп түбәгә суктылар.

Галина. Адымыңның дөреслеген исбат итә белергә дә кирәк бит, бигрәктә ул яңа адым булса...

Арслан. Иттерделәрме соң? Авыз ачарга да бирмәделәр бит. Әнә Юнусов үзе шунда иде. Аңа да өстәл сугып бер генә кычкырды Кадыйров.

Юнусов. Ә без аның белән бу мәсьәләдә көн саен өстәл сугышабыз.

Галина. Син шурләп төштең? Сүздә исбат итәргә бирмәсәләр, син эштә исбат ит, чөбешне бит көз көне саныйлар.

Арслан. Көз көне... өч көннән уракка чыгарга. Колхозчының җилпучында бер умачлык он юк, ә син көз көне...

Галина. Бәлки, Кадыйров үзе килеп аванс бирер синең колхозыңа.

Арслан. Бирер. Әнә өзлексез телефоннан кычкырып тора. Заданиене үтәми торып, беркемгә бер грамм...

Галина. Арс-лан! Синме соң бу? Син сөйлисеңме бу сүзләрне? Ничә мәртәбә үлемнең үзе белән якага-яка килгән Арслан, коры йодрык белән өстәл сукканга коелып төштең. Сайлаган юлыңның дөреслеген белә торып.

Арслан. Дөреслек! Син дә белә идең бит ул дөреслекне. Юнусов та белә иде. Әй, нәрсә сөйләргә!.. Институтны бетергәч, мин аспирантурада калам, дидем. Башлап син каршы килдең. Ярый, кайттым, агроном булдым. Әнә Юнусов башымны менә монда китереп бәйләде.

Юнусов. Димәк, миндә хата булган. Сиңа карата ялгыш фикердә булганмын икән мин. Туган туфрагына ябышкан кеше дип уйлаган идем мин сине. Авылдашларың да сине председатель итеп кайтаруны сорагач... Ә син инде үзеңә карата булган ышанычка шулай карыйсың икән, ул вакытта кит, без сине тотмыйбыз. Авылдашларың да бик ябышырга тормаслар шикелле, болай булгач...

Галина. Кайчандыр дүрт йөз хуҗалык булган авыл өч йөз хуҗалыкка калса, Гариф кебек колхозчылар берәм-берәм китеп торсалар, өч йөз хуҗалыкның йөз иллесе сыерсыз калса...

А р с л а н. Мина кадәр калганнар бит алар!

Г а л и н а. Шул аяныч хәлгә син сыкрый белмәсәң, иген иккән игенчегә син ипи ашатмасан, печән чапкан колхозчыга сыерын түгел, кәжәсен дә кышлатып чыгарлык печән бирә алмасаң, синең кемгә һәм ни өчен кирәгең бар?

А р с л а н. Мин боларның берсен дә аңламыйммыни? Минем бөтен омтылышым шуңа юнәлмәгәнмени? *(Түр тәрәзәгә килеп, тәрәзә рамнарын ике якка ачып җибәрә.)* Сизәсеңме, басу исе... Басудан яңа икмәк исе авылга бөрки!.. Ә нигә ашыга ул Гариф? Шушы хәзинәне ташлап китәргә нигә ашыга?

Г а л и н а. Бәлки, синең үзеңә ашыга төшәргә кирәктер? Ә Гариф мәсьәләсендә борчылма син. Мин хәзер аның өенә барам. Бу хәл минем үземне дә борчый. Ничә ел балаларда туган туфракка мәхәббәт уятырга тырышам. Ә алар җидене бетерәләр дә, тизрәк тузаннарын кагып, авылдан чыгып качарга ашыгалар. Җирдә кем калыр болай булса?!

А р с л а н. Син бар. *(Күз яше белән.)* Бар! Күр Гарифны.

Г а л и н а *(килеп аның чәчләреннән сыйпый)*. Барам. Менә шулай өметле яшь белән сугарылган яшәү татлырак була ул, картым! *(Кинәт яшәреп китеп Арсланны кочаклап үбеп ала, шунда ук Юнусовка борыла.)* Сез безне гафу итегез инде, бик сирәк була ул бездә мондый хәл! *(Чыгып китә.)*

А р с л а н. Гафу ит, Юнусов, кайвакыт шулай пружина бушап ала. *(Күрше бүлмәгә.)* Сания! Хәзер үк бөтен бригадаларның ярты еллык хезмәт көннәренә йомгак ясап куй. Идарә утырышына әзер булсын! Әхми, атыңа атлан да бөтен идарә члennарына хәбәр ит, ярты сәгатьтән монда булырга. Чираттан тыш идарә утырышы була. *(Юнусовка.)* Ә син нигә елмаясың, хәйләкәр?

Ю н у с о в. Кадыйровның өстәл сугуыннан курыкмыйсыңмы соң?

А р с л а н. Өстәл ике башлы бит ул, Юнусов.

Ю н у с о в. Икенче башына син сугарсыңмы?

А р с л а н. Һәм өстәл сугар өчен дә түгел ул, өстәлгә халык өчен сый-хөрмәт хәзерләп куялар. Ә сые мул өстәлгә берәүнең дә кулы күтәрелмәячәк.

Ю н у с о в. Ышанасыңмы син сыеңның мул булачагына?

А р с л а н. Ышанам.

Ю н у с о в. Ә ул әнә ышанмый, Кадыйровны әйтәм, курка. Үз шәүләсеннән үзе курка. Искерде, картайды. Үзе дә, фикере дә. Ә фикер картаю... Ай-һай, безнең эштә яман нәрсә. Тормыш бит ул алга бара... Ә без аның алдыннан атларга, ерактан күреп атларга тиешбез.

А р с л а н. Син бар, кайт, бүгенгә хатының, семьяң янына кайтып тор.

Ю н у с о в. Мин райком секретаре гына түгел, шушы колхозның уполномоченные да.

А р с л а н. Ә мин идарә членнарын гына чакырам.

Ю н у с о в. Курыкма, мин сезнең демократиягезгә кул салмам.

А р с л а н. Мин сезгә идарә утырышының беркетмәсен җибәрермен.

Ю н у с о в. Барлык колхозлар өчен дә үрнәк беркетмә булсын иде инде ул. Карт йодрыгыннан катырак килеп төшәрлек булсын иде өстәлгә. Аңладыңмы?

А р с л а н. Аңладым.

Ю н у с о в. Аңласаң шул, хәрәкәттә бәрәкәт.

Ишектән С ө л ә й м а н, М а р г а р е т, Х ә й д ә р керәләр.

А р с л а н. Я... Мәликәнең казларын биреп җибәрдеңме?

С ө л ә й м а н. Җибәрдем. Эризультаты өчен үзең җавап бирерсең.

А р с л а н *(Хәйдәргә)*. Тагы кем малары бар аның лапасында?

Хәйдәр. Нигъмәтжанның танасы иде, сеңерен буып куйган. Ветеринарга алып китте.
Сөләйман. Мин аны төбәк басуыннан ук алып кайттым. Куып житәр хәл юк. Сеңерен бугач туктады хайван.
Арслан. Менә нәрсә, син артык кыр сакчысы булырга ярамыйсың. Бүген төнлә амбарлар янына каравылга.
Сөләйман. Во-первых, мине син куймадың, идарә куйды.
Арслан. Хәйдәр, бер әйбәт кандидатура хәзерлә. Хәзер идарә утырышы, шунда расларбыз.
Сөләйман. Во-вторых, мин каравылга ярамыйм, миндә тавык күзе.
Арслан. Күп йомырка ашаганнан ул. Умачка күчкәч узар.
Сөләйман. Товарищ Юнусов, бу нинди башбаштаклык бу? Мин бывший нуменклатурный работник. Мин бөтен авылны ике бармагымда тоткан кеше. «Син районның бердәнбер терәге» дия иде трибунадан торып иптәш Кадыйров. Мин хәзер аның үзенә жалоба белән барам.
Арслан. Бик әйбәт, төнлә каравылда торырсың, ә көндезләрен жалоба белән йөрерсен. Ә сез, Мәрьямбану ханым?
Маргарет. Ә юк инде, миңа батмый, мине бернинди эшкә дә куша алмыйсың. Мин эвакуированный, мин бывший комсостав хатыны.
Арслан. Эвакуированныйлар күптән урыннарында инде. Аннан соң бездә бывшийлар да юк хәзер. Сез — колхозчы Сөләйман Сабиров хатыны. Әгәр дә колхозда эшләргә теләмисез икән, устав нигезендә колхоздан чыгарып, бәрәңге бакчагызны алачакбыз. Гомуми жыелышның колхозда эшләмәгән семьяны бөтенләй авылдан сөрергә дә хакы бар. Барыгыз, иртәгесе көннән эшкә!
Хәйдәр. Маргарет ханымны кая кушарга?
Арслан. Печәнчеләргә. Чүмәләгә печән биреп торырга.
Маргарет. Мин аның кайсы башыннан тотып бирәсен дә белмим ул печәннең.
Арслан. Юан башыннан тотып бирерсең.
Маргарет. Кара, кара... Томан икәнсең син, әй, гел томан!
Арслан. Томан юк инде хәзер, Маргарет ханым, томан таралып бара. *(Сөләйман юан итеп тәмәке урый да, бүрегенең бер колагын күтәреп, ишек төбендәге аралыкка барып идәнгә чүгәли, тәмәке кабыза.)*
Арслан. Ә син нәрсә?
Сөләйман. Эңгер-меңгер төшә. Тиздән каравылга менәргә вакыт. Бер генә көйрәтеп алам да... Тәмле бит биредә көйрәтүе. Идарәдә тәмәке көйрәтү элек-электән калган гадәт инде ул.

Ишектән Галина кайтып керә.

Арслан. Я, ничек? Күрдеңме? Сөйләштеңме Гариф белән?
Галина. Туган туфрагын ташлап китү кешегә җиңелме әллә. Бераз төшереп алган. Елый. Хатыны да китмик дип ялвара. Ә син ашык, ашык, Арслан!
Арслан. Хәйдәр, хәзер идарә утырышында печәнне печәнчеләргә процентлап бүлеп бирәбез.
Хәйдәр. Арслан! Болай булса, без өч көндә бөтен болынны ялап чыгабыз. Халыкны болынга сыйдырып булмаячак.
Арслан. Өч көннән уракка. Беренче суккан икмәкне колхозчыларга. Хезмәт көненә икешәр йөз граммнан аванс бирергә. Бар, идарә әгъзаларын шуңа хәзерли тор. *(Хәйдәр эчке бүлмәгә үтә.)*
Арслан *(Юнусовка)*. Әйдә, иптәш секретарь. *(Арслан эчке бүлмәгә үтә, Юнусов Галина каршында тукталып кала.)*
Галина *(авыр һәм тирән сулап)*. Башлана бугай... Инде... авылга... Бер мәктәп тә салып җибәрсәк... хәерле сәгатьтә! *(Арып агарынып бу-*

*мә буендагы урындыкка утыра. Аралыкта утырган Сөләйман акрын гына килеп телефон трубкасын ала.)*

Сөләйман. Станция, миңа райкомны бирегез. Иптәш Кадыйровны. *(Юнусов килеп телефонның рычагына баса.)* Нәрсә? Карап торып колхозның икмәген, печәнен таратырга юл куяргамы? Дәүләт заданиесен өзәргә! Кадыйров... Кадыйровны миңа!!

Юнусов. Арыган инде ул. Борчымагыз сез аны. Ә сезгә, Сөләйман абзый... *(сәгатенә карап.)* Каравылга вакыт. *(Сөләйман кулыннан трубканы ала, Сөләйман бүрегенең сыңар колагын төшереп чыгып китә. Юнусов Галина янына килә.)* Сезгә начармы? Сез агарып калгансыз.

Арслан чыга.

Арслан. Сезне көтәбез, Юнусов.

Юнусов. Керәм. *(Эчке бүлмәгә китә.)*

Арслан *(Маргаретка)*. Ә сез нәрсә? Барыгыз.

Маргарет. Кычкырма син миңа. Әнә, хатыныңа кычкыр, ярыймы, Казан юлын сирәгрәк таптасын.

Галина. Шуның белән нәрсә әйтергә телисез?

Маргарет. Теләмим. Миңа әнә шул йоны коелган өтек карт бик житкән, мин артыгын теләмим. Артыгын теләүчеләр Казан юлын таптыйлар. Мәктәп төзергә проект дигән булып.

Арслан. Таптаса ни булган?

Гариф керә.

Маргарет. Ни булганын мин каян белим. Ни булганын син инде аның Казандагы сөяркәсеннән барып сора.

Арслан. Нәрсә? Кемнән, кемнән?

Маргарет. Теге миндә кунып киткән врач егет Игорьдан. Әнә, Гариф та күреп кайткан үзен.

Гариф. Күрсә ни булган?

Маргарет. Булмаган. Монда, якынга Вишневский бульнисына кайтып урнашкан. Өйләнмәгән дә ди үзе. Нигә өйләнсен, гутовый хатын булганда. Расходсыз. Ара-тирә күчтәнәчен-мүчтәнәчен алып килеп тора.

Гариф. Ах, менә син мине нәрсәгә урарга телисең икән. Күптән кулым кычытып йөри иде үзенә...

Маргарет. Кара-у-ул-о-л! *(Чыгып йөгерә, Гариф аны куып китә.)*

Арслан. Тынычлан. Үзеңне кулга ал.

Галина. Кайчан барган идем соң мин Казанга?

Арслан. Әнә шул мәктәп проекты артыннан иде. Иөрмә. Хөкүмәтнең әле авыр еллары. Бер-ике ел түз. Аннан, колхозга мая туплагач, колхоз хисабыннан салырбыз мәктәпне, менә дигән итеп, таштан.

Галина. Игорьның Казанга кайтканын белмәгән дә идем бит әле мин.

Арслан. Гафу ит, ул миңа хат язган иде. Эшнең кызу вакытына туры килде. Җавап яза алганым юк. Сиңа да әйтми тора идем. Гайбәттән өстен булырга кирәк. Бүген үк хат язарга кирәк үзенә. Кунакка чакырып.

Галина. Юк, юк, кирәкми.

Арслан. Кирәк. Мин бит аңлыйм, сиңа бирсдә аннан да якын кеше юк. Шулай булгач, йөрешергә кирәк үзе белән, ачыктан-ачык.

Гариф әйләнеп кайта.

Гариф. Тотып булмады бит кычыткан чыпчыгын. Яра идем менә шушы каеш йөгән белән.

Арслан. Кирәкми, Гариф.

Гариф. Хатын авырый бит, Казанга врачка алып барган идем атынны. Шул врачка туры килдем. Сәлам әйтте сезнең барыгызга да. Э хатынның хәле шәп түгел. Мине гафу ит син, Арслан. Мин аптырагач... Китим микән әллә диган идем. Китеп кая барасың, авыру хатын белән. Менә йөгән, хәзер алашамны жигәм дә печәнгә, богыл тартты-ырга. *(Китә.)*

Арслан. Күрәсең, бар да җайлана. Әйдә, кайтарып куйыйк үзеңне, Галимә.

Галина. Юк, юк. Мин үзем кайтам. Балаларым Тәнзилә, Илдусым иына. Акрын гына, кичке салкынча һаваны сулап. Ә син бар... Бар, Арслан, анда кер... Анда!

Ут сүнә.

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

Арсланнар өе. Күп еллар үткән. Вакыйга инде бүгенге көнгә килеп тоташа. Пәрдә ачылганда Сабира, Тәнзилә, Мәликә ашыга-ашыга залда кунак табыны әзерләп йөриләр.

Сабира. Була микән инде, балалар? Киртәсенә керде микән? Без кунак алып кунак уздырган кешемени соң?..

Мәликә. Әйе шул, Сабира түти, сезнекеләр бигрәк инде сау-сәламәт вакытта яши белеп яшәмәделәр. Башка председательләр әнә кунак-кунак уйнаудан туймыйлар. Машинасы-машинасы белән төяп алып кайталар кунакны, төяп озаталар. Районнан димсең, Казаннан димсең.

Тәнзилә. Куй инде, Мәликә апа, шул яши белеп яшәүне.

Мәликә. Ник, гомер ике киләмени ул, рәхәтен дә күреп калмагач.

Сабира. Кайтып та җитәрләр, Казан асты тирәләрен карый торырга иде.

Мәликә. Теге нәрсәләрегез бер дә күренми әле монда, шкаф аслагыз да буп-буш, председатель табынымыни инде ул, бер шешәсе дә булмагач...

Сабира. Андый нәрсәне өемә керткәнем булмады минем, кем, Мәликә. Инде көмеш туй хөрмәтенә үзләре белән Казаннан ала кайталар икән, бер генә юлга дәшми калырга исәп, күрмәмешкә салышып.

Мәликә. Галимәне әйтәм, туй мәҗлесендә утыра алырлык микән соң?

Сабира. Терелә бугай инде... Бер ел бит, бер ел түшәк өстендә.

Тәнзилә. Башта профессор якын да килмәгән иде, кичә консилиумнан соң бөтенләй алып кайтырга рөхсәт итте. Тик өегезгә кадәр үзем кайтарып куям, ди. Туй мәҗлесе уздырырга да ризалык бирде.

Сабира. Больниска китә киткәннән бирле шул көмеш туй дип саташкан инде, балакаем. Әнкәй туйга фәлән нәрсәне хәзерлә, төгән нәрсәне онытa күрмә дип, барган саен мине кисәтеп торды. Үзе хәл эчендә ятa, үзе көмеш туй дип хыяллана.

Мәликә. Сырхау кешегә балалар акылы керә шул.

Сабира. Сагындым дип өзгәләнде. Кыз вакытыннан килгән сандыгы бар аның, шунын ачкычын узган ел больниска киткәндә машинага кертеп салгач сорап алып куенына тыкты. Барган саен бер чыгара

ачкычын баш астыннан, бер салып куя. «Сандыгымны миннән башка ача күрмәгез, алай-болай булсам, менә ачкычы баш астымда» дип гел искә төшереп торды.

Мәликә. Ниләр керми сырхау кешенең башына.

Сабира. Булды шикелле инде бу, балалар.

Мәликә. Әйбәт табын булды инде бу, шәһәр табыны шикелле булды. Монда ниләр генә юк.

Сабира. Чәкчәкне туйда кунаклар табынга утырышып беткәч кенә чыгаралар бугай.

Гариф бер кочак чәчәк күтәреп керә.

Гариф. Чәкчәкне шулайдыр, ә менә чәчәкне алдан утыртып куегыз табынга.

Тәнзилә. Ой, нинди матур чәчәкләр!..

Гариф. Моны Зәйтүнә кызым үстерде, теге синең белән бер класста укыганы. Казанга, асраулыкка илтеп биргән идем бит мин аны теге елны, җүләр. Әниең тәки кайтартты бит шул кызны. Кайтартты да бакчачылар курсына җибәрттерде. Ә хәзер менә нинди чәчәкләр үстерә колхозга.

Тәнзилә. Кая, мин аларны вазага утыртыйм.

Гариф. Кызым бакчачы, улым Идрис колхозның почетный тезүче-техникы булды. Кара, Сабира түти, минем улым нинди мәктәп төзеттереп бирде колхозга. Укытучы апам өчен дип тырышты. Тик укытучы апалары гына... Кызык икән ул кеше дигәнең, Сабира түти, әй... Галимә киленне әйтәм әле, нинди авыр елларны җиңеп чыкты, авырлыкларга түзде. Ә менә шатлыкка түзә алмады. Узган ел шушы мәктәпне ачканда бит инде... Иптәш Юнусов, үзегез төзегән мәктәп, үзегез беренче булып атлап керегез дип, Галимә кулына кайчы тоттырды. Галимә шатлыгыннан нишләргә белми. Йөзе ап-ак булды, куллары калтырый. Ишеккә аркылы тарттырган кызыл лентаны кисеп җибәрде дә... чайкалып китеп...

Сабира. Сөйләмә инде...

Гариф. Ярый әле шул тантанага профессор үзе килгән иде Казаннан.

Мәликә. Бәхеткә каршы диген.

Сабира. Әнә, кызым Тәнзиләнен укытучысы бит ул. Икесе бергә кайткан иде, әниләренең бәйрәменә.

Тәнзилә. Профессор Игорь Валериановичны әйтәсезме? Безнең кафедра мөдире ул.

Сабира. Тәнзилә кызымны бик ярата.

Тәнзилә. Таня, Танюша дип кенә йөри ул миңа.

Гариф. Бүгенге мәҗлескә ул да кайтадыр бит кунак булып?

Сабира. Ансыз мөмкинме соң? Галимә балакаемны шул профессор гына аякка бастырды бит, юкса, бөтенләй өметсез иде...

Гариф. Хатыны белән чакырырга иде үзен, парлап.

Тәнзилә. Аның хатыны юк шул. Ул өйләнмәгән, егет кеше.

Гариф. Ничек юк? Шундый ап-ак чәчле егет була димени?

Тәнзилә. Була икән шул, фәнгә гашыйк ул. Наука Ивановна белән торып калган ул дип көләләр үзеннән безнең студентлар.

Сабира. Сезгә, яшьләргә, көләргә генә булсын. Әйдә, кызым, чәкчәкләрне дә чыгарып куйыйк. Ярый әле, син алдан кайттың булышырга.

Тәнзилә. Илдус абыйга да әйткән идем мин алдан кайта торыйк дип.

Сабира. Илдус миңа нәрсә булыша алсын соң ул...

Керен китәләр.

Г а р и ф. Әйе, Галимә киленне аякка бастырды профессор, ә минә минем хатынны... Ике ел бит инде, ике ел хатынны җирләгәнгә. Балалар белән генә яшәве авыр, Мәлика. Җиткән кыз белән җиткән егет булсалар да авыр. Җан дусты кирәк. Эч серләрен бушатырга сер сандыгы да кирәк кай вакытта... Мәлика, теге чакта инде син Низаметдинымны көтәм дип отказ биргән идең. Низаметдиның, мескен, кайта алмады. Бәлки, хәзер үйлап карарсың, ә? Сиңа да җиңел түгелдер ялгыз яшәве.

М ә л и к ә. Кем әйтте сиңа мине ялгыз яши дип? Мин ялгыз яшәмим. Мин һаман да әле Низаметдиным белән яшим, мин һаман да әле аны көтеп яшим.

Г а р и ф. Соң, сугыш беткәнгә дә инде егерме биш ел булды бит.

М ә л и к ә. Булсын. Утыз булсын, илле булсын! Мин барыбер аны көтәчәкмен. Үлгәнче көтәчәкмен. Нәрсә соң сез барыгыз да миңа бәйләнәсез. Хатыннары үлсә — Мәлика, хатын аерсалар — Мәлика. Мин сезгә нәрсә? Тол хатынмы? Мин тол түгел, минем Низаметдиным бар. Ул исән, ул бар. Бар, бар!..

Мәлика елап эчке бүлмәгә кереп китә.

Г а р и ф. Авырткан җиренә бастым, ахры.

Күршедән С ө л ә й м а н чыга.

Г а р и ф. Син кая болай йөгерәсең, мулла?

С ө л ә й м а н. Күрше авылга.

Г а р и ф. Әлхәм-колһуалла укыргамы?

С ө л ә й м а н. Анысын да укыштыргалыйбыз, ә как-же.

Г а р и ф. Тәлинкәгә әлеф тә язгалап бирәбезме?

С ө л ә й м а н. Булгалый анысы да карт-корыга.

Г а р и ф. Үтәме соң товарың?

С ө л ә й м а н. Ераграк авылларда үткәли. Ә безнең тирә халкы эре кыланган була бит ул элек-электән. Кая, папиросың бармы?

Г а р и ф. Тәмәкелек тә акчаң юкмыни мулла булып йөреп?

С ө л ә й м а н. Вак-төяк хәер белән ерак китеп буламыни. Кесә төбендә кайткан тиеннәрне дә чүпләп кенә тора Маргарет җиңгән.

Г а р и ф. Малайлар булышмыймы?

С ө л ә й м а н. Булышыр бар, килеп тә карамыйлар. Бу йортның үз хуҗалары Харис белән Халисә кайткач, безне Зарифа карчыктан калган җимерек йортка күчергән булдыгыз бит үзегез. Зарифа карчыкның җимерегә астында калсаң, актарып алырга да килмәс ул балалар. Суд белән алимент алмый булмый инде ул җүнсезләрдән. Әнә, Маргарет кәнсәләр иданен юарга бара. Күреп алса, ул мине дә үзе белән сөйрәячәк. Булышырга дигән булып. Ычкыныйм әле мин тизрәк... *(Кача-поса чыгып китә. Гариф икенче якка китә башлый. Сабира чыгып баса.)*

Еракган кычкыра-кычкыра М а р г а р е т керә.

М а р г а р е т. Кая качасың, карт күркә?! Кара, кара, китте бит, артына да әйләнеп карамады. Әрәмкәй генә үтте бит гомерләрем шул өтек белән.

Г а р и ф. Зато мулла, әлхәм-колһуалла укып йөри карт-корыга.

М а р г а р е т. Әлхәмен укытам әле мин аңа. Кайтып кына керсен. Кәнсәләр иданен борыны белән кырдыртып юдырам. Яшьлегемне әрәм иттем бит шул күркә белән. Я, әйт, кемгә ярыйм инде мин хәзер.

Г а р и ф. Аттестатлар томан булып очтымы?

М а р г а р е т. Томан шул, томан. Бар да томанга әйләнде. Менә хәзер шул указсыз мулланың тәһарәт чүпрәкләрен юып йөр инде. Әй, дөнья, әй, язмыш! *(Сукрана-сукрана китә.)*

С а б и р а. Син кая, Гарифулла?

Г а р и ф. Кайтыйм. Табыныгызны бизәргә чәчәк китерим дип кенә килгән идем.

С а б и р а. Юк, юк, җибәрмим. Чәчәкләрең табынны бизәсә, үзең мәҗлесне бизәрсең.

Г а р и ф. Мин бит чакырулы кеше түгел.

С а б и р а. Берәү дә чакырылмаган. Галимә киленем башта ук кисәтеп куйды, кечкенә генә итеп, семья туе итеп кенә уздырырга. Әнә Казаннан балаларны — Илдусны, Тәнзиләне кайтартып. Инде менә синең кебек якын итеп килүчеләр була икән, аларны кире чыгару юк.

Г а р и ф. Бөтен колхоз белән уздырасы иде бит мондый мәҗлесне...

Машиналар тавышы.

Т ә н з и л ә террасага йөгереп чыга.

Т ә н з и л ә. Кайттылар!

С а б и р а. Казан астын карагыз дидем бит.

М ә л и к ә. Зарар юк, өлгерербез.

Каршыларга чыгалар, артта шау-шу, каршы алу, исәнләшү-күрешү. Бераздан Г а л и н а н ы И л д у с белән А р с л а н җитәкләп алып керәләр. Ул үз өенә кайтканына шат, зәгыйфь тавышы белән кете-кете көләргә азаплана. Алар белән С а б и р а, Т ә н з и л ә, М ә л и к ә, И г о р ь, Г а р и ф, Х ә й д ә р керәләр.

С а б и р а. Менә монда, менә түргә утыртыгыз балакаемны! *(Креслога мендәр китереп сала.)*

Г а л и н а. Юк, юк... монда утырып тормыйк инде без, әнкәй. Менә кайтып та җиттем үз йортыма... О! Туй табыны. Вакытны бушка уздырмыйк инде. Кунаклар утырыша торсыннар, ә без синең белән, этисе,— кәләш белән кияү. Әйдә туй киемнәребезне киеник. Йоласына туры килсен. Минем сандыгым... Минем сандыгымны ачмадыгызмы?

Т ә н з и л ә. Юк, юк, әнкәй, сандыгың үз бүлмәңдә. Әйдә.

Г а л и н а. Анда кермәгез инде сез, балалар. Берегез дә. Без кияү белән кәләш икәү генә керик. Бар да әзер булгач, без киенешеп чыгарбыз. Нәкъ туйдагы шикелле булсын. Мәликә, әйдә син кәләшне киендерүче булырсың. Ә кияү ягыннан кияү егете Хәйдәр булыр.

А р с л а н. Алайса, Хәйдәр, син табынга утыра тор. Мин үзем дәшеп алырмын.

Г а л и н а, А р с л а н, М ә л и к ә эчке бүлмәгә кереп китәләр.

С а б и р а. Духтыр, менә түргә, түргә утырыгыз.

И г о р ь. Без алар чыкканны көтик инде. *(Саквояжыннан өстәлгә ике шешә шампанское чыгарып куя. Илдус вино шешәләре чыгара.)*

С а б и р а *(Игорь янына килеп, пышылдап)*. Иртә кайтармадыгызмы, духтыр, кыяфәте бик әйбәт күренми?

И г о р ь. Юк, нәкъ вакытында.

С а б и р а. Әле дәваларга кирәк түгел идеме?

И г о р ь. Артык дәвалауның кирәге юк инде, әбекәй.

С а б и р а. Шулайдыр инде, шулайдыр... Сез духтыр, үзегез беләсездер.

Х ә й д ә р. Сез бик ачык әйтмәдегез шикелле, профессор?

И г о р ь. Ярый, бу турыда балалар алдында кирәкми.

А р с л а н *(эчке бүлмәдән)*. Хәй-дәр!

И г о р ь. Бар, әнә кияү егетен сорыйлар.

Х ә й д ә р. Кияү егетенә сөлге-фәлән асмыйлармы, Сабира түти?

С а б и р а. Юк, кияү егетенә чиккән яулык белән сөяк саплы пәкә бирәләр.

Хәйдәр. Аларын кем бирергә тиеш?

Сабира. Яулыгын яшь килен, пәкесен яшь кияү бирә.

Хәйдәр. Димәк, болардан миңа бернәрсә дә тәтемәячәк.

Сабира. Бар, бар, анысын үзләре карарлар әле. *(Хәйдәр эчке ·лмәгә кереп китә.)* Әй, яшьлек! Нинди генә әкәмәтләре булмаган ың әлек... Ул ишек бавы тоту дисеңме!..

Тәнзилә. Ничек ишек бавы, әбекәй?

Сабира. Әнә, ишеккә кара, ишеккә.

шек ачыла, аннан житәкләшеп Арслан белән Галина чыгалар. Алар артында айдәр белән Мәлика. Арслан — өр-яңа кара костюмнан, ак күлмәк, кара галстук м кара кәләпүштән. Галина — озын ак туй күлмәгеннән, туй бөркәнчегеннән. Аның емендә Украина халкының милли чигешләре. Алар парлап өстәлне әйләнәләр. Аннан өстәл башындагы ике урындык артына килеп басалар. Барысы да тынып кала.

Сабира *(килеп икесенең дә маңгайларыннан үбә)*. Котлы, мөбарәк улсын туегыз, балакайлар!..

Хәйдәр. Амин. Алтын туйга кадәр яшәргә насыйп булсын.

Сабира. Утырыгыз, балакайлар. *(Бары да утырышалар, тик горь генә Галинага карап сокланып басып тора.)*

Галина. Сез нигә утырмыйсыз, Игорь Валерианович?

Игорь. Менә мин сезне күреп онытылып киттем бит әле, Галина аксимовна... Ничек һәм кайда саклаדыгыз сез шул гомер буе туй киемәрен? Бу сезнең кыз вакытыгызда, үзегез, үз кулларыгыз белән чигеп шләгән хәзинәгез бит.

Галина. Әйе. Кыз вакытымда, туема дип эшләгән идем. Сезнең елән булачак туема дип эшләгән идем. Ләкин безнең ул туебыз булыйча калды. Безнең яшьлек коточкыч чорга туры килде. Арслан елән дә безнең туебыз блиндажларда, траншеяларда узды. Өстебездән рапнель яңгырлары яуды безнең туебызда. Шулай бит, әтисе? Ләкин үй хыялы минем күңелдән китмәде. Еллар авыр булган саен, мин бу изәкләрне ераграк, әчкәрәк яшерә бардым. Бөтен нәрсәмне сатып, изыкка алыштырып бетердем, әмма боларны саклаדым. Шулай итеп езнең беренче ширбәт туебыз була алмый калды. Ләкин мин үкенмим. ның каравы, менә ничек мул итеп уздырабыз без көмеш туебызны. Јуның өчен бер ел буе больница койкасында ашкындым да бит мин. , башлыйк инде.

Игорь. Болай булгач, башлыйбыз инде, дуслар. *(Шампанское шәсен кулга ала.)* Шартлатабыз!!!

Хәйдәр. Шартласыннар шешәләр, чыңласыннар бокаллар! *(Шешәәр шартлый, бокаллар тула. Барысы да бокалларын кулларына алаар.)* Я, ни өчен күтәрәбез беренче бокалларны?

Игорь. Берни өчен дә күтәреп булмый әле. Ачы бит бу.

Хәйдәр. Чыннан да, ачы икән бит, ачы!

Бары да. Ачы, ачы! *(Арслан белән Галина акрын гына үбеләр.)*

Хәйдәр. Менә хәзер күтәрсәк тә була.

Игорь. Яшьлек өчен! Сезне бу бизәкләрдә күргәч, яшьлегем искә өште бит әле минем дә, Галина Максимовна! Яшьлек үткән туган яклаым күз алдыма килеп басты. Днепр буйларында ялан аяк йөргән вакытар!.. *(Галинага кинәт авыр булып китә, ул бөтен гәүдәсе калтыранган әлдә, чайкала-чайкала, бүлмәсенә кереп китә. Арслан, Игорь, Сабира ның артыннан ташланалар.)*

Арслан. Галимә!

Игорь. Галина!

Сабира. Балам! *(Бары да эчке бүлмәгә омтылган килеш калалар.)*

*Пәрдә.*

## БИШЕНЧЕ КАРТИНА

*Шул ук сәхнә, иртән таң беленеп килгән вакыт.* Г а л и н а *үз бүлмәсендә, калын бер дәфтәргә ашыга-ашыга нидер яза. Арыгач, бераз туктап, бармакларын хәрәкәтләндереп хәл жыеп ала да, тагын дөньясын онытып яза башлый.* А р с л а н *залда, туй киемнәрен дә салмаган килеш, тирән креслога утырган да йокыга киткән. Бераздан кинәт сискәнеп уяна. Хафаланып Галина бүлмәсенә карый. Анда ут янганын күреп, акрын гына торып ишеккә килә.*

А р с л а н. Әнисе... Син йокламыйсыңмыни? Әнисе!

Г а л и н а. Әйе, әйе, әтисе, кер, минем яныма кер, менә көндәлек дәфтәремне карап утыра идем әле. Уйласаң, искиткеч. Озын юл үткән без икән без синең белән. Авыр да, газаплы да. Шул ук вакытта татлы да булган икән ул безнең юлыбыз, аның шатлыгы да, кайгысы да булган. Ләкин без ул юлны синең белән бик матур үткәнбез. Мин канәгать, мин үткәнебездән бик канәгать, Арсланым!

А р с л а н. Сиңа йокларга иде.

Г а л и н а. Юк, йокладым, бик әйбәт йоклаганмын. Төш күреп. Ә син чишенмәгәнсең дә.

А р с л а н. Мин, чишенмичә, залда гына ятып торган идем.

Г а л и н а. Син сал инде боларны... Сал. Туебыз үтте бит инде.

А р с л а н. Әйе, үтте.

Г а л и н а. Рәхмәт инде сиңа, сүземне жирдә калдырмадың. Нинди мул итеп әзерләгәнсең туебызны. Хәтта Игорь Валериановичның да исе китте. Ул кая, китмәдеме ул?

А р с л а н. Юк, китмәде. Йоклый әле.

Г а л и н а. Әйт инде, торсын.

А р с л а н. Нәрсә, кәефең начармы?

Г а л и н а. Юк, кәефем минем әйбәт, бик әйбәт, мин сәламәт хәзер, бөтенләй сәламәт. Мин хәзер инде иң сәламәт йокы белән йоклый алам. Бүген нинди матур төш күрдем мин. Хәтерлисеңме, беренче елларыбызда, тегендә — Украинада... Син һәрвакыт төш күреп уяна идең, уяна идең дә миңа сөйли идең. Чаптырган чишмәләрен. Мин дә бүген шундый матур төш күреп уяндым. Сөйлимме?

А р с л а н. Сөйлә, кадерлем, сөйлә.

Г а л и н а. Үзебезгә, Украинага кайтканмын, имеш. Днепр буйларына. Анда безнең Днепр ярына ятып үскән зур бер өянке бар иде. Мин шуның яфрагына үреләм, ә кулымда абага чәчәге кебек ап-ак чәчәк өзелеп кала. Тагын үреләм, тагы чәчәк. Чәчәкләр, чәчәкләр! Һавадан, күктән чәчәкләр ява. Кояшлы яз иртәсендәге ләйсән кары кебек эре-эре, ябалак-ябалак чәчәкләр ява. Мин көләм, мин чәчәкләргә битемне куям, алар явалар да явалар.

А р с л а н. Тазарасың, кадерлем, яшьлегең кайта.

Г а л и н а. Әйе, әйе, минем яшьлегемне күрәсем килә, яшьлегем үткән Днепр буйларында йөрисем килә. Уят Игорь Валериановичны. Ул чәйгенә эчеп алсын да, без юлга әзерләник.

А р с л а н. Кая, нинди юлга!

Г а л и н а. Ник, без сөйләшкән идек бит инде, Игорь Валерианович сиңа әйтмәдемени?

А р с л а н. Нәрсә турында?

Г а л и н а. Без, көмеш туйны уздыру белән үк, сәфәр чыгарга тиеш идек. Шулай дип сүз куештык бит.

А р с л а н. Шушы хәлеңдәме?

Г а л и н а. Минем хәлем хәзер бик әйбәт. Миңа хәзер күбрәк сәяхәттә йөрергә кирәк. Кама, Идел өсләрендә... Пароходта, палубада. Миңа консилиумдагы профессорлар да шулай диделәр. Пароход белән озак сәяхәткә чыгарга киңәш иттеләр, шулай диделәр бит, Игорь! *(Зал ише-*

*ен ачып кычкыра.)* Игорь Валерианович! *(Залга ашыгып Игорь килеп :ерә.)* Нәрсә инде сез, Игорь Валерианович, шулай ярыймыни инде?

Игорь. Сез нәрсә турында, Галина Максимовна?

Галина. Без сөйләшкән идек бит, сез сүз бирдегез бит. Нигә инде безнең сәяхәт турында Арсланга әйтмәдегез?

Игорь. Ул бүген үк түгел бит әле, Галина Максимовна, әле бер-ике көн хәл алырга кирәк.

Галина. Юк, юк. Бүген үк! Хәзер үк! Мин аз гына да соңлый алмыйм, мине Днепр буйлары үзенә чакыра. Аңлатыгыз инде Арсланга, миңа сәяхәт кирәк. Минем туган илемне кайтып күрәсем килә. Минем Днепр буйларында ялан аяк йөрисем килә! Нигә, нигә аңламыйлар икән кешеләр!!

Арслан. Акыллым, тынычлан. Аңлыйм мин сине, мин бит синең теләгеңә каршы килмим, бары тик бераз сабыр итикме әллә, дип кенә әйтүем иде.

Галина. Рәхмәт. Син курыкма, минем хәлем әйбәт хәзер, әнә профессордан сора, ул бит белә, ул бит анда үзе генә түгел иде, алар күбәү иде. Барысы да шулай диделәр. Галимнәр сүзенә ышанырга кирәк. Без анда озак булмыйбыз, бер атна... Күп булса, ун көн. Баруы-кайтуы белән. Миннән башка бер ел торганны ун гына көн тора алмыйсыңмыни син?

Арслан. Алай булса, әйдә бергә барабыз. Балалар белән. Мин отпуск алам.

Галина. Юк, юк. Кирәкми. Кешеләр әллә нәрсә уйларлар. Кешеләргә белгертмик. Хәйдәрләр дә, Мәликәләр дә белми калсын. Белсәләр, гөтләргә тотынырлар. Без җиңел генә, сәяхәткә генә, пароход белән йөреп кайтырга дип кенә чыгып китәбез. Без пароход белән генә барабыз да. Моннан Идел-Дон аша Ростовка, аннан Днепрга күпме генә кала... Рөхсәт ит инде, кадерлем. Парлап барырга бит анда безне беркем дә көтми. Анда минем беркемем дә юк. Туган җирем генә. Туган туфрагымны бер учлап үбәм дә кайтам.

Арслан. Ә профессор бара аламы соң?

Галина. Бара, бара. Ул бит сүз бирде. Без үзебез белән Илдусны да алабыз.

Арслан. Ул чагында Тәнзиләне дә алыгыз.

Галина. Тәнзилә синең янда калсын инде, әтисе. Мин сине дә кайгыртам, синең бер дә тәрбиячең булмаячак. Әнкәй әнә картайган, көч-хәл белән йөри. Тәнзилә сезне вакытында, җиренә җиткереп, тәрбияләп торыр. Ярый, әтисе, мин әзерләнәм. Син машинаны чакырт. Пристаньга кадәр безне шофер гына илтеп кайтыр... Сез зурга җибәреп озатып йөрмәгез. Игорь Валерианович, барыгыз, чәй эчегез дә юлга!

Игорь. Рәхмәт, без балалар белән эчтек инде.

Галина. Алайса, мин кереп киенә башлыйм. Менә күрәсең, кадерлем, миңа хәзер киендерүче дә кирәкми. Мин хәзер барысын да үзем эшли алам. Сез барыгыз, бар, әзерләнегез. *(Булмәсенә керә.)*

Арслан. Игорь Валерианович, бу нәрсә инде бу?

Игорь. Аның теләгенә каршы килергә ярамый.

Арслан. Ләкин ул анда барып әйләнеп кайта алырмы?

Игорь. Ул анда бармаячак та. Менә күрерсез, юлдан борылып кайтачак. Без Куйбышевка да житмәячәкбез, ул кайтам, диячәк. Идел ярларыннан кузгалып китүгә, ул сезне, авылны сагына башлаячак.

Арслан. Әгәр дә барам дисә, барып житә алырмы ул анда?

Игорь. Шулай да аны дулкынландырырга ярамый. Чыгып карыйк без сәяхәткә һәм, ышаныгыз, без бик тиз әйләнәчәкбез. Авыруның психологиясен мин беләм бит инде.

Арслан. Ә сез соң? Аның белән юлга чыгарга вакытыгыз рөхсәт итәме?

Игорь. Мин аның булачак капризларын истә тотып, монда тоткарлану ихтималын әйтеп киттем. Кафедрамда кеше калдырдым. Мин тулысынча аның ихтыярында. Әйдәгез, балаларны һәм Сабира әбине кисәтеп куйыйк. Юлга чыкканда бернинди ай-вайлар булмаска тиеш. Гүя без монда, якын урманга яки болынга гына сәяхәт кылып кайтырга китәбез. Бернинди эмоцияләргә юл куярга ярамый. Шулай кирәк, аңладыгызмы?

Арслан. Аңладым.

Игорь. Менә шуның өчен яраттым да мин сезне. Сез чын ир кеше. Сездән башка яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм мин хәзер. Менә ничә ел инде мин сезгә туган йортыма кайткан шикелле кайтам. Ә балалар... Ә Тәнзилә? Ул минем беренче ассистентым булачак. Әйдәгез! *(Эчке бүлмәгә кереп китәләр.)*

Залга киенеп Галина чыга.

Галина. Кызым, Тәнзилә!

Тәнзилә керә.

Тәнзилә. Нәрсә, әнкәй?

Галина. Без... китәбез инде... Барып кайтабыз. Озакка түгел.

Тәнзилә. Беләм, әнкәй.

Галина. Белсәң шул инде, өйдә син каласың, әбиең бик бирешкән, аңар салынма. Әтиеңне яхшы тәрбияли күр. Көн дә иртән аңа каймак бир. Ул иртән каймак ашарга ярата. Бер-ике йомырка пешер. Сыеккына итеп. Каты пешкәнне ашамый. Ә көндезгә...

Тәнзилә. Ярый, әнкәй, син тыныч бул. Барысын да эшләрбез. Сез әйбәт кенә йөреп, әйләнеп кайтыгыз.

Галина. Сиңа әйтәм, этисе, буласызмы инде?

Өйдәгеләр бары да залга чыгалар.

Арслан. Без булдык инде, әнисе.

Галина. Ә машинаңны чакырдыңмы соң?

Арслан. Машина капка төбендә.

Галина. Әнкәй, син безгә рөхсәт ит инде, авырсына күрмә, без барыйк инде... Бик күптән булганым юк бит минем туган якларымда.

Сабира. Рөхсәт, кызым, рөхсәт, барыгыз. Исән-сау йөреп кайтыгыз.

Галина. Улым, Илдус, син әзерме?

Илдус. Әзер, әнкәй.

Галина. Алайса, утырышыгыз. Юлга чыгар алдыннан утырып алыйк, йола бит.

Утыралар. Пауза.

Я, кузгалыйк акрынлап. *(Килеп Сабираны кочаклап үбә.)* Әнкәй, сиңа нинди генә рәхмәтләр әйтергә дә белмим инде мин.

Сабира. Ярый, балам, кайткач әйтерсең рәхмәтеңне.

Галина. Әйе шул, син инде, әнкәй, озата чыгып йөрмә, күршеләр дә алай зурга алмасыннар. Кая, тагы бер тапкыр үбим дә... *(Үбә. Сабира үзен көчкә-көчкә генә тыеп тора.)* Әйдәгез, хәерле сәгатьтә! *(Бар да акрынлап чыгалар, өйдә Сабира гына кала. Алар чыгып киткәч кенә, Сабира чыдамлыгын югалта.)*

Сабира. Балакаем минем, ниләр генә уйлап чыгаруың булды соң бу синең? Бигрәкләр дә беткән бит. Кая гына бара ала соң ул хәзер?! Әллә чыгыймммы артларыннан. Җибәрмимме әллә?! *(Террасага китә. Машина кузгалып киткән тавыш.)* Киттеләр!.. Китте балакаем... Туфраклары гына сөйрәп алып киттеме әллә үзен?! *(Елый.)*

Арслан керә.

А р с л а н. Әнкәй, тынычлан, кайта ул. Менә күрерсең, кире борыла.

С а б и р а. Нигә җибәрдең? Кая җибәрдең син аны шул кыяфәгендә?!

А р с л а н. Ул доктор, профессор белән. Борчылырга урын юк, әнкәй.

С а б и р а. Докторыгызны да әйтер идем инде. Тәнзилә кая?

А р с л а н. Ул әнисе белән. Чаптырган чишмәсенә кадәр озата бара.

Х ә й д ә р керә.

Х ә й д ә р. Арслан, син нәрсә, нигә җибәрдең Галимәне?

А р с л а н. Зарар юк, Игорь Валерианович аның белән...

Х ә й д ә р. Соң, шул Игорь Валерианович бит инде миңа... кич мине озата чыккач баскычта...

А р с л а н. Нәрсә, нәрсә диде?

Х ә й д ә р. Ул сиңа әйтергә уңайсызлана... Өмет юк, гел юк, ди... Ин күбе бер-ике көн...

А р с л а н. Нәрсә? *(Аның якасыннан ала.)* Син нигә миңа шунда ук җиткермәдең? Шушымы синең дуслыгың? *(Үз-үзен онытып, йөрәк өзгеч тавыш белән.)* Машина!! Машина кая?!

Х ә й д ә р. Капка төбендә.

А р с л а н. Син кал. Син шалтырат. Юл өстендәге бригадага шалтырат. Машинаны туктатсыннар. Мин куып җиткәнче җибәрми торсыннар. *(Ашыгып чыгып йөгерә, Хәйдәр телефонга килә.)*

Х ә й д ә р *(номер җыеп)*. Туң Кичү? Шакир, синме? Хәзер үк мотоциклыңа утыр да олы юлга чык. Анда «Волга» белән Харис пристаньга китте. Туктат. Арслан «Газик» белән куып җиткәнче тоткарлап тор. Шулай кирәк. *(Кычкырып.)* Әйткәнне тыңла. *(Урамга йөгерә.)*

С а б и р а. «Җан тартмаса да кан тарта, төн тартмаса да туфрак тарта» диләр. *(Машина тавышы.)* Машина... машина кайтты! Ай алла, бик тиз борылды бит әле бу... Куып җитә алмады микәнни соң? *(Терраса тәрәзәсенә килә.)* Әнекәем лә... Әтисе түгел бит әле бу... үзе! Балакаем, Галимәм. *(Ишеккә ташлана, анда Тәнзилә кочагында кергән Галинаның муенына асылына.)* Балам, кызым, кайттыңмы, кадерлем?!

Галинаны як-ягыннан кочаклап алып креслога утырталар, алар белән бергә И л д у с, И г о р ь  В а л е р и а н о в и ч, Х ә й д ә р, М ә л и к ә керәләр.

Г а л и н а. Әтиегез кайда?

Т ә н з и л ә. Ул сезнең арттан, сезне куып китте.

Г а л и н а. Ә без Чаптырган чишмәсенә борылып төшкән идек. Күрәсең, ул безне күрми узып киткән. *(Машина тавышы.)*

И л д у с. Әнә кайтты әтием дә!

Йөгереп А р с л а н керә, Галинага ташлана.

А р с л а н. Әнисе, кадерлем, кайттыңмы?

Г а л и н а. Кайттым. Чаптырган чишмәсендә битемне юып, суын эчтем дә кайттым. Үз өемә, үз нигеземә, үземнең туган туфрагыма кайттым. Бөек Кобзарь ул, Игорь Валерианович, башка... бөтенләй башка. Аның туган туфрагы чикләнгән булган. Аны кыерсытканнар, кимсеткәннәр... Ә мине бит бирелә берәү дә кимсетмәде. Бу туфрак мине үз баласы итеп кабул итте. Бу туфракка минем тирем, кайнар яшьләрем тамды. Бу туфракта минем татлы хыялларым тормышка ашты. Шулай булгач, бу — минем туган туфрагым! Мин моннан беркая да китмим инде. Ә сез, Игорь Валерианович, барыгыз, кайтыгыз... Үзегезнең эш урыныгызга кайтыгыз.

И г о р ь. Юк, мин бер-ике көн сезнең янда булам әле.

Г а л и н а. Нәрсә, куркасызмы? Үләр бу дип куркасызмы? *(Урыныннан торып, алга, халыкка таба килә.)* Юк, мин үлмим әле!.. Мин яшим әле!..

*П ә р д ә.*

## Егор Уткин

### Күпләр аны сагынып искә ала

Гел бер булды сүзе: йолдыз дәшсә,
Сукмак ярып, зәңгәр күккә мен.
Сайлады ул юлның кыенын гел,—
Кешеләрнең каргап сүккәнен.

Җиңел эшне җаны үз итмәде,
Нидер эзләп, янып сызланды.
Күпләр аңа карап гаҗәпләнде,
Күпләр көлде, күпләр кызганды.

Авыл сусыз кала, ак чишмәне
Су баскач, дип, язгы ташкында,
Көрәк алып ул беренче чыкты,
Эш башлады авыл башында.

Аннан күрше-күлән, бөтен урам
Тирән итеп кое казыды.—
Күпме халык шунда суга килә.
Ә ул юкка ничә яз инде...

Язын килгән җиргә, язын китте,
Яшәде дә янып, талпынып.
Юлсыз юллар аны илткән икән
Күңеленә авылы халкының.

Аның исемен йөртә шушы кое,
Бирмәделәр моны киңәшеп.
Күпләр аны сагынып искә ала,
Хөрмәт итеп, күпләр көнләшеп.

### Хәтерләтте

Әллә дворникка ялланганмы,
Әллә ачар өчен күңелен,
Сары яфракларны җил себерә.
Төнге караңгыга күмелеп.

Авыл йоклый, тып-тын. Бер өйдә дә,
Сыңар тәрәздә дә юк утлар.
Караңгыга чумган көзге урам
Күңелемдә шушы минутта.

Үткәннәрнең авыр хатирәсен,
Ил өстенә килгән давылны
Хәтерләтте... Маскировка! Кичен
Караңгылык кочып авылны

Ала иде. Төнге сакка чират
Белән чыга иде әниләр.
Иптәш итеп әни үзе белән
Ала иде кайчак мине дә.

Кара төндә әллә шомланган ул,
Әллә өйдә газиз баласы
Куркып уянмагай иде диеп,
Булды микән күргән чарасы.

Хәзер соң шул инде сорашырга,
Бу хакта бит белми каен да...
Хыялларга чума идем ул чак:
Иң беренче булып янгынга

Ташланамын, шундук сүндерәмен,
Иң беренче булып бомбаны
Зарарсызлыйм. Зур командир орден
Бирде. Аны горур аламын.

Болар — төштә. Тын каравыл өе.
Караңгыга авыл сыенган.
О, бу тынлык нинди кыйммәт булган,
Аңлашылды миңа соңыннан...

## Нәрсәнедер күңел хәтерләде

Суда рәхәт йөзеп йөри иде
Ашыкмыйча гына, җай гына
Йорт казлары. Шулчак очып үтте
Кыр казлары болын ягыннан.

«Кыйгак, кыйгак!» диеп, су өстендә
Бер әйләнде алар, аннары
Китеп югалдылар. Бу казларның
Тетрәп калды, ахры, җаннары.

Без дә каз бит, без дә ирекле бит,
Алар бит дип безне дәштеләр,
Каңгылдашып судан күтәрелеп,
Очтылар да... кабат төштеләр.

Төшсәләр дә,
Шактый горурланып
Күтәрделәр алар шау-шуны,
Берсен-берсе котлап карлыктылар...
Тик бераздан бары да басылды.

Очар кошлар булу бу казларда
Бер мизгелгә бары уянды.
Күңел шулчак нидер хәтерләде,
Нәрсәдәндер шулчак оялды...

## Булат Сөләйманов

Кояшым, җаем идең син,
Киттеңме әллә юри?
Кырга ак кәфен теккән дә
Җил үксеп елап йөри.

Төн каплаган тәрәзәмне,
Җилләргә табына урам.
Кайтыр идем, җәйләр ерак,
Юлларда уйный буран.

Агачларда беткән яфрак,
Урамнан киткән кошлар.
Канаты каерылган йөрәк
Ялгызы ничек кышлар.

### Кырлар буйлап

Очар коштай поезд чаба
    Кырлар буйлап,
Кырлар көен яңгыратырлык
    Җырлар уйлап:
Карап барам тәрәзәдән
    Уңга-сулга,
Тәгәрмәчләр йөрәк тибешем
    Санап суга.
Бодайларың, арышларың —
    Сары дулкын,
Алтынланган бу кырларың
    Җанга якын.
Чишмәләрең, елгаларың —
    Нәкъ терекөмеш,
Урманнарда төн кызларың
    Яши, имеш.
Кырлар буйлап тәгәрмәчләр
    Тык-тык утә,
Гүя алар миңа шуны
    Хәбәр итә:
Күрәсеңме, саргаешып
    Бетте кырлар,
Туган якка кайтуыңны
    Көтә-көтә!

Астраханьнан килгән карбыз,
Берсен мин дә сатып алдым...
Гүя җир шарының үзен
Алып учларыма салдым.

Астраханьнан килгән карбыз,
Эче тулы кып-кызыл «кан».
Әллә җир дә шулай микән
Бертуктаусыз сугышлардан?..

## Кавыштылар

Салкыннары берни түгел —
Чәчәк ата Обь ярлары.
Бүген яңа кавыштылар
Ивдель белән Нарыкары.

Поезд чаба очкан уктай,
Давыллардан, җилдән көчле.
Рельслар чаба, каеш булып
Җирнең билен буган төсле.

Күктә очкан самолетның
Ап-ак тасма эзе кала.
Тасма кебек юл сузылган,—
Тайга аша поезд чаба.

Фәләх Насыйров

# ҮЛЕМНЕ ҖИҢЕП



Төнге тынлыкны ярып, кинәт ат аягы тавышлары яңгырады. Озак та үтмәде, каты итеп ишек шакыган тавышлар ишетелде, аларга сүгенү авазлары кушылды.

Габидулла абзый сискәнеп йокысыннан уянды һәм, аягына да киеп тормастан, ишеккә ташланды. Хатыны Бәдигөлҗамал апа, куркынып:

— Һай алла, ни хәл бу?..— дип пышылдады.

Өйалды ишеге шыгырдап ачылу белән:

— Карт тәре!.. Ник озак ачмый тордың?..— дип, әшәке итеп сүгенделәр.

Шул ук секундта Габидулла абзыйның аркасына чыжылдап камчы төште. Аны төрткәләп өйгә алып керделәр. Ачык калган ишектән салкын һава бәрелде.

— Ут яндыр!.. Тиз!..— дип акырындылар.

Йорт хуҗасы, каушап, лампа таба алмый азапланганда, каеш камчы аның аркасын кабат телеп узды.

Сукыр лампа уты өй эченә тулган ак бандитларның ярсыган күзләрен, кулларына кысып тоткан мылтыкларын яктыртты. Бәдигөлҗамал апа, тезләрен кочаклап, сәке өстендә утыра. Ул, котырынган солдатларның савыт-сабаны идәнгә атып бәрүләрен, йортның астын-өскә әйләндерүләрен күреп, телсез калган.

Нигъмәтнең тәрәзә янагына элеп куелган сәгатен унтер-офицер кесәсенә алып салды.

— Синме кызылармеец?

Нигъмәт белән рәттән яткан Хәкимулла өстенә дә камчы төште. Яшүсмер, сикереп торып, нәфрәт белән палачларга карады.

— Маңка... яшь икәнсең әле...— дип мыгырданды офицер. Аклар икенче бүлмәгә ташландылар. Анда Габидулла абзыйның олы улы Сәмигулла йоклый. Менә шул Сәмигулла Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайткан иде. Күрәсең, аклар шуны эзләп килгәннәр.

Зур гәүдәле, киң күкрәкле Сәмигулла, офицер кергәндә, аягына торып баскан иде инде. Акларның барлык сорауларына да ул бик тыныч җавап бирде. Әйтерсең лә аны кулга алырга, җәзаларга килмәгәннәр, ә көндәлек гади нәрсә турында сорашалар. «Менә нинди икән минем абый!» — дип уйлады Нигъмәт эченнән.

— Кызыл Армиядә хезмәт иттеңме? — дип сорады офицер.
— Иттем,— диде аңа каршы абыйсы.
— Кем җибәрде?
— Беркем дә җибәрмәде. Үзем бардым.
— Үзең бардың?!. Ә ни өчен бардың?
— Буржуйларга каршы сугышырга дип бардым.

Офицерның йөзе тартышып куйды, камчы тоткан кулы йомарланды, әмма сукмады. Шулай бераз сүзсез торганнан соң:

— Киен! — дип әмер бирде.

Абыйсын аклар алып чыгып киткәч: «Ничек болар миңа тимәделәр?!» — дип уйлады Нигъмәт. Чөнки халыкны Кызыл Армиягә язылырга өндәп, иң беренче башлап йөргүче кеше ул иде бит.

...Әйе, узган 1918 елның август аенда, ак чехлар һөҗүме башлангач, аны укытучы Лотфулла Мансуров үз янына чакырып алды. Заманында Нигъмәт әнә шул Лотфулла ачкан мәктәптә укып, башлангыч белемне шунда алды. Соңыннан ул, аның киңәше белән, Минзәләгә, укытучылар хәзерләү курсына барып укыды. Шунда революцияне каршылап, авылга укытучы булып кайтты. Кайтып эшли башлагач та, Лотфулла аңа бик күп нәрсәләрне төшендерде, тормыш һәм революцион вакыйгаларны дөрес аңларга ярдәм итте. Менә хәзер дә ул аны юкка гына үз янына чакырмаган булыр, нинди дә булса ашыгыч эше бардыр, дип уйлады Нигъмәт. Мансуровның өенә килеп кергәндә, кич булган иде инде. Ул анда бер чит кеше күрде. Башында 1914 елгы сугыштан калган солдат бүреге, өстендә иске генә шинель, аягында күн итек. Үзе уртачадан озынрак буйлы. «Бу нинди кеше булыр?» — дип уйлады Нигъмәт.

— Бу — Уфадан, большевиклар комитетыннан килгән вәкил,— дип таныштырды аны Лотфулла.

— Гыйльметдин Шаммасов,— дип, әлеге вәкил үзенең зур, кытыршы кулын сузды һәм:

— Утырыгыз,— дип урын тәкъдим итте.

Утырдылар. Сүзне Мансуров башлады.

— Менә, иптәш Шаммасов килгән безнең авылга. Добровольцлар җыярга ярдәм итүне сорый. Үзең дә беләсең, хәл бик авыр. Чехлар бөтен яктан һөҗүм итәләр, ә илне саклар өчен кешеләр кирәк. Шуның өчен сине чакырдык, Нигъмәт. Синең ярдәм безгә бик кирәк. Син авыл яшьләрен яхшы беләсең. Сиңа төне буе йокларга туры килмәс. Иртәгә авыл халкының җыелышы булачак, базар мәйданында. Шунда Шаммасов агымдагы мәсьәләләр турында доклад ясаячак... Добровольцларның исемлеген башлап җибәрү өчен, син алдан бернечә кешене табып куярга тиеш буласың.

Башта яшь укытучы аптырап калды. Башына: «Ничек итеп эшләрмен мин бу эшне, кешеләрне килештереп булырмы, аңлатып булырмы?..» — дигән уй йөгерде. Шулай да ул:

— Тырышырмын,— дип вәгъдә бирде.

Нәрсәдән башларга? Иң элек кемгә барырга?.. Башта өйләренә кайтты. Бертуган абыйсы лапас астындагы арбага ятып йоклаган. Вакыт инде кич. Нигъмәт, арба янына килеп:

— Тор әле! — дип абыйсын уятты да Мансуров сөйләгәннәрне төшендереп бирде һәм:

— Абый, әллә тәвәккәл итәбезме? — диде.

Сәмигулла бераз сүзсез торганнан соң:

— Әйдә, барабыз,— дип риза булды.— Тик әлек без әти янына керик әле. Әти рөхсәт итмәсә, чыгып китү бик үк яхшы булмас.

Ишекне шакып, туганнар өйгә керделәр.

— Нәрсә эшләп йөрисез төнлә? Ни булды? — дип каршы алды аларны аталары. Нигъмәт абыйсына әйткәннәрне сөйләде.

— Менә шулай, әти. Син инде безгә фатихаңны бирерсең дип ышанабыз.

— Һе, ә сездән башка Кызыл Армиягә язылырга кешеләр беткәнмени? — диде Габидулла абзый.— Беткән шул, әти. Һәр кешенең әтисе: «Синнән башка кеше беткәнме?» — дисә, кем Советский властьны саклар соң? Син безгә фатихаңны бир инде.

Ата улы сөйләгәннәрне сүзсез генә тыңлады.

— Ярар, хәерле булсын,— дип әйтүдән башка чара калмады аңа.

— Әти, тагын бер нәрсә бар бит әле,— дип, яңадан сүз башлады Нигъмәт.

— Нәрсә тагын?

— Иртәгә син җыенда чыгып бер-ике сүз әйтсәң иде, әти.

— Нәрсә дип әйтим соң? Гомердә дә җыенда сөйләгәнем юк...

— Син әйт, «Менә, егетләр, Советский власть үзебезнеке», дип әйт. «Аны саклар өчен мин ике малаемны да бирәм», дип әйт. «Җәмәгать, әйдәгез, үз властебызны яклыйк», дип әйт. Әйтерсеңме шуны?

— Һи-һи-и, балалар, сезнең белән әллә нәрсәләр әйтеп бетерерсең әле. Ә соң хәзер кая барасыз?

— Үзебезгә иптәшләр дә табарга кирәк бит.

— Совет власте да бик кадерле, сезне дә бер дә югалтасым килми шул, балалар,— дип калды ата.

Нигъмәт белән Сәмигулла күршеләре Хәррас йортына юнәлделәр. Хәррас гомере буе итеккә олтан салып, башмак, кәвеш төзәтеп, бик ярлы гына торган кеше. Аның улы Фатих белән Нигъмәт бергә укыганнар иде. Бәлки, ул да риза булыр?..

Фатих та ишегалдындагы арбада йоклап ята иде. Аны уятып, аңлатып бирделәр. Фатихның фронтка алай тиз генә чыгып китәргә исәбе юк иде.

— Егетләр, бит ул... сугыш бит ул, егетләр... тукта әле, сез бит җиңел генә сөйлисез дә, анда сугышырга туры килә бит!..— дип, бик нык уйга калды егет.

— Сугышырга туры килә, Фатих, сугышырга. Сугышмагач, кеше дә кирәк булмас иде. Аклар килсә, без яңадан җирдән колак кагабыз бит. Яңадан кулакларга бил бөгәбез.

Яшь укытучының бу сүзләренә каршы Фатих җавап таба алмады. Җирнең алыну куркынычы турында сүз чыккач:

— Соң, егетләр, анда да кеше сугыша инде. Ярар, әйдә, сезнең белән булгач, барам мин дә,— дип ризалык бирде.

— Менә нәрсә, Фатих, иртәгә җыенда: «Мин ирекле булып Кызыл Армиягә язылам»,— дип әйтергә кирәк булачак сиңа.

— Сугышка барырга риза булгач, анысын гына инде әйтермен.

Фатихны ияртеп урамга чыкканда, ярты төн узган иде инде.

— Кая барабыз инде, егетләр? Тагын бер-ике кеше кирәк иде бит,— дип, алар юл уртасында туктап калдылар.

— Тукта әле, егетләр. Керик Бадыйкшан янына,— диде Фатих.— Мин аны бик яхшы беләм, минем дус кеше ул. Аңлы егет. Ул бармый калмас.

Бадыйкшан да йоклап ята иде. Уятып керделәр. Тәнге кунакларны хуҗа әйбәт кенә кабул итте. Бадыйкшан да гомергә байларда, авыл кулакларында эшләп, очын-очка көчкә генә җиткерүче, читкә дә чыгып керә торган бер кеше. Аның бер имана җире дә бар. Әмма яртысын да чәчә алмый. Я аты, я сука-тырмасы булмый. Кызыл Армиягә язылырга уйлап та тормыйча риза булды.

Нигъмәт егетләр белән сөйләшеп Мансуров янына кайтканда, инде кояш чыгып килә иде. Яшь укытучының сүзләрен тыңлап бетергәннән соң:

— Фатихны беләм инде мин. Сәмигулланы да беләм. Алар ышанычлы кешеләр. Ә менә Бадыйкшанны белеп җиткерә алмыйм шул. Ул читтә йөргән кеше. Соң, ышанычлыдыр бит инде, Нигъмәт? — диде Мансуров шикләнебрәк.

— Ышанычлы булырга тиеш, Лотфулла абый, вәгъдә бирде,— диде аңа каршы Нигъмәт.

Өенә дә кайтып тормастан, Нигъмәт базар мәйданына юнәлде. Мәйдан халык белән тулы иде инде. Җыенны Мансуров ачты да сүзне Шаммасовка бирде. Большевиклар комитетыннан килгән вәкил Совет властеның авыр хәлен, акларның, баш күтәргән кулакларның һөҗүм итеп килүләрен аңлатты.

Аннары Нигъмәтнең әтисе Габидулла Хәмидуллин торды. Кичә улы кушканнарның барысын да бик әйбәтләп кенә әйтеп бирде. Бу җыелышта утыз ике кеше ирекле булып Кызыл Армиягә язылды. Алар барысы да, кулларына корал алып, яшь Совет илен сакларга киттеләр.

Менә хәзер инде Колчак бандитлары Кызыл Армиядә хезмәт иткән шул кешеләрне кулга алырга килгәннәр.

...«Ничек соң алар миңа тими калдылар? Белмиләрме... Белсәләр, мине дә атачаклар!.. Качарга! Качарга!..»

Нигъмәт тиз генә өстенә киенде. Ишеккә җиткәч, туктап, өй эченә күз салды. Өч яшьлек Әсхапҗамал белән ун яшьлек Шәмсеҗамал сеңелләре бер-берсенә сыенышып утырганнар. Күзләрендә яшь ялтырый. Унике яшьлек энесе Мәхмүтнең дә йөзе агарынган. Әтисе, аякларына авыр гер аскандай, кузгала алмый идән уртасында басып тора...

Ата улының кичерешләрен аңлады булса кирәк.

— Бар... Үзеңне эләктергәнче тизрәк сыз! — дип, ишеккә ымлады.

Капкадан гына чыккан иде, аны көчле куллар эләктереп алды.

— Качаргамы? Юк, кача алмассың!..

Тартышу файдасыз иде. Аклар күп. Сыек кына таң яктылыгында ике зур шәүлә күренде. Якыная төшкәч, Нигъмәт аларның салам күтәреп килүче солдатлар икәнен аңлады. Берсе саламны ишек төбенә, икенчесе тәрәзә каршысына ыргытты. Кесәләренә суккалап, шырпы эзләргә тотындылар.

«Ут төртәләр!.. Ата-анасын, туганнарын тереләй яндыралар!..» Бу уй Нигъмәтнең бөтен тәнен калтыратып узды. Ул, үз-үзен белмичә, бик каты итеп кычкырды.

— Яндыралар!.. Пожар!..

Аның бу әче тавышы, тәнге караңгылыкны ярып, бөтен авыл өстенә яңгырады. Каяндыр офицер килеп чыкты. Саламга ут төртеп маташкан солдатларга:

— Коммунистлар оясы бу авыл. Хәзергә кирәкми. Халык уянса, бәрелеш чыгуы бар,— дип кисәтте.

Нигъмәтне җиргә егып бик каты кыйнаганнан соң, чанага күтәреп бәрделәр.

...Кем эше булыр бу? Аклар әле бу тирәгә килеп җитмәгән иде бит. Кайсыдыр саткан...

Аның башыннан шундый уйлар узды. Абыйсы Сәмигулланы кая алып китүләрен белми иде әле ул. Әмма егерме яшьлек укытучы шуны яхшы аңлады: ак палачлардан шәфкать булмаячак.

Аны Сәлимгәрәй Тәйхузин дигән кулакның ишегалдына китерделәр дә мунчага алып кереп ташладылар.

Лотфулла Мансуровны да монда китереп япканнар иде. Аның да авызы-борыны Нигъмәтнеке кебек шешенеп беткән.

— Беләсеңме, Нигъмәт, атарга алып баралар бит безне,— диде Лотфулла, Нигъмәтнең күзләренә сынаулы карап.

Шулай булачагын Нигъмәт үзе дә сизенә иде.

— Син шуны белеп тор,— дип дәвам итте Мансуров.— Чехословаклар һөҗүме башлангач, Мөхәммәтҗан мулланың Харисы белән Сәлимгәрәй безнең исемлекне язып биргәннәр. «Утыз ике кеше ирекләләр. Нигъмәт Хәмидуллин белән Лотфулла Мансуров — коммунистлар, красноармеецларны оештыручылар»,— дип. Син әле миннән яшьрәк. Алай-болай исән калсаң, моны исеңнән чыгарма.

Озак та үтмәде, тоткыннарны Метрәй авылына алып киттеләр.

Күктә таң атып килә. Кырлар каралган. Чана юлы да бетеп бара. Яз башы. Әйе, Совет власте яшәвенең икенче язы килә.

Чанага яткан тоткыннар бер сүз дә сөйләшмиләр. Һәркайсы үз уена чумган. Нигъмәтнең күзләре ерак офыктагы таң нурларына текәлгән. Алар ул кояшны тагын күрә алырлармы?..

Метрәй авылына килеп җитү белән, тоткыннарны штаб урнашкан ике катлы йорт янына алып килделәр.

— Берегез югарыга менегез! — дип боерык бирде солдат.

Нигъмәтне өске катка алып менделәр. Сәкегә солдатлар утырган. Ул килеп керү белән, офицер команда бирде. Сигез солдат бер яктан, сигез солдат икенче яктан сикереп торды. Тагын бер команда — штыклары бер-берсенә каршы сузылды. Нигъмәткә шул штыклар коридорыннан үтәргә боердылар. Нигъмәт штыклар арасыннан узып, офицер каршысына килеп басты. Офицер карап-карап торды да каты итеп Нигъмәткә сугып җибәрде.

— Синме ул коммунист көчекләрен котыртучы!..

Наган тоткасы Нигъмәтнең артерия тамырына тиде, аның чигәсеннән фонтан кебек кан сиптерә башлады. Бу палачны айнытып җибәргәндәй итте.

— Чыгарып ташларга! — дип боерды ул.

Нигъмәтне өйалдына чыгарып салдылар. Тоткын идәнгә йөзтүбән капланды. Яртылаш аңсыз булса да, Мансуровны алып кереп китүләрен ул абайлап калды.

Салкында аңа бераз хәл керде. Шуышып, баскыч янына килде. Баскыч кырыйларына куелган тоткычларга ябышып, аягына басты һәм түбән төшәргә ниятләде. Әмма аяклары тыңламадылар. Ул, мәтәлчек ата-ата, ишегалдына егылып төште.

— Улым, бар, син кит. Солдатлар күрмәс борын, бар, кит!

Ике-өч карт, кулларыннан тотып, аны капканың урам ягына чыгардылар. Ә Нигъмәт кая барырга да белми, каян килгәнен дә хәтерләми иде. Шулай да монда калырга ярамый. Хәзер аңа тыкрыкның теге ягына чыгарга кирәк. Шулчак каяндыр:

— Стой! Стой! — дип кычкырган тавыш колагына чалынды.

Башы әйләнеп, Нигъмәт җиргә ауды. Әзәрлекләп килгән солдат:

— Тор! Тор!..— дип, прикладлы белән аның аркасын төяргә керешге...

Һушыннан язган Нигъмәтне солдатлар, үлегә санап, зиратка илттеләр дә карлы су эченә ташладылар. Штабка кайткач:

— Бер большевикны дөмектердек! — дип мактандылар.

— Аттыгызмы? — дип сорады офицер.

— Патрон әрәм итмәдек, кыйнап үтердек.

— Юк, сез аны атыгыз,— дип әмер бирде палач.— Менә бу коммунист Мансуровны атканда, тегесен дә дөмектерегез,— дип кабатлады ул.

Күрше Карамалы авылыннан ату тавышлары ишетелде. Анда Нигъмәтнең абыйсы Сәмигулла белән күршесе Бадыйкшанның гомерләре өзелде. Авыл башында кабер казытып, кабер кырына бастырып аттылар аларны.

Нигъмәт боларның берсен дә белмәде, берни дә ишетмәде. Озакламый менә шушында, зиратка Лотфулла Мансуровны алып килеп атачакларын да белми иде ул.

Ниһаять, яшьлек үзенекен итте. Нигъмәт аңына килеп, күзләрен ачты. Өстенә ак сакаллы бер карт иелгән.

— Улым, тор, атарга киләләр сине... Кит моннан. Тизрәк китә күр!..— дип ялвара карт.

Ә Нигъмәтнең кутәрелерлек көче юк. Карт, солдатлар килеп җитмәгәе дип, як-ягына карана. Үзе һаман үгетли, ялвара. Ниһаять, үгетләп эш чыкмаячагын аңлады, Нигъмәтне сөйрәргә кереште. Зират капкасына кадәр алып чыккач, Мөслим ягына күрсәтеп:

— Әнә, улым, авылыгыз. Ничек кенә булса да шул якка китәргә тырыш! Солдатлар килгәнче. Сине аталар алар! — дип киңәш бирде.

Нигъмәт, карт күрсәткән сукмак буйлап, Мөслимгә таба шуышты. Мең газаплар белән күпергә җитте. Күпер канатларына ябышып, аякларына басарга теләде. Әмма әлсерәп, тагын җиргә капланды...

Түбәндә ярсып-ярсып су ага. Анда язгы ташу. Анда салкын су! Эх, эчәргә иде шуны! Аның эче яна... Үләрдәй булып эчәсе килә. Бер генә йотым... бер генә йотым булса иде...

Юк. Булмый шул... Бу бары тик татлы хыял гына. Су яр астында, елгада гына түгел, чокыр-чакырларда да су күп. Әмма ул эчә алмый. Наган түтәсе белән телгәләнеп беткән иреннәре ачылмый аның. Алар кан белән укмашып, бер-берсенә ябышып катканнар.

Нигъмәт Мөслимгә җиткәндә кич булды, тирә-якны караңгылык каплады. «Шәт, инде котылганмындыр!..» дип уйлап куйды ул. Әмма уйсулыкка җыелган су аша ничек үтәргә? Нигъмәтнең куллары юеш карга батты. Аларны кире тартып алырлык хәле юк иде аның. Кычкырып, ярдәм чакырыр иде, авызы ачылмый. Иреннәре ябышып каткан.

Нишләргә?.. Торган саен аның куллары, гәүдәсе карга тирәнрәк бата бара. «Юк, юк, үлмәскә!.. Тәгәрәп булса да чыгарга!..»

Соңгы көчләрен җыеп, гәүдәсе белән бер-ике тапкыр әйләнде ул. Шуннан соң... Шуннан соң аның сызланулары да, сусавы һәм туңуы да, барысы да бетте...

...Нигъмәт аңына килгәндә, аны өйгә алып кергәннәр иде. Ике ир кеше башын, битен юалар. Ниндидер хатын чүмеч белән су салып тора.

Юып бетергәч, ир кешеләрнең берсе:

— Без моны бабасына илтеп бирик инде. Үлсә-китсә, шунда булыр,— диде.

Яшь укытучыны толыпларга төреп, чанага чыгарып салдылар. Аны әнисенең туган авылы — Төгенгә, бабасы белән әбисе йортына алып киттеләр.

Күпме вакыт юлда бардылар, Нигъмәт хәтерләми. Ат туктагач кына ул күзләрен ачты. Таң атып килә иде. Эңгер-меңгер яктылыгында әбиләре ишегалдына килеп керүләрен абайлап алды ул. Әнә әбисе белән бабасы йөгереп чыкты. Алар чана янына килеп, оныкларын күтәреп алдылар...

Кызыл гаскәрләр Кәүҗияк авылын азат иткән көнне үк, Нигъмәтнең әтисе Габидулла абзый улларын акларга саткан кулак Сәлимгәрәй Тәйхузиннар йортына китте һәм аны, тотып алып, кызыллар штабына алып килде.

— Авыл коммунистларын менә шушы кеше сатты инде. Аларның үлеменә, аларның гомере өзелүгә менә шушы кеше гаепле,— диде.

Кулак тиешле җәзасын алды.

Нигъмәт, аягына басу белән, кулына корал алып, Совет властен сакларга китте. Тыныч төзелеш еллары башлангач, башы-аягы белән партия һәм совет эшенә чумды. РКП(б)ның Сарман волостенда, соңрак Чаллы кантонында секретарь булып эшләде. Аннан Шөгергә җибәрделәр. Анда аны район Советы башкарма комитеты председателе итеп сайлап куйдылар.

Оештыру сәләте булган тырыш коммунист озакламый Казанга, Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты аппаратына алынды. Башта ул инструктор, аннан соң бүлек мөдире булып эшләде. Бөек Октябрь социалистик революциясенең илле еллыгы уңае белән хөкүмәтебез аны «Почет билгесе» ордены белән бүләкләде.

**Клара Нәҗипова**

# ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Бөек Октябрь революциясенә кадәр Татарстан патша Россиясенең артта калган провинциясе булып, бары тик чимал җитештерү һәм илнең башка районнарында эшләнгән промышленность продукциясен куллану урыны булып кына хезмәт итә иде. 1913 елда хәзерге Татарстан территориясендә промышленность барлык халык хуҗалыгының бары тик дүрттән бер өлешен генә тәшкил итә, җан башына исәпләгәндә Россия буенча уртача җитештерелә торган промышленность продукциясенә караганда дүрт мәртәбә кимрәк күләмдә иде. Промышленность башлыча авыл хуҗалыгы, терлекчелек чималын эшкәртүдән һәм урманчылык продукциясе әзерләүдән гыйбарәт иде.

Авыр промышленность предприятиеләреннән берничә химия заводы, суднолар ремонтлау мастерскойлары, төзү материаллары җитештерү предприятиеләре генә бар иде. 203 шундый вак предприятиеләрдә барлыгы 25 меңгә якын эшче эшли иде. Биш йөздән артык эшче эшләгән завод-фабрикалар бары тик дистәләп кенә булып, күпчелегендә 60—120 кеше эшли иде.

Совет властеның беренче елларында ук партия техник-экономик артталыкны бетерү, милли республикаларда җитештерү көчләрен үстерү, яңа завод һәм фабрикалар салу, җирле халыктан, аеруча крестьяннар арасыннан культуралы, техник яктан грамоталы, политик аңлы эшчеләр әзерләү мәсьәләләрен алгы планга куйды.

Милләтләр арасындагы тигез хокуклылыкны тәэмин итү нәтиҗәсендә үзара ярдәмләшү, үзара хезмәттәшлек тә үсте. Татарстан промышленносте үсешендә башка тугандаш халыкларның, беренче чиратта, рус халкы, аның эшчеләр сыйныфының эчкерсез ярдәме моның ачык мисалы булып тора.

Милләтләр арасындагы экономик тигезсезлекне бетерү милли республикалардагы экономик үсеш темпын бөтен илдәге гомуми дәрәҗәгә караганда арттыру аша гына мөмкин иде. Татарстан республикасында, мәсәлән, бөтенсоюз эре промышленносте үсешенә караганда үсеш темпы шактый артык булды. 1913 ел белән чагыштырганда Татарстанда промышленность 1969 елда 337 мәртәбә артык үсте. (Ә РСФСР буенча бу үсеш 119, ә СССР буенча 121 тапкыр иде.) Шушы чор эчендә республикада машина төзү һәм металл эшкәртү 12 мең 519 тапкырга, төзү материаллары җитештерү 490 тапкырга, химия промышленносте 253 тапкырга үсте.

Совет власте елларында Татарстанда машина төзү, приборлар ясау, нефть чыгару, газ, нефть-химия, резина ясау, кинопленка, синтетик каучук промышленносте, җиңел промышленностьның күп тармаклары, электр энергиясе эшләп чыгару, төзү материаллары промышленносте өр-яңадан оештырылды.

Хәзер нефть чыгару, җылылык үлчәү приборлары ясау, кинопленка җитештерү, мех әйберләре, сыек газ, желатин, кетгут һ. б. лар эшләп чыгару буенча Татарстан Союзда беренче урында тора.

Татарстан промышленностеның үсешендә илебезнең башка республикалары һәм шәһәрләре белән бәйләнешнең, хезмәттәшлекнең роле зур. Татарстан промышленностен үстерүгә Мәскәү, Ленинград, Свердловск һәм башка шәһәрләр күп төрле машиналар белән, Урал — чимал, Донбасс, Караганда, Кузбасс — күмер, Әзербәйҗан нефть һәм башкалар белән ярдәм итте.

Хәзерге көндә Татарстан өчен кирәкле әйберләр 100 республикадан һәм өлкәдән алына. Мәскәү, Ленинград, Горький, Харьков, Свердловск, Куйбышев, Ульяновск, Уфа машиналар, станоклар, промышленность җиһазлары бирә, Украинадан машиналар, металл, ташкүмер, Белоруссиядән тракторлар, автомобильләр, приборлар, радио аппаратлары, Латвиядән радиоалгычлар, Грузиядән, Казагыстаннан, Уралдан металл, Мари, Чувашстан, Удмуртия республикаларыннан, Пермь һәм Киров өлкәләреннән агач материаллары килә. Советлар Союзында Татарстан белән бәйләнешкә кермәгән бер генә почмак та юк. Безнең республика үзендә житештерелгән промышленность продукциясенең 70 процентын, шул исәптән — нефтьнең, химия предприятиеләре эшләп чыгарган продукциянең 90 процентын, җиңел промышленность җитештергән продукциянең күп өлешен башка өлкәләргә чыгара. Татарстанда эшләнгән машиналар һәм җиһазлар, нефть һәм газ, сәгатьләр һәм язу машиналары, резина-техник әйберләр, вакуум насослары һәм медицина кораллары, кинопленка һәм дарулар, фанера һәм кетгут, мехлар һәм кием-салым, киез һәм күн аяк киемнәре, химикатлар һәм башка бик күп әйберләр СССРның барлык республикаларына, крайларына һәм өлкәләренә җибәрелә. Татарстан нефте трубалар буйлап Мәскәүгә, Ярославльгә, Рязаньга, Одессага, Новороссийскига, Гурьевка, Орскига, Ишимбайга, Саратовка, Куйбышевка һәм башка промышленность районнарына ага. Хәзер Татарстанда элеккеге бөтен патша Россиясендәгегә караганда алты мәртәбә артыграк электр энергиясе җитештерелә.

Татарстандагы куәтле электр станцияләре Чувашстан, Башкортстан, Мари республикаларын, Горький, Куйбышев өлкәләрен энергия белән тәэмин итә. Республикабыз ике меңгә якын төрдәге промышленность продукцияләрен алтмыштан артык Европа, Азия, Африка һәм Америка илләренә озата. Советлар Союзыннан экспортка чыгарыла торган нефть — тулаем диярлек Татарстан нефте.

Илебезнең эре промышленность үзәкләре — Мәскәү, Ленинград, Урал һәм Донбасс белән күпкырлы туганнарча бәйләнеш аеруча илне индустрияләштерү елларында зур үсеш алды.

1930 елның гыйнварында Мәскәүдәге «Красный богатырь» заводы коллективы инициативасы белән Мәскәү өлкәсе һәм Татарстан республикасы арасында ун елга хуҗалык-политик договоры төзелде. Бу договор нигезендә Мәскәү эшчеләре үзләренең производство һәм политик тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, инженер-техник кадрлар һәм югары квалификацияле эшчеләр әзерләүдә ярдәм иттеләр, республикабызны хәзерге заман техникасы белән тәэмин итүдә булыштылар.

1929 елның февраль аенда ук инде Казанга Мәскәү эшчеләре делегациясе килә. Делегация бездәге завод һәм фабрикаларның эшчәнлеге белән таныша, үзләрендәге яңалыклар белән Казан эшчеләрен таныштыра, күп кенә кимчелекләрне күрсәтә.

1932 елның апрелендә төзелгән договор нигезендә Урал профсоюзлары республикабыз төзүчеләренең квалификациясен күтәрергә ярдәм иттеләр. Татарстан, үз чиратында, Уралдагы яңа төзелешләргә эшче көче белән булышты, Уралдагы күп санлы татар эшчеләре арасында политик тәрбия һәм культура-агарту эшләре алып баруны юлга салды.

Шушы елның май аенда Х. Галиуллин җитәкчелегендәге Урал төзүчеләренең Татарстан төзүчеләренә язган чакыру хаты басылып чыгуга 40 ел тулды. «Казанда яңа төзелешләрдә эшләүче бетончыларны ярышка чакырабыз: рекордлар яулагыз!» диелгән иде анда.

Хәзер дә Татарстан белән Урал аерылгысыз бәйле.

Донбасс белән Татарстан арасында да шундый ук мөнәсәбәтләр дәвам итә.

Татарстанда төзелгән зур промышленность предприятиеләре экономик бәйләнешнең һәм үзара туганнарча ярдәмләшүнең матур үрнәге булып тора.

Беренче бишьеллыкта илебездә иң зур төзелешләрнең берсе булган ТЭЦ-1 салуга бөтен ил катнаша. Югары басымга чыдамлы казаннарны, куәтле турбиналарны,

һава насосларын, роторларны һәм генераторларны Ленинградтагы металл эшкәртү һәм «Электросила» заводлары ясый. Башка бик күп төрле җиһазлар һәм материаллар Мәскәүдән һәм башка шәһәрләрдән килә.

ТЭЦ-1 дә иң беренче бетончылар бригадасын Березники шәһәрендә электростанция һәм химкомбинат төзелешләрендә катнашып, хезмәтнең алдынгы ысулларын өйрәнгән В. Зарипов оештыра. ТЭЦ төзүдәге фидакарь хезмәте өчен аңа Татарстан Социалистик төзелеш герое исеме бирелә. Л. Миңнуллин да югары квалификацияле бетончы булып, Березники шәһәрендә таныла. Ул да үзенең белемен, тәҗрибәсен Казанда ТЭЦ-1 төзегәндә киң файдалана. Л. Миңнуллинга да шундый ук мактаулы исем бирелә. Бу төзелештә Березникидан килгән бетончылар бригадасы белән бергә Магнитогорскидан күчкән монтажчылар да эшли. Казанга Штеровск электр станциясе белгечләр җибәрә. Донбасс шахтерлары Казан ТЭЦы өчен планнан тыш чыгарылган бер эшелон ташкүмер җибәрәләр.

ТЭЦ-1 нең төзелеп сафка басуы Татарстанда алдагы үсеш өчен энергетик база булдырып кына калмый, ул яңа төзелешләр өчен югары квалификацияле, тәҗрибәле эшчеләрнең яңа отрядын да әзерләп бирә.

СССРдагы башка төзелешләрдә тупланган тәҗрибә дә Татарстанда промышленность объектлары төзүдә зур ярдәм күрсәтә. Мәсәлән, Казанда синтетик каучук заводын салганда Ярославль, Воронеж һәм Ефремовск заводларын төзегәндә тупланган тәҗрибә истә тотыла. Казан заводы бары тик илебездә җитештерелгән аппаратлар белән генә җиһазландырыла. Аларны Киевтәге «Большевик», «Мәскәүдәге «Компрессор» заводлары җибәрәләр. Ярославль заводы коллективы Казандагы СК-4 заводы өчен белгечләр һәм югары квалификацияле эшчеләр әзерләүдә ярдәм итә. Заводны җиһазлауга илебезнең 60 тан артык предприятиесе һәм фәнни-техник учреждениеләре катнаша.

В. В. Куйбышев исемендәге Казан химия заводын проектлаштыруда һәм салуда Мәскәү, Ленинград, Киев, Одесса, Харьков шәһәрләрендәге күп кенә оешмалар, предприятиеләр катнаша. Промышленность объектларының нигезен салу Горький өлкәсеннән килгән коммунист И. Нехорошковның егерме ике кешелек бригадасына тапшырыла. Җир асты эшләрен Мәскәү метросын төзүчеләр башкаралар.

Алтмышынчы елларда бу завод реконструкцияләнде һәм тагын да киңәйтелде. Бу эшкә Советлар Союзындагы 300 дән артык предприятие һәм күп кенә чит ил фирмалары катнашты.

Бөек Ватан сугышы еллары илебездәге халыклар дуслыгына зур сынау булды. Туганнарча бәйләнеш, үзара ярдәмләшү бу елларда тагын да үсте. Бу Татарстан промышленносте үсешендә дә ачык чагыла. Республикага күчеп килгән кайбер предприятиеләрдән промышленностьның яңа тармаклары үсеп чыкты; квалификацияле кадрлар — инженер-техник хезмәткәрләр, эшчеләр ишәйде. Мәсәлән, Мәскәүнең икенче сәгать заводы базасында Чистайда сәгать заводы барлыкка килде. Киевтән күчеп килгән медицина кораллары ясый торган завод коллективы ярдәмендә Казанда да шундый ук завод эшли башлады.

Татарстанда нефть промышленностеның барлыкка килүе һәм үсүе илебез халыклары дуслыгының, туганнарча үзара ярдәмләшүенең матур үрнәге булып тора. Республикабыз нефть промышленносте үсешенә һәм нефтьче кадрлар туплауга Советлар Союзындагы кырык милләт вәкилләре ярдәм итте. Әзербайҗан, Башкортстан, Дагстан, Куйбышев өлкәсе, Краснодар крае, Сахалин, Украина нефтьчеләре Татарстанга беренче вышка төзүчеләр, бораулаучылар, промысловиклар һәм башка белгечләр җибәрделәр. Алар җирле халык вәкилләреннән меңә диган нефтьчеләр тәрбияләделәр. Свердловскидан бораулау җайланмалары, Пермь һәм Куйбышев өлкәсеннән бораулау вышкалары, бораулар, Украинадан нефть үткәргеч һәм насос трубалары, Мәскәүдән, Ленинградтан, Бакудан, Грозныйдан, Уфадан һәм башка шәһәрләрдән төрле җиһазлар, машиналар килде.

Грозный нефть ятмаларын чыгаруда егерме дүрт ел эшләгән Корбан ага Вәлиев 1942 елда туган якларына — Бөгелмәгә кайта. Лениногорскида, Әлмәттә, Яңа Сәләй нефть промыселларын оештыруда, нефть чыгаручы кадрлар тәрбияләүдә аның белеме һәм тәҗрибәсе зур ярдәм итте. Унсигез ел дәвамында Татарстан промыселларында эшләү дәверендә Корбан ага Вәлиев иң кыен участокларда гына булды. Ул

җитәкләгән бригада илгә 40 миллион тонна нефть бирде. 1959 елда хөкүмәтебез Корбан ага Вәлиевкә Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бирде.

Республикабызның ярты гасырлык юбилей елында — 1970 елда — 100 миллион тонна нефть чыгаруга ирешкән Татарстан нефтьчеләренә Әзербәйҗан нефтьчеләре шундый котлау хаты җибәрделәр: «Гүзәл казанышларыгыз белән, нефть техникасына һәм технологиясенә керткән күренекле өлешегез белән бүген без дә горурланабыз. Нефть ятмаларын эзләү һәм эшкәртү буенча сез туплаган бай тәҗрибә илебездәге бик күп нефтьчеләргә сабак булып хезмәт итә».

Бөтенсоюз комсомол удар төзелешләре дип игълан ителгән Казан оргсинтез заводын, Миңлебай газ-бензин заводын, Түбән Кама химия комбинатын, Зәй ГРЭСын, «Дуслык» нефть үткәргечен төзегәндә илебезнең күп республика һәм өлкәләреннән вәкилләр катнашты.

Елга 15 мең күп тонналы йөк машиналары һәм автопоездлар эшләп чыгарачак Кама автомобиль заводын салу КПСС Үзәк Комитетының Татарстан промышленностен үстерү турында даими кайгыртуын күрсәтүче ачык мисал булып тора. Мондый зур колачлы төзелешнең әлегә кадәр дөньяда булганы юк иде.

КамАЗ Днепрогэс, Магнитка, Турксиб һәм социалистик индустриянең башка гигантларын төзүчеләр эстафетасын кабул итеп алды. КамАЗны бөтен Советлар Союзы төзи. Проект документларын эшкәртүгә, төзү материаллары, җиһазлары белән төзелешне тәэмин итүгә барлык союздаш республикалар катнаша. Илебезнең 500 заводы һәм фабрикасы Кама автомобиль заводы заказларын үти.

Мәскәүдән, Киевтән, Минскидан, Харьковтан, Донецкидан, Сухумидан, Орскидан, Ижевскидан, Пермьнән, Чиләбедән, Новороссийскидан, Амурдагы Комсомольскидан, Тольяттидан, Ангарскидан, Уфадан, Саратовтан һәм башка шәһәрләрдән КамАЗ төзелеше өчен краннар, бораулау җиһазлары, электр приборлары, машина частьлары, кабельләр һәм башка бик күп машиналар, җайланмалар, төзү материаллары килеп тора. Магнитогорск металл прокаты, Чиләбе һәм Свердловск өлкәләре цемент, Салават — пыяла, Сызрань тимер-бетон әйберләр җибәрә.

Украинаның җәүһәре булган атаклы Донбасстан КамАЗга металл һәм машиналар, цемент һәм пыяла, пластмасса һәм шифер һәм башкалар килә.

Кама автомобиль заводын салуда иң алдынгы, яңа, прогрессив алымнар кулланыла. Мәсәлән, «Гидропроект» инициативасы белән төп производство объектлары өчен нигез салганда тимер-бетон свайлар бораулап тишелгән җиргә коела. Бу ысулны куллану нәтиҗәсендә төзелеш вакыты шактый кыскара.

Горький монтажчылары үрнәгендә производство биналарын конвейер тәртибендә җыя башладылар. Моның нәтиҗәсендә монтаж эшләрен ике мәртәбәгә тизрәк башкару мөмкинлеге туды.

КамАЗ эшләп чыгарачак автомобильләрнең һәм автопоездларның үрнәкләре Лихачев исемендәге Мәскәү автозаводында, Ленин исемендәге Минск автозаводында, аларның двигательләре, дизельләре Ярославль моторлар төзү заводында ясалды. Күп кенә заводларда КамАЗда эшләячәк кадрлар туплана.

КамАЗ төзелешенә беренчеләрдән булып төрле союздаш республика вәкилләреннән оешкан «Дуслык» бригадасы килде. 1970 елда төзелештә 29 милләт вәкилләре эшли иде. Коллективта мөнәсәбәтләр интәшлек, дуслык, үзара ярдәмләшү принцибында оешты. Татарстанның атказанган төзүчесе коммунист Геворг Геворгян бригадасындагы утыз ике кеше — биш милләт вәкиле. Аларның барысы да берничә төзүче һөнәрен үзләштергән, бер-берсе белән тәҗрибә уртаклашалар, иҗтимагый тормышта актив катнашалар.

Г. Геворгян үзе Чаллыга Түбән Кама ГЭСы төзелә башлаганда ук килгән. Ул — биредә үсеп чыккан шәһәрнең беренче йортларына нигез салган кеше.

Монтажчылар бригадиры И. Давиденко Украинадан килә. Ул — утызынчы еллар эшче династиясе вәкиле, әтисе һәм абыйсы белән Днепрогэс төзи, соңрак «Запорожсталь»да автогенщик булып эшли, беренче бишьеллык чорында ударник-стахановчы булып таныла. Бөек Ватан сугышында катнаша, сугыштан соң фашистлар җимергән Днепрогэсны төзәтешә, Цимлянск су саклагычы, Кременчуг, Каховка, Киев ГЭСларын сала, Коммунистик хезмәт ударнигы дигән мактаулы исемгә лаек була. КамАЗда

автогенщикларның бөтен бер отрядын әзерли. Аның бригадасында хәзер белорус Геннадий Яунзем, татар Расих Хәлимов, Мичуринскидан килгән Анатолий Кичик, украин Микола Шубин, нанай Артем Тайборея һәм башкалар бердәм, тату коллектив булып эшлиләр.

Биектә эшләүчеләр бригадиры Ирек Гәрәев башта Братск ГЭСы төзелешендә эшли, аннары Түбән Кама ТЭЦын салыша. «Татспецстрой»ның СМУ-37 монтажчылар бригадиры Солтан Алимов КамАЗга килгәнче Белоруссиядә нефть эшкәртү заводын салуда катнаша, Ангарскида су чистарткыч корылмалар төзи, Татарстанда Ромашкино һәм Көнчыгыш Сөләй ятмаларын үзләштерү эшләренә хезмәт күрсәтә.

КамАЗ төзүчеләре беренче бишьеллыклардагы хезмәт геройларының традицияләрен дәвам итәләр. Завод төзелешендә социалистик ярыш инициаторлары Рәис Сәлахов, Виктор Деребизов, Михаил Никишин, Петр Кемаев, Кашаф Хәмитов, Рәис Сабирҗанов, Камил Еникиев һәм башкаларның чакыруы бөтен илгә таралды. Алар производство резервларын даими эзләү, тырышып өйрәнү, профессиональ осталыкны күтәрү, технологияне камилләштерү, хезмәтне төгәл итеп оештыру нәтиҗәсендә һәр объектта һәр көннең, һәр атнаның, һәр айның заданиесен арттырып үтәргә һәм һәр эшне яхшы сыйфатлы итеп башкарырга йөкләмә алдылар. Социалистик ярыш инициаторларына һәм Камадагы грандиоз төзелештә эшләүчеләргә беренче бишьеллык батырлары, югары хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешү өчен бөтенсоюз патриотик хәрәкәтен башлап җибәрүчеләр Алексей Стаханов, Петр Кривонос, Мария Виноградова, Иван Гудов, Александр Бусыгин хат белән мөрәҗәгать иттеләр. «КамАЗ төзелешендә, фәнни-техник прогресс, тугызынчы бишьеллык заданиеләрен үрнәк төстә үтәү өчен көрәшнең алгы сызыгында социалистик ярыш ялкыны тагын да активрак дөрләсен,— дип яздылар алар.— Бөек төзелешкә — удар темп һәм төгәл ритм!»

Кама автомобиль заводын төзүчеләргә «Магнитстрой» ветераннары һәм В. И. Ленин исемендәге Магнитогорск металлургия комбинатының алдынгы эшчеләре теләк хаты җибәрделәр. Анда шундый юллар бар: «...Без сезне төзелә торган объектларны тизрәк сафка бастырырга, хезмәттә югары җитештерүчәнлеккә, эшләнгән эшләрнең бик яхшы сыйфатлы булуына ирешергә чакырабыз. Без КамАЗны металл белән тәэмин итәрбез. Дүрт дистәдән артык еллар дәвамында тупланган тиз төзү тәҗрибәсе белән уртаклашырга без әзер — безгә кунакка килегез...

Индустрияләштерү таңында без «Даешь Магнитка!» лозунгысы астында эшләдек. Сезнең көрәшегездә «Даешь КамАЗ!» дигән девиз байрак булсын!»

КамАЗда эшләүче эшчеләр, инженерлар һәм техниклар, бу мөрәҗәгатьләргә җавап итеп, социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдерделәр.

Шулай итеп, Татарстан хезмәт ияләре, совет халыкларының туганнарча ярдәменә таянып, элек артта калган аграр провинцияне күп тармаклы куәтле промышленносте булган, чәчәк аткан республикага әверелдерделәр.

* * *

Борын-борыннан татарлар җирсезлектән һәм булган кадәр җирдә дә уңыш бик начар булу сәбәпле, туган якларын ташлап, читкә китәргә мәҗбүр булганнар. Ә элек Казан губернасында артта калган промышленность җирле халыкны эш белән тәэмин итә алмаган. Шуңа күрә татарлар, эш эзләп, иксез-чиксез Россиянең төрле почмакларына таралганнар. Патша Россиясендә Казан губернасы халыкның читкә таралу проценты буенча беренче урында торган.

1926 елда Татарстаннан читтә — башлыча, Уралда, Донбасста, Әзербәйҗанда һәм илнең башка районнарында — 90 мең татар эшчесе эшләгән.

Беренче бишьеллыкта Татарстанда нигездә җиңел промышленность үсә. Шуңа күрә безнең республика ул елларда социализмның бөек төзелешләренә күбрәк үзенең эшче көчләре белән катнаша.

Партия чакыруы һәм йөрәк кушуы буенча безнең бик күп якташлар, туган якларыннан китеп, эшчеләр сыйныфы сафына бастылар һәм алар яңа урыннарда да героик хезмәт үрнәкләре күрсәттеләр.

Татар хезмәт ияләренең социалистик индустрия гигантларын төзүгә актив катнашулары чит илләрдәге татар буржуаз милләтчеләренә, акгвардияче эмигрантларга ошамады. «Милли юл» дигән ак эмигрантлар журналында алар Советлар Татарстанына каршы ялa ягу кампаниясе оештыралар, «республиканы татарларсыз калдыралар»,— дип аһ оралар.

Казанбаш авылы колхозчылары республиканың барлык хезмәт ияләре исеменнән буржуаз матбугатның яла ягуларына протест белән чыгалар. «Без татарларны Донбасска, Магнитогорскига һәм Советлар Союзының башка индустриаль районнарына көчләп җибәрәләр, дигән ялганны нәфрәт белән кире кагабыз,— дип язалар алар.— Безне беркем дә беркая да көчләп җибәрми — моны катгый төстә раслыйбыз. Киресенчә, без гигант социалистик төзелешләргә ярдәмгә иң яхшы ударник-колхозчыларны җибәрергә үзебез тырышабыз һәм ташкүмер чыгару, Магнитогорскины төзү, Кузбассны сафка бастыру буенча программаларны тормышка ашыруга катнашуыбыз белән горурланабыз». («Красная Татария» газетасы, 2 сентябрь, 1932 ел.)

1931 елның беренче яртысында гына да Уралдагы һәм Себердәге яңа төзелешләргә Татарстаннан 53 мең эшче китә. 1931 елда Магнитогорскига Татарстаннан 10 мең 668 эшче килә. Татарстан республикасы Магнитогорск төзелешен эшче көч белән тәэмин итү буенча Урал өлкәсеннән кала беренче урынга чыга.

Якташларыбыз дөнья күләмендәге иң зур металлургия үзәкләрен — Магнитогорск һәм Кузнецк металлургия комбинатларын, Чиләбе һәм Сталинград трактор заводларын, Березники химия комбинатын, Днепрдагы гидроэлектростанцияне, Мәскәү метрополитенын һәм башкаларны төзүгә һәм аларны үзләштерүгә актив катнаштылар. Алар Донбасста, Кузбасста һәм Карагандада һәм башка урыннарда ташкүмер чыгару эшенә зур өлеш керттеләр. Бик күп якташларыбызның исемнәре илебезне индустрияләштерү буенча героик эшләр елъязмасына керде. Илне индустрияләштерү елларында Татарстанда «Магнитстрой» (Норлат районы), «Урал» (Кукмара районы), «Шахтер» (Арча районы) дип исемләнгән колхозларның барлыкка килүе юкка гына түгел. Алар республикабызның социализмның бөек төзелешләре белән тыгыз бәйләнеше турында сөйлиләр.

1935 елда М. Горький редакциясендә басылып чыккан «Были горы Высокой» дигән китапта тимер рудасы рудникларын, Түбән Тагил металлургия заводын сафка бастыручы эшчеләрнең хезмәте турында сөйләнелә. 1929 елда Высокогорский рудныгында руда ташу өчен беренче асылма юл эшләнә башлый.

Анда юл эшләре мастеры Я. Тихонов җитәкчелегендәге бригада дан тота. Бу бригада составындагы алты татар эшчесе: И. Әхмәтов, М. Миңкадыйров, М. Гарипов, Шәрәфетдинов, Ш. Галиәхмәтов һәм «Алешка» турында Я. Тихонов болай дип яза: «...Кулакларның янавына карамастан, мин ударниклыкка язылдым. Минем арттан бригададагы алты татар да язылды. Без ныгыдык, эшләргә өйрәндек, бүтәннәрне дә эшләргә өйрәттек... Караңгы төшкәнче эшли идек. Барысы да инде кайтып китә иде. Ә безнең бригада кала. Темпны киметмәскә, юл эшләрен үз вакытына тәмамларга булдык».

Асылма юл үз вакытында өлгерә, һәм ул арбалар җигелгән меңнәрчә атларның эшен алыштыра.

Высокая тавына беренче экскаватор 1929 елның май аенда китерелә. Ул 1916 елдан бирле тик яткан, аның күп кенә частьлары юкка чыккан була. Бу экскаваторны төзәтү Вәли Насыйровка тапшырыла. Ул үзенә өч ярдәмче ала да эшкә керешә. Җитешмәгән частьларны алар үзләре ясыйлар. Экскаватор эшли башлый һәм алтмыш кешене авыр җир казу эшеннән азат итә.

Соңрак рудникка чит илләрдән сатып алынган экскаваторлар китерелә. Аны эшләтә белүчеләр төзелештә бик аз була. Әмма йөк ташучылар, җир казучылар аптырап калмыйлар, яңа машинаны җыяргa, анда эшләргә өйрәнәләр. Көйсезләнеп мәташканда, ялындырып эшләгәндә шул ук Вәли Насыйров экскаваторда эшли башларга рөхсәт сорап администрациягә керә һәм бу эшне үз вакытында бернинди кимчелексез башкарып чыга.

В. В. Криворучкин — Вәли Насыйров җитәкчелегендәге бригада члены (Ленин ордены кавалеры) — болай дип яза: «Рудник җитәкчеләре безнең барыбызга да премия бирде. Удар бригада исеме бирделәр. Бу турыда газетага да яздылар. Шатлык

никтөн ашты. Шатланырлык урын да бар иде шул: без, гади эшчеләр, чит ил белгечләре ярдәменнән башка да техниканы үзләштерә алабыз икән».

Советлар иленең индустриаль байрагы булып күтәрелгән һәм социалистик дәүләтебезнең какшамас нигезен чагылдырган Магнитогорск төзелешләрендә утыз алты милләт вәкилләре эшли. Магнитка төзелешенә Татарстан республикасының йөз меңләгән уллары катнаша.

Н. Шәйхетдинов Магниткага 1930 елда, Кызыл Армия сафларыннан кайткач килә. Ул егерме алты татар эшчеләреннән торган җир казучылар бригадасын җитәкли.

1930—1931 елгы кышның никадәр зәһәр булуын, ул вакыттагы кыенлыкларны күз алдына китерү өчен бер документка күз салыйк.

«Каты салкыннар аркасында төзелештәге хәллар бик куркыныч,— дип телеграмма суга 1930 елның октябрь аенда партиянең Магнитогорск район комитеты секретаре Румянцев ВКП(б)ның Урал өлкә комитетына.— Кар төште. Баракларда ягарга утын юк, 3 мең 500 эшче палаткаларда яши. Әгәр, күп дигәндә, ике-өч көн эчендә җылы киемнәр — туннар, телогрейкалар, җылы чалбарлар килмәсә, 500 эшче эштән китәчәк. Җылы киемнәр җибәрү һәм 5000 кубометр утын белән тәэмин итү буенча ашыгыч чара күрегез».

Каты салкыннарда палаткаларда, суык баракларда яшәүгә карамастан, Шәйхетдинов, Галиуллин, Сәгъдиев, Батыев, Корбангалиев, Зәйнуллин, Бугушев, Хөсәенов һәм башкалар җитәкчелегендәге бригада членнары чын ударникларча фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр. Кырык градуслы салкын көннәрдә дә Шәйхетдинов бригадасы ике-ике ярым норманы үти. Ә котлованнарны бик тиз әзерләп бетерергә кирәк булгач, бригада членнары ялсыз-нисез 34 сәгать буена төн җирне казыйлар. Бригаданың барлык членнары партия, комсомол сафларына кабул ителә. Ә Нурулла Шәйхетдинов үзе Магнитка төзелешендә иң беренче Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек була.

Яшь эшче Гашигулла Мәҗитовның да язмышы бик кызыклы. Бәхет эзләп бик күп юллар үзә ул. Владивостокта, Кузбасс шахталарында эшли, Бакуга да барып чыга. Ниһаять, Магнитогорскига килеп, плотина төзелешенә балта остасы булып эшкә урнаша. Аның тырышлыгын бик тиз күрәләр һәм бригадир итеп күтәрәләр. Аның бригадасы карт балта остасы Зуев бригадасы белән ярышып эшли. «Зуевчылар» да, «Мәҗитовчылар» да бөтен төзелештә тырыш хезмәтләре белән дан ала. Әмма коксохимия комбинаты төзелешендә эшләгәндә Зуев бригадасы ниндидер сәбәпләр аркасында артта кала, планны үтәми башлый. Алтмыш кешедән торган Мәҗитов бригадасы акча азрак төшә дип тормый, Зуев бригадасына ярдәмгә килә. Шуннан соң бу ике бригада членнары берләшергә карар чыгаралар һәм «Зуевчы-Мәҗитовчылар» исеме белән тенгә керәләр. Алар, һәркөнне планны 136—143 процентка үтәп, үзләренә билгеләнгән эшне вакытыннан элек тәмамлыйлар. Шул ук көнне ике дус бригадир — Зуев белән Мәҗитов — партиягә керергә гариза бирәләр.

Чиләбе өлкәсе буенча партиянең XVII съездына әзерлек уңае белән үткәрелгән киңәшмәгә җибәрү турында партиянең Магнитогорск шәһәр комитеты 1933 елның 11 декабрендә язган белешмәдә болай диелгән: «Мәҗитов (татар) эшен балта остасы булып башлый. Энергияле булуы һәм энтузиазмы белән бик тиз күтәрелә, күп кенә премияләр ала, партиягә керә, Ленин орденына тәкъдим ителде».

1931 елның уртасында Магнитогорскида коксохимия комбинаты һәм металлургия комбинаты төзелешендә бетончылар ярышы башланып китә.

Утызынчы елларда «Егерь» һәм «Кайзер» тибындагы бетон әзерләү машиналарында сменага 200 изма бирү капиталистик илләрдә норма була. Харьков трактор заводын төзүчеләр 1931 елның маенда сменага 306 изма биреп рекорд куялар. Бу турыдагы хәбәр барлык төзелешләргә тарала. Магнитогорскида Сәгъдиев җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасы бу рекордны беренчә тапкыр яңарта: башта 8 сәгатькә алар 429 изма бирәләр, аннары 7 сәгать 30 минут эчендә 525 изма бирүгә ирешәләр. Ә июльдә рекорд 840 ка җитә. Моңа ышанырга теләмиләр. «Бу мөмкин түгел, булса да бетоны начар сыйфатлы»,— диләр. Кулак калдыклары, әле ул заманда үзен шактый иркен тоткан сыйнфый дошманнар: «Татарлар эшләгән эш рәтле булмас, антихристларга юкка ирек бирәләр, барысы да җимерелеп төшәчәк»,— дип котны салалар. Әмма «эт өрер, бүре йөрер» дигәндәй, Сәгъдиев

бригадасының рекорды бетон әзерләү эшендә революция ясый. Ярыш бөтен союз буйлап җәелеп китә, аңа Түбән Тагил, Харьков, Чиләбе, Мәскәү һәм башка шәһәрләрдәге бетончылар кушыла.

Бу ярышта бетон әзерләү эшендә дөнья рекорды куеп, Хәбибулла Галиуллин җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасы җиңеп чыга. Сигез сәгатьлек смена дәвамында Апас районыннан килгән Галиуллин егетләре 375 кубометр бетон сыешлы «Егерь» машинасы белән 1196 измә бирәләр. Ә бетон бик яхшы сыйфатлы дип табыла. Бер измә бирү өчен бары тик 30 секунд вакыт китә. Бу турыда профсоюзларның Мәскәүдә үткәрелгән IX съездында сөйләгән речендә Х. Галиуллин үзе болай ди:

«Безнең бетончылар бригадасы татарлардан тора. Алар Магнитстройга төзелеш башланганда ук килделәр. Без плотина төзедек, коксохимия комбинаты салдык, ә хәзер мартен цехында эшлибез. Алда әле эшләр күп, әмма безне бу куркытмый. Без эшсез яши алмыйбыз. Минем бригада дөнья рекорды куйды. Без сигез сәгать эчендә 1196 измә бирдек. Моңа кадәр дөньяда күрелмәгән рекорд, әмма ул чик түгел».

«Магнитстрой безнең өчен социализм мәктәбе булды,— дип яза Х. Галиуллин 1932 елда.— Магнитстройга килгәндә безнең арада партиягә кандидат та юк иде, ә хәзер дүртебез — партияле, 22 кеше — комсомолец».

Галиуллин бригадасының даны бөтен илгә тарала. Бригада Бөтенсоюз күчмә Кызыл Байрагын яулап ала, ә Х. Галиуллин үзе Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Американың «Мак-ки» фирмасының механикалаштыру һәм бетон эшләре буенча баш инженеры Девис, 1931 елны Советлар Союзына килгәч, Магнитогорск комбинатын төзүгә катнашучы СССР халыкларының иҗади күтәренкелеген аңламаэы турында сөйли. «Ниндидер татар эшчеләре,— ди ул,— бетон кою буенча, американлыларны да артта калдырып, дөнья рекордлары куялар».

«Завод эшли башлагач, без аңа сокланып кызыгып карый идек,— дип искә алалар соңрак Мөхәммәт Зиннуров, Мәннан Кадыйров һәм Сәфәр Гафуров.— Үзебез ясаган агрегатларда эшлисебез килде. Әмма башта ул безнең өчен мөмкин түгел эш дип саный идек».

Галиуллин бригадасы членнарыннан: Мөхәммәт Зиннуров, Хәлләә Шәйдуллин, Фәтхи Мортазин, Сәфәр Борһанов, Галәветдин Гамәлетдинов, Самат Сабиров, Хәбибулланың энесе Хәмидулла Галиуллин һәм башкалар 1933 елда металлистлар әзерли торган курсларга керәләр. Аларның күбесе соңыннан атаклы корыч коючылар булып таныла.

Мәннан Кадыйров Бөтенсоюз социалистик ярыш нәтиҗәләре буенча рәттән берничә ел «СССРның иң яхшы корыч коючысы» исемен ала.

Апас районы Кормаш авылы егете Мөхәммәт Зиннуров Бөек Ватан сугышы елларында иң беренчеләрдән булып броня корычын коюны үзләштерә. Ул Магнитогорск металлургия комбинатында корычны тизләтелгән алым белән кою инициаторы була, аның инициативасы Советлар Союзының барлык корыч коючылары арасында тарала. Хөкүмәтебез Мөхәммәт Зиннуровның фидакарь хезмәтенә зур бәя бирә: ул ике тапкыр Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Корыч кою буенча тизләтелгән алымнар кертүе өчен 1951 елда М. Зиннуровка СССР Дәүләт премиясе бирелде.

Хәбибулла Галиуллин исә 1936 елда, Магнитогорскида стахановчылык хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрнең берсе буларак, бетон эшләре буенча хезмәтнең алдынгы ысулларын пропагандалау инструкторы итеп билгеләнә. Галиуллин үзе дә, аның шәкертләре дә Бөек Ватан сугышы елларында моңарчы күрелмәгән фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр. Дошманга каршы атылган һәр өч снарядның берсе һәм һәр ике танкның берсе Магнитогорск корычыннан ясала. 1942 елның көзендә барлык домна мичләрендә бары тик корыч кына коелганга, илдә чуен кытлыгы башлана. 1942 елда 5 номерлы домна төзергә һәм чуен бирә башларга! дигән боерык куела. Бу домнаны төзегәндә Х. Галиуллин шәкерте Фәез Рәхимов, норманы 1089 процентка үтәп, яңа рекорд куя. Ә Х. Галиуллин бригадасы исә аны да уздырып җибәрә, ул норманы 1800 процентка үти. Бу рекордлардан соң, «меңчеләр хәрә-

көтеү башланып китә. Һәм бу хәрәкәт Дәүләт Оборона Комитеты заданиесен үтәүне тизләтүдә зур роль уйный.

Х. Галиуллин исеме күп еллар дәвамында газета-журнал битләреннән төшми. Аның турында күп кенә китаплар, очерклар, мәкаләләр язылган, күп кенә күренекле совет художниклары һәм скульпторлары үз әсәрләрен аның образын сурәтләүгә багышлаганнар. Магнитогорскига килгән чит ил язучылары һәм журналистлары бу гади, тыйнак совет кешесе белән күрешеп сөйләшүне үзләренең бурычы итеп санаганнар. Магнитогорскидагы яңа урамнарның берсе Галиуллин исемен йөртә. Металлургия комбинатында хәзер Хәбибулла Галиуллинның ике улы — Габдулла һәм Дарбин эшли.

«Кама автомобиль заводын салучыларга «Магнитстрой» һәм В. И. Ленин исемендәге Магнитогорск металлургия комбинаты ветераннары һәм алдынгы эшчеләре хатында түбәндәге юллар бар: «Татарстан вәкилләре хезмәт батырлыгы һәм интернационализм үрнәкләре күрсәттеләр. Галиуллин, Сәгъдиев бригадаларының батырлыгы Магнитка тарихына алтын хәрефләр белән язылган. Татарстанның Апас районы батыры Хәбибулла Галиуллин һәм аның иптәшләренең бетон кою буенча дөнья рекорды Магнитка төзелешенең югары аңлылык символы булып өверелде...»

Березники химия комбинатында да М. Ардуанов, М. Солтанов, Закиров, Сәхапов җитәкчелегендәге татар бригадалары бөтен илгә дан казандылар.

1927 елда Татарстаннан күчеп киткән М. Ардуановның бетончылар бригадасы авыр табигать шартларында героик хезмәт үрнәкләре күрсәтә. Бу алдынгы бригада членнары һәрвакыт төзелештәге иң кыен участокларда эшли. Алар, бер-берсенә ярдәмләшеп, бер-берсе белгәннәрне уртаклашып, төрле-төрле һөнәрләр үзләштерәләр. Аларга арматурчы да, штукатурчы да булырга туры килә. 1929 елдан башлап 1933 елга кадәр дүрт ел эчендә Ардуанов бригадасында бер генә прогул да, бер генә тәртип бозу да булмый, бригада һәрвакыт норманы 120—150 процентка үти. Бетон эшләренең үзкыйммәте 32 процентка кими, ә хезмәт җитештерүчәнлеге 35 процентка күтәрелә. 1932 елда бригада «Березники химия комбинатының беренче чиратын төзүдәге героик хезмәтләре өчен» Уралның Мактау китабына кертелә. Ә Мирсает Ардуанов үзе 1933 елның декабрендә Ленин ордены белән бүләкләнә, СССР Үзәк Башкарма Комитеты члены, Советларның VII—VIII Бөтенсоюз съездларына делегат итеп сайлана.

Мифтах Солтанов та 1935 елда Березники химкомбинатының беренче чиратын төзүдәге батыр хезмәтләре, бетон эшләрендә югары хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешкәнлеге өчен Ленин ордены белән бүләкләнә.

1929 елда «Днепрострой» Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына, Татарстан хезмәт батырларының төзелештәге эшләрен билгеләп, Кызыл Байрак тапшыра. Днепрогэс төзүчеләреннән бетончы Закир Таһиров белән инженер Изатулла Ибәтуллин Ленин ордены белән бүләкләнәләр.

1931 елда Донбасс белән Татарстан республикасы арасында хуҗалык һәм политик договор төзелә. Бу договор нигезендә Татарстан Донбасс шахталарын эшчеләр белән тәэмин итә, ә Донбасс исә, үз чиратында, республика колхозларына материаль-техник ярдәм күрсәтә. Украинаның партия оешмалары һәм хөкүмәт органнары Совет властеның беренче елларыннан ук Донбасстагы татар хезмәтчәннәрен һөнәргә өйрәтү, алар арасында коммунистик тәрбия эше алып бару буенча нәтиҗәле чаралар күрергә керешә. Бу юнәлештә Татарстан үзе дә җитди эш алып барды. Донбасста татар эшчеләренең политик аңлылыгын һәм культура дәрәҗәсен үстерү буенча күп кенә чаралар үткәрелде.

1931 елның августында Красный Бор районы колхозчыларыннан Ф. Нурмөхәммәтов, И. Шәмсетдинов, М. Хәкимов һәм башкалар республиканың барлык колхозчыларына хат белән мөрәҗәгать иттеләр. «Бөтенсоюз кочегаркасы — Донбасс эшче көчләр җитмәү аркасында үзенә алган йөкләмәләрне үти алмый. Ягулык кытлыгы бөтен халык хуҗалыгын кыен хәлгә куя.

Донбасс эшчеләре ярдәм сорап безгә мөрәҗәгать иттеләр. Без, Красный Бор районы колхозчылары, Татарстан республикасында беренче булып 25 кешелек удар бригадага оештык. Без Донбасска китәбез...

Колхозчыларны һәм аерым хуҗалыкларны безнең белән Донбасска чакырабыз!..»

1931 елда Донбасс шахталарына Татарстаннан 41 мең 530 кеше килә.

Татар халкы вәкилләре Донбасста үзләрен хезмәт сөючән, тырыш итеп күрсәтәләр. Мәсәлән, 1931 елда Горловка, Рыковск, Лисичанск, Крамоторск, Амвросиевск районнарындагы 21 предприятиедәге 7634 татар эшчеләренең дүрт меңе ударбригадаларда эшли. Мәскәү, Сталин районнарында да меңәрләгән татар эшчеләренең 70—75 проценты ударниклар була. Гришанск районында Закиров бригадасы планны арттырып үтәгәне өчен күп тапкырлар бүләкләнә һәм ул ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы мөрәҗәгатендә үрнәк бригада итеп телгә алына.

Сталин районындагы «Пролетар» шахтасы забойщигы Габдрахманов, планны ай саен 120—130 процентка үтәп, алдынгы хезмәт үрнәкләре күрсәтә.

1931 елда Мәскәүдә В. Юрезанскийның «Җир асты кешеләре» дигән китабы басылып чыга. Китапка язган кереш сүзендә ул болай ди: «Татар бригадасы җитәкчесе забойщик, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән Хәсьян Хөснетдинов барлык тирә-як рудникларга билгеле».

Юзов районы рудникларында Х. Хөснетдинов 1921 елдан бирле эшли. Ул яхшы забойщик булып таныла, Астахов, Корнеев, Сиражетдинов кебек атаклы шахтерлар белән ярышка чыга. Шахта парткомында аның турында болай диләр: «Сменага чыгу белән башын да күтәрми эшли. Бер минутны да бушка уздырмый. Үз участогы турында гына түгел, бөтен шахта эше өчен кайгырта».

Шахтага яңа килүчеләр арасында бик күпләре рус телен белмиләр. Шуның аркасында эштә шактый кыенлыклар туа. Десятниклар алардан зарланалар. Татарлар да аптырап тормыйлар, аларга карап: «Син сүз белән ботка пешермә, эшләп күрсәт. Без аңларбыз. Тел чарларга түгел, эшләргә килдек»,— диләр. Бу хәлдән чыгу юлын да Хөснетдинов таба. Ул шахта комитеты утырышында татарларны аерым бригадага тупларга тәкъдим кертә. Һәм иртәгесе көнне үк 27 кешедән торган татар бригадасы эшкә керешә. Үз эшенә таләпчән карарга өйрәнгән тәҗрибәле шахтер оста укытучы булуын да күрсәтә. Бер айдан ук бригада планны арттырып үти башлый.

— Ни белән сихерләдең син егетләреңне? — дип сорыйлар аңардан.

— Юк, сихерләмәдем,— ди ул.— Алар үзләрен ударник дип игълан иттеләр. Шахтада беренче урынга чыгарга җыеналар.

— Әй, юкны сөйләмәсәнә!

— Дөресен әйтәм, беренче урынга чыгачаклар!

— Татарлармы?..

— Син аларның милләтенә карама, эшенә кара. Элек татарлардан көлгәннәр, хәзер аларга каршы тора алмыйлар.

...Чыннан да, бригада беренче урынны яулап ала.

Шахтага беренче бораулау машинасы алынгач, аны да иң беренче Хөснетдинов бригадасы егетләре үзләштерә...

1929—1931 елларда Хөснетдинов өч татар бригадасын, бер украин бригадасын забойщик һөнәренә өйрәтә. Соңрак, 1931 елның көзендә, Татарстаннан яңа килгәннәрне инде аның шәкертләре: Шәйдуллин, Әхмәтов, Төхфәтуллин, Якупов, Мөхәммәтов, Кашаповлар өйрәтә.

Стахановчылык хәрәкәте башлангач, Чувырин исемендәге шахта забойщигы Х. Зарипов 3 номерлы участокта дүрт кеше урынына берүзе эшләргә керешә. 1935 елның октябрендә заданиене 254 процентка үтәп, күмер чабу остасы дигән исемне яулап ала.

1940 елның августында Донецкида 14 номерлы орденлы шахта машинисты Гобәйдуллин, 22 мең 260 тонна ташкүмер казып, бөтенукраина рекордын куя.

Шахтер Газиз Габдрахмановның да язмышы кызыклы. Ул, 1929 елда Казаннан Донбасска килеп, күмер ташучы булып эшкә керә. Озакламый күмер чабарга керешә, иң яхшы шахтерларның эш алымын өйрәнеп, үзен ударник итеп таныта. Портреты шахтерлар газетасында басылып чыга, бригадир булып сайлана. Бик тиз фикер йөртүчән, тырыш, ару-талуны белмәс рационализатор булып таныла. Иң беренчеләрдән булып күмер бораулау машинасын үзләштерә һәм, Донбассның иң

беренче механизаторларыннан берсе булганы хәлендә, бик күп тау эшчеләренә үз һөнәрен өйрәтә. Донбассның иң яхшы шахтерларыннан берсе булган Г. Гобәйдуллин Кизель ташкүмер бассейнына, «Комсомолец» шахтасына яңа машиналарны үзләштерергә ярдәм итәргә җибәрелә. Катлаулы геологик шартлар өчен Газиз бригаданың яңа эш графигын төзи. Бу алым белән эшләүгә күчкәч, хезмәт җитештерүчәнлеге өч мәртәбә арта. Күршедәге шахта җитәкчеләре бик еш кына аннан: «Вакытлы рәвештә генә булса да бораулау машиналарын үзләштерергә ярдәм итәргә килеп китсәгез иде»,— дип үтенәләр. Аның тәҗрибәсен кулланып, шахтерлар бербер артлы яңача эшләүгә күчәләр.

Бөек Ватан сугышы башлангач, ул берничә тапкыр фронтка җибәрүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Ләкин аны җибәрмиләр. Күмер чыгаруда үз-үзен аямыйча эшләве өчен аны «тылның үрнәк сугышчысы» дип атыйлар. Шахталарны ремонтлау буенча ул керткән тәкъдимнәр күп кенә дәүләт акчасын янга калдырырга, материалларны экономияләргә мөмкинлек бирә. Аның тәкъдимен тормышка ашыру нәтиҗәсендә эшчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеге ике мәртәбәгә арта. Партиянең Пермь өлкә комитеты Урал шахталарында Г. Габдрахманов тәҗрибәсен киңрәк куллану турында махсус карар чыгара. Совет хөкүмәте атаклы шахтер Газиз Габдрахмановның хезмәтен зурлап, 1948 елда аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирде.

1959 елда Татарстаннан читтә — РСФСРда 910 мең 200 дән артык, Белоруссиядә 1971, Казагыстан ССРда 55 мең 572, Үзбәкстанда 110 мең 239, Кыргызстанда 14 мең 833, Төркмәнстанда 14 мең 183 татар эшчесе эшли иде.

Татарстан уллары һәм кызлары сугыштан соңгы бөек төзелешләргә дә актив катнаштылар. Братскида һәм Курск ГЭСында, Караком каналында һәм Красноярск ГЭСында, Тольятти автомобиль заводында һәм башка бик күп төзелешләрдә халыкларның туганнарча хезмәттәшлеге һәм үзара ярдәмләшүе матур традиция булып дәвам итте. Бик күп Татарстан төзүчеләре Ташкент шәһәрен төзекләндерделәр, Мәскәүдә Останкино телевизион башнясын корыштылар.

Үз вакытында илебезнең төрле районнарындагы нефтьчеләр Татарстан нефтен үзләштерергә ярдәм иткәннәр иде. Хәзер йөзләрчә Татарстан нефтьчеләре Себердәге һәм Казагыстандагы нефть ятмаларын үзләштерәләр.

Дамир Нурисламов үзенең бөтен бригадасы белән Мангышлакка киткән иде. Аның бригадасы Казагыстанда бораулау буенча иң яхшы күрсәткечләргә иреште. Хәзер ул анда бораулау конторасы директоры булып эшли. Татарстаннан киткән Кави Вәлиәхметов, Иван Моржавиннар да Мангышлыкта бик күпләргә билгеле.

Мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин. Татарстан нефтьчеләре Төмән һәм Иркутск өлкәсендә, Удмуртиядә һәм Белоруссиядә, Украинада һәм Сахалинда, Төркмәнстанда һәм башка урыннарда мактауга лаек хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр.

Кыскасы, якташларыбыз илне индустрияләштерүгә, илебездә социализм төзүгә зур өлеш керттеләр һәм алар хәзер дә коммунизмның материаль-техник базасын төзүдә үз-үзләрен аямый эшлиләр.

# ХӘЗИНӘБЕЗ УРТАК БУЛСЫН

*Татар һәм удмурт әдәбиятларының үзара бәйләнешенә карата*

Без, янәшә торган күршеләр, ничә гасырлар буе бер-беребезнең хәлен, күршебез йортында нинди энҗеләр, нинди рухи байлыклар барлыгын белми яшәдек. Ә бит чабаталы, кара нужалы милли йортларыбызда — татар һәм удмурт халкында — революциягә кадәр үк шактый иде ул хәзинәләр. Тапкыр мәкальләребез, тылсымлы әкиятләребез бар иде, сагышлы җырларыбыз, дәртле биюләребез бар иде. Милли әдәбиятыбыз бар иде. Кыскасы, һәр халыкның үзенчәлекле культурасы, зур иҗат җимешләре бар иде. Тик шул хәзинәне бүлешеп, уртаклашып яшәү мөмкинлеге генә булмады. Андый мөмкинлекне Октябрь давылында без үзебез яулап алдык һәм бер-беребезгә ишекләребезне киереп ачтык:

— Рәхим итегез, күршеләр! Түрдән узыгыз! Гасырлар буе тупланган рухи байлыгыбыз уртак булсын!..

Татар халкының әдәби казанышлары турында беренче төшенчәләр удмуртларга рус теле аша килә. Егерменче елларда удмурт укучылары Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури кебек классик әдипләрнең русчага тәрҗемә ителгән әсәрләре белән танышалар. Ә утызынчы елларда татар әдәбиятының кайбер үрнәкләре удмуртчага тәрҗемә ителә. Бу зур һәм гаять җаваплы эшне беренче буларак удмурт халкының күренекле язучысы М. П. Петров башлап җибәрә. Татар телен бик яхшы белгәнлектән, ул барлык тәрҗемәләрен турыдан-туры татарчадан эшли.

1934 елда «Әдәбият фронтында» исемле журналда М. Петров Муса Җәлилнең «Зәйнәп» исемле поэмасын тәрҗемә итеп бастыра. Соңрак бу тәрҗемә М. Петровның «Ошмес син» («Чишмә») исемле җыентыгына да кертелә.

М. Җәлил белән М. Петров якын танышлар булалар һәм алар, еш кына очрашып, тыгыз иҗади элемтәдә торалар. М. Петровны бигрәк тә Җәлил иҗатындагы индустрия темасы һәм яңа тормыш төзүче эшче образлары кызыксындыра.

Кырыгынчы елларда «Молот» журналында М. Гафуриның күп кенә шигырьләре басылып чыга. Удмурт әдипләре М. Виноградов һәм М. Можгин, бу әсәрләрне тәрҗемә итеп, ике халык арасында «тел, әхлак вә лөгать» алмашу эшенә тагын шактый өлеш кертәләр.

Бөек Ватан сугышыннан соң тагын бер зур әдип — удмурт шагыйре Гай Сабитов җиң сызганып тәрҗемә эшенә кереша. Г. Сабитов та татар телен үз туган теледәй яхшы белә, турыдан-туры оригиналдан тәрҗемә итә. Ул Муса Җәлилнең бик күп шигырьләрен удмурт халкына җиткерде. 1960 елда «Моабит дәфтәре» циклыннан 27 шигырьне, Г. Кашшаф язган сүз башы белән, аерым китап итеп чыгарды. Шулай итеп, удмуртлар патриот шагыйрьнең иҗаты һәм тормыш юлы белән тагын да ныграк танышу мөмкинлеге алдылар.

Безнең рухи хәзинә уртаклашуыбыз берьяклы гына түгел, әлбәттә. Удмурт әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре татар халкына да иреште. Шагыйрь Нури Арсланов М. Петровның «Иске Мултан» романын та-

тарчага тәрҗемә итте. Р. Гайнанов «Совет әдәбияты» журналында Т. Архиповның «Яз» исемле хикәясен тәрҗемә итеп бастырды. «Ялкын» журналы битләрендә Г. Красильниковның «Иске йорт» повестеннан «Акташ базарында» исемле зур гына өзек бирелде.

Удмурт язучыларының кайбер әсәрләре турында өлкән һәм могтәбәр татар әдипләре авызыннан матур-матур фикерләр ишетелү шулай ук күңелле хәл. «Яшь язучы Г. Красильниковның «Кәләш» исемле уңышлы хикәясен татар укучылары җылы каршыладылар,—дип язды Г. Бәширов.— С. Самсоновның «Абзый» һәм «Мин туган көнемне белмим» дигән хикәяләре шулай ук яратып укылалар».

Поэзия үрнәкләреннән беренче удмурт шагыйрәсе Ашальчи Ока (Л. Векшина) әсәрләре татар телендә дөнья күрде. Заманында Казан рабфагында укып, татар халкына дуслык җепләре белән бәйләнгән бу талантлы шагыйрәнең «Юл буенда», «Мин хәтерлим», «Сорадың син миннән» исемле лирик шигырьләрен Зәки Нури тәрҗемә итте. М. Петровның «Дусларга», «Кояш», «Эх, син, йөрәк» исемле шигырьләрен шагыйрь Хәсән Туфан тәрҗемә итеп татар халкына ирештерде. М. Покчи-Петровның «Чыршы» шигыре шулай ук Хәсән Туфан тәрҗемәсендә чыкты. Р. Гәрәй Н. Байтирәковның «Варзи» исемле һәм С. Широбоковның «Россия» шигырьләрен татар телендә бастырды. Татарстан пионерлары газетасы удмурт балалар язучысы Г. Ходыревның М. Шабаев тәрҗемә иткән күп кенә шигырьләрен урнаштырды. Болардан тыш, А. Бутолин, И. Гаврилов әсәрләрен дә татар дусларыбыз үз ана телләрендә укыйлар.

Бу мәкаләнең авторы тарафыннан язылып, «Казан утлары» журналында һәм «Социалистик Татарстан» газетасында басылган ике мәкалә буенча, татар укучылары удмурт әдәбиятының тарихы һәм бүгенге хәле турында кайбер мәгълүматлар алдылар.

Тугандаш халыкларның әдәби хәзинәсен удмурт халкына җиткерү эшен башлыча «Молот» журналы оештырып килә. Бу эш соңгы елларда тагын да җанланды һәм журнал битләрендә татар әдәбиятының яңадан-яңа үрнәкләре басылып чыкты. Удмурт укучылары Х. Туфан, Ә. Фәйзи, С. Хәким, Ә. Ерикәй, С. Баттал, Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдова, И. Юзеев, С. Шакир, М. Фәйзуллиналарның яңа шигырьләре белән таныштылар. Проза әсәрләреннән Г. Бәшировның «Кунак егете», Г. Галиевның «Дуслык», А. Шамовның «Хисаметдин абзый», Н. Фәттахның «Хәйләкәр» исемле хикәяләре удмурт матбугатында урын алды. Соңгы елларда тәрҗемә эшенә яңадан-яңа әдипләребез тартыла. И. Гаврилов, С. Широбоков, Г. Туганов, А. Лужанин, Г. Ходырев кебек әдипләребез дә татарчадан тәрҗемә итү буенча шактый тәҗрибә тупладылар.

Дуслык элемтәләрен ныгытуның төрле юллары бар. Соңгы елларда татар язучыларыннан Г. Әпсәләмов, М. Садри, Х. Туфан, бездә кунакта булып, күп кенә очрашулар уздырдылар, халык алдында үзләренең дулкынландыргыч әсәрләрен укыдылар. Мондый очрашулар, әлбәттә, ызандаш ике халыкның тагын да якынлашуына таба зур этәргеч ясый, культура, әдәбият, сәнгать элемтәләрен, дуслык җепләрен ныгыта. Тик андый иҗади очрашуларны тагын да ешайта төшәргә кирәк. Һәм без сезгә— татар дусларыбызга чын күңелдән кабатлап әйтәбез:

— Түрдән рәхим итегез, күршеләр! Рухи байлыгыбыз, милли хәзинәбез уртак булсын!

**Ф. ЕРМАКОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

**Валерий Шнайдер,**
Казан кинохроника студиясенең баш редакторы

# КУЛЫНДА КИНОКАМЕРА...



Казан кинохроника студиясе работниклары еллык иҗади конференция үткәргәндә 1971 елның иҗади йомгаклары тикшерелде һәм алдагы елда документаль кино тикшерүчеләр алдында торган бурычлар билгеләнде. Бу конференциягә партия оешмалары вәкилләре, республиканың иҗади оешмалары вәкилләре, кинофикация һәм кинопрокат җитәкчеләре, телевидение работниклары һәм заводлардан вәкилләр чакырылган иде. Конференцияне болай киң катлау кешеләр белән берлектә уздыру үзе үк безнең эшебезгә — кино эшенә никадәр әһәмият бирелүе, барыннан да элек безнең өскә никадәр җаваплылык төшүе турында сөйләп тора.

Быелгы ел безнең барыбыз өчен дә күренекле ел. Быел без Дәүләтебезнең — Совет Социалистик Республикалар Союзының 50 еллыгын бәйрәм итәбез. Безнең алда, кинодокументалистлар буларак, КПССның егерме дүртенче съездының тарихи карарларын уңышлы үтәп баручы совет халкының батыр хезмәтен экранда тулы һәм тирән итеп яктырту буенча зур бурычлар тора. Киностудия бу юнәлештә ел башында ук төзелгән конкрет план нигезендә максатка омтылышлы эш алып бара.

Тупланган тәҗрибәне иләп карарга һәм безнең әзләнүләрдә нәрсәләрнең илак өстендә көрпә булып файдасызга калуын, нинди кинотасмаларның игътибарга лаек булуын, үстерергә кирәклеген билгеләргә һәм, ниһаять, киноинформациянең нәрсә булуы турында, киносюжетның ничек тикшерелүе һәм төрле берничә сюжеттан җыелган киножурналның нинди эчтәлекле булуы, диктор тексты һәм киносценарийларның ничек язылуы турында ачыктан-ачык төпле итеп сөйләшергә вакыт җиткән иде инде. Моны бездән бүгенге көннең алдыбызга куйган югары бурычлары таләп итә. Шуңа күрә бөтен игътибарны документаль кино төшерүнең методологик мәсьәләләренә, аны ничек яхшырту һәм камилләштерү мәсьәләләренә юнәлтергә кирәк. Хәзер Казан киностудиясе тиешле югарылыктагы кино техникасы һәм җиһазлары белән тулысынча тәэмин ителгән, кинооператорларның һәм режиссерларның алда торган бурычларны тулысы белән үтәп чыгарлык профессиональ осталыгы бар.

Шунлыктан бүген куелган төп мәсьәлә — осталык мәсьәләсе. Чыннан да, көндәлек эшебездә без ленинчыл идеяләрне актив пропагандалаучыларның сугышчан сыйфатларын булдыра алдыкмы, әллә арттарак сөйрәләбезме? Кинодокументалистлар бүген тормыш күренешләрен кинотасмага теркәп, тезеп кенә баручымы, вакыйгаларны фотога гына төшерүчеме, әллә сугышчан партияле кинопублицистлармы? Бүген илебезнең һәр почмагында, тугызынчы бишьеллыкның зур һәм куәтле төзелешләрендә әлегә кадәр күрелмәгәнчә тизлек белән хезмәт кайнаганда кулына кинокамера тоткан кешенең — кинооператорның роле бик зур. Чөнки ул бүгенге

экран өчен генә түгел, ә киләчәк буыннар экраны өчен дә эшли һәм шуңа күрә аның өстенә икеләтә бурыч йөкләнә.

Үткән елгы иҗади эш йомгакларына әнә шушы күзлектән чыгып бәя бирелде. Үткән ел Казан киностудиясе фильмнар һәм журналлар чыгару буенча производство планын тулысынча үтәде. Алты кисәктән торган дүрт документаль фильм, заказ буенча эшләнгән унбер кисәкле биш фильм, Бөтенсоюз сатира журналы — «Фитиль» өчен зур сюжет, Мәскәүдәге үзәк студия өчен без хезмәт күрсәткән республикалар тормышыннан биш сюжет, 150 метрлы ике заказ ролик, рус, татар һәм чуваш телләрендә 36 киножурнал эшләп чыгарды. Моңа тагын башкорт, татар, чуваш, мари, удмурт телләренә тәрҗемә ителгән 70 нәфис фильмны да өстәргә кирәк.

Үткән елдагы эшне яхшылап тикшереп чыккач, булган уңай һәм кимчелек яклар бик тиз күзгә ташлана. Мәсәлән, «Кощак» совхозындагы эксперимент» дигән документаль фильм бик тизлек белән эшләнде — аны төшерү, монтажлау эшләре өчен нибары ун көн кирәк булды. Фильмнар төшерү буенча Мәскәүдәге Баш идарә (РСФСР кинокомитеты каршындагы) бу фильмны беренче күрсәтүдән үк кабул итте һәм ул, күбәйтелеп, федерациянең төрле өлкәләренә озатылды. Фильмның авторлары Х. Фәхретдинов, М. Хөснимәрдәнов, Э. Заһидуллин бу ун минутлык кинотасмада республика авыл хуҗалыгының мөһим һәм перспективалы тармагы — кролик асрауның үсеше турында, Татарстан кролик асраучыларының КПССның егерме дүртенче съезды куйган бурычларны үтәүгә керткән өлешләре турында документаль экран теле белән оста һәм үтемле итеп сөйли алганнар.

Үткән елның икенче фильмы халкыбызның яраткан композиторы Салих Сәйдәшевнең образын экранлаштыру бурычын куйган иде. Фильм авторлары — режиссер Ш. Сарымсаков, кинооператорлар Е. Афанасьев һәм В. Кузьмин бу бурычны намус белән үтәп чыктылар. Экраннарга Татарстанның танылган композиторы турында дулкынланып сөйләгән беренче фильм чыкты. Республикабыз җәмәгатьчелеге тарафыннан ул яратып каршыланды.

Мари терлекчеләренең алдынгы тәҗрибәсе, әһәмиятле актуаль тема буларак, «Мари терлекчеләре янында» дигән фильм өчен нигез булып чыкты. Сценарий авторы В. Байдерин, режиссерлар Н. Лебедев, В. Стрелков тарафыннан эшләнгән бу фильмда механикалаштырылган терлекчелек комплекслары — чын мәгънәсендә ит, сөт, йомырка фабрикалары төзү, авыл хуҗалыгын индустрияләштерү нигезендә авыл эшчәннәренең тормышында һәм аңындагы үзгәрешләр турында сөйләнелә.

Тугызынчы бишьеллыкның зур төзелешләреннән берсе — Кама автомобиль заводы төзелеше. Беренче таш салганнан башлап Казан киностудиясе автогигант төзелешенең барышын системалы рәвештә кинокамера күзәтүе астына алды. Үткән елның соңгы кварталында режиссер Д. Дальский, оператор В. Алабердин тарафыннан төшерелгән «Батыр төзелә» дигән документаль фильм союз күләмендәге экраннарга тапшырылды. Кинорепортаж рухында төшерелгән тасмалар завод төзелеше турында, аны төзүчеләрнең язмышлары турында сөйлиләр. Экранда чагыла торган кадрлар яшьләребезне КамАЗ төзелешенә эшкә барырга ялкынлы чакыру белән өндиләр.

Болардан тыш Казан киностудиясе цехларында төрле учреждениеләр һәм ведомстволар тарафыннан бирелгән заказ буенча эшләнгән берничә фильм бар. Шулар арасында иң әһәмиятлеләре — «Евфрат елгасында гидроузел», «Асуан яктылык бирә» дигән төсле фильмнар. Алар һәр икесе дә Мисыр Гарәп Республикасында төшерелделәр һәм уңышлы эшләнеше өчен СССР Министрлар Советы каршындагы кинематография комитеты тарафыннан билгеләп үтелделәр һәм югары бәя алдылар. Һәр ике фильм да бер үк режиссер-оператор В. Вайда тарафыннан төшерелде. Алар югары профессиональ дәрәҗәдә эшләнүләре белән аерылып торалар.

Нәфис фильмнарны төрле телләргә тәрҗемә итү кебек шактый катлаулы һәм мәшәкатьле булган эшне Казан киностудиясе работниклары яхшы үзләштерделәр. Дубляж эшендә катнашучы милли актерларның осталыгы ел саен камилләшә бара. Алар үзебездә үк инде нәфис фильмнар төшерә башлауга иҗади мөмкинлекләре белән тулысынча хәзер. Үткән ел студия татар, башкорт, чуваш, мари, удмурт телләренә 70 нәфис фильм тәрҗемә итте. Автономияле республикаларның кинопрокат конторалары тарафыннан бу фильмнарның күпчелеге беренче категория билгесе белән кабул ителде.

Ай саен өчәр тапкыр рус, татар, чуваш телләрендә чыгып бара торган «Идел киңлекләрендә» киножурналының эчтәлеге бүгенге көннең төп темасын — КПССның егерме дүртенче съезды карарларының тормышка ашырыла баруын яктырта. Шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәренең хезмәт вахтасы, совет кешеләренең хезмәт һәм революцион традициясе, Идел бу милли республикаларының культура һәм хуҗалык тормышында ирешкән уңышлары киножурналга төшерелгән сюжетларның төп эчтәлеген тәшкил итә. Редакция тарафыннан КПССның егерме дүртенче съезды карарларын пропагандалау буенча махсус план төзелде һәм ул план урында партия һәм совет органнары тарафыннан яхшы дип табылды. Шушы максатлардан чыгып Яр Чаллыда — автогигант төзелешенең нәкъ үзендә аерым кинокорреспондентлык пункты төзелде. Бу пункт үзен аклады. Үз теләге белән Кама автозаводы төзелешенә киткән кинооператор В. Алабердин үткән ел кырыкка якын сюжет төшереп җибәрде һәм аларның күбесе «Идел киңлекләрендә» киножурналында иң беренчеләрдән булып тамашачыга җиткерелделәр.

«Идел киңлекләрендә» киножурналының махсус һәм тематик саннары эчтәлеге белән күп төрле. Шуларның иң уңышлы дип саналганнары түбәндәгеләр: «Кощак» совхозындагы эксперимент», «Миллиард тонна нефть», Мордовия республикасының иң алдынгы сыер савучысы Мария Сивцова турында сөйләгән киножурнал, Казан төзүчеләренә багышланган кинотасмалар, КамАЗ төзелешен яктырткан ике киножурнал, җыелма сюжетлардан торган киножурналлар арасында иң уңышлылардан дип 18, 36 нчы саннарны әйтергә мөмкин.

Җыелма сюжетлардан торган киножурнал безнең продукциянең төп формасы иде һәм ул шулай булып кала да. Бу җыелма киножурналларда Идел буендагы без хезмәт күрсәтә торган дүрт милли республика тормышын чагылдырган төрле сюжетлар туплана. Илебезнең барлык документаль студияләрендә киножурналларның бүгенге йөзе турында бәхәс бара, төрле юллар һәм формалар эзләнә. Турысын әйтергә кирәк, әле безнең киножурналларда без теләгәннәрнең һәммәсе дә диярлек күренми. Кайберәүләр бүгенге көн таләпләреннән чыгып җыелма киножурналлардан баш тартырга кирәк, дисәләр, икенче берәүләр моңа каршы төшәләр. Җыелма киножурналга каршы төшүчеләр үз позицияләрен телевидение вакыйгаларны тизрәк һәм оператив күрсәтә бара, дип нигезлиләр. Шунлыктан җыелма киножурналларның формасы үзгәрә, журналларга авторлар тарафыннан озын-озын сюжетлар кертелә башлады. Режиссерлар һәм операторлар тематик һәм махсус киножурналлар ясауга омтылдылар. Шунлыктан киножурналларда кыска, сугышчан һәм үтемле сюжетлар урынына бүгенге көн бурычларына бик үк җавап бирми торган кинотасмалар урын ала башлады. Аларны сюжет дип тә, фильм дип тә атарга мөмкин түгел. Шулай итеп, кинохроника телевидение белән иҗади ярышта көрәш кырын калдырып китү омтылышы белән «чирләде».

Ләкин җыелма киножурнал безнең илдә дә, чит илләрдә дә яши, үз бурычын үти. Аның эчтәлеге турында гына ныклап уйлыйсы бар, сюжетлар төшерүгә иҗади якын килергә, профессиональ осталыкны күтәрә барырга кирәк. Киножурналга керерлек, аңа сюжет булырлык нинди темалар бар? Безнеңчә, һәр тема сюжет була ала. Сорауны бары тик «нәрсә?» дип түгел, ә «ничек?» дип куярга кирәк. Җыелма киножурнал вакыйгалар барышын төшергән сюжетлардан башка була аламы? Әлбәттә, юк. Кеше портретыннан, информациядән башка да журнал була алмый.

Иң мөһиме шунда — ул информация ничек бирелә. Әгәр экранда бирелгән информациядә тамашачы үзен күрсә, үзенең иптәшләрен таныса, үзенең туган якларына әйләнеп кайтса һәм, ниһаять, ул информация бүгенге көннең төп сыйфатларын бирсә — андый сюжет җыелма киножурналда урын алырга тулысы белән хаклы һәм ул зур игътибар белән карала да. Мәсьәләне шулай куйганда җыелма киножурналларда һәртөрле теманың урын алырга хакы бар. Һәм бу очракта автороператорның, сугышчан пропагандист буларак, фактларга иҗади якын килүе, уйлана белүе бик мөһим. Кулына кинокамера алган кеше тормышны, чынбарлыкны күзгә кебек күрсәтергә омтылырга тиеш түгел, ә аларны бүгенге көн позицияләреннән чыгып, партия-дәүләт күзлегеннән карап фикерләп тамашачыга җиткерергә омтылырга тиеш. Мәсьәләне шулай куйганда телевидение белән кинодокументалистлар арасында нинди көндәшлек булуы турында сөйләп торырга да кирәк булмая-

чак. Телевидение информация бирсә, кинопублицист ул информациянең образын тудыра һәм тамашачыга җиткерә. Публицистиканың мәгънәсе, билгеле булганча, «актуаль», «көн кадагына сугу» дигән төшенчәләр белән генә чикләнми. Аның көче — күтәрелгән теманың иҗтимагый әһәмиятендә, теманың фикер көчендә, фактларның эчке мәгънәсен ача белүдә, шул фактлар белән бүгенге көн күренешләрен ачыклый белүдә. Иң көчле чагылдыручы художество алымнары да, оста итеп башкарылган кинооператор эше дә, әгәр алар артында тирән акыллы яңа фикер юк икән, көчсез булып кала. Күптән билгеле әйбер булса да, тагын бер тапкыр кабатламый булмый: тормыш факты экранда көзгедәге кебек күрсәтүне түгел, ә фәлсәфи фикерләүне таләп итә.

Чын мәгънәсендәге публицист фактлар белән идарә итә белергә, аларны образлы сафка бастырырга һәм төп политик бурычка буйсындыра алырга тиеш. Биредә аңа фактларны һәм документларны сайлап алу һәм һәрьяклап уйланган, төп бурычларга буйсындырылган чагылдыру чараларын сайлап алу ысулы булышлык итә.

Шушы фикерләрне ныгыту өчен тагын КамАЗга әйләнеп килик. Без инде әйткән идек, Казан киностудиясе анда беренче таш салганнан башлап киноелъязмасы алып бара. Үткән ел төшерелгән сюжетлардан тыш шул төзелеш җирлегендә дүрт махсус киножурнал һәм бер фильм эшләнде. Студиянең киноархивында КамАЗ төзелешеннән төшерелгән бай материал бар. Ул фонд һаман арта тора. Болар, әлбәттә, әле сан ягыннан гына үсеш дигән сүз. Хәзер КамАЗда, образлы итеп әйтсәк, бөек төзелешнең иртәсе. Биредә бит яңадан-яңа объектлар төзелеше генә түгел, биредә эшче коллективлар, яңа кеше шәхес буларак формалаша. Әгәр дә кулына кинокамера тоткан кеше әнә шул бөек төзелеш иртәсенең рухы белән яшәмәсә, әгәр дә анда эшләнгән эшләр аның өчен якын һәм кадерле булып тоелмаса, әгәр дә ул үзен шул төзелешнең тулы хокуклы катнашучысы итеп тоймаса — аңа киносюжетлар өчен геройларны кайдан эзләргә һәм нинди геройларны кинотасмага төшерергә кирәклеген беркем дә әйтеп тормас.

Кинодокументалистика тарихында моңа мисаллар күп. Братск ГЭСы төзелешен экранда тулы яктыртып барган өчен Иркутск киностудиясе югары бәягә лаек булды. Төзелеш беткәч югары хөкүмәт бүләге белән бүләкләнүче төзүчеләр арасында кинооператор фамилиясе дә бар иде. Указда «...төзелештә актив катнашканы өчен» дип язылган иде. Бу кинооператорның фамилиясе Петр Артемьевич Петров. Киночылар арасыннан берсе дә төзелешне, аның нәрсә белән сулаганын, нәрсә белән яшәгәнен кинооператор Петров кадәр белмиләр иде. Ул, иҗат кешесе буларак, Братск ГЭСын актив төзүчеләр рәтендә йөрде. Аны ул үзенең сугышчан коралы — кинокамерасы белән төзеште. Художник өчен шуннан да изгерәк бурыч бар микән?

Әлбәттә, теге яки бу иҗади работникны приказ тәртибендә аерым төзелешкә беркетергә була. Ләкин безнең кинооператор Леонид Васильевич Барышевны бернинди приказ белән дә билгеләмәгәннәр. Ул Татарстанда нефть чыга башлаганнан бирле нефтьчеләр тормышын чагылдырган сюжетлар төшерде. Билгеле, ул һәр вакыт режиссерлар, редакторлар белән киңәшә иде, ләкин аның һәрчак үз фикере бар иде, һәрвакыт актив рәвештә үзенең иҗади тәкъдимнәре белән килер иде. Кайбер операторлар трибунага чыгалар да «миңа тема бирегез, аны ничек төшерергә кирәклеген, кемне төшерергә кирәклеген әйтегез — шул чакта мин аны барам да төшерәм», дип күкрәк сугалар. һәм кинохроникада төп фигура булган автор-операторның, сугышчан публицист булырга тиешле кешенең шулай дип белдерүе бик кызганыч, әлбәттә. Иң гаҗәбе һәм иң куркынычлы ягы да шунда — мондый авторларның, төп иҗади багажларында фикер ялкаулыгы тутырып йөрткән кинохроникерларның позициясен кайбер тәҗрибәле работниклар да яклыйлар, уртаклашалар. Әгәр дә газетада яки журналда эшләүче журналист «миңа тема бирегез, аның кайда икәнлеген күрсәтегез, ничек язарга икәнен әйтегез, шуннан соң мин язармын» дисә; мондый журналистның газета редакциясендә эшләве кирәк булыр идеме икән? Әлбәттә, аңа анда урын булмас иде.

Кулына кинокамера тоткан кеше дә үз темасының авторы булырга тиеш. Ә редактор, режиссер аңа киңәш бирә, юл күрсәтә.

Бигрәк тә яшь кинооператорлар арасында булган әнә шундый фикер ялкаулыгын акларга тырышу, гадәткә кергән шаблоннан баш тартасы килмәү темаларны

иҗади итәсе урынга уйланып-нитеп тормаган коры иллюстрациягә алып килә дә инде. Экранда матур-матур «картинкә»ләр чыга, яки тимер-бетоннан коелган сюжетлар урын ала. Моның сәбәпләре нәрсәдә соң?

Чөнки ул иҗатта бик җиңел юл. Икенчедән, ул тормыш дөреслеген чагылдыргандай була. Ләкин ныклабрак уйлап карасаң, әнә шул кинооператор искергән алымнар белән төшергән «тәти» кадрлар иллюстрациянең төп асылын тәшкил итәләр. Документаль кино төшерүнең кайсыдыр баскычында, ихтимал, бу ысул үзен аклагандыр. Чөнки иллюстрация дә тамашачыны чынбарлыктагы фактлар белән таныштыра, бу юнәлештә үзенең танып белү функциясен үти дигән сүз. Ләкин бу ысул үз чиратында художникны өстән-өстән генә «йөзәргә» этәрә, аның өчен фактларны санап китү, аның сыйфатын әйтү, гомуми генә бәяләү җитә, ә аларның мәгънәсен ачып бирү ничектер читтә кала. Коры иллюстрациянең куркынычы шунда — ул сугышчан публицистика иллюзиясе тудыра. Чөнки тема декларация белән чикләнә, һәм шушыннан инде залда утыручы тамашачының экранда бара торган фактларга, вакыйгаларга ваемсыз карашы килеп туа. Безнең кинохроника практикасында шундый очраклар да була: автор үзен сугышчан партияле публицист дип хис итә, ә чынлыкта исә ул нәкъ менә коры иллюстрация белән шөгыльләнә, үзе экраннан әйткән сүзгә, күрсәткән кадрга ышанырга куша, ә үзенең фикеренә һәм хисләренә чын художникларча ияртеп алып китми. Мондый позиция көчле каршылыкка очрамый, ләкин ул дөрес түгел, чөнки инде документаль кинода бу күптән искерде. Иллюстрация ысулы документаль киноның балалык чоры иде. Хәзер инде балалык чоры күптән үткән. Татарстанда гына да кинохроника яши башлаганга быел 1 апрельдә кырык ел тулды.

Кулларына кинокамера алган безнең кайбер иптәшләребез иллюстрация алымындагы тагын бер куркынычны аңлап бетермиләр: бу алым белән киного төшерү үзең утырган ботакны үзең кисү белән бер. Чөнки төп иҗади фигура — автор-оператор тарафыннан төшерелгән кадрлар иллюстрация алымы белән эшләнгәннәр икән, бернинди редактор да, бернинди режиссер да аны инде эш процессында төзәтә алмый. Ул сюжетны я кәрзингә ташларга, я, автор белән килешеп, ул барган җиңел юлдан барып, сюжетны журналга куярга туры килә. Яхшы язылган диктор тексты да, әйбәт эшләнгән музыка да фикер сайлыгын тутыра алмый.

Образ һәрвакыт киңрәк, иллюстрациядән тирәнрәк була. Образ тудырганда сайлап алынган фактларның һәрвакыт үзләренең эмоциональ буяулары була. Образ һәрвакыт эчтәлекле һәм шуңа күрә дә иллюстрациягә караганда аның йогынтысы көчлерәк. Ул информация биреп кенә калмый, тамашачының фикер йөртешен активлаштыра һәм безнең бүгенге көн бурычлары нәкъ менә шуннан гыйбарәт тә. Шунлыктан кулына кинокамера тоткан кешенең — кинооператорның әзер шаблоннар белән генә эшләве, үз профессиясенә карата таләпчән булмавы һич тә гафу итәлә торган сыйфат түгел. Кинокамера хуҗасы фактлардан курыкмыйча, аларны әлегә кадәр эшләнгән калыпларга көчләп тутырмыйча, аларны бәяли белергә партия һәм халык алдында гражданин, художник буларак бөтен җаваплылыкны тоеп, безнең идеяләребезне сугышчан пропагандалаучы позициясеннән торып художестволы образларны үз талантының коралы итә белергә тиеш. Кулыңа кинокамера тотып тормыш фактлары уртасына ташландыңмы, коллектив яки бер кеше тормышы турында сөйләп бирергә җыендыңмы — син инде, кинооператор буларак, үз өстеңә бик зур җаваплылык алдың дигән сүз. Телисеңме, юкмы, камерадан чыгып экранга күчкән материалыңдагы фактка син дәүләт күзлегеннән чыгып бәя биргән буласың.

Кулына кинокамера тоткан кешедә аерылгысыз бер сыйфат юлдаш була: тормыш фактлары нинди генә булмасын, ул алар белән очрашырга әзер булырга тиеш. «Әзер» дигән сүз артында кыска һәм озын фокуслы оптиканың тулы комплекты яисә запас пленка булдыру гына ятмый, билгеле. Тормыштагы фактны, фактлар суммасын безнең идеяләр күзлегеннән күрергә, аларны сайлый белергә, безнең тормышыбызны билгеләүче, чынбарлыгыбызны яктыртучы төп моментларны алгы планга куярга һәм шуның белән яңалыкны расларга, безгә чит булган, комачаулый торган күренешләрне фаш итәргә — кинооператор өчен иң әһәмиятлесе шунда. Җыелма киножурналлар өчен сюжетлар төшерергә алынган кинооператорның төп позицияләре әнә шундый.

* * *

Безнең продукциянең төп формасы булган җыелма киножурналлар кинохроника студиясендә махсус һәм тематик киножурналлар эшләүгә һич тә комачауламый. Шушы уңай белән документаль кинода төп әдәби нигез булган сценарий турында да фикер алышасы килә. Күп очракта киножурналларның махсус һәм тематик саннары өчен һәм документаль фильмнар өчен дә сценарийлар бик өстән-өстән генә язылалар. Документаль кино буенча танылган сценарист Горохов бер интервью вакытында болай дигән: «...Без «колхоз турында», «завод турында», «шәһәрләр турында», «алдынгылар турында» кино төшерәбез. Кыскасы, тормышның өске катлавында нәрсә ята, шуларның бөтенесе турында да... Мондый әсәрләрнең драматургиясенә хас булган бер сүз бар: «сүз уңаенда»... Мәсәлән, Н. шәһәрендә театр бар. Сүз уңаенда әйтеп китик, стадион һәм завод та бар. Сүз уңаенда гына әйтеп китик, ул заводта хезмәт алдынгысы эшли, аның өендә телевизоры бар... һәм башкалар...»

Бу сүзләр тулысы белән безнең эшебезгә дә турыдан-туры кагыла. Чыннан да Волжск һәм Чабаксар шәһәрләре турында эшләнгән махсус киножурналлар һәм Идел буе республикаларының ярты гасырлык юбилейларына багышланган фильмнарның сценарийлары нәкъ менә шундый стильдә язылганнар. Бу сценарийларның йомшак булуы барыннан да элек аларның әдәби яктан йомшак нигезгә корылуларында. Дөрес, алар тормыштагы реаль фактлардан файдаланып язылганнар. Ә фактларга нигезләнгән документаль кинода драматургиягә урын юкмы әллә? Бар, әлбәттә. Документаль студияләр тарихында драматургия ягыннан оста эшләнгән бик күп фильмнарны санап китәргә була. «Вахта», «Комдагы замоклар», «Гадәти фашизм» дигән фильмнар, мәсәлән, кеше характерын чагылдыру, кызыклы һәм гыйбрәтле фикерләр уятулары белән тамашачыда йогынтылы тәэсир калдырдылар. «Гадәти фашизм» фильмы политик памфлет, сугышчан публицистиканың югары үрнәге буларак тамашачының игътибарын казанды. Безнең студиядә эшләнгән «Эрзя», «176 нчы буровой» дигән документаль тасмаларда нәкъ менә фактларны драматик үсештә бирергә омтылыш сизелә.

Барыннан да элек, моның өчен тормыш фактлары арасында үзеңә кайнарга, алар белән яшәргә, аларның һәркайсына үз бәяңне билгеләргә, Вертов әйтмешли, «кечкенә фактикларны» түгел, фактлар тавын күрә белергә кирәк. Югыйсә, безнең кайбер сценаристларыбыз бер тапкыр да КамАЗ төзелешендә булмыйча, аның сулышы белән суламыйча сценарийлар яудыра башладылар. Тормыштагы фактларны иҗади оештырганда һәм аларны кино драматургиясе кануннары буенча сценарийга салганда гына сценарийны фильмның нигезе дип санарга була. Әдәби эшләнгән киносценарийларга шундый таләп куйганда гына булачак фильмнарның уңышлы барып чыгачагына ышанырга мөмкин.

Документаль фильмда диктор тексты әһәмиятле урын алып тора. Югарыда санап үтелгән таләпләр тулысы белән диктор текстына да кагыла. Текст фильм өчен языламы, журнал яки аерым бер сюжет өченме — барыбер ул кинодраматургия кануннары нигезендә язылырга тиеш: комментарий биреп кенә калмаска, ә экранда күргән кадрларның кешенең аңына барып җитүенә булышырга — диктор текстының төп бурычы әнә шул.

Бөтенсоюз Дәүләт кино институтында ясаган лекцияләренең берсендә Довженко болай дигән иде: «...Минем эш тәҗрибәм шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирде: фильмның сыйфаты нигезендә сүз ята, аннан соң фикергә буйсындырылган монтаж бара. Нәрсә генә әйтсәң дә фильмны монтажлаганда ук инде безнең күңелдә булачак фильмның тексты туа бара. Бик катлаулы процесс бу. Әйтерсең лә пар атта чабасың. Алар бер-берсен узарга тырышалар. Башта һәммәсе дә материалда бара, аннан сүз китә, әйтәсе килгән фикер сүзгә күчеп, монтажны куып җитеп узып китә».

Төптәнрәк уйлап карасаң, практикадан чыгып әйтелгән бу сүзләрдә бүген диктор тексты алдына куелган таләпләр бик ачык һәм образлы итеп күрсәтелгәннәр.

Сюжетка языла торган диктор тексты берничә җөмләдән генә тора. Ләкин монда да үзенең драматургиясе була. Тагын бер мисал китереп үтик. Сюжет өчен языла торган текстның нинди принципта язылырга тиешлеген ул ачыклап китәр.

Илебез студияләренең берсендә көймәче карт турында сюжет төшерәләр. Ул

яшьтән үк сәламәтлеккә туймаган һәм кырык елга якын беркая бармыйча көймәсе белән кешеләрне елга аша чыгарып торган. Сюжет традиция буенча төшерелгән: киң себер елгасы, кешеләр елганың бер ярында көймәгә утыралар, икенче ярда төшәләр. Эре планда көймәче карт, аның йөзе, куллары... Елгадагы дулкыннар...

Бераз вакыттан соң студия бу сюжетны җыелма киножурналга кертә һәм бу журнал фестивальдә күрсәтелә. Ә көймәче карт турындагы сюжет кеше портретын бөтен тирәнлеге белән күрсәтүче сюжет буларак беренче бүләкне ала. Ул сюжетка менә нинди диктор тексты язылган була:

«...Т е г е  я к к а — Ленинга баручы йомышчыларны,

Б у  я к к а — колхозга.

Т е г е  я к к а — укырга китүчеләрне,

Б у  я к к а — агрономнар һәм зоотехникларны.

Т е г е  я к к а — таза дүрт яшь егетне,

Б у  я к к а — култык таягына таянган һәм орденнар таккан кешене.

Т е г е  я к к а — балаларны,

Б у  я к к а — оныкларны.

Кырык ел. Һәр көн. Теге якка һәм бу якка. Бүген теге якка соңгы тапкыр. Пенсия документлары алу өчен. Ә бу якка — «Ракетада».

Бу текст кемгәдер ошарга, кемгәдер ошамаска мөмкин. Ләкин принципта ул дөрес корылган.

* * *

Без быел бөтен совет халкы белән берлектә СССР төзелүгә 50 ел тулуны билгеләп үтәбез. Казан киностудиясе Идел буендагы дүрт милли республикага хезмәт күрсәтә. Бу республикалар мисалында без ленинчыл милли политиканың тормышка ашырылуын аермачык күрәбез. 50 ел эчендә бу республикалар халык хуҗалыгының бөтен тармаклары, фән һәм сәнгать өлкәсендә бик нык алга киттеләр. Кулына кинокамера тоткан кеше өчен, иҗат эше өчен никадәр киң мәйдан монда. Темаларның күплегеннән, аларның киңлегеннән һәм тирәнлегеннән югалып калмыйча фактларны фәлсәфи яктан гомумиләштереп, безнең идеяләребезне сугышчан пропагандалаучы сафында атларга кирәк. Һәр яңалык турында коры хәбәр генә бирел калмаска, ә һәр сюжетта, һәр киножурналда, фильмда, һәр диктор текстында партиябез политикасының тормышка ашуы, экранда күрсәтелә торган һәр вакыйгада безнең идеяләребез, тормышка булган мөнәсәбәтебез ачык чагылырга тиеш.

Кулына кинокамера тоткан кеше алдында торган җаваплылыкның төп сызыклары әнә шундый.

**Казбек Гыйззәтов,**
философия фәннәре кандидаты

# ЛЕНИННЫҢ ЧАГЫЛЫШ ТЕОРИЯСЕ ҺӘМ ХУДОЖНИКНЫҢ АКТИВЛЫГЫ

Башка рухи күренешләр кебек, сәнгатьнең асылын аңлау да философиянең төп мәсьәләсен дөрес хәл итү белән бәйләнгән. Материалистик позицияләрдә торып фикер йөрткәндә, рухи якны материаль якның продукты дип карамыйча булмый.

К. Маркс: «Идеаль як кеше башына күчереп утыртылган һәм анда үзгәртелгән материаль як кына ул, бүтән нәрсә түгел»,— дип язган. (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Рус телендә. 23 том. 21 бит.) «Безнең тойгыларыбыз, безнең аңыбыз,— ди В. И. Ленин,— тышкы дөньяның **сурәте** генә, һәм үзеннән-үзе аңлашыла ки, сурәтнең сурәтләнүчесез булуы мөмкин түгел». (В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 14 том. 64 бит.) Шуннан сәнгать, иҗтимагый аңның бер формасы буларак, реаль дөньяның сурәте, чагылышы гына дигән нәтиҗә килеп чыга. Башкача әйткәндә, реаль дөнья булмаса, сәнгать тә булмас иде.

Ленинның чагылыш теориясе сәнгатьнең асылын, аның кешелек җәмгыяте тормышындагы объектив ролен дөрес бәяләүдә методологик һәм теоретик нигез булып тора. Ул сәнгатьнең танып-белү функциясен, художество процессында субъектив факторның тоткан урынын ачып бирә. Ул шулай ук сәнгать әсәрләренең эчтәлегендә объектив чынбарлыкның хәлиткеч роль уйнавын фәнни нигезли. Ленинның чагылыш теориясе художникка кешене рухи яктан баета, иҗтимагый прогресс өчен көрәшкә рухландыра торган әсәрләр иҗат итү өчен кирәкле ачкыч бирә.

Чагылыш теориясенең дошманнары һәм аны юкка чыгарырга азапланучылар: сәнгать әсәрен реаль дөньяның, объектив чынбарлыкның сурәте дип карау художникның ролен инкарь итүгә китерә, иҗат практикасында бу шаблонга, схемага алып бара, художникны индивидуальлектән мәхрүм итә, диләр.

Чынлыкта исә һич алай түгел. Сәнгатьнең реаль чынбарлыкны чагылдыра алу сәләтен һәм иҗат процессында объектив дөньяның хәлиткеч роль уйнавын тану һич тә әле художникның активлыгын инкарь итми. Танып-белү процессында объектив һәм субъектив факторларның диалектикасына тукталып, В. И. Ленин болай ди: «Кешенең аңы объектив дөньяны чагылдырып кына калмый, бәлки аны иҗат та итә». (В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 38 том. 213 бит.)

Художество иҗаты — аңлы, максатчан характерлы процесс. Әлбәттә, иҗат процессында художникның интуициясе мәгълүм урын тота. Интуиция илһам дип аталган аерым бер психик халәт туугa сәбәп була. Бу гаҗәеп халәт турында А. С. Пушкин болай язган:

И мысли в голове волнуются в отваге,
И рифмы легкие навстречу им бегут.
И пальцы просятся к перу, перо —
к бумаге,
Минута — и стихи свободно потекут.

Иҗат процессында башка төр сәнгать кешеләре дә шуңа охшаш халәт кичерәләр. Фон Мекка язган хатларының берсендә Чайковский: «Башыма төп фикер килгән һәм ул мәгълүм формалар алып үсә башлаган мизгелдә үземдә туган чиксез рәхәтлекне Сезгә сүзләр белән генә аңлатырга тырышу файдасыз булыр иде. Һәммә нәрсәне онытасың, бөтенләй акылдан язган кеше хәленә киләсең, эчтәге бөтен нәрсәң дулкынлана һәм тыпырчына, эскизларны сызарга чак-чак өлгерәсең, фикерләр бер-берсен ашыктыралар»,— ди.

Шулай булуга да карамастан, күренекле сәнгать осталары үзләре үк икърар иткәнчә, иҗат процессында интуитив башлангыч өстенлек итми, һәм ул иҗат процессын билгеләүче бердәнбер фактор түгел. Төп урынны барыбер аң, фикер алып тора.

Бу фикерне философиядәге идеалистик юнәлеш вәкилләре — интуитивистлар һәм фрейдистлар — шик астына куялар. Алар, иҗат процессы бөтенләе белән аңсыз башлангыч карамагында була, ул, аңлы башлангыч белән килешмәүчән каршылыкка кереп, аны «кысрыклап чыгара», диләр. Шуның өстенә, З. Фрейд теориясе буенча, аңсыз башлангыч дигәне җенси инстинктлардан («эдип комплексыннан») бүтән нәрсә түгел икән. Аныңча, әлеге инстинктлар кешенең бөтен эшчәнлегенә, шул исәптән, аның художество иҗатына да юнәлеш бирәләр. Интуитивистлар (А. Бергсон, В. Кроче һәм башкалар) интуитив башлангычны фикерләүнең иң әһәмиятле һәм иң югары формасы дип игълан итәләр. Болай уйлаганда, художество иҗаты стихияле, пассив рәвештә башкарыла торган процесс булып чыга, ә инде художникның роленә килгәндә, ул бары ниндидер серле, мистик көч тарафыннан үз карамагына бирелгән нәрсәләрне сурәтләүче генә булып кала.

Үзенең дөньяга карашыннан чыгып, үзе иҗат итә торган образга художник, һичшиксез, нәрсә дә булса өсти. Монда ул «ишеткәннәре» һәм «күргәннәре» белән генә чикләнеп калмый, фактларны һәм күренешләрне үзенчә гомумиләштерергә омтыла. Габдулла Кариевның скульптур портретын ясаганда Бакый Урманче, мәсәлән, бөек артистның портретын оригиналга охшатырга гына тырышып калмаган. Ул аңа Кариевның биографиясен, ул яшәгән һәм иҗат иткән чордагы вакыйгаларны «салырга» омтылган. «Портретны ясаганда, мин,— ди ул,— шуларның һәммәсен уйлаган, мәрмәрне булат кискеч белән уйган чакта, чүкечнең мелодик чыңгылдавы шушы уйлар белән тибрәнгән иде». (Габдулла Кариев турында истәлекләр. Казан. 1967 ел. 160 бит.)

Тормышны сәнгать чаралары ярдәмендә чагылдыру — катлаулы һәм дәвамлы процесс. Үзенә таләпчән художник, хәтта аның хезмәте җәмгыять тарафыннан танылганнан соң да, иҗат процессын туктатмый, әсәрен һаман камилләштерә бара. Һәм образлар тудырганда художник кичерә торган иҗат җәфалары аның объектив дөньяны эстетик танып-белүе процессының дәвамы гына булып тора.

Чагылдыру процессында художникның активлыгы иң элек шуннан гыйбарәт ки, ул чынбарлыкның эстетик сыйфатларын **күрә, танып-белә, бәяли.** Иҗат процессында художник реаль дөньяның эстетик сыйфатларын сәнгать әсәре сыйфатларына әверелдерә.

Чыннан да, объектив реальлекнең эстетик сыйфатлары һәммә кеше өчен дә яшии, аларны бөтен кешеләр дә күрмиләр генә. Художникның үзенчәлеге шунда ки, ул чынбарлыкның эстетик сыйфатларын тотып алырга сәләтле була. Эстетик башлангычны күрерлек сизгерлеге булмаган кешеләрдән (ә андыйлар күпчелек) үзгә буларак, художник аларны һәр җирдә, шул исәптән, тыштан караганда бер ягы белән дә аерылып тормаган иң гади әйберләрдә дә күрә.

Менә ботак-чатаклы гади бер агач ята. Аның яныннан йөзләрчә кешеләр һичбер игътибар итмичә үтеп йөриләр. Скульптор исә хәтта шундый агачта да булачак әсәренең образын күрә һәм аның «артык» җирләрен алып ташлап, берәр җанлек яки кеше фигурасы ясый. Чишмә чылтыравы һәм таң алдыннан сандугач сайравы, ачык диңгездә дәһшәтле җил улавы, әлбәттә, поэтик яки музыкаль сәләте булмаган кешеләрдә дә мәгълүм тойгылар һәм кичерешләр тудырмый калмый. Ләкин аларның дулкынланулары һәм кичерешләре, әгәр шулай әйтергә ярасса, «локаль» характерда гына була, чөнки ул кичерешләр, никадәр генә көчле булмасыннар, әлеге кешеләрнең «үзләре өчен» генә туалар һәм соңгы чиктә «үзләре эчендә» йомылып калалар, ассоциатив үсешләрен дәвам иттермиләр. Шагыйрь белән композиторга килгәндә, хәл башкарачак. Шул ук тавышларның аларда, «бөтен кешеләрдә

була торган» гадәти ассоциацияләрдән тыш, мәгълүм бер шигырь яки көй чыгаруга этәрә торган бүтән, махсус ассоциация тудыруы мөмкин.

Һәм монда художник фантазиясенең роле гаять зур. Сәнгатьчә фантазиянең асылына, аның үзенчәлегенә тукталып, Гегель «аны ниндидер пассив хыял белән буташтырырга» ярамый дигән. (Гегель. Эстетика. Дүрт томда. Рус телендә. 1 том. 292 бит.) Ул фантазиянең акылга буйсынырга тиешлеге турында бик дөрес фикер әйткән. Чыннан да, тик акылга сыя торган, яки реаль чынбарлыкның үз закончалыгына туры килә торган фантазия генә чын иҗади фантазия була ала. Ә менә сюрреалистларның яки «абсурд театры» өчен әсәрләр язучының фантазиясе берсе өстенә берсе өелгән вакыйгалардан, ситуацияләрдән тора. Ул — чынбарлыкта булмаган һәм асылда була да алмый торган, бернинди логикага, акылга сыймый торган нәрсәләрнең җыелмасы гына.

Иҗади фантазия шартлылыкны, реаль чынбарлыкның үзендә булмаган нәрсәләрне сәнгатьчә сурәтләүне һич тә инкарь итми. «Илаһи комедия», «Фауст», «Диканька янындагы хуторда кичләр», «Шүрәле» әсәрләренең мифик геройлары әнә шул турыда сөйли. Фантастик образлардан файдалану социалистик реализм сәнгатенә дә ят нәрсә түгел. Аерым алганда, татар совет әдәбиятында Һади Такташ бу алымнан уңышлы файдалана иде. Хәзерге татар шагыйрьләре дә мифик образларга мөрәҗәгать итә киләләр. Мәсәлән, И. Юзеевның Муса Җәлил батырлыгына багышланган «Соңгы сынау» поэмасында шундыйрак образ бар. Анда Моабит төрмәсенең Муса Мефистофель кыяфәтендә гәүдәләнгән явызлык белән бәрелештә күрсәтелә. Фантастик образдан файдалану язучыга көрәшче-шагыйрь күрсәткән батырлыкны гаять көчле һәм ышандырырлык итеп ачарга мөмкинлек биргән.

Әгәр мифик образлар реаль тенденцияләрне (яхшылыкны һәм явызлыкны), алар арасындагы көрәшне гәүдәләндерәләр икән, сәнгатьтә мондый образларны куллану бик табигый. Үзенең хыялында мифик образларны тудырып, кеше аларны теге яки бу реаль җан ияләренә хас булган сыйфатларга, шул ук вакытта үзенә хас булган сыйфатларга, кертә. Кеше алланы да үзенә охшашлы итеп «тудырган» бит. Әгәр кошлар аллага ышансалар, дигән Фейербах, ул чакта алла канатлы зат булыр иде, чөнки кошлар өчен канатлы булудан да зуррак бәхет юк.

Әлбәттә, художникның хыялы мифик, фантастик әйберләр белән генә чикләнми. Ул, барыннан да элек, реаль дөнья картиналарын, реаль җан ияләренең образларын күздә тота. Һәм художник тарафыннан аңлы рәвештә юнәлдерелә торган хыял эше чагылдыру процессының актив ягын характерлый.

Ләкин реалистик сәнгатьтә фантазия художникның башбаштаклыгы нәтиҗәсе генә түгел. Ул сәнгатьнең табигатеннән килеп чыга торган мәгълүм закончалыкларга буйсына. Чынбарлык фактларын һәм күренешләрен сәнгатьчә гомумиләштерү, ягъни типиклаштыру, шундый закончалык булып тора да. Типиклаштыру — художник өчен объектив зарурлык. Ләкин бу зарурлыкны тормышка ашыручы кеше художник бит. Монда да нәкъ менә сәнгать әсәрен иҗат итүченең шәхси сыйфатлары: күзәтүчәнлеге, шулай ук әйберләрнең асылын танып-белүдәге зирәклеге, иҗтимагый тормыш фактларын һәм күренешләрен гомумиләштерә белүе, сыйнфый позициясе һәм милли традицияләргә мөнәсәбәте, үз иҗатында чорның объектив таләпләрен аңлавы һәм исәпкә алуы һ. б. мөһим роль уйный.

Художникның политик, философик карашлары үзгәрүе еш кына аны элек иҗат иткән әсәрләрен җитди рәвештә үзгәртергә мәҗбүр итә. Дөнья сәнгате тарихында моның мисаллары аз түгел. Бу яктан Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының яңа вариантын эшләве бик гыйбрәтле. Кабат эшләүнең сәбәбен язучы үзе түбәндәгечә аңлата: «Әсәр... егерме ел элек язылып тәмам булган. Егерме ел элек дигән сүз — авторның әдәби балачагы дигән сүз, һәм авторның һичбер төрле сәяси партия белән бәйләнмәгән чагы дигән сүз. Беренче революция һәм реакция елларындагы сыйнфый сугышларны, иҗтимагый көчләрне ачык, кискен рәвештә, Ленинча аңларлык дәрәҗәгә күтәрелмәгән һәм үзенең иҗат процессында шул аң буенча (Ленинча) әдәби сәнгать эшен алып бару дәрәҗәсенә җитмәгән заманы дигән сүз. 1914 ел редакциясе буенча чыккан беренче басманы яңадан кайтып карагач, минем күңелне иң нык канәгатьсезләндергән үзәк, нигез момент менә шул булды». (Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. 3 том. Казан. 1956. 432 бит.)

Типиклаштыру җәмгыятькә хас материаль һәм рухи эшчәнлекнең барлык яклары һәм аспектларын үз эченә ала. Сәнгать әсәренең үзәгендә художество образы тора, ул коры абстракция генә түгел. Ул милли яктан да конкрет характерда була.

Соңгы елларда бездә «милли характер», аның никадәр урынлы булуы турында бәхәсләр күп булды. Ләкин, аерым иптәшләр телиләрме-юкмы, теге яки бу милләт яки халыкка хас сыйфатларны йөртүче әдәби образ шул ук вакытта (әгәр дә тормыштан алынган икән) милли характер да ул. Теге яки бу милләткә хас сыйфатларны йөрткән художество образына аерым сыйныф, катлау, сословие һ. б. гәүдәләндерергә һич тә комачауламый. Бу аңлашыла, чөнки сыйнфый һәм милли сыйфатлар бер-береннән аерым яшәмиләр, бәлки нык, аерылгысыз бәйләнештә булалар һәм сәнгатьтә шулай гына гәүдәләнә алалар да.

Ләкин милли характерны тудыру, сәнгатьне милли яктан конкрет итү — бу бит художник эше, аның иҗаты нәтиҗәсе. Бу мәгънәдә сәнгатьтә миллилек, **объектив** нәрсә генә түгел, бәлки художникның **субъектив** иҗаты продукты, аның **активлыгы** нәтиҗәсе дә.

Бу — катлаулы мәсьәлә. Заманында Белинский болай дип язган иде: «Әдәби әсәрдә миллилек — иҗади эшнең казанышы түгел, аның зарури нәтиҗәсе генә. Һәм ул шагыйрь тарафыннан һичнинди тырышлык куймыйча барлыкка килә». (В. Г. Белинский. Әсәрләр. Рус телендә. Дүрт томда. Икенче том. С-Пб. 1896. 327 бит.) Әлбәттә, сәнгатьтә милли үзенчәлекләрне гәүдәләндерү ниндидер «эвристик» проблема түгел. Шул ук вакытта аны художникның «катнашыннан башка», «үзеннән-үзе» килеп чыга торган «фаталь» нәрсә дип карау да дөрес булмас иде. Әгәр эш алай торса, сәнгатьтә һәм сәнгать турындагы фәндә милли үзенчәлек проблемасы да булмас иде. Бөек рус тәнкыйтьчесе милли үзенчәлекне гәүдәләндерү **чын** художник өчен авыр эш түгел, дигән фикердә торды. Чөнки дип аңлатты ул: «Әгәр әсәр матур әдәбият әсәре икән, ул үзеннән-үзе милли әсәр дә була, ә шунсыз аның матур әдәбият әсәре булуы да мөмкин түгел». (Шунда ук.)

Үз халкының тормышын сурәтләргә алынган художник, материал җыйганда, халык тормышындагы милли үзенчәлекләргә аеруча нык игътибар бирә. Ул халыкның көнкүрешен һәм традицияләрен, тарихи чор белән билгеләнә торган идеалларын, милли характер сыйфатларын, образлы сөйләмен, фразеологик әйләнмәләрен, тел үзенчәлекләрен һәм башкаларны җентекләп өйрәнә.

Билгеле бер милләт вәкиле булган художник үз халкының тормышына хас үзенчәлекләрне әсәренә кертмичә кала алмый. Тормышның табигый, шулай ук иҗтимагый-тарихи шартлары котылгысыз рәвештә халыкның психик төзелешенә, аның характерына мәгълүм эз сала. Милли характер исә һич тә «уңай» һәм «тискәре» сыйфатлар суммасына гына кайтып калмый. Ул гомумән «яхшы» яки «начар» дигән бәя киртәсенә генә сыймаган сыйфатларны да күздә тота. Мәсәлән, әйләнә-тирә табигатьне тик шул халыкка гына хас булганча сиземләү — шундый сыйфатларның берсе. Һәм бу нәрсә сәнгатьтә үзенчәлекле чагылыш таба. Әйтик, Ч. Айтматов «Ак пароход» дигән әсәрендә Мәэмүн картның, ә аның аркылы Малайның да адашкан боланнарга гаҗәеп хөрмәтле карашын бик ачык һәм тәэсирләндерерлек итеп күрсәткән. Мондый карашның нигезендә борынгы легенда ята. Кайчандыр Ана болан кеше балаларын үлемнән коткарып калган, имеш. Һәм шушы болан тарафыннан коткарылган балалар, янәсе, ыругны башлап җибәргәннәр. Әсәр геройларының әйләнә-тирә табигатьне сиземләүләрендә борынгы кыргызларның кыргый хайваннарга табыну калдыклары чагылган. Бу исә кыргыз халкы тормышының үзенчәлекле тарихи шартлары белән аңлатыла.

Атаклы калмык шагыйре Д. Кугультинов әсәреннән түбәндәге юлларны китерик:

**Степь! Если в грозном бою,**
**Струсив, себя запятнаю;**
**Степь Джангара и Хонгра**
**Я оскверню имена,—**
**Кровь мою в гной преврати,**
**О степь!**
**И, брезгуя мною,**
**Тело мое не прими**
**В лоно святое свое!**

Нинди оригиналь поэтик фикер! Шигырьдә туган җир табигатенең атрибуты булган дала изге хөкемче дәрәҗәсенә күтәрелгән. «Дала дусты» калмыкның образлы фикерләве турында сөйли торган кызыклы бер мисал бу.

Ә менә борынгы грек сәнгатендә табигать бөтенләй диярлек чагылмаган. Хәлбуки, Эллада табигате элек-электән матурлыгы һәм гүзәллеге белән дан тотып килгән. Бу ил кешеләренең матурлыкны, аерым алганда, табигать матурлыгын аңламаулары мөмкин түгел. Ләкин борынгы греклар игътибар үзәгенә гармоник үсешкә ирешкән кеше культын (аның акылын, ораторлык сәләтләрен, физик камиллеген h. б.) куйганнар. Бу нәрсә шул кадәр көчле булган ки, кешенең физик һәм акыл сыйфатларын турыдан-туры чагылдыра алмаган нәрсәләрне алар арткы планга калдырганнар. Ул тарихи чорда грекларның образлы фикерләвенең милли үзенчәлекле сыйфатларыннан берсе әнә шунда.

Художникның активлыгы аның милли сәнгатьне тагын да үстерү эшчәнлегендә дә чагыла. Зур художникның сәнгатьтә алдынгы юнәлешне сайлап алуы һәм шул юнәлеш белән баруы, кагыйдә буларак, искергән милли традицияләрне яклаучыларның каршылыгына очрый. Мондый шартларда новатор иҗатчыдан үзалдына куйган максатка ирешүдә ихтыяр көче һәм зур тәвәккәллек сорала. Татар мәдәнияте үсеше тарихының төрле чорларында Г. Тукай һәм h. Такташ, Г. Камал һәм Г. Ибраһимов, Г. Кариев һәм С. Гыйззәтуллина-Волжскаяга, С. Сәйдәшев һәм Н. Җиһановка шундый тәвәккәллек күрсәтергә туры килде. Яңалык юлындагы киртәләрнең күбесе, беренче чиратта, реакцион яки консерватив элементларның хәрәкәтләренә бәйләнгән. Ләкин эш анда гына түгел. Бу нәрсә прогрессив сәнгатьне аңларга әзерлеге җитмәгән публикага да бәйле. Моның белән исәпләшмичә ярамый. Һәм новатор иҗатчы милли сәнгатьтә прогрессив принципларны тизрәк урнаштыруның объектив зарурлыгын яхшы аңласа да, мәгълүм бер дәрәҗәдә милли укучының, тамашачының, тыңлаучының h. б. таләпләренә һәм критерийларына җайлашырга мәҗбүр була.

Мондый җайлашу яңалыкны акрынлык белән кертүдә дә, керә торган яңалыкны, милли тамашачының, укучының h. б. эстетик критерийларына туры китереп, үзенчәлекле аңлатуда да күренә. Мәсәлән, Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр Коста Хетагуров, Абай Кунанбаев, Габдулла Тукай һәм Садретдин Айни кебек демократик язучылар һәм шагыйрьләр прогрессив рус әдәбиятын актив пропагандалаучылар булдылар. Рус сүз осталарының әсәрләрендә алар бөтен кешелекне тирантен дулкынландыра, халыкны азатлык керәшенә чакыра торган идеяләр таптылар. Бу язучыларның идея һәм эстетик карашлары Пушкин, Лермонтов һәм Некрасов кебек язучыларның карашларына якын тора һәм туры килә иде. Ләкин рус культурасын пропагандалаганда, алар халыкның сәнгатьчә зәвыклары белән исәпләшмичә булдыра алмадылар. Бу язучылар тәрҗемә өчен рус классикларының милли укучыга аңлаешлырак әсәрләрен сайладылар. Шул ук вакытта алар кайвакыт тәрҗемә ителә торган әсәрләрне, үз укучыларының тормыш тәҗрибәсенә һәм эстетик карашларына туры китереп, иҗади эшкәртергә дә мәҗбүр булдылар. Мәсәлән, казакъ шагыйре Абай «Евгений Онегин» геройларының бәхетсез мәхәббәтендә казакъ яшьләренә якын булган нәрсәләр күрә. Ләкин әсәрдә рус халкы тормышы белән таныш булмаган, милли традицияләрдә генә тәрбияләнгән дала кешеләре аңлый алмаслык әйберләр дә табыла. Әсәрне казакъчага тәрҗемә иткәндә Абай, Онегин һәм Татьяна образларына көнчыгыш кешеләре өчен хас яңа сыйфатлар биреп, оригиналдан беркадәр тайпыла.

Тәрҗемә ителә торган әсәрләрне традицион образлар һәм милли колорит белән баетып, Тукай да кайвакыт шундый «гонаһлар» эшли торган булган. Пушкинның «Десятая заповедь» дигән шигырен тәрҗемә иткәндә, шагыйрь, хатынның матурлыгын сурәтләү өчен, татар укучысына шактый таныш булган көнчыгыш традицион образларын — Зөләйха һәм Ләйлә образларын куллана. Пушкинның «Сказка о золотом петушке» әкиятен тәрҗемә иткәндә, Тукай Дадон патшаны «Мәмәт атлы һиратханы», патша улларын — «шаһзадәләр», Шамахан патша кызын — «Айдай нур йөзеннән яктылык сачып» торган чибәр кыз (татар әкиятләренең традицион образы) итеп күрсәтә. Ә Әтәч, мәчет манарасына кунып, дошман гаскәрләренең якынлашып килүен хәбәр итә. («Ханның мәсҗете башына бас алтын Әтәч менде...»)

Шунысы кызыклы, башка халыкның сәнгать әсәрләрен «кулланучы» публика ул әсәрләргә күпмедер дәрәҗәдә милли интерпретация кертеп үзләштерә. Бу бигрәк тә музыка өлкәсендә күренә. Мәсәлән, В. Виноградов М. Блантерның мәшһүр «Катюша» җырын төрле милләт вәкилләренең (мәсәлән, кыргызларның һәм әзербайҗаннарның) шактый нык үзгәртеп башка-

рулары турында яза. Бер очракта «Катюша», кыргыз халкының музыкаль традицияләренә туры китереп, «формасы ягыннан импровизацияләнгән, озын җырга әйләндерелгән». Икенчесендә шул ук җыр әзербәйҗан гармончысы тарафыннан «тәгәл үлчәнешле лезгинка рәвешендә» эшкәртелгән. («Советская музыка» журналы. 1952 ел. 4 сан. 54 бит.) Шул ук автор Соловьев-Седойның «Вечер на рейде» дигән җырын демобилизацияләнгән кыргыз солдатының үзенчә, милли җайга салып, башкаруын язган иде. Н. Шахназарова да казакъ думбрачысының «Камаринская»ны, белорус гармончысының грузин лезгинкасын милли үзенчәлекле итеп башкарулары турында яза. (Музыкада милли үзенчәлекләр турында. Мәскәү. 1963 ел. 16 бит.)

Бу фактлар халыкның башка милләт әсәрләрен үз милли җаена үзгәртүе, аларны үзенең гасырлар буена эшләнеп килгән традициясенә һәм образлы фикерләү рәвешенә «якынайту»ы турында сөйли.

Башка милләтләрнең сәнгате белән танышуның нәтиҗәләре берьяклы гына күренеш түгел. Алар һич тә «чит» нәрсәне үз җаеңа үзгәртүгә генә кайтып калмыйлар. Монда барыннан да бигрәк, «чит», башка милләт сәнгатендәге бөтен уңай яклы иҗади үзләштерү күздә тотыла. Шулай итеп, милли сәнгатьләрнең объектив рәвештә бер-беренә йогынты ясау процессы субъектив якның (художникның, халык массаларының) катнашыннан башка бармый. Алай гына да түгел, бу процесс нәкъ менә субъектив як тарафыннан тормышка ашырыла.

Милли үзенчәлектәге субъектив башлангыч художество фикере туудан башлап (ни өчен, мәсәлән, бүтән фикер түгел, нәкъ менә шушысы?) бөтен нәрсәдә күренә. Ул художникның идея-эстетик фикерен тормышка ашыру өчен «тормыш материалы» сайлап алуында да, жанрдан башлап троплар системасына кадәр милли сурәтләү чараларын сайлап алуында да, милли публиканың мәгълүм өлешенә, аның эстетик зәвыкларына һәм гүзәллек критерийларына исәп тотуында да һ. б., һ. б. күренә.

Әйткәнебезчә, хәзерге буржуаз философлар һәм ревизионистлар, Ленинның чагылыш теориясенә һөҗүм итеп, совет галимнәрен сәнгатьтә субъектив башлангычны санга сукмауда гаепләмәкче булалар. Күренгәнчә, мондый гаепләүләрнең нигезсезлеге ап-ачык.

Сәнгатьтә субъектив факторның һәм шулай ук чагылдыру процессында художникның актив ролен тану белән бергә, сәнгатьнең асылын һәм бурычын художникның «үз-үзен гәүдәләндерүе» дигән нәрсәгә кайтарып калдыру белән килешергә ярамый. Үткән заман идеалистлары алга сөргән бу караш ренегат Роже Гароди тибындагы хәзерге ревизионистлар тарафыннан күтәреп алынды. Р. Гароди болай ди: «Художество иҗатының бурычы дөньяны сурәтләү түгел, бәлки художникның омтылышын гәүдәләндерү». (Очсыз-кырыйсыз реализм турында. Мәскәү. 1966 ел. 46 бит.) Мондый теорияләр миллионнарча хезмәт ияләренә рухи азык бирә торган чын, реалистик сәнгать белән халык интересларына ят булган буржуаз модернизм сәнгате арасындагы чикләрне «бетерүгә» исәпләнгән.

Эш шунда ки, «үз-үзеңне гәүдәләндерү» дигән уңайлы сүзне чын сәнгатькә карата да, теләсә нинди формалистик тәҗрибәләргә карата да кулланырга мөмкин. Ул абстракционистның теләсә ничек кәгазь яки киндер пычратуларын да, музыка булырга дәгъва итә торган какофониянә дә, формалистик нигездә эшләнгән сүз корылмаларын да аклый. Ленинның чагылыш теориясе сәнгать теориясендә һәм практикасында бөтен шундый ялган новаторлыкның чын асылын фаш итәргә ярдәм итә. Ул сәнгатьнең чагылдыру һәм үзгәртү функциясен, рухи кыйммәтләр тудыручы художникның актив һәм иҗади ролен фәнни яктан нигезли.

Энгель Нигъмәтуллин

# ЖАН-ЖАК РУССО ҺӘМ XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Билгеле булганча, һәрбер әдәбият үзенең үсешендә моңарчы тупланган тарихи тәҗрибәгә таяна. Дөньяга Париж Коммунасын биргән революцион Франция XX гасыр башы татар әдәбияты өчен әнә шундый тәҗрибә булды. Моны Руссо иҗаты мисалында аеруча ачык күрергә мөмкин.

Күренекле француз философы, француз буржуаз революциясенең идеологы Руссо үзенең иҗатында плебейларның һәм башка демократик катлауларның карашларын чагылдырды. Аның замандашлары исә бу чорда феодализм һәм абсолютизмга каршы көрәшне яклау белән чикләнделәр.

Руссоның демократик идеяләре киләчәккә юнәлдерелгән иде. Иҗтимагый тигезлек, изүнең барлык формаларын юк итү, изелгәннәрнең хокукларын яклау — боларның барысы да изелгән хәлыкларга буржуаз-демократик азатлык бирү белән генә чикләнеп калмаска дигән чакыру булып яңгырады. Үзенең революцион рухы, социаль тигезсезлеккә каршы өзлексез көрәшүе белән Руссо марксизмга күтәрелү өчен бер баскыч булып хезмәт итте. Карл Маркс һәм аның тарафдарлары Руссо тәгълиматын фәнни социализмның үсеше өчен кирәк булган факторларның берсе дип санадылар. Маркс тарихи процессның социаль-экономик законнарын өйрәнгәндә Руссоның «Җәмгыять килешүе»нә мөрәҗәгать итте.

XX йөз башында Руссо идеяләре безнең татар әдәбиятына да үтеп керә. Моның өчен исә татар дөньясында җирлек әзерләнгән иде инде.

1905 елгы революция массаларда буржуаз иллюзияләргә карата булган ышанмаучылыкны арттырды, кешенең җиргә, ирекка, хезмәткә булган хокукларын таләп итүне көчәйтте.

XIX йөзнең ахырында, XX йөзнең башларында татар әдәбиятының үзендә дә Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятларында «руссоизм» дип аталган күренешләргә охшаш идеяләр һәм образлар формалашкан иде. Без монда З. Һади, Ф. Кәрими, Г. Ибраһимов кебек язучыларның иҗатларын күз алдында тотабыз. Руссоның татар язучыларына йогынтысы нигездә рус әдәбияты һәм Көнбатыш Европа телләреннән русчага тәрҗемә ителгән әсәрләр аша барды. Бу җәһәттән Руссо идеяләре белән сугарылган әсәрләрдән А. С. Пушкинның «Алеко»сын, Л. Н. Толстойның «Хаҗи Морат», «Тере мәет», «Крейцер сонатасы»н, «Кавказ әсире» кебек әсәрләрен, В. Гюгоның «Фәкыйрь кешеләр»ен, «Туганга каршы туган»ын, Бернарден де Сен Пьерның «Сурат каһвәханәсе»н, Ф. Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт»ен, «Юлбасарлар»ын, Байронның «Мәхбүс»ен, Г. Сенкевичның «Диңгез артында»сын һ. б. әсәрләрне күрсәтеп үтәргә кирәк.

XIX гасырда, әле руссоизм барлыкка килгәнче үк, бездә тамырлары Көнчыгыш әдәбиятына — социаль тигезлек идеяләрен күтәргән гарәп фәлсәфи поэзиясенә һәм

прозасына (Абуль-Эль Мэгарри, ибне Фараби), көнчыгышның табигать культын һәм кешенең табигый хисләрен чагылдырган мәхәббәт лирикасына (Гомәр Хәйям, Хафиз, Нэвои, Фозули, Руми) барып тоташкан әдәби-тарихи хәрәкәт барлыкка килә. Монда шулай ук төрек әдәбияты да билгеле бер роль уйный. Француз телен белгән кайбер татар язучылары (Р. Фәхретдинов, Ф. Әмирхан, Ф. Сәйфи, Г. Камал һ. б.) Руссо әсәрләре белән оригиналда танышалар. Ул чорда чыгып килгән татар журналларында һәм газеталарында, мәсәлән, Руссоның француз телендә басылган «Контра Сосиаль», «Яңа Элоиза» кебек әсәрләре телгә алына.

## РУССО ИДЕЯЛӘРЕН СОЦИАЛЬ ПЛАНДА ҮЗЛӘШТЕРҮ

Егерменче гасыр башында татар әдәби хәрәкәтенең катлаулы һәм идея-художество ягыннан каршылыклы булуы татар язучылары һәм публицистлары арасындагы төрле идеологик группаларның Руссо идеяләренә карата да төрле мөнәсәбәттә булуларына китерде. Татар укымышлыларының бер төркеме Руссоны дин һәм милләтчелек позицияләреннән, икенчеләре буржуаз-демократик һәм революцион-демократик позицияләрдән торып кабул итәләр.

Дин һәм милләтчелек позициясендә торган язучылар Руссога каршы чыгалар. «Гарәп әдәбияты вә ауропалылар» дигән мәкалә авторы, французлар үзләренең Вольтер, Руссо, Дидро кебек философларының идеяләрен үзләштерделәр, ә мөселманнар хәтта ибне Рушд, Әбугалисина кебек энциклопедистларны да белмиләр, ди. Ахырдан: «Һич булмаса үзебезнең тормышны шул динсез француз тормышы белән чагыштырып карыйк»[1],— дип нәтиҗә ясый.

Күрәсез, үз вакытындагы динчеләр әзәрлекләгән шикелле үк, хәзергеләре дә Руссоны «динсез» дип камчыларга әзер торалар.

Икенче бер автор исә Руссоның иҗтимагый йөзен бөтенләй бозып күрсәтергә тырыша: «Руссо үзенең бик хөббенәфесе (мин-минлекле) булуы сәбәпле үзе теләгән эшне генә эшләгән. Халык алдында һич вәксынмаган»[2].

Әйе, Руссо бәйсез булуны яраткан. Әмма кемнән бәйсез булырга тырышкан соң ул? Бу сорауга кыска гына итеп болай дип җавап бирергә була: аристократ салоннарыннан. Чөнки шул аристократларга гомер буена ялланып хезмәт итеп йөрүдән ул инде тәмам туйган була.

«Шура» журналында басылган мәкаләләрнең берсендә француз революциясенең алдынгы идеологларына ни өчендер «бәхетсез милләтләр»нең уллары каршы куела. Ул мәкаләнең түбәндәге юлларына игътибар итегез:

«Кияү кайниш туфрагыннан ярала» дигән сүзне Монтескье, Руссо вә яки шуларга охшаган бер Ауропа хакиме әйткән булса иде, шул сүзнең дәреслегенә хәйран калыр, могҗиз сүзләрдән санар идек. Ләкин ул сүзне бәхетсез милләтләрнең бәхетсез бабалары сөйләгәннәр дә, шуның өчен кыйммәте дә юк, мәгънәсе дә»[3].

Бу инде Руссоны тәп җирләгәннән — төрле милләтләрнең, инсаниятнең «бәхетсез балалары»ннан аерырга маташу, ягъни Руссога яла ягу, аның демократ булуын я аңламау, я аңламаска тырышу дигән сүз.

Язучыларның икенче төр группасы «гарәптә беренче уларак инсанның хокукын тасдыйк (раслау) иткән, инсанны чын мәгънәсе белән инсан дип таныган Руссоны... идарәсен «җөмһүрият» нигезендә бина иткән мәмләкәтнең гражданины булган Руссоны» күкләргә чөеп мактый[4]. Әмма бу төр язучыларга тарихка идеалистик караш, прогрессны метафизик аңлау хас иде: «Ни өчен унсигезенче гасыр азагында

---

[1] «Шура» журналы. 1912 ел. 24 сан.
[2] «Идел» газетасы. 1912 ел. 463 сан.
[3] «Шура» журналы. 1913 ел. 21 сан.
[4] «Сөембикә» журналы. 1915 ел. 18 сан.

Жан-Җак Руссоның асары ялгыз Франциядә генә түгел, бәлки бөтен Аурупа галәмендә мисле күренмәгән бер сурәттә тәэсирләр иҗраэ (эшкә ашырылу) итте?.. Чөнки бөтен Аурупа, хосусан Франциядә, ул заманның бозык шәраэт иҗтимагыясенә, асыл идарәсенә каршы **үзе әйтеп бирә алмаса да — һәркемнең** (ассызык безнеке — Э. Н.) күңелендә бер нәфрәт, бер шикаять мәүҗүд (бар) иде. Бу нәфрәтләрне, бу шикаятьләрне Руссо һәркемнән артык хис кылды... Француз инкыйлаб кәбире мәйданга килде. Димәк, бу инкыйлабның асыл мөәссире Руссоның асар әдәбиясы вә ул асар илә мөһиренә гомергә гарыз ителгән **амаль** галиядер (бөек өмет)»[1]. Күренгәнчә, биредә француз революциясен хәрәкәткә китерүче көч итеп җитештерүче көчләр белән җитештерү мөнәсәбәтләре арасындагы көрәш түгел, ә бәлки «бөек ышаныч» күрсәтелә.

Югарыда саналып кителгән мәкаләләрнең авторлары Руссоны гадәттә эре буржуазия идеологлары Монтескье, Вольтер һ. б.лар белән бер рәткә куялар. Бу исә аларның Руссо идеяләренең халыкчанлык асылын аңламаулары турында сөйли.

Руссога революцион-демократик күзлектән карап, аның идеяләрен дөрес аңлатуга мисал итеп, прогрессив татар журналисты Р. Рәкыйповның «Бөек философ Жан-Жак Руссо» дигән мәкаләсен китерергә мөмкин. «Руссо бу әсәрендә (сүз «Рассуждение о происхождении и основаниях неравенства между людьми» әсәре турында бара — Э. Н.) инсаннар арасында мөсават (тигезлек) юклыкка, халык арасында мәхәббәт вә өхуәт (кардәшлек) беткәнлеккә кайгыра иде. Аның гындендә (фикеренчә) бөтен дөнья икегә тәкъсим (бүлү) кылынмыш иде: берсе — югарыдагы бозылган, әхлаксыз, авыру азчылык — байлар вә задәганнәр (ак сөякләр), вә икенчесе — фәкыйрь, хәкарәтләнмеш, изелгән вә тапталган, ләкин хаканият вә гадаләт хамил, гыйффәт руханиясен югалтмамыш халыктыр»[2].

Р. Рәкыйповның Руссога инде марксизм позициясеннән торып карый башлавы шуннан күренә ки, 1906 елда басылып чыккан «Франция революциясе» исемле китабында ул, Маркс фикеренә таянып, сыйнфый көрәш турында менә болай ди: «Буржуазия бар куәтне үзенә алырга тырышу илә... үзенә каршы килә торган пролетариат сыйныфын күбәйтә: шуның илә бәрабәр социальный[3] переворотның булуын якынлайтадыр, буржуазия, пролетариат сыйнфын вөҗүдкә китергәннән, үзенең тылсымнары илә ясаган җеннәр вә пәриләрен үзе теләгәнчә йөртә алмаган сихерче кебек булып калмыштыр»[3].

Р. Рәкыйпов Габдулла Тукайлар мохитендәге кеше була. Менә шуңа күрә дә аның белән аралашып яшәгән Тукайның Руссо тәгълиматындагы тигезсезлек турындагы фикерләргә якын торуы бер дә гаҗәп түгел. Дөрестән дә, тарихи прогрессны кешенең табигый таләпләре һәм аларны тормышка ашыру юлында килеп туган каршылыклар бәрелеше дип аңлаткан Руссо идеяләре Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һ. б. язучыларның игътибар үзәгендә тора.

Зур сәнгать көченә ия булырлык тулы канлы образлар тудыру теләге, милли тормышның тарлыгына һәм торгынлыгына каршы шәхси бунт Галимҗан Ибраһимовны баштарак бу тормышка, аның социаль ягын исәпкә алмыйча, ниндидер бер «табигый асыл» итеп карауга китерә. «Бездә руслардагы кеби гавамлашу, ак куллыктан чабаталыга әйләнү мәгънәсе һәм авылга бару дәгъвасы юк, бездә асылга кайту, авылыңа — туган җиргә кайту гына булачак»...— дип яза ул «Авылда мәгыйшәт»[4] дигән мәкаләсендә.

Г. Ибраһимов карашларындагы чикләнгәнлек аңа әле татар авылының үзендәге сыйнфый каршылыкларны күрергә комачаулыйлар. «Рус, төрек вә татар тарихыннан» дигән мәкаләсендә ул бәрлык катлаулары да Наполеон баскынчылыгына каршы торган ниндидер тоташ, сыйныфларга аерылмаган рус милләте турында яза.

---

[1] «Йолдыз» газетасы. 1912 ел. 807 сан.
[2] «Шура» журналы. 1909 ел. 8 сан.
[3] Р. Рәкыйпов. Франция революциясе. Нәшере «Мәгариф» көтепханәсе. Казан. 1906. 38 бит.
[4] «Йолдыз» газетасы. 1911 ел. 760 сан.

Ләкин иҗтимагый-сыйнфый каршылыклар көчәя барган саен, төрле социаль теорияләргә анализ ясап, Руссо йөзендә ул изелүчеләрнең яклаучысын күрә һәм кешеләргә бәхет бирергә кулыннан килмәгән җәмгыятьнең идеологик кризисын тоя: «Әдәбиятмы, сәнгатьме — һәркайда, һәр заманда тук мещаннар белән бай аристократлар эшсезлектән туган эчпошуларын бетерергә хезмәт итә килгән бер-ике нәрсәгә һичбер заманда нык иманым булмады» [1].

«Табигать балалары» хикәясендә Г. Ибраһимов табигать баласы булган кешенең идеалы тормышка ашуын хезмәтчел крестьянда күрә. Бу хикәя XX гасыр башындагы татар әдәбиятында Руссо идеяләрен ачык чагылдырган әсәр булып тора.

Әмма Галимҗан Ибраһимов Руссо позицияләрендә озак кала алмый. Пролетар революциясенә хәзерлек чоры, татар халкы арасында марксистик идеяләрнең көннән-көн киңрәк тарала баруы татар язучысының Руссога карата булган мөнәсәбәтен дә үзгәртә һәм ул үзенең мәгърифәтчелек идеалларын тәнкыйть күзлеге аша үткәреп, өр-яңадан карап чыгарга мәҗбүр була.

«Безнең көннәр» романның беренче (1914 елгы) басмасында ук инде язучы кешеләрнең эшләрен, үз-үзләрен тотышларын аларның характерындагы үзгәрешләр, җәмгыять тормышындагы социаль вакыйгалар белән бәйләп бирүне алга сөрә. Шулай итеп, аның иҗатында табигать баласын идеаллаштыру сыйнфый-политик көрәш учагында чыныккан уңай геройны күрсәтү хисабына торган саен ныграк кысрыклана, арткы планга чигә бара («Безнең көннәр» романының икенче басмасы, «Тирән тамырлар» һ. б. әсәрләр).

Тарихи яңарыш үскән саен татар язучылары иҗатында Руссоның цивилизациягә каршы юнәлдерелгән карашлары, кешенең «табигый хокуклары»н яклау мәсьәләләре аеруча кискен төс ала. Бу уңайдан Ф. Әмирхан һәм Г. Тукай фикерләрен искә төшереп үтәсе килә. Мәгърифәтче буларак, Ф. Әмирхан культура өлкәсендәге яңа идеялардән башка, Көнбатыш Европа һәм рус цивилизациясе тудырган барлык казанышларны үзләштерүдән башка социаль-тарихи прогрессның булуы мөмкин түгеллегенә тирәнтен ышана. Шуңа күрә ул Руссоның цивилизацияне кире кагуына ирония белән карый. Бу уңай белән ул менә нәрсә ди: «...Адәм балаларына меңнәрчә еллык тырышлыгы белән барлыкка килгән фәннәр һәм фәлсәфә урынына «изгелекле» надан лыгың булыр!» [2] (Монда Ф. Әмирхан, күрәсең, Руссоның «Сәнгатьнең әхлакка кире йогынтысы турында»гы трактатын күздә тота.)

Г. Тукай исә Руссо идеяләре тарафдары булган Толстойның икенче бер фикерена — ул чордагы цивилизациянең халыкка каршы характерда, ягъни буржуаз характерда булуы турындагы фикерена басым ясый. Кешеләрнең азатлыкка омтылышы тик залимнәргә каршы нәфрәт аша гына ныгыячагын Тукай яхшы аңлый: «Мәсәлән,— ди ул,— Наполеон таләбе бар, Әнвәр бай таләбе бар. Боларның таләбе мәгълүм: бөтен дөньяны үзләренә мөсәххәү (буйсындыру) итү» [3].

Ф. Әмирхан һәм Г. Тукай, мәгърифәтчелек позицияләрендә торып калмыйча, Руссодан бер адым алга — революцион демократлыкка атлыйлар [4].

Ф. Әмирханга килгәндә исә, пролетариатның буржуазиягә карата булган мөнәсәбәтен ул: «Сарык-куй тирәсендә килгән бүрене белделәр вә аңа сугыш игълан иттеләр»,— дип ачыклый.

---

[1] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. I том. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1957. 199 бит.

[2] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. I том. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1957. 333 бит.

[3] Г. Тукай. Әсәрләр, дүрт томда. 4 том. Татарстан китап нәшрияты. 1956. 181 бит.

[4] Бу мәсьәлә буенча З. А. Ишмөхәммәтовның фикере кызыклы гына. «Академик А. Н. Бахның «Царь-голод» исемле брошюрасының Тукай тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителү факты да игътибарга лаеклы,— ди ул.— Бу брошюрада марксизм-ленинизмның җәмгыять үсеше закончалыклары турындагы положениеләре популяр телдә аңлатылган, капитализм чорында сыйныфлар арасындагы антагонистик каршылыкларның экономик нигезләре ачып салынган...» (З. А. Ишмөхәммәтов. Тукай атеизмы. Татарстан китап нәшрияты, Казан. 1971. 7 бит.)

## РУССО ИДЕЯЛӘРЕН ФИЛОСОФИК ПЛАНДА ҮЗЛӘШТЕРҮ

Егерменче йөз башы татар әдәбиятында Көнбатыш һәм Көнчыгыш акыл ияләренең фәлсәфи идеяләрен бер-берсенә бәйле рәвештә карау кирәк дигән фикерләр уяна башлый. Мәгърифәтче Фатих Кәрими, мәсәлән, Руссоны Көнчыгыш фикер ияләре белән бер рәткә куя[1].

Романтик шагыйрь Нәҗип Думави Руссоны Көнчыгыш суфилары белән чагыштыра. Руссо, дип яза ул, борынгы грек философиясе инде тәмам урнашып җиткән чорда философиягә килеп керде. Һәм Руссоны ул «чынлап ук инде фәлсәфә турында эшли башлаган» кешеләрнең берсе итеп саный.

Руссоны ибне Туфейль һәм суфилар белән бер рәткә кую һич тә очраклы хәл түгел. Бу факт язучыларның дөньякүләм культура турында фикер йөртә башлаулары турында сөйли. Ибне Туфейль һәм суфилар Руссога кадәр яшәгәннәр. Ә соң аларның Руссога йогынтылары булмадымы икән? Әбү Мәхмүд Тимра һәм Думави әнә шундый сорауга җавап эзлиләр.

Татар язучыларын Руссо тәгълиматындагы кайбер проблемалар (күренешләрнең асылын танып белү, иреклелек һәм зарурилык һ. б. лар) кызыксындыра.

Руссо тәгълиматында танып белү процессында акыл һәм тойгының үзара мөнәсәбәте мәсьәләсе зур урын алып тора. Руссо рационализмга, акылны абсолютлаштыруга каршы чыга. Аның фикеренчә, прогресс чыганагы һәм танып белү процессының нигезе булып акыл түгел, ә бәлки тойгылар тора.

Руссоның, табигать баласы булган кеше тормыштагы күренешләргә үз күзләре белән карарга тиеш, дип өйрәтүләрен татар язучылары сукыр кануннарга каршы көрәшер өчен файдаланалар.

Татар язучылары Руссоның рационализмга каршы идеяләре белән кызыксына башлаганнар икән, бу инде татар мәгърифәтчеләре аңында кризис башлануы турында сөйли. Татар мәгърифәтчеләре Руссоның әхлак турындагы өйрәтмәләрен дә кабул итәләр. Билгеле булганча, Руссо һәр кешедә табигать тарафыннан бирелгән әхлакый башлангыч бар дип саный. Аныңча, тумыштан кеше һәрвакыт яхшы, аның күңелендә берниндн дә бозыклык юк.

Кайбер татар тәнкыйтьчеләре һәм язучылары Руссоның шул рухтагы фикерләрен үзләштерүгә юнәлеш тоталар. З. Һади «Бәхетле кыз» повестенда уңай герой сыйфатында алынган Габбасның үз-үзен тотышын әнә шул ноктадан торып аңлата. Тукай «бөтен җаннарның җаны вә бөтен инсаннар вөҗданы» булган руссочы Толстойны табигатькә якын торган шәхес итеп саный («Мөбарәк тәсбих үзелде»). Руссоның вөҗданлы һәм итагатьле булу турындагы карашлары татар язучылары иҗатында (Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Н. Думави һ. б.) гарәп шагыйре һәм философы Мәгарри карашлары белән керешәләр. 1907 елда татар теленә Мәгарринең «Әл-лөзүмиять» дигән хезмәте тәрҗемә ителә. Ә 1908 елда Р. Фәхретдиновның «Әбү-Әлгалә Әл Мәгарри» исемле китабы басылып чыга.

«Дин синең һәркемгә карата гадел булуың дигән сүз ул,— дип яза Мәгарри.— Башкаларны табигатьнең үзе тарафыннан бирелгән хокукларыннан мәхрүм итүчеләр нинди дине булырга мөмкин?.. Әй, кеше, кош күкәйләрен оясыннан алма, чөнки аларны синең өчен куймаганнар. Бал табарга теләсәң дә, алладан курык, чөнки бал кортлары аны башкалар өчен түгел, үзләре өчен җыйганнар».

Мәгарри идарәче даирәләрнең, чиновникларның, дин башлыкларының паразитларча тормышын аларның төрле кәеф-сафа һәм бозыклыклар кылып яшәүләрендә күрә. Ә андый тормышны булдырмау өчен, ди ул, кеше начар эшләрдән баш тартырга сәләтле, намуслы һәм вөҗданлы булырга тиеш.

Егерменче гасырда татар халык шагыйре Г. Тукай Мәгарринең бу фикерләренә янә бер тапкыр әйләнеп кайта:

**Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт,**
**Бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың бирлән җылыт!**
**Мин адаштым тугры юлга үл торып күндермәсә,**
**Дурт эгым гыйсъян уты, сүнмәс һич, ул сүндермәсә.**

---

[1] Ф. Кәрими. Аннан-моннан. Оренбург. 1907 ел.

**Бер бөтү чорында мин, юктыр нәҗат, коткармаса.**
**Мәңге тотынып нәрсә юктыр, ул килеп җеп салмаса.**
**(«Өмит»)**

Гуманизм идеясен Мәгарри барлык нәрсәләрдән өстен куя. Романтик шагыйрь Н. Думави «Мәгарри» шигырендә[1] болай ди:

**Ник мине сез орышасыз безне әйтәдер дип гыйтаб,**
**Мин үзем дә бәндә бит, мин бәндәгә итәм хитаб.**

Мәгарринең кайбер фикерләре Руссоның революцион тәгълиматына («Җәмгыять килешүе») тәңгәл килә: «Халык үзе ничек дөрес тапса, шулай кылсын,— дип яза Мәгарри.— Идарәче бит бары тик аның ялчысы гына»[2].

Әмма Руссоның этик карашлары аның иң якын табынучылары тарафыннан да тәнкыйть күзлеге аша карап бәяләнә. Мәсәлән, Г. Ибраһимов әхлакый тойгыларның мөстәкыйльлеген шик астына ала. Үзенең «Альбом»ында ул болай дип яза: «Жан-Жак Руссо урынлы да, урынсыз да санагыь нәфисәнең әхлакка начар тәэсирен сөйләп, аны каралларга, аның сихерле куәтен киметергә тели»[3].

Руссоның ирекле булу һәм зарурияtlek идеяләре реакцион немец философы Фридрих Ницше идеяләре белән бәрелешәләр. Руссога таянып, татар язучылары ницшеанчылыкны тәнкыйтьлиләр һәм Руссоны яклап чыгалар. «Әдәбият һәм хәятта вәхшелөнү вә тәкәммел» исемле мәкаләсендә Самат исемле автор болай ди: «...Ницше әсәрендә дә шундый ук хәл. Анда да аерым шәхес вә аның халыктан аерым торган хәлдәге матурлыгы, көчлелеге хакында гына сөйләнә»[4].

Бу сүзләр бик дөрес һәм алар борынгы ерткыч ханнарны мактаган язучыларга да кагыла. Менә И. Кильдибеков дигән бер язучының тарихи очеркында («Дин нәрсә?») Тимер хан турында ничек языла. Аның: «Бары кулында кылыч илә генә олуглык ныгытыла», дигән сүзеннән соңгы сыйфатлары галәбә иткәне аңлангандай улса да, каты вә вәхши диярга булырмы шул кешене»[5].

Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» романында «дала кызы» Карлыгачны идеаллаштыра һәм бер үк вакытта Калтай образында үзен «Чыңгызлар токымы» вәкиле дип санаучы ницшеанчы геройны фаш итә. Калтайны халык язмышы кызыксындырмый. Ул «табигатькә», казакъ даласына дошман һәм шуңа күрә дә, көрәшкә күтәрелгән халык тарафыннан кысрыкланып, дәнсыз үлем белән дөньядан китә. Калтайга автор халык тарихын яхшы белгән, аның традицияләрен саклаган аксакал Биремҗан карт образын каршы куя.

## РУССОНЫҢ ЭСТЕТИК КАРАШЛАРЫНА МӨНӘСӘБӘТ

Моңа кадәр без Руссоның татар язучыларына идеологик йогынтысы турында сөйләдек. Бөек француз мәгърифәтчесе безнең язучыларның эстетик карашларына никадәр йогынты ясаган соң?

Моңа җавап бирер алдыннан иң элек Руссоның табигать баласы булган кешенең табигатькә карашы турындагы концепцияләренә тукталып үтәргә кирәк.

Руссоның эстетик карашлары мәгърифәтчелек реализмы вәкилләрендә үк инде зур кызыксыну уята. Фатих Кәрими беренче планга җәмгыять тормышы белән бөтенләй кызыксынмаган «табигый кешене» куя. «Салих бабайның өйләнүе» (1897) хикәясендә умартачы Салих бабай образы сурәтләнгән. Ул япа-ялгыз гомер кичерә һәм балалар белән аралашудан үзенә рәхәтлек таба, аларга әкиятләр сөйләргә ярата. Руссо

---

[1] «Шура» журналы. 1914. 5 сан. 155 бит.
[2] С. Широян. Великий арабский поэт и мыслитель Абу-ль-аля аль Маари. Мәскәү, 1957 ел. 27 бит.
[3] Г. Ибраһимов. Альбом (Санагыь нәфисә мәҗмугасы). Казан. 1915 ел. 27 бит.
[4] «Тормыш» газетасы. 1916 ел. 5116 сан.
[5] «Мәгълүмат» журналы. 1908 ел. 11 сан. 218 бит.

йогынтысы бу язучының «Мирза кызы Фатыйма» (1907) повестенда да шактый сизелә. Бу әсәрдә бакчачы Мостафа белән Мирза кызы Фатыйма арасындагы мәхәббәт тасвирлана. Аларга «нә русчадан, нә мөселманчадан хәбәре» булмаган дворян малае бозык Габделгәрәй комачаулый. Руссоның «Яңа Элоиза» романы геройлары Сен Пре һәм Юлия д'Этанжның язмышлары трагик планда хәл ителә. Бу исә яңа чорны фаҗигале итеп аңлау белән бәйле. Ф. Кәрими чорга, тарихка алай тирәнтен үтеп керми. Ул үзенең геройларын бәхетле финалга алып килә. Шулай да автор монда шактый әһәмиятле бер социаль-психологик деталь китерә. Фатыйма, Мостафаның пычрак җаннар тарафыннан каты кыйналганлыгын белсә дә, үзенә тугрылыклылыгын сынар өчен, аны шул ук көнне очрашуга чакыра. Ләкин, язучының дөньяга карашы чикле булуы аркасында, әлеге деталь героиняга характеристика биргәндә төп рольне үти алмый. Ф. Кәрими киң социаль фоннан баш тарта, геройларның тормышын тар хисләр белән чикли.

Закир Һади «Җиһанша хәзрәт» (1908) повестенда циник предприниматель Җиһаншаны инде Руссоның «Җәмгыять килешүе» исемле әсәрендәге позицияләрдән торып хөкем итә. Геройның индивидуализмына авыл балалары каршы куелган: «Бер урамдагы авыл балалары үзләренә бер җыен җыеп, икенче урам балалары үзләре бер җыен булып, ике балалар җәмгыяте булып, бер урам баласы икенче урам баласына зарар итсәләр, үзләренә бер иттифакта булып, киңәшеп, берләшеп, анларга барчасы каршы торырлар»[1].

Мораль яктан тотрыклы булмаган геройга үз-үзенне тотуның җәмгыять нормаларын каршы кую мәгърифәтчелек реализмы өчен очраклы нәрсә түгел.

Фатих Кәримидән аермалы буларак, Руссоның Закир Һадигә йогынтысы аның буржуаз принципларны кабул итмәвендә күренә. Монда буржуаз стройның башка, гадел строй белән алышыначагына ышанган язучының тарихи сиземләве ачык чагыла. Аңа буржуаз тормыш иллюзияләре ят. Менә шуннан чыгып, геройның тормыш алдына куйган таләпләрен билгеләгәндә, язучы катгый тәгаллекне таләп итә («Мәгъсүм», «Бәхетсез кыз» h. б. повестьлар). Авыл балаларының әхлакый дөньясы белән кызыксынуы язучының педагогик, мәгърифәтчелек таләпләре турында гына түгел, балаларында гаделлек һәм җәмәгатьчелек идеяләрен тәрбияли алган хезмәт кешеләренең дөньяга карашларын аңлавы турында да сөйли. Шулай итеп, Руссоның иҗтимагый идеяләре язучыга киләчәктә иҗади фикерләүне нинди рәвештә алып барырга кирәклеген ачык аңлата.

Күренекле татар язучысы Фатих Әмирхан Руссога карата каршылыклы мөнәсәбәттә торды. Ул Руссоның цивилизациягә карата булган карашы белән килешми. Язучының идеалы — әйбәт костюм кигән, европача белем алган, Парижндагы, Лондондагы Халыкара күргәзмәләрне карап йөрүче татар интеллигенты («Гарәфә кич төшемдә»). Тик шулай да язучының гомум милли прогресс турындагы иллюзияләре тормышның конкрет күренешләре белән каршылыкка керә.

Ф. Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык» (1909) хикәясендәге Гайса буржуазиянең өнә шундый тупас вәкиле булып күз алдына килеп баса. Гайса аерым бер социаль төркем вәкиле. Социальлек исә, Ф. Әмирхан фикеренчә, катлаулы характерлы булуы белән аерылып тора[2]. Шуңа күрә Гайса образы катлаулы коллизияләргә: фәлсәфи (пароходтагы дини бәхәс), эстетик (Гайсага капма-каршы буларак сурәтләнгән акыллы, нәфис, көчле характерлы Разия), мораль-әхлакый (Гайсаның хатын-кызга карашы, аның кәеф-сафа кылып, типтереп гомер уздыруы), җәмәгать-гражданлык (прогрессив карашлы журналист алдында тетрәнү) кебек коллизияләргә корылган. Философик аспектта ул бик сай йөзә, мораль аспектта — дан яратучы һәм чикләнгән эгоист, эстетикада безне чолгап алган табигатьнең гармониясен аңламый, җәмгыятьтә исә «мужик»ларны күрә алмый.

---

[1] Закир Һади. Сайланма әсәрләр. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1957. 178 бит.
[2] «...Сыйныфлар, аларның тормышлары — һәммәсе шул кадәр күп төрләргә, күп фиркаларга аерылалар ки, аларны озак вакытлар хосусый өйрәнгәннән соң гына яхшы аңлап җиткерә алсаң да куанырга кирәк әле»,— ди Ф. Әмирхан. (Сайланма әсәрләр. 2 том. 423—424 битләр.)

Шулай булуга да карамастан, геройның асылын ачып бирүдә төп билгеләмә булып аның милләткә карата булган карашы хезмәт итә. Фатих Әмирхан фикеренчә, милләт тә табигатькә охшаш, чөнки ул да, табигать шикелле үк, эчке бер закончалык нигезендә үсә.

Руссо табигатьне тормыштан аера. Аның уңай персонажлары «бозык цивилизацияле» шәһәрләрдән качып, табигать кочагында яшиләр (Эмиль, Юлия д'Этанж һ. б. лар). Ф. Әмирхан, киресенчә, социаль тормышны табигать белән бергә кушарга тырыша, чөнки аларда икесенә дә уртак булган диалектик каршылыклар күрә. Җәмгыятьтә яманлыклар бар икән, аңа капма-каршы булган яхшылык та сакта тора. Бу бик тирән идея һәм ул тормышта бары тик кире, әшәке якларны гына эзләүче әдипләрне бик каты камчылый.

Табигать белән охшашлыклары булган милләттә аның тормышындагы күренешләрнең асылы да, әхлак та, гармония дә, гражданлык вөҗданы да бар: «Балконда йөренә башлыйм: я рабби! Бөтен табигатьтә никадәр гүзәллек, никадәр тәүсыйфә (сыйфатлауга) бирелми торган шигърият; бөтен тормышта никадәр якты, матур тарафлар...»[1] — ди автор.

Г. Тукай иҗатында табигать баласы булган кеше һәм табигать идеясе һәр шигырь яки прозаик әсәр саен өр-яңа яклары белән ачыла барган катлаулы диалектик образга әверелә. Шагыйрьнең әхлакый идеалы, Руссодан (һәм Л. Н. Толстойның «Фикерләр»еннән) аермалы буларак, бик нык эшләнгән эстетик формага яшеренгән. Менә шуның бер үрнәге:

Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын,
Якты көн булганда.
Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

(«Бала белән күбәләк»)

Монда әхлакый акыл сату юк. Әмма бу шигъри юлларны сүз уйнатуга кайтарып калдыру һич тә дөрес булмас иде. Күбәләкнең күңелне җилпендереп җиңелчә җилкенүе, катлаулы ассоциацияләр ярдәмендә, укучыны табигатькә авыл малае күзе белән карарга, шул табигатьнең тупас «Кисекбашлар» күрә алмаган чисталыгын тоярга ярдәм итә.

«Тормыш» шигырендә Руссо тәгълиматы тарафдары Толстой фикере белән тышкы охшашлык бар:

Көрәш утында ар, тал, тирлә, имгән;
Өмит итмә булышмакны ләимнән.

Ләкин бу коры мораль уку түгел. Руссо хезмәтнең әхлакый-күтәренке характерда булуы турындагы фикерләрне укучыга нигездә ораторлык сәнгате аша җиткерә. Тукай хезмәтнең авырлыгы турында язганда аны Көнчыгыш әлмына хас булган матур, нәфис образлар аша тасвирлый. («Өмит», «ләимнән», «угрында».) Шигырьләрдән алынган төрле-төрле тәэсирләр укучыда билгеле бер фикер уята һәм менә шундый синтезга китерә: хезмәт тә, кеше характеры да матур, ләкин көчләп тагылган хезмәт кенә үзенең матурлыгын югалта.

Тукай да, Руссо шикелле үк, табигатьне һәм ялган цивилизацияне капма-каршы ике полюска куя. Табигать ул — шагыйрьнең бәйсез «мин»е, аның яраткан эше, дуслары, якыннары турында уйлап җирсәве. Ялган цивилизация — Муса Бигиевнең гарәп телендәге китаплар, кульязмалар белән дыңгычлап тутырылган кабинеты («Мәкаләи махсуса»). Ул өем-өем китаплар кешенең бәхеткә карата булган иң гади таләпләренә дә җавап бирмиләр. Авыру шагыйрь Петербургта яшәүче М. Бигиевка

[1] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. 1 том. 349 бит.

кунакка килә, ул ютәл белән иза чигә. Ләкин М. Бигиевнең көнчыгыш кунакчыллыгы формальлек рамкаларыннан узмый. Муса Бигиев һәм Тукай — төрле полюс кешеләре. Шуңа күрә аларның карашлары да төрлечә. Беренчесендә — китаптан, традицион, кеше күңелендәге тирән яраларга игътибарсызлык, икенчесендә — акыллы, кешелекле хисләр. Хәтта үзенең канәгатьсезлеген дә шагыйрь соңыннан гына, дала буйлап барган чагында гына, белдерә: «Бу — сахра. Бу — казакъ җире. Әүвәл «бисмиллаһи» дип бер чишенеп ташладым... Бөтен нәрсә табигый, бөтен нәрсә алдаусыз»[1].

Руссодагы шикелле үк, Тукайда да табигать кешенең сәламәт көчен гәүдәләндерә:

**Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;**
**Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.**

Мәгърифәтчеләр культураны гадәттә кешенең эчке кичерешләренә бәйсез рәвештә карасалар, Тукайны кешене сафландыручы культура кызыксындыра:

«Аннан соң без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен иң элек аның «вәкар»ен бозарга кирәк.

Бу — өй салганда иң элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кеби кагыйдә инде.

Андый «вәкарь» яшьлектә җимерелмәсә, бәгъзан, мөхаррир булып гомер итеп, неграмотный үләчәк «зате галимнәрдә дә кала»[2].

Руссо идеяләренең йогынтысы Г. Ибраһимов иҗатында да сизелә. Галимҗан Ибраһимовны Руссо белән, барыннан да элек, «авторитетларга» каршы протест якынәйтә. «Яшь йөрәкләр» романында язучы «канында зурлык нәтиҗәсе булган «данлылык» һәвәсе, рухында бабалар зурлыгының күләгәсе» калган Җәләш хәзрәт образына карата кире мөнәсәбәттә тора.

Г. Ибраһимовны Руссога соңгысының хисләрне һәрнәрсәдән өстен куюы тарта. Руссо героинясы Юлия д'Этанж, бернәрсәгә дә хис итмичә яшәгәнгә караганда, тормыш белән араны өзү артыграк, дигән фикердә тора. «Яшь йөрәкләр» романындагы Зыя һәм Мәрьям дә хисләр дөньясында яшиләр. Кешенең, дип өйрәтә Руссо, шәхси бурычларыннан тыш җәмгыять, Ватан, бәхетсезләр алдындагы гражданлык бурычлары да бар. Г. Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм» хикәясендә герой, үзенең авыр тормышы турында гына түгел, ватандашларының язмышы, үз милләте тормышындагы трагик каршылыклар турында да уйлана.

Кант өйрәтүенчә, бурыч ул гакыл белән бәйләнешле. «Яшь йөрәкләр» романындагы руссочы Сабир гакыл көченә ия итеп сурәтләнә. Тәнкыйтьче Г. Газиз бу хакта менә нәрсә яза: «Агасы Сабир Зыяның бөтенләй гакысе. Ул чын Руссо фикерендә, эш өчен, чын кул эше өчен туган бер кеше. Ул мәдәниятне яратмый, шәһәрне сөйми, аңар хәтта язу тану да мөһим түгел. Ул шундый кызны хатынлыкка да ала... Зыя хис белән яшәсә, Сабир гакыл белән яшидер[3]». (Ассызык безнеке — Э. Н.)

Руссодагы шикелле үк, Г. Ибраһимовта да табигать, романтик функцияне үтәп, тотып алуы кыен булган хисләр агымын җанлы әйберләргә әверелдерүче «тышкы» материал хезмәтен үти. Монда без йолдызлы күкнең янсә җир өстенә караңгылык җәеп кояш баюның эстетик картиналарын күрәбез. Табигать кеше күңелендә әһәмиятле фикерләр уята, геройның халәтенә һәм гадәтләренә туры килерлек ритмда эшли. Бу очракта ул романтика таләпләренә җавап бирә. («Рухымның әллә кайчаннан бирле эзләп тә таба алмый йөргән теләге шул вакытта, шул караңгы төндә өзлексез коелган вак яңгырның шыбырдавы астында табылгандай тоела.» — Г. Ибраһимов, Сайланма әсәрләр. I том, 111 бит.)

Авыл хезмәт ияләренең әхлак матурлыкларын ачып биргән табигать руссочыл субъектив характерын югалта һәм танып беленергә тиешле объектив асылга әверелә. Печән чапканда карт Кәримнең Хафизга юл бирүе тикмәгә генә түгел («Табигать балалары»).

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 том. 135 бит.
[2] Шунда ук.
[3] «Аң» журналы. 1913 ел. 11 сан. 192 бит.

Халык җанын кешеләр белән якыннан аралашканда гына тирәнтен аңларга мөмкин. Хикәядәге әлеге эпизодның төп фикере әнә шуннан гыйбарәт. Кәрим карт Хафизга халыкның, милләтнең таянычы итеп карый. Хафиз — кыю, энергияле, хезмәт сөючән, акыллы егет. Аңа бәхетнең хезмәт һәм көрәш белән яулап алынуын төшендерү — «табигать баласы» Кәрим картның теләге әнә шул. Әсәрнең герое Хафиз шул табигатьнең асылына төшенергә, аның мәгънәсен, тирәнлеген аңларга өйрәнә.

Югарыда сөйләнгәннәр белән генә Руссоның әдәби әһәмияте чикләнми. Без монда образ төзелешен һәм эстетик идеалны күздә тотабыз. Татар шагыйре Дәрдмәнд швейцарлы язучы Родольф Тёпферның «Абакамның көтепханәсе» исемле повестен тәрҗемә итә. («Шура» журналы. 1909 ел. 4, 5, 9 саннар.) Руссоның тормыш казанында кайнаган героеннан («Икърар итү» исемле повесть) үрнәк алып, Тёпфер да үз героен төрле кичерешләр аркылы уздыра. Баланың саф, керсез күңеле һәр күренешкә игътибар итә һәм мораль яктан аның нинди икәнлеген тикшерә. Менә шул геройның «күңел диалектикасын» Толстой да сизә һәм «Бала чак» исемле повестен язган чакта Тёпфер әсәрен кат-кат укып чыга (француз телендә). С. Рәмиевнең «Ул исерек түгел иде» дигән автобиографик повестенда да Руссо, Тёпфер, Толстойга хас «күңел диалектикасы» сизелә («Казан мөхбире» газетасы. 1909 ел. 341—347, 349, 351—354, 361 саннар). Авыл малае Мәҗит тирә-яктагы кешеләр тормышындагы психологик һәм социаль күренешләрне күңеле аркылы үткәрә (әйтик, Мирза Сөләйманның крестьяннарга карата кыланышы һ. б.).

Эстетик идеалга килгәндә, мисал итеп Дәрдмәнднең «Хикәяи гыйшык» исемле шигырен күрсәтик. Аның темасы — туган җирнең эстетик матурлыгы — руссочы Гердерда да очрый.

Руссоның безнең әдәбиятыбызга булган йогынтысы турында түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин. Татар әдәбиятында Руссо идеяләрен кабул итү рус, төрек һәм Европа әдәбиятындагыга караганда башкачарак характерда бара.

Татарлар өчен Руссо — узган заман түгел, ә бәлки бүгенге көн. Якынлашып килгән революция үзенең характеры белән кешелекнең иң табигый таләпләренә җавап бирергә тиеш була. Октябрь революциясенең дөньякүләм характеры Руссоның татарлар тарафыннан интернационализм рухында кабул ителүендә дә үзенең эзен калдыра.

Каршылыклар һәм ялгышлар арасында гуманизмның ныклы җирлегенә килеп туктаган Руссоның тәҗрибәсеннән башка, аннан соңгы тәҗрибә, шул исәптән XX гасырдагы татар әдәбияты тәҗрибәсе дә булмаган булыр иде.

Рифат Сверигин

# ЗАМАН ҺӘМ ТОРМЫШ ТАЛӘБЕ

*Бүгенге проза турында сөйләшәбез*

Татарстан халык хуҗалыгының барлык тармаклары кызу темплар белән үсә. Республиканың төрле почмакларында яңа калалар салына, завод-фабрикалар төзелә. Бездә промышленностьның өр-яңа бер тармагы — автомобиль төзелеше туып килә. Нефть промышленностеның күрелмәгән темплар белән үсүе Татарстанны нефть һәм нефть продуктлары җитештерүче иң эре районнар сафына чыгарды. Соңгы елларда республикабызның авыл хуҗалыгы да зур уңышларга иреште. Авыл хуҗалыгы культураларыннан уңыш алу бермә-бер күтәрелде, терлекчелек продуктлары җитештерү һәм хәзерләү нык артты. Бу уңышларның һәммәсе республикабыз хезмәт ияләренең — данлы нефтьчеләрнең, химикларның, машина төзүчеләрнең, төзелеш эшчеләренең, колхоз-совхоз хезмәтчәннәренең — фидакарь хезмәте белән яуланды.

Әнә шул кешеләрнең хезмәте һәм тормышы, теләк-омтылышлары һәм рухи дөньялары бүгенге әдәбиятта ничек чагыла, никадәр тулы һәм тирән чагыла?

Дөресен әйтергә кирәк, соңгы берничә ел эчендә безнең проза бүгенге көн кешеләренең тормышын, заман темасын яктыртуга күбрәк игътибар бирә башлады. Бүгенге көн мәсьәләләре, замандашларыбызның әдәби образлары Ф. Хөсни, С. Рафиков кебек тәҗрибәле язучылар иҗатында гына түгел, роман, повесть кебек катлаулы жанрларны әле үзләштереп кенә килгән яшьләр иҗатында да киң урын алды. Моңа ышану өчен соңгы бер-ике ел эчендә дөнья күргән проза әсәрләренең исемнәрен санап чыгу да җитә: Г. Ахуновның «Чикләвек төше», Б. Камаловның «Ялыкмаслар», Ф. Хөснинең «Мәйдан» һәм М. Хәбибуллинның «Икмәк кадере» исемле повестьлары, С. Рафиковның «Тын елга буенда», Г. Мөхәмматшинның «Йөрәктәге эзләр» һәм Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романнары... Боларның барысы да заман темасына багышланган әсәрләр. Күрәсез, бу яктан зарланырлык урын юк. Безне сыйфат мәсьәләсе, бүгенге проза әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре борчый. Бергәләп тикшерәсе, хәл итәсе нәрсәләр нигездә шул өлкәгә карый.

Сүзне авыл темасына караган әсәрләрне тикшерүдән башлап китәсе килә. Билгеле булганча, безнең язучыларның күбесе авылдан чыккан кешеләр. Татар әдәбияты элек-электән авыл әдәбияты булып килде. Бездә бу теманы яктыртуның бай традицияләре бар, безнең бу темага караган бик шәп әсәрләребез бар. Ләкин, бүгенге авылны яктыртканда, элекке тәҗрибәгә таяну гына җитми. Авылның йөзе үзгәрде, аның кешеләре үзгәрде. Авыл белән шәһәр, авыл хуҗалыгы белән промышленность арасындагы элемтәләр көчәйде. Промышленностьның, бигрәк тә нефть һәм химия промышленностеның, кызу темплар белән үсүе Татарстан авылларына күп төрле яңалыклар алып килде. Шуның белән бергә, шактый гына кыенлыклар да тудырды. М. Хәбибуллинның

«Икмәк кадере» исемле яңа повесте шул хакта сөйли торган характерлы бер мисал була ала.

Исеменнән үк күренгәнчә, әсәрдә сүз икмәккә һәм җиргә мәхәббәт тәрбияләү, табигатькә, табигый байлыкларга карата сак мөнәсәбәт булдыру турында бара. Сүз дә юк, автор ифрат актуаль һәм мөһим мәсьәлә күтәрә.

Нефть идарәсе начальнигы Ходайбирдиннең гамьсезлеге аркасында, «Ленин юлы» колхозы зур зыян күрә. Нефть вышкасында авария булып, колхозның утыз гектар уҗымы эштән чыга. Бер ел эчендә генә дә скважиналар тирәсендәге дегет күлләренә батып, колхозның дүрт бозавы, колхозчыларның унҗиде сарыгы үлә. Колхоз егерме-утыз меңгә эшләткән күлгә нефть агып, бөтен маймычлар харап була. Шуларның һәммәсе колхоз председателе Сәхаб Кадыйровның бик нык ачуын чыгара. Ул, Ходайбирдингә җәза бирүне, аны партиядән чыгаруны таләп итеп, райком секретаре Бакир Галиев янына килә. Повестьның төп сюжет сызыгы шушы вакыйгалар тирәсендә оеша. Әсәрнең үзәгендә колхоз председателе Сәхаб Кадыйров белән идарә начальнигы Вәкил Ходайбирдин арасындагы конфликт ята.

Күрәсез, автор мәсьәләне характерлар каршылыгын көчәйтү исәбенә үткенәйтә. Конфликтның бер башында уңай образ Кадыйров, икенче очында тискәре Вәкил тора. Моңа каршы килеп булмый, билгеле. Әдәби конфликт буларак, М. Хәбибуллин сайлаган алым да начар түгел. Тик бу очракта әсәрдә күтәрелгән актуаль мәсьәләнең үткенлеге кими төшә. Нефть чыга башлау белән, Татарстандагы иген кырларына күпмедер зыян килгән икән, бу бит Ходайбирдин кебекләрнең гамьсезлеге аркасында гына килеп чыккан нәрсә түгел. М. Хәбибуллин исә мәсьәләне җиңел юл белән хәл итмәкче. Аныңча, Ходайбирдин кебекләрне партиядән куу, эшләреннән алу җитә. Шул чагында мәсьәлә үзеннән-үзе җиңел генә хәл ителәчәк. Безнеңчә, повестьның кимчелеге шунда, автор образларның характерларын тормыш агышы, заман сулышы, чынбарлыкның объектив законнары белән тиешенчә бәйләп җиткерә алмаган.

Табигатьне саклау, аның матурлыгын киләчәк буыннарга калдыру турында бүген күпләр баш вата. С. Герасимовның «Күл буенда» исемле фильмы да шул мәсьәләгә багышланган. Сүз анда Байкал күлен, аның табигый байлыкларын саклау турында бара. Әмма, «Икмәк кадере» повестеннан аермалы буларак, С. Герасимов мәсьәләне бөтен җитдилеге белән күтәрә. «Күл буенда» фильмы тормышка актив үтеп керүе, эмоциональ тәэсир көченең зурлыгы, җитди мәсьәләләрне җитди төстә хәл итүе белән игътибарны үзенә тарта. Иртәме-соңмы, табигатьне саклау мәсьәләсе татар совет әдәбияты алдына да бөтен кискенлеге белән килеп басачак. Аны уңышлы хәл итү өчен, язучы тирән һәм төпле белемле булырга тиеш. Шулай булмаганда, уңышлы әсәрләр иҗат итү кыен булачак. «Икмәк кадере» повестенда зур мәсьәләләр гадиләштереп, ансатлаштырып сурәтләнә. Шуңа күрә әсәр укучыны ышандыра алмый.

Нефть идарәсе начальнигы Ходайбирдингә райком бюросының мөнәсәбәте дә аңлашылып җитми. Бюро членнары, ни өчендер, мәсьәләне ныклап тикшермиләр, әлеге күңелсез хәлне китереп чыгарган сәбәпләрне тирәнтен ачмыйлар. Эш җиңел юл белән хәл ителә: гамьсезлеге өчен Ходайбирдинне партиядән чыгаралар. Әсәрне укыганда, шундый әшәке кешегә ничек итеп җаваплы пост тапшырганнар икән, дип аптырап утырасың.

Әсәрдә совет-партия работникларының күп кенә образлары белән очрашабыз. Ләкин алар шактый төссез һәм зәгыйфь эшләнгән. Повестьны укыганда, район, колхоз җитәкчеләре башкарган эшнең катлаулылыгын һәм үзенчәлеген тоеп булмый. Бакир һәм Мөршидәнең райком секретарьлары, Ходайбирдиннең идарә башлыгы икәнлегенә дә без автор сүзенә карап кына ышанырга тиеш. Бүгенге прозада, гомумән, җитәкче коммунист образлары күбәеп бара. Мондый образлар белән без «Икмәк кадере»ннән тыш, Фатих Хөснинең «Мәйдан», Гариф Ахуновның «Чикләвек төше», Барлас Камаловның «Ялыкмаслар» исемле әсәрләрендә, Сөббух Рафиковның «Тын елга буенда» романында очрашабыз. Бер карaганда, бу бик күңелле хәл. Шул ук вакытта сагаерга мәҗбүр итә торган нәрсәләр дә бар. Беренчедән, бу мавыгу материаль һәм рухи байлыклар тудыручылар—эшчеләр, колхозчылар, укытучылар һ. б. тормышын сурәтләүдән читләшү хисабына бармыймы? Икенчедән, әлеге нәрсә язучыларны бер урында таптануга, схематизмга китермәсме?.. Ә шундый куркыныч юк түгел. 1971 елда дөнья күргән биш әсәрнең өчесендә бер үк төрле ситуация

кабатлана. Җитәкче работникны башка районга эшкә күчерәләр. Әлеге әсәрләрнең һәркайсы шул вакыйганы тасвирлаудан башланып китә. Бу үз чиратында фабуладагы бертөрлелеккә, кабатлануга алып килә. Герой күңелендә бер үк төрле сораулар туа да котылгысыз. Бик кыенга туры килмәсме, эшли алырмы ул анда? Яңа урында аны ничегрәк кабул итәрләр? Бу эшкә гаилә членнары ничек карар?.. Кагыйдә буларак, геройлар яңа урынга башта үзләре генә күчеп килә. Семьялары иске урында калып тора. Шунда аларны тагын бер куркыныч — матур хатыннар яки яшьлек мәхәббәтләре сагалап тора. Мәсәлән Ф. Хөснинең «Мәйдан» повестендагы председательне кара кашлы, бик чая, ирдән аерылып кайткан кибетче хатын җәтмәгә эләктерергә йөри. М. Хәбибуллин повестенда яңа урынга килгән райком секретаре үзенең яшьлек мәхәббәтен очрата. Шулай әсәрләргә мәхәббәт мәсьәләләре килеп керә. Җитәкче работниклар, яшь җилкенчәкләр шикелле, мәхәббәт утларында яна башлыйлар.

Ф. Хөсни бу кыенлыктан шактый җиңел котыла. Колхоз председателенең хатыны тота да, төнгә каршы сыер җитәкләп, егерме чакрым ераклыктагы авылга, ире янына чыгып китә. (Ә бит тормышта алай булмый. Хәзер 7—8 чакрым араны да җәяү йөрмиләр.) Барып җитә ире янына, «алып кит безне», ди. Бу сөйләшүне тыңлап торган кара кашлы кибетче хатын яңа председатель тирәсендә бөтерелүдән туктый. «Мәйдан»да повестьның кыйммәтен төшерә торган ситуация һәм вакыйгалар бер бу гына түгел. Әйтик, кеше бөтенләй ят авылга эшкә барып төшә. Шуңа кунар урын да әзерләп куймаганнар. Отчет-сайлау җыелышы булган кичне, башын кая төртергә урын тапмагач, яңа сайланган председатель клубка кереп йоклый. Әлбәттә, бу хәлгә укучы ышанмаячак.

«Мәйдан» повестенда Ф. Хөснигә генә хас эчке җылылык белән язылган урыннар аз түгел. Шулай да, әсәр күңелдә каршылыклы тәэсир калдыра. Күренекле язучы хәзерге колхоз авылындагы зур иҗтимагый, политик һәм экономик үзгәрешләрнең тормыш-көнкүрешкә, характерлар тасвирланышына тәэсирен күреп җиткерә алмаган.

Яңадан ситуацияләр охшашлыгы турындагы мәсьәләгә әйләнеп кайтыйк. Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, «Икмәк кадере» повестендагы баш геройның хәле гадәттән тыш четерекле. Райкомның икенче секретаре булып эшләүче Мәршидә заманында Бакирны яратып йөргән булган. Алар бик күп көннәрне һәм төннәрне бергә уздырганнар. Мәршидәнең буйга җитеп килгән кызы Бакирдан икән. Шул ук вакытта колхоз председателе Кадыйров та Мәршидәгә күз атып йөри. Әйтәсе дә юк, шактый кыен ситуация. Әмма фаҗигага артык тирәнгә китми. Геройларыбыз бераз вакыт иләс-миләс йөриләр дә, ахыр чиктә хисләрен йөгәнләргә тиеш булалар. Чөнки партия членнарына, җитәкче кешеләргә болай йөрү килешми. Шуны яхшы аңлап, алар вакытында туктап калалар.

«Икмәк кадере» повесте турында тәнкыйть сүзләре күбрәк булды бугай. Әсәр, чыннан да, камиллектән шактый ерак тора. Шул ук вакытта аны бөтенләй бетереп ташлау да гаделлек булмас иде. М. Хәбибуллин хәзерге авылны, авыл кешеләренең уйларын, теләкләрен-омтылышларын шактый әйбәт белә. Аны шулай ук сюжет, композиция, конфликтлар корырга, детальләр белән эш итәргә дә өйрәтеп торасы юк. Тик алга таба ул тормыш дәрәсләреген исеннән чыгармасын, әсәрләренең ышандыру көче турында күбрәк уйлансын иде.

Шул ук сүзләрне Б. Камаловның «Ялыкмаслар» исемле повестена карата да әйтергә мөмкин. Бу әсәрдә сюжет ике сызык буенча үстерелә. Беренчесе — яшь баласын ташлап калдырган ананың еллар үткәч кичергән газаплары. Әсәрнең икенче сызыгы райком секретаре Кадергулов образы белән бәйләнгән.

«Ялыкмаслар»дагы райком секретарен да, партия эшләреннән, халык кайгысыннан бигрәк, шул ук мәхәббәт хисләре, яшьлек хатирәләре күбрәк борчый. Аның да кайдадыр беренче мәхәббәте калган икән. Бу әсәрләрне укыгач, күңелдә канәгатьсезлек хисе кала. Без авторлар җитәкчеләрнең эшләре, уйлары, халык файдасына булган олы һәм җаваплы хезмәтләре турында тулырак язарлар дип көткән идек. Өметләребез акланмады. Язучылар алгы планга партия җитәкчеләренең шәхси-интим кичерешләрен чыгарырга яраталар.

С. Рафиковның «Тын елга буенда» исемле романы Зәй электр станциясен төзүчеләр тормышын сурәтләүгә багышланган. Әсәр бүгенге эшчеләр, коммунизм төзелешенең алгы сафында баручылар тормы-

шына багышланган икән, анда аларның хезмәт процесслары сурәтләнми кала алмый. Шунсыз характерлар тулы ачылмаячак. Кешенең хезмәткә мөнәсәбәте нинди? Хезмәт аны ни дәрәҗәдә дулкынландыра һәм борчый? Нәрсә хакына ул тир түгеп эшли? С. Рафиковны әнә шундый сораулар борчый һәм ул аларга җавап бирергә тырыша. Бүгенге проза әсәрләре арасында әлеге роман әнә шул ягы белән аерылып тора. Әсәрнең сюжеты, конфликтлары аша кешеләрнең хезмәткә булган мөнәсәбәте һәм хезмәт процессындагы үзара мөнәсәбәтләре күрсәтелә. Зәй ГРЭСын төзү аларның намусын, чыдамлыгын, дөньяга карашларының ныклыгын сынаучы бизмәнгә әйләнә. Һәм әнә шул юнәлеш романның беренче битеннән соңгы битенә кадәр сузыла. «Тын елга буенда» романының уңышлы ягы шунда.

С. Рафиковка Зәй яклары яхшы таныш. Мондагы тормышны да, кешеләрне дә ул яхшы белә. Әсәр үзәгенә куелган конфликтлар тормышчан һәм кызыклы. Романда төзелеш мәсьәләләре белән бәйләнгән бик күп проблемалар күтәрелә. Аларны санап кына чыгу өчен дә күп вакыт, зур урын кирәк булыр иде. Күтәрелгән мәсьәләләр күп булганга күрә, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларда катнашучы геройлар саны да күп. Кызганычка каршы, аларның күбесе истә калырлык, тормышчан характерлар дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Әйтик, төзелеш башлыгы Андрей Никитин партком секретаре Солтан Сабировтан бер ягы белән дә аерылып тормый. Дересен әйткәндә, алар индивидуаль характер сыйфатларыннан бөтенләй мәхрүм. Никитинның адым саен «бу беренче пландагы эш» дип сөйләнүен генә үзенчәлекле сыйфат дип әйтеп булмый әле. Романдагы берничә образ гына азмы-күпме тулы эшләнгән. Аларның берсе — Васил Сафин. Ул туры сүзле, уйлаганын күзгә карап, бәреп әйтә торган принципиаль кеше. Василдан тыш, азмы-күпме уңышлы образлар рәтенә тагын Юлдашев керә. Бусы — Василның киресе, антиподы. Тулы канлы, үзенчәлекле геройлар иҗат итү өчен язучыга әдәби осталык, профессиональ хезерлек җитмәгән. Бу кимчелек кайбер башка язучылар өчен дә хас. Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның «Тема, идея, осталык» исемле мәкаләсендә бу турыда ачык әйтелә. Аның фикере белән килешми мөмкин түгел.

С. Рафиков геройларның портретларын сурәтләүдә артык саранлык күрсәтә, аның персонажларын ачык итеп күз алдына китереп булмый. Ә. Еникидәгечә, Г. Бәширов яисә Ф. Хөсни әсәрләрендәгечә, теге яки бу күренешнең билгеле бер вакыттагы халәте тотып алынмый. Язучы образлы картиналар тудырмый, хәрәкәт турында, вакыйгалар турында хәбәр итеп, сөйләп кенә бара. Вакыйгаларның әһәмиятлеләренә дә, әһәмиятсезләренә дә бердәй игътибар итү әсәрнең артык озынаюына китергән. Романда бертөрлелек хөкем сөрә. Вакыйгаларның артык салмаклыгы сюжет сызыгына да зыян иткән. Бер-берсен кабатлаучы яисә охшаш эпизодлар күп очрый.

Шәхси мөнәсәбәтләрне сурәтләүгә багышланган эпизодлардан корылык, рәсмилек бөркелеп тора. Яшь, матур кызлар Васил абыйларының сөйләгән сүзләренә «әйе шул», «алай икән» дип, ияк кагып кына торалар. Детальләр яңгырашына, аларның төгәллегенә игътибар җитми. Мәсәлән, бер урында ул самолетны «һава кошы» дип атый. Бирәдә «һава» сүзе бөтенләй артык. Халык «һава кошы» дип сөйләми. Язучы үзенең геройларын артык ясалма, купшы тонда сөйләштерә. Менә бер мисал:

«— Хатыныгыз?

— Арматурачы иде. Менә өченче ай инде болытларга үрмәли.

— Кранчымы?..»

Егет белән кыз менә болайрак сөйләшәләр:

«— Әйдә икәү бергә киного барыйк, билетын үзем алырмын.

— Кирәкми, бүген мин күргән картина бара инде».

Кызның җавабына игътибар итегез. Җавап бирүче бу очракта конкрет кинофильмны күздә тота бит. Димәк, кыз фильмның исемен әйтергә яисә, кешечәрәк итеп, «ул картинаны минем күргәнем бар», «мин ул картинаны карадым инде» дияргә тиеш иде.

Романда очраган тагын берничә кимчелеккә тукталыйк. Берничә еллар элек Гариф Ахунов, нефтьчеләргә багышлап, «Хәзинә» исемле роман язган һәм анда Әлмәт шәһәрен Кәлимәт дип алган иде. Әлеге «Кәлимәт» «Тын елга буенда» романына да килеп кергән. Беренчедән, «Хәзинә»дә уңышлы кулланылган бу исемне кабатлау кирәкмәс иде. Икенчедән, шәһәр исемнәрен үзгәртеп яисә бозып алу бик үк уңышлы алым да түгел.

Композицион яктан таркаулык романның эчке бөтенлегенә дә зыян китергән. Уйламаганда-көтмәгәндә әсәр уртасында яңа персонажлар килеп керә. Укучы аларның исем-фамилияләрен, кем булып эшләүләрен хәтерләп тә өлгерми, юкка да чыгалар.

Романның сюжет сызыгы кайбер урыннарда ак җеп белән генә тегелгән. Вакыйгаларның ни белән беткәсен укучы алдан ук сизеп тора. Мәсәлән, Васил — Нурзилә — Гөлзадә арасындагы мөнәсәбәтләр нәкъ шундый. Нурзиләнең начар хатын булып чыгачагын да, Васил белән Гөлзадәнең өйләнешеп бергә тора башлаячакларын да алдан ук белеп торасың.

Мондый кимчелекләр, билгеле, әсәрнең әдәби кыйммәтен нык төшерәләр. Шулай да, әсәрне тәнкыйтьләү белән мавыгып, хезмәт процессын тасвирлауда С. Рафиков алга сөргән уңай якларны күрмичә үтү дөрес булып бетмәс иде. Моңа кадәр тәнкыйть бу романны фәкать негатив планда гына карады [1].

Әгәр язучы, әдәби штамплар яисә уйлап чыгарылган катлаулы ситуацияләр белән мавыгып китеп, тормыш чынлыгын оныта башласа, аны бу очракта да бары уңышсызлык кына көтә. Хәзерге прозада андый авыруның шаукымнары да сизелгәләп тора. Соңгы елларда безнең әдәбиятка Б. Камалов, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов кебек сәнгатьчә сурәтләүнең яңа чараларын үзләштергән кызыклы прозаиклар килде. Аларның кайберләре Көнбатыш әдәбиятына хас тышкы, ялтыравыклы бизәкләрне яратып кулланалар. Бу бигрәк тә А. Гыйләҗевның «Урамнар артында яшел болын» исемле әсәрендә ачык сизелә. Б. Камалов та тышкы бизәкләргә зур урын бирә. Дөрес, А. Гыйләҗевтан аермалы буларак, ул халыкчан сурәтләрне — халык тәгъбирләрен, халык әйтемнәрен мул кулланә. Шулай да ул әйберләр һәр очракта да әсәрнең рухына, геройларның характерына ятышып бетми, үзмаксатка әйләнә башлый. Нәтиҗәдә образларның табигыйлеге югала, сурәтләрнең эмоциональ тәэсир көче кими. Б. Камалов әсәрләрендә ситуацияләрне кирәгеннән артык катлауландыру күренешләре дә очрый. Билгеле булганча, форма өлкәсендәге яңалыклар тиешле эчтәлек, идеяләр, авторның укучыга әйтерлек ачык фикере булганда гына уңай нәтиҗә бирә. Яңа алымнарны мул куллану гына әдәби осталыкның дәрәҗәсен билгеләми.

Ә. Баяновның «Ут һәм Су» исемле романында укучыга олы тема тәкъдим ителә. Сүз анда Түбән Кама ГЭСы һәм аны төзүчеләр турында бара. Әмма бу җаваплы һәм җитди теманы язучы тиешле югарылыкта башкарып чыга алмаган. Үтә яңа булып күренгән алымнар гына романның кимчелекләрен яшереп кала алмаган. Ә. Баянов проза кебек җитди жанрда характер тудыру осталыгын үзләштереп җитмәгән әле. Ә бу, мәгълүм булганча, әдәби әсәр язарга алынган кеше алдына куела торган иң мөһим таләпләрнең берсе. Геройлар нинди сыйфатлары белән хәтердә калалар? Кай яклары белән бер-берләреннән аерылалар? Характерны характер иткән төп сыйфатлар нинди? «Ут һәм Су» романын укыганда әнә шундый сораулар туа. Ә җавап табып булмый. Геройлар төссезләр, чырайсызлар, бер-берләреннән фәкать исем-фамилияләре белән генә аерылалар.

Гомуман, «Ут һәм Су» романында җанлы, хәтердә уелып калырдай итеп эшләнгән картиналар аз. Лирик дип уйланылган образлар да (авторның күңел җылысы белән сугарылмагангамы) дулкынландырырлык, хисләндерерлек түгел. Мәсәлән, автор Каманы матур кыз рәвешендә сурәтли, поэтик образ дәрәҗәсенә күтәрергә уйлый. Әмма герой хыялындагы образны һәм реаль кешене елга белән чагыштыру яисә елганы гүзәл кыз рәвешендә сурәтләү аңлашылып җитми. Күчешләр кинәт һәм хәзерлексез килеп чыга. Мондый «модернистик» алымга исәп тотып кына укучы күңелен яулап булмый [2].

Романның баш герое Фаез үзе дә сәеррәк кеше. Без авторның «Яшьлегемнә ээлим» повестенда да шундыйрак бер герой белән очрашкан идек. Дөрес, һәр геройның идеаль образ булуын таләп итеп булмый. Шулай да, язучы геройның гел сәер, кимчелекле якларын гына популярлаштыра башлый икән, күңелдә ризасызлык хисе уяна. Мәсәлән, Фаез кечәнеп-кечәнеп башкалар алдында матур күренергә яисә кәлкегә калмаска тырыша («Яшьлегемнә ээлим»дәге Әнис тә шундый иде).

[1] Ф. Хөсни. Шунда, тын елга буенда. «Социалистик Татарстан» газетасы, 1971 ел, 10 ноябрь.

[2] Бу моментка үзенең бер мәкаләсендә Б. Камалов та игътибар итә. («Социалистик Татарстан» газетасы, 7 май, 1972 ел.)

Фәезнең Борис белән булган бәрелешләренең нигезендә чиктән тыш күпертелгән мин-минлек тойгысы да ята.

Хәзерге роман һәм повестьларда күпсүзлелек чире көчәеп килә. Без еш кына әсәрдә вакыйгалар үсеше, герой характеры яисә композиция өчен һич кирәге булмаган, авторның күп белүен, эрудициясен күрсәтү өчен генә кертелгән эпизодларга юлыгабыз. А. Гыйләҗевның «Урамнар артында яшел болын» исемле әсәрендә персонажларның урынлы-урынсыз анекдот сөйләп йөрүләре шактый туйдыра. Ә. Баяновның яңа романындагы югары материя, галәм, Леонардо да Винчи, Бакминистер Фуллер, антиэтропия һ. б. турындагы фәлсәфә фәкать авторның эрудициясен күрсәтү өчен генә кертелгән. Популяр чит ил фильмнарының эчтәлеген сөйләү дә «интеллектуальлек» фонын бирү өчен файдаланылган өстәмә һәм мәҗбүри булмаган кисәкләр генә. «Шантеклэр королевасы» һәм «Килиманджаро карлары» кебек чит ил фильмнары нәкъ шул максатларда файдаланылган.

Соңгы вакытта роман һәм повесть кебек күләмле жанрларга таләпләрнең кими баруы борчый. Озын, композицион яктан таркау, гражданлык пафосы сүрән, үзәк идеяләре ачык билгеләнмәгән һәм эшләнешләре ягыннан зәгыйфь әсәрләр туктаусыз язылып, басылып тора. Әдәби форма өлкәсендәге эзләнүләр үзмаксатка әйләнсә, мондый әсәр язучыга уңыш, укучыга эстетик ләззәт китермәячәк.

Яшь кешенең тормыш, хезмәт сукмагындагы адымнары, аның гражданин буларак формалашуы, җәмгыятьтә үз урынын табып, гомуми эш өчен көрәштә чыныгуы — зур, җаваплы һәм бәрәкәтле тема. Ул әдәби җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә тора. Ә. Баяновтан тыш, бу темага мәрхүм Г. Мөхәммәтшин дә үзенең «Йөрәктәге эзләр» исемле романында мөрәҗәгать иткән иде.

Институт тәмамлаган яшь егет Айзат үзе эшкә билгеләнгән урынга — Себернең ерак районнарының берсенә бара. Максаты: үзенең семья хәлләрен сөйләп, бирегә килә алмаячагын аңлату һәм, рөхсәт алып, Казанга кайтып китү. Ерак юлда кешеләр белән очрашулар, уйланулар егетнең фикерен үзгәртә, әсәр барышында кешенең дөньяга карашы үзгәрә. Г. Мөхәммәтшин әнә шул турыда ашыкмыйча сөйли, җанлы картиналар аша кеше психологиясендәге үзгәрешләрне сурәтли.

Әсәрне җыйнаграк итеп эшләргә дә мөмкин булыр иде. Кабатланулар, кайбер очрашуларның эчпошыргыч охшашлыгы әсәрнең сюжет үсешен шактый тоткарлый. Төссез, коры образлар да бар бу әсәрдә. Шуларга да карамастан, Г. Мөхәммәтшин кулланган әдәби алымнар: Айзатның үткәннәр турындагы уйланулары, мәхәббәте хакында зур лирик чигенешләр әдәби яктан акланган. Аларның төп вакыйга белән янәшә үстерелүе Айзатның рухи үзгәрешен ачыграк дәлилләү өчен кирәк. Дөрес, вакыты-вакыты белән әлеге ике сызыкны — хәзерге вакыйгалар белән үткәндәгеләрне — сурәтләгәндә чама хисе югалып та киткәли. Вакыйгалар планының кайсы да булса берсе озаграк дәвам итеп, икенчесе шактый тоныклана.

Нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне әйтәсе килә: язучыларыбызның олы темаларга мөрәҗәгать итүләре, замандашыбызның рухи дөньяларын, фидакарь хезмәтләрен тасвирларга омтылышлары, һичшиксез, уңай күренеш. Әмма бу язучыдан тормышның яңа күренешләрен, кешеләрнең эчке дөньяларын үтә җентекләп өйрәнүне һәм үзенең профессиональ хәзерлегенең тиешле югарылыкта торуын, җитдилеген һәм зур җаваплылык хисен таләп итә.

1970—71 еллар татар прозасында заман героен сурәтләүдә мәгълүм җанлану сизелсә дә, зур иҗат уңышлары турында сөйләү әлегә иртәрәк һәм урынсыз булыр иде. Яңа алымнар белән тәҗрибәләр күп булды, шулай да яңа формага һәр очракта да тиешле эчтәлек салынмады, яисә алар бер-беренә ярашып җитә алмадылар. Әдәби әсәрнең кыйммәтен яңа форма алымнарыннан бигрәк, аның нигезенә салынган тормышчан идея һәм тиешенчә эшләнгән характерлар билгели.

Олы гражданлык мотивлары белән сугарылган, җитди, тормышчан проблемалар куелган әсәрләр иҗат ителгәндә, замандашыбызның олы омтылышлары, рухи һәм интеллектуаль йөзләре тулырак ачылганда гына прозабызда чын мәгънәсендә иҗат эзләнүләре хакында киң сөйләшү алып барырга мөмкин булыр.

# КОЯШЛЫ ДӨНЬЯ

Күз алдына китерегез: кемдер урамга чыкты һәм кояш нурларын лупа аша учына төшерде ди. Әлегә уч төбе белән лупа арасы шактый ерак — учта тонык һәм салкын зур тап хасил була. Күчерелмә мәгънәдә алганда, бу — роман. Шунда әлеге кеше, фокусны эзләп, пыяланы учына якынайта төшә. Тап кечерәя, яктыра, җылына бара. Бусы — повесть. Ниһаять, нурлар бер ноктага җыелып бетә — кулны пыяла астыннан тизрәк тартып алырга туры килә. Күз чагылдырырлык якты, бәләкәй нокта түзә алмаслык пешерә.

Бу күренеш әйтерсең лә юри Рөстәм Кутуй өчен уйлап чыгарылган. Аның уч төбенә төшкән кояш нуры кебек бәләкәй, шул нур кебек үк пешереп-яндырып ала торган хикәяләре аеруча уңышлы була. Рөстәмгә повестьлар авыррак бирелә, ә гадәти романнарны ул, билгеле булганча, бөтенләй язмый. Бу мәкаләдә мин аның «Юлда»[1] исемле соңгы китабы турында сөйләргә телим. Ул проза өлкәсендә язучы алып барган иҗади эзләнүләрнең йомгагы кебегрәк булып тора.

Рөстәм Кутуй әсәрләренең тематик диапазоны шактый киң. Китапны ачуга, сез анда малайлар мәхәббәте кебек саммми һәм моңсу, бала чакта пешкән беренче җәрәхәт кебек сыкрата торган «Беренче очрашу» исемле өч кенә битлек миниатюраны очратырсыз. Аннан китаптагы башка хикәяләрне укырсыз: сугышта өч улын югалткан солдат хатыны Луша турында, иң кирәк, иң кыен минутта ярдәмгә ашыгучы «Нихәл» кушаматлы эчкерсез кеше турында. Шуннан сугыш бетә, һәм китап битләренә яңа геройлар килә. Сез бер врачның авылда нинди маҗараларга таруы турында, физиклар арасындагы бәхәсләр турында белерсез, яшь художникның рәсем ясавын күзәтерсез, җыентыктагы бердәнбер повестьның төп герое булган солдатның бала чак хатирәләре турында уйланырсыз һәм, ниһаять, китаптагы иң яхшы хикәяләрнең берсендә — «Еллык бөҗралар» дип исемләнгәнендә табигатькә гашыйк искиткеч кеше белән очрашырсыз.

Рөстәм Кутуй әдәбиятка каршылыксыз, җиңел килеп керде, үзенә генә хас буяулар дөньясы, даими ритмы, үзенчәлекле фикере булган стилист буларак килеп керде. Ул үзе кичергән, үзе белгән, күңеленә нык урнашкан һәм якын булган нәрсәләр турында гына яза. Кутуй әсәрләре асыллары белән үк лирик характерда, җыентыктагы повесть һәм хикәяләрдән авторның тынгысыз җанын, борчылулы тавышын сизәсең, һәм аның тавышы, дөньяга карашы, халәте бөтен китапны тотып торучы төп персонажга әверелә һәм анда тупланган аерым-аерым хикәяләрне әйтерсең лә бер герой язмышына багышланган үзенчәлекле романга әйләндерә. Ул — авторның лирик герое. Әгәр без аны Рөстәм Кутуй үзе дип, хикәяләрдә аның башыннан узган хәлләр тасвирлана дип уйласак, бу үтә беркатлылык булыр иде. Юк, алай түгел, реалистик әдәбиятта кабул ителгәнчә, аның герое сәнгатьчә гомумиләштерелгән, типиклаштырылган образ. Бер дә юкка гына лирик герой хикәяләрдә әле сугыш чорындагы малай, әле врач яки физик, художник яки солдат итеп бирелми. Ләкин шунысы кызыклы, аның тормыш этаплары гаять эзлекле төстә тасвирлана. Башта ул укый, тормышны өйрәнә, килә вакыт, аның өстенә беренче авыр кайгы төшә: фронтта әтисе һәлак була. Аннан лирик герой олыгая, дөньяны тирәнрәк аңлый, эшли, ярата, нәфрәтләнә башлый. Ул инде явызлыкның нәрсә икәнен аңларга өйрәнә, күп кенә ачышлардан һәм күңел кайтулардан соң, «Еллык бөҗралар» исемле хикәядә, шәһәр шау-шуыннан еракта торып яшәгән еллар, тормышка ашмаган хыяллар турында уйлану. Идея ярындагы комда кояшта кызыну өчен, табигать кочагына китә. Һәм нәкъ менә шунда әлеге үзенчәлекле романның төп лейтмотивы яңадан бөтен көчкә яңгырый башлый — тулы бәхет белән яшәү өчен,

[1] Р. Кутуй. На дороге. Повесть и рассказы. Рус телендә. Казан. 1969 ел.

кеше табигать белән килешеп яшәргә, туган җирен, халкын, илен яратырга тиеш.

Язучы буларак, Р. Кутуйга нәрсә хас, аның талантының үзенчәлеге нидә? Барыннан да элек, иҗади хыялының төгәл булуында. Ул хыялның символик характерда булуында. Һәм, ниһаять, авторның бөтен әсәрләрендә кулланылган сөйләм алымында. Моңа ышану өчен, мисал төсендә, «Тынлык» исемле хикәяне карап узыйк.

Хикәянең исеме үк символик характерда. Ул, табигать хәлен аңлатудан бигрәк, гомеренең соңгы көннәрен туган авылында яшәргә җыенган ялгыз картның салмак, шактый бертөсле яшәү рәвешенә ишарәли. Автор моңа нинди чаралар ярдәмендә ирешә соң, шуларга игътибар итик. Язучыны, вакыйганың үзеннән бигрәк, геройның хикәядә сөйләнгән вакыйгага кадәр булган хисләрен һәм кичерешләрен психологик яктан төгәл сурәтләп бирү кызыксындыра. «Һәр очып узган чебенгә дә өреп калмасын» өчен, карт этенең тамагын туйдырып куя, урамнан исәнләшеп киткән хатынның сәламен алмый, чөнки «бер генә дә артык сүз сөйләшәсе килми», кызлары шәһәргә күчеп кил дип чакыралар, карт катгый төстә баш тарта: «ташка түзәрлек аяклары, телевизор карарлык күзләре юк», аның баш өстендә болытларның да, ак тәтен кисәге кебек, яңгырсызлары, тормыш әсәре булмаганнары гына йөзә. (Бирәдә антитеза кулланылган: язучының яраткан символы яңгыр — яшьлек, сәламәтлек билгесе. «Димка», «Яңгыр астында ике кеше» исемле беренче хикәяләрен искә төшерегез.) Кыскасы, «кирәкми», «теләми» кебек сүзләр ярдәмендә хикәядә ялгызлык, моңсулык атмосферасы тудырыла. Шул ук вакытта бу детальләр, хикәядәге башка детальләр белән бергә, тагын да катлаулырак икенче бер максатка — әсәрнең шигъри яңгырашын тудыруга хезмәт итәләр. Рәстәмнең үзенчәлекле таланты менә шунда ачыграк күренә дә инде. Әйтик, картның уртак сөйләм аша бирелгән истәлекләрендә күпме яшерен шатлык, тантана бар.

«Карт, кулларын тез өстенә куеп, оныкларының ыгы-зыгы килүен сүзсез генә күзәтеп утырды. Үзе белән балалар арасында кан якынлыгы эзләп, аларның гадәтләрен өйрәнде. Иң кечкенәсе, очып барган авыр төклетурага карап, хәйран калып катып калгач, аңарда үзенә якын нәрсәдер булуын чамалап, тын гына шатланды. Нәрсә күрде ул аның карашында, карт моны төгәен генә әйтеп бирә алмас иде, ләкин чамалавын төгәл чамалады һәм, эченнән балкып, кыска гына бер сүз әйтте: — Безнеке».

Һәм әсәрдә шундый шигърият тугач, без үзебез дә сизмәстән геройга симпатия белән карый башлагач кына, автор хикәягә нокта куя: баксаң, бу — картның якты дөньядагы иң соңгы көне булган икән. Әйе, Василий Никодимыч үлә, ләкин тыныч җан белән үлә.

Юл уңаеннан тагын бер күзәтү. Василий Никодимыч та, «Тишек медаль» исемле күптән язылган хикәядәге Ленка да бер үк хәрәкәт ясыйлар — кулларын тез өстенә куеп утыралар. Ләкин бу кабатлау түгел, ә шул ук ачыш, тормышның кайсыдыр мизгелендә автор башына килгән бәхетле ачыш. Халык бит, башланып кына килгән балалык матурлыгы белән инде сүнеп бара торган картлык матурлыгы арасында якынлык булуын белдерергә теләгәндә, ярым шаярып: «Картлык ни дә, яшьлек ни», ди. Р. Кутуй шул охшашлыкның, якынлыкның тышкы гәүдәләнеш формаларын эзли һәм таба. Гомумән, тышкы хәрәкәтләрнең аңга буйсынган булуын, аларның кеше хисләре һәм кичерешләре белән бәйле булуын ачу — Р. Кутуй стиленә хас сыйфатларның тагын берсе.

Р. Кутуй әсәрләрендәге һәр нәрсә язучы тарафыннан иҗат ителгән кояшлы дөньяга чынлык, реальлек хисе бирә һәм, электрон микроскобындагы лазер нуры кебек, үзгә бер үткенлеге белән аның иҗатын кече формаларда эшләүче башка әдәбиятчылардан аерып тора.

1962 елның җәендә язучы әтисе Гадел Кутуйның каберен зыярат кылырга Польшага бара. «Яңгыр тавышы» исемле хикәя шул сәяхәт тәэсирендә языла. Автор җиңел юлдан да китә ала — әлеге сәяхәтне игътибар үзәгенә куеп, гадәти юлъязмалар яза алыр иде. Хәлбуки, ул моның белән генә чикләнми. Һәрвакыт яңача язарга омтылучы автор буларак, ул үзенә хас символик сөйләм стиле алымында хикәясен гомумиләштерә һәм лирик геройның очраклы рәвештә рус эмигранты белән очрашуын төп эпизодка әйләндерә. «Ә ул минем әтием булырга мөмкинме?» — дип сорый герой үз-үзеннән. Әгәр хикәя герое урынында сәяси мәсьәләләрдә тәҗрибәсезрәк башка берәү булса, ул, ихтимал, эмигрантның әдәпле, нәзакәтле кыланышларыннан эреп китәр иде. Ләкин сәяси сизгер булу, әлеге хәлне сәяси тирән

бәяли белү геройга үзе үк куйган сорауга: «Юк, мөмкин түгел», дип җавап бирергә нигез бирә. Ни генә булмасын, теләпмә-теләмичәме, халкын, рус җирен ят җиргә алмаштырган кешә анық әнисенең ире була алмас иде. Әлегә сәяхәтнең сәяси ягы, шул рәвешчә, аңлы рәвештә куертыла, үткенәйтелә.

Кыска вакытлы очрашулар («Яңгыр тавышы» янына «Карлыгач — авыл кошы» исемле хикәяне өстәргә мөмкин), очраклы туры килүләр («Картлач, телефонга») яки күршедәш булып яшәүләр («Люстра») авторга гүя үзенең эстетик принципларын расларга хезмәт итә. «Ныклабрак тирә-ягыгызга карагыз һәм игътибар белән күзәтегез,— ди тесле язучы,— сезнең алда көнкүреш һәм этник, социаль һәм сәяси, фәлсәфи һәм һәртөрле башка закончалыклар ачылыр». Аның прозасының интеллектуальлеге һәм заманчалыгы, әерым алганда, тагын шунда күренә, ул хикәяләренә һәркемгә билгеле, тапталган нәрсәләрне якын да җибәрми, хакыйкатьне шаблон җаваплар, беркатлы нәтиҗәләр белән алыштырмый, ул укучының талантына ышана, аларга нәтиҗәне үзләренә ясарга калдыра.

Билгеле, бу кояшлы дөньяның үзенә генә хас күләгәле яклары да бар. Менә шуларның берсе һәм, безнең уебызча, иң җитдие. Р. Кутуй еш кына әле Пушкин белән Лермонтовтан, әле Тургенев белән Куприннан, әле Блок белән Бабельдән, әле Есенин белән Маяковскийдан һәм башка бик күп язучылардан әдәби өзекләр китерергә ярата. Дөрес, моның коры хәреф ятлаучылык һәм литературщина (ялган әдәбият) белән бернинди галәкәсе юк. Ул әдәбиятны искиткеч нык ярата. Һәм классикларга да тик торганнан гына мөрәҗәгать итми, бик кирәк булганда, шуны бөтен күңел агышы катгый таләп иткәндә генә китерә. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, бу — тагын да язучының иҗат үзенчәлеге, художникның индивидуаль стиле турында сөйли торган факт.

Әмма хәтта Пушкиннан да өзекләр китерергә кирәкми. Бу — искереп беткән РАПП лозунгысына кире кайту түгел. Без: «Пушкинны заман корабыннан сөрергә» җыенмыйбыз. Бирәдә эш бөтенләй башка нәрсәдә. Язучы алдыннан, бигрәк тә ихлас күңелле, табигатә белән үк әйләнә-тирәне конкрет, сәнгатьчә кабул итәргә сәләтле язучы алдыннан, тормыш панорамасы ваклапмаган, бозылмаган килеш, үзенең табигый хәлендә ачылырга тиеш. Тормышның җанлы хәрәкәтенә чумган язучы үзе актив шәхескә әйләнә, шул чагында аңарда теге яки бу конкрет тема өлгерә. Алга таба исә, өстәл янына утыргач, әлеге темага яраклы рәвештә, образлар, конфликтлар, сюжет линияләре табигый хәлгә килергә тиешләр. Гаҗәеп төрле һәм искиткеч серле тормышка язучы азат килеш, бернинди әдәби концепцияләр белән богауланмаган хәлдә якын килергә тиеш. Хәлбуки, бу әле язучыга белем кирәкми диган сүз түгел, киресенчә, ул мөмкин кадәр тирән белемле булырга тиеш. Бу мәсьәләдә безгә бөек Горький үрнәк була ала. Минем исә, алда әйтелгәнне кабатлап, шуны гынә әйтәсем килә: реаль тормыш белән очрашканда Р. Кутуйга әдәби белем йөгеннән арынырга өйрәнергә кирәк.

Ун ел өзлексез эшләү дәверендә язучы күп нәрсәгә өйрәнде. Әгәр аның иң яхшы әсәрләрендә (андыйлар рәтенә мин бер тапкыр телгә алынган «Еллык бозралар» хикәясен, күптән үк язылган «Топольләрдән мамык оча» исемле повесть-новелланы, рецензияләнә торган китапта басылган «Юлда имән чикләвекләре белән ялгызым» исемле повестьны һәм күп кенә хикәяләрне кертер идем) язучы күпмедер дәрәҗәдә 50—60 елларга хас тормыш сулышын, без яшәгән чорның шатлык-кайгыларын, борчу-мәшәкатьләрен чагылдыра алган икән, моның өчен ул җентекләп һәм тирәнтен бүгенге заманны өйрәнүенә бурычлы. Тагын шундый кызыклы закончалык күзгә ташлана: язучы чынбарлыкка никадәр якынрак торса, аның иҗат фантазиясе дә шул кадәр шәбрәк эшли, тормыш күренешләрен гомумиләштерү нәтиҗәсендә ирешкән нәтиҗәләре дә шул кадәр тирәнрәк һәм көчлерәк чыга.

Ритм белән, фикер музыкасы белән язар өчен һәм тулысынча хискә бирелер өчен, ювелирча чарланган осталык язучының «тире астына» китәргә тиеш. Р. Кутуй кайчандыр үзенең лирик герое, язучы Арсений авызыннан («Җыр» исемле хикәя) мин «коры, авыр һәм күңелсез язам» дип әйттергән иде. Ул заманнар артта калды. Хәзер ул «миңа илһам сәгатьләре» еш килә дип әйтә ала. Бу исә аның осталыгы торган саен «тире астына» китә бара, аның артистлык табигатенең иң яшерен почмакларына кереп килә диган сүз.

Кыскасы, хәзер Р. Кутуй иҗатының чәчәк аткан чорын кичерә. Гүзәл шигърият дөньясы аны беркайчан да ташламасын иде.

**ИЛДУС АХУНҖАНОВ.**

# НУР ЧӘЧЕП ТУДЫ



*Ш. Шамильский.*

1912 елда «Сәйяр» труппасы артисткалары С. Гыйззәтуллина-Волжская, Фәхренисa Сәмитова, Зөләйха Богданова Уфага килеп тагын бер татар профессиональ драмтруппасы оештыралар. С. Гыйззәтуллина-Волжская бу хакта түбәндәгечә яза: «1912 елны мин Уфада «Нур» труппасын оештыру дәрте белән янып йөри идем. Булачак труппага кешеләр табарга кирәк иде. Шул чакта атаклы җырчы Фәттах Латыйпов миңа Пермь шәһәрендәге һәвәскәрләр арасында театрны бик сөюче, бик сәләтле Шакир Вахитов дигән бер яшь егетнең барлыгын әйтте. Егет үзе Агафуровлар дигән байларда приказчик булып эшли икән. Фәттах Латыйпов белән сөйләшкәннән соң, мин шул егетне «Нур»га чакырып телеграмма җибәрдем. Озак та үтми, Шакир, үзенең Нуретдин Хәнҗәров дигән тагын бер яшь һәвәскәр иптәшен ияртеп, Уфага килеп тә җитте. Труппа, ниһаять, җыелып бетте. һәм Шакир, үзенә «Шамильский» дигән сәхнә фамилиясе алып, «Нур»-ның беренче спектакленнан ук уйный башлады»[1].

«Нур» труппасы оешып, Уфада 1912—1913 елгы сезонын тәмамлагач, Себер, Урал якларында була, аннан Оренбургка килә, 1913—1914 елгы сезонда шушы шәһәрдә кала. «Нур» труппасы күп кенә шәһәрләрдә гастрольдә йөргәннән соң 1916 елның көзендә Уфага әйләнеп кайта һәм даими рәвештә шунда эшли башлый.

Бу елларны «Нур» труппасы Уфаның сәләтле яшь һәвәскәрләре исәбенә тулылана бара. Театрга Әмин (Габдулла) Зөбәиров, Локман Аитов, Исхак Әлмәшев, Гата Исхаков, Маһирә Мирвәлиева кебек сәләтле яшьләр килә. Театрның репертуарына, татар драматурглары Г. Камал, М. Фәйзи, Ф. Әмирхан, әзербәйҗан драматургы Н. Вәзиров пьесалары белән беррәттән, көнбатыш әдәбияты классиклары Ж. Мольер, Ф. Шиллер әсәрләре кертелә.

Труппаның 1916—1917 елда Уфадагы сезоны М. Фәйзинең «Кызганыч» исемле яңа драмасы белән ачыла. Бу пьесада С. Гыйззәтуллина белән Казанский Гәүһәр һәм Заһит рольләрен башкаралар. Алар арасындагы мәхәббәт драмасы тамашачыда зур тәэсир калдыра. Артистлар пьесаның социаль яңгырашына әһәмият биреп һәм үз образларын тормышчан итеп башкарырга омтылалар.

Аннан соң «Яңа клуб» бинасында Мольерның «Саран»ы куела. Бу пьесаны да Г. Камалның «Уйнаш», «Бәхетсез егет», Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» постановкаларын да тамашачылар җылы кабул итәләр.

Давыллы революция елларына «Нур» идея-иҗади яктан билгеле дәрәҗәдә чыныгып, революцион сафларда нык торырлык тәҗрибә туплап килде.

1917 елгы Февраль буржуаз демократик революциясеннән соң, цензура бетүдән файдаланып, «Нур» труппасы 3 апрельдә Г. Коләхметовның «Яшь гомер» исемле

[1] Ә. Еники. Ш. Шамильский. Казан. 1965 ел. 5 бит.

пьесасын сәхнәгә куя. Сүз уңаенда әйтеп китәргә кирәк, моңа хәтле театр тарихына карата язылган әдәбиятта революция алды елларында «Сәйяр» труппасы тарафыннан Горькийның «Мещаннар» пьесасы куелуы турында гына әйтелә. «Нур» һәм «Сәйяр» труппаларында «Яшь гомер» пьесасының куелу факты бөтенләй диярлек искә алынмый. Ә бит татар пролетар әдәбиятына нигез салучыларның берсе Г. Коләхметовның «Яшь гомер» пьесасын кую факты үзе генә дә «Нур» труппасының бик кыска вакыт эчендә идея-эстетик яктан да, иҗади яктан да ныгуы, өлгерүе турында сөйли.



С. Гыйззәтуллина-Волжская сәхнәдә.

1917—1918 еллар сезонында «Нур» А. Островскийның «Яшенле яңгыр» исемле драмасын сәхнәләштерә. Бу пьесада С. Гыйззәтуллина-Волжская Катерина образын иҗат итә. «Томкынлыкта изелгән вә шул сәбәпле дөнья белән бәхилләшергә мәҗбүр булган мазлума яшь килен Катя ролен Волжская, берәүне чыннан сөюдән башка гөнаһсы булмаган вә шул ук горефтән газап күргән гашыйк Борис ролен Казанский чынлап та үз рольләренең рухына кереп уйнадылар» [1],— дип яза рецензент бу драма хакында.

Уфада эшләү дәверендә «Нур» труппасы Уфа тамашачыларын театрны яратырга, ихтирам итәргә өйрәтеп кенә калмый, яшьләргә демократик тәрбия бирү буенча да зур роль уйный, труппа чын-чынлап Уфа тамашачыларының олы мәхәббәтен казана.

Башкорт халкы тормышы сурәтләнгән пьесалар да һәрвакыт диярлек труппаның игътибар үзәгендә була. Мәсәлән, үзешчән драматург Сөләймановның «Ашказар» пьесасын артистлар шатланып каршы алалар һәм сәхнәгә кую чарасына керешәләр. Бу хакта «Тормыш» газетасы болай дип язып чыга: «Җомга көн, 30 мартта «Новый клуб» залында «Нур» труппасы тарафыннан мәшһүр «Ашказар көе»нең вакыйгасыннан алынып язылган «Ашказар» исемле дүрт пәрдәле драма уйнала. Җырлау, бию, скрипка вә курай уеннары булачак. Башкортның кыз бирү вә туй итү гадәтләре күрсәтеләчәк. Бу пьеса өчен махсус яңа кием-ләр хәзерләнде». Кызганычка каршы, «Ашказар» пьесасы матбугатта басылып чыкмаган һәм аның кульязмасы да сакланмаган. Кыскача рецензия һәм башка чыганакларга караганда, бу спектакль этнографик планда куела. Җыр, бию, төрле уен, туй йолалары, Ашказарга сунарга барган җирендә батып үлгән яшь кияүгә багышлап курайчылар тарафыннан көй чыгару ярышы күренешләрен эченә ала.



Г. Казанский.

«Нур»ның 1918 елны «Ашказар»ны куюы нәтиҗәсез калмый. Ике елдан соң шул ук темага «Ашказар» исемле драманы башкорт драматургы Буранулов яза һәм бастырып та чыгара.

Гражданнар сугышыннан соң С. Гыйззәтуллинаның талантлы шәкертләре Ш. Шамильский, Г. Казанский, И. Әлмәшев h. б. Уфа, Оренбург, Семипалат, Чиләбе, Ташкент, Баку h. б. шәһәрләрдә труппалар оештыралар, яшь артистлар хәзерләүгә күп көч куялар. Ш. Шамильский, Г. Казанский h. б. артистлар Уфада эшләп, Башкорт совет милли театрының формалашуына зур ярдәм күрсәтәләр.

[1] «Тормыш». 1918 ел. 25 февраль.

Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә Башкортстан һәм РСФСРның халык артисты Әмин Зөбәиров «Бетен йөрәктән» исемле мәкаләсендә татар артистларының эшен зур хөрмәт белән искә алды[1].

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.

# ШИҺАП ӘХМЕРОВ

*Тууына 90 ел*



Халык шагыйре Габдулла Тукайның якын дусты, композитор Салих Сәйдәшевнең тәрбиячесе, күренекле мәгърифәтче Шиһап Әхмеров 1882 елның 30 декабрендә хәзерге Чүпрәле районында крестьян семьясында туа. Буа мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң ул Әлмәт авылында балалар укыта. Ш. Әхмеров шул елларда ук инде башлангыч мәктәпләр өчен дәреслекләр төзү эшенә керешә.

1908 елда ул Казанга килеп «Сабах» китап нәшриятына эшкә урнаша. Аның 1909 елда басылып чыккан «Матбагачылык тарихы» дигән китабы татар халкына беренче буларак китап бастыру эшенең кайчан һәм кайда кемнәр тарафыннан эшләнүен ачык һәм аңлаешлы телдә сөйләп бирүе белән әһәмиятле. Шул ук китабында Ш. Әхмеров 1800 елдан башлап татар телендә китап бастыру буенча эшчәнлек күрсәткән күп кенә типографияләр турында бай мәгълүмат бирә.

1913 елның 21 февраленнән Казанда Ш. Әхмеров редакциясендә «Мәктәп» журналы чыга башлый. Журналның беренче саны Г. Тукайның «Олуг юбилей уңае белән халык өметләре» дигән публицистик шигыре белән ачыла, һәм, гомумән, «Мәктәп» журналы һәрвакыт әдәбият мәсьәләләренә киң урын биреп килә. Журналның беренче санында Г. Ибраһимовның «Мәктәптә әдәбият» дигән мәкаләсе, ә икенче санында исә хатын-кызлар өчен гимназия булдыру турында редакторның үз мәкаләсе басыла. Журналның дүртенче саны тулысы белән Тукай истәлегенә багышлана. Бу санда басылган материаллар арасында Г. Кариевның «Габдулла Тукайның Уральскидагы тормышы» дигән мәкаләсе аеруча тирән эчтәлекле язылган.

Ш. Әхмеров сәнгать һәм әдәбиятны ихлас күңелдән ярата, Г. Тукайга, бигрәк тә Салих Сәйдәшевкә төрлечә ярдәм күрсәтә. Зур белемле, тыйнак табигатьле, киң күңелле бу кеше үзе дә шигырьләр иҗат итә, шуларның берсендә ул совет иленә булган әчкерсез мәхәббәтен белдереп болай яза:

Таулар ашып, сулар кичеп, күп җирләрне таптадым.
Үз илемнән матур илне һичбер кайда тапмадым.
Минем илем — дуслык иле, тынычлыкка нык нигез,
Юк аңарда көчле-көчсез, һәрбер кеше бертигез.

Ш. Әхмеров пенсиягә чыккач та сәнгать һәм әдәбият белән кызыксынуын дәвам иттерә. Аның 1966 елда «Казан утлары» журналында басылган «Тукай һәм Сәйдәш» дигән мәкаләсе, Салих Сәйдәшев турындагы китапка урнаштырылган «Детские годы Салиха» дигән истәлеге әнә шул турыда сөйли.

Ш. Әхмеров 1966 елның 30 апрелендә вафат була.

М. ГАЙНУЛЛИН.

---

[1] «Совет Башкортстаны». 1957 ел. 24 май.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ВОРОШИЛОВГРАД КУНАКЛАРЫ ТАТАРСТАНДА

СССР төзелүгә 50 ел тулуга әзерлек унае белән Татарстанда Украина ССРның Ворошиловград өлкәсе әдипләре һәм сәнгать осталары атналыгы зур уңыш белән узды. Алар арасында прозаик В. Титов, драматург һәм прозаик Ф. Вольный, шагыйрьләр И. Савич, М. Яременко, С. Бугорков, В. Мальцев, В. Горяинов, О. Холошенко, А. Лебединский, художник Н. Неклюенко, Украина язучылары союзының Ворошиловград бүлеге секретаре Т. Рыбас, артистлардан А. Захарова, В. Якубович, Д. Якубович, Л. Ставицкий, Н. Нестеренко, А. Павлов бар иде.

Кунаклар В. И. Ленин һәйкәленә, революция эше өчен һәлак булганнар истәлегенә куелган обелискка, Г. Тукай, М. Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салдылар, Казан киностудиясенең Татарстан турындагы фильмнары белән таныштылар.

Казан консерваториясенең Актлар залында Татарстан язучылары союзы идарәсе һәм Украина язучылары союзының Ворошиловград өлкәсе бүлеге, СССРның 50 еллыгына багышлап, дуслык кичәсе үткәрделәр. Башта тантаналы утырыш булды. Утырышны КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев ачты. Ул КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, Министрлар Советы исеменнән кунакларны кайнар котлады.

Украин дусларның Татарстан җирендә очрашулары әдәбиятларыбыз һәм халыкларыбыз арасындагы дуслыкны тагын да киңәйтүгә, тирәнәйтүгә ярдәм итәр. Украина белән Татарстан арасындагы туганлык элемтәләре электән үк килә. Беренче бишьеллыкларда Украинадагы зур төзелешләргә безнең күп санлы ирләребез китсә, бүген Кама ярында төзелүче автогигантны салышуда йөзләрчә украиннар катнаша. Соңгы вакытларда ике халык арасында культура алмашу, бер-берсен рухи баетышу да көчәйде. Күптән түгел генә Татарстан язучылары, артистлары, нәфис сүз осталары Ворошиловград өлкәсендә булып, эшчеләр, игенчеләр, интеллигенция вәкилләре белән очраштылар. Бүген ворошиловградлылар кунакчыл Татарстан җирендә.

Украина язучыларының Ворошиловград өлкәсе бүлеге секретаре Тарас Рыбас үзенең чыгышын рус, украин, татар телләрендә: «Кадерле дуслар», сүзе белән башлады.

— Сезгә данлыклы Донбасс яклары сәламен алып килдек,— диде ул.— Донбасс шахталарында, гомумән, Ворошиловград өлкәсендә татарлар бик күп. Анда сезнең бабаларыгыз, әтиләрегез, абыйларыгыз күчеп килгән. Безнең якта да эш сөючән, уңган татарлар яши. Сезнең уңышлыкларны да ишетеп торабыз, алар таңга калырлык.

Халыкларыбыз арасында электән килгән туганлыкка кагылып, Тарас Рыбас Бөек Ватан сугышы елларындагы мисалларга тукталды:

— Украина җирен фашистлардан азат итүдә катнашучыларга тиздән чик буенда һәйкәл салачакбыз. Ә аны азат итүдә илебезнең күпчелек милләт вәкилләре катнашкан, шул исәптән татарлар да зур батырлыклар эшләгән...

Кичәне алып баручы шагыйрь Зәки Нури украин шагыйре Иван Савичка сүз бирде. Ул сәнгать әсәре аша замандашыбызга дан җырлады. Татар шагыйрьләре шигырьләрен үз тәрҗемәсендә украин телендә укыды.

Михайло Яременко, Степан Бугорков, Ольга Холошенко яңа шигырьләрен укыдылар.

Соңыннан Украина һәм Татарстан сәнгать осталары зур концерт бирде. Фойеда Украина, Татарстан язучылары әсәрләреннән күргәзмә һәм китап сату оештырылды.

КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Табеев Украинадан килгән әдипләрне, сәнгать осталарын кабул итте. Дусларча әңгәмә вакытында ул республикабыз тормышы, аның экономикасы, фәне һәм культура үсеше турында сөйләде.

Ворошиловград өлкәсе культура эшлеклеләре делегациясе җитәкчесе Тарас Рыбас Татарстанга чакырулары, җылы һәм дусларча очрашулар оештырулары өчен КПССның Татарстан өлкә комитетына, Татарстан язучылары союзына рәхмәт әйтте, КПССның Ворошиловград өлкә комитеты җибәргән бүләкләрне тапшырды. Ф. Табеев кунакларга истәлек итеп герой шагыйрь Муса Җәлил бюстен, Казан күренеше барельефын бирде.

Очрашуга КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Хәсәнов, КПСС өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. Мусин, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Кадыйрова һәм Татарстан язучылары катнашты.

Аннары Украина кунаклары, өч төркемгә бүленеп, Татарстан районнарында хезмәт иясләре белән очраштылар.

Бер төркем әдипләр һәм артистлар Питрәч районы хезмәт ияләре белән очрашуларын Ленино-Кокушкино авылындагы В. И. Ленин музей-йорты белән танышудан башладылар. Аннары алар Ильичның энисе Мария Александровна исемен йөрткән урта мәктәптә, андагы М. А. Ульянова музей-бүлмәсендә булдылар. Соңыннан авыл хезмәт ияләре белән очраштылар.

Украин һәм татар халыкларының дуслыгына багышланган бәйрәмне укучылар Г. Гыйләжева һәм Т. Перепеченова шигырьләр белән ачып җибәрделәр. Ленино-Кокушкино урта мәктәбе директоры Ф. Госаметдинов яшь буынны интернациональ рухта тәрбияләү буенча педагогик коллектив башкарган зур эшләр турында сөйләде. Т. Калинина кунакларны почетлы пионерга алу турында дружина советы карарын укыды.

Т. Рыбас, язучы В. Титов, шагыйрь А. Лебединский очрашудан алган тәэсирләре турында дулкынланып сөйләделәр, җырчы Д. Якубович берничә җыр башкарды. Татар әдипләре З. Нури, Н. Дәүли, Ю. Белостоцкий, М. Фәйзуллина, Т. Миннуллин үз әсәрләрен укыдылар.

Шундый ук җылы һәм эчкерсез очрашу кичен район культура йортында да булды.

«Бөреле» җәнлек совхозында аларны совхоз җитәкчеләре, эшче-хезмәткәрләре, урта мәктәп пионерлары ипи-тоз белән каршыладылар, һәркайсына чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр, кызыл галстук бәйләделәр.

Кунаклар совхозда эшчеләрнең тормыш, көнкүреш хәлләре, кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләр белән таныштылар, совхоз поселогындагы В. И. Ленин һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре салдылар.

Яшел аланлыктагы очрашуга әдәбият сөючеләр күп җыелган иде.

Владислав Титов совхоз эшчеләренә Донбасс шахтерларыннан сәлам тапшырды. Шагыйрь А. Лебединский үзенең яңа әсәрләрен укыды. Татар язучыларыннан З. Нури, Н. Дәүли, М. Фәйзуллина, Т. Миннуллиннар да очрашуга катнашучыларны үзләренең кайбер әсәрләре белән таныштырдылар.

Болардан тыш бу төркемдәге язучылар Биектау районының Шәпше агро-шәһәрендә булдылар, Зеленодольск шәһәрен карадылар, андагы предприятиеләрдә эшләүче хезмәт ияләре белән очраштылар.

Икенче төркем язучыларны Актаныш аэропортында республикабызның иң ерак читендәге район хезмәт ияләре ипи-тоз белән каршыладылар. Аэропорттан алар «Чишмә» колхозына юл тоттылар. Кичен авыл культура йортында колхозчылар белән очраштылар, үзешчән һәвәскәрләр концертын карадылар. Икенче көнне дусларыбыз Актаныштагы төзелешләр белән таныштылар. Культура йортында район үзәге хезмәт ияләре белән очраштылар. Аннары «Коммунизмга», «Маяк» һәм Нур Баян исемендәге колхозларда булдылар. Бирелә Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә куелган һәйкәлләргә, татар совет язучысы Нур Баян һәйкәленә чәчәкләр салдылар. КПССның Актаныш райкомы секретарьлары М. Сәмигуллин, Х. Низамов кунакларны район тормышы белән таныштырдылар. Очрашуларда украинча, русча, татарча җырлар, шигырьләр яңгырады.

Аннары кунаклар Минзәлә шәһәренә киттеләр. Ленин һәйкәленә, гражданнар сугышында һәлак булган туганнар каберлегенә, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәйкәленә чәчәкләр куйдылар. Минзәләдә Украина ССР көне уза иде. Безнең кунакларыбыз да туры килү бу бәйрәмне аеруча зур итте. Район үзәгендә гаять зур шигъри-музыкаль митинг үткәрелде.

Куйбышев исемендәге колхозда үткәрелгән дуслык кичәсе Минзәләдәге Украина ССР көненең дәвамы булды. Кичәне КПСС райкомы секретаре Г. Хәкимова ачты, язучы Гариф Ахунов алып барды. Мәктәп балалары, пионерлар кунакларга чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр. Федор Вольный зур хөрмәт күрсәткәннәре өчен колхозчыларга чын күңелдән рәхмәт әйтте. Шагыйрь Михайло Яременко йөрәкләрдә туган дуслык хисләрен шигырьләре аша иреште рде.

Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Шәүкәт Галиев, Рәшит Гәрәй, Мәдинә Маликова үз әсәрләрен укыдылар. Украина шагыйре Василий Горяинов чыгышын Донбасс шахталарында кулга-кул тотышып эшләүче, бертуганнардай гөрләшеп гомер итүче украин һәм татар халыкларының бөек дуслыгына багышлады. Ворошиловград филармониясе артистлары — нәфис сүз остасы А. Захарова, баянчы А. Павлов, җырчы Н. Нестеренко әдипләр чыгышын тагын да тулыландырдылар.

Муса Җәлил исемендәге колхоз председателе Сабирҗан Зарипов, Минзәлә драма театрының баш режиссеры, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Мулланур Мостафин, Мичурин исемендәге колхоз парткомы секретаре Әмир Нәбиуллин, «Ленар» колхозы вәкиле Венера Камильянова дусларыбызны колхозчылар исеменнән кайнар котладылар, истәлек бүләкләре тапшырдылар.

Йомгаклау сүзе белән район Советы башкарма комитеты председателе С. Вильданов чыкты.

Аннан соң язучылар легендар КамАЗ төзелешендә булдылар, Түбән Кама хезмәт ияләре белән очраштылар, шәһәрдәге төзелешләрне карадылар.

Лениногорск шәһәре хезмәт ияләре дә Украинадан килгән кунакларны якты йөз белән каршылады. Украин дуслар башта шәһәр белән таныштылар, нефтьчеләр музеенда булдылар. Татарстанда беренче нефть биргән 3 нче скважинаны карадылар.

Кичен нефтьчеләрнең Техника йортында украин һәм татар язучылары белән очрашу булды. КПСС шәһәр комитетының икенче секретаре Р. Гыйләҗев, дуслык кичәсен ачып, украин дусларны шәһәр халкы исеменнән кайнар котлады.

И. Савич кичәгә катнашучыларны каләмдәшләре белән таныштырды.

— Украин белән татар халкы дуслыгы күптәннән килә,— диде шагыйрь Иван Савич.— Бөек Ватан сугышы елларында шахталарда эшләгән татарлар бездә әле дә күп. Хәзер аларның уллары һәм кызлары илебезнең көчен ныгытуда өлеш кертәләр.

Аннары Иван Савич үз телендә татар шагыйрьләренең әсәрләрен укыды.

— Безнең туганлык җепләре кан белән береккән,— диде Советлар Союзы Герое Самат Садриев.— Без, төрле милләт кешеләре, Украина җирләрен фашист илбасарлардан азат иттек. Ә хәзер «кара алтын» чыгарабыз. Илебезгә Донбасс күмере кебек үк, нефть тә кирәк. Ә язучылар хезмәт кешесенә дан җырлыйлар, безгә алар дәрт өстиләр.

Ольга Холошенко яшь гвардиячеләргә, шахтерлар хезмәтенә багышланган шигырьләрен, Вениамин Мальцев үз әсәрләреннән өзекләр укыды. Залдагылар аларны алкышлап каршы алдылар.

Кичәнең икенче бүлегендә Техника йорты үзешчән сәнгать коллективының концерты булды.

Икенче көнне алар Лениногорскидан Әлмәткә юл алдылар. Ике район чигендә кунакларга милли киемнәр кигән татар кызлары чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр. Биредә украин дусларны КПССның Әлмәт шәһәре комитетының беренче секретаре В. Е. Борисов, шәһәр Советы башкарма комитеты председателе И. Д. Мусаев, Әлмәт шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Гамил Афзал һәм башкалар каршылады.

Аннары украин һәм татар язучылары нефтьчеләр шәһәре белән таныштылар, хезмәт урыннарында эшчеләр белән очраштылар.

Кич белән Техника йортында шәһәрнең әдәбият сөючеләре белән очрашу гаять тантаналы булды. Ворошиловград шагыйре Иван Савичның Муса Җәлилгә багышланган шигырен, Ольга Холошенко, Вениамин Мальцев әсәрләрен кичәгә килүчеләр яратып тыңладылар.

Украина кунаклары белән бергә килгән татар шагыйрьләре һәм язучылары Ренат Харисов, Мөхәммәт Мәһдиев, Равил Фәйзуллин, Шамил Рәкыйпов, Сажидә Сөләйманованың чыгышы әлмәтлеләргә шулай ук ошады.

Язучылар иртәгесен Бөгелмәгә килделәр. Украин дуслар һәм татар язучылары КПССның шәһәр комитетында булдылар. Партия шәһәр комитетының икенче секретаре М. И. Баянов шәһәрнең үткәне, бүгенгесе һәм матур киләчәге турында сөйләде. Республиканың фәнни үзәкләреннән берсе — Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау институтында кунаклар бик күп яңалыклар, республикабызның шул өлкәдәге олы казанышлары белән таныштылар. Аннан алар өлкәне өйрәнү музеенда, үзәк китапханәдә булдылар.

Кич белән Техника йортының зур залында шәһәр хезмәт ияләре тугандаш Украина һәм татар әдәбияты әсәрләрен яратып тыңладылар. Дуслыкка багышланган кичәдә украин, рус һәм татар җырлары яңгырады.

Казанда һәм республикабыз районнарындагы бу очрашулар чын-чынлап татар һәм украин халыклары арасындагы дуслык бәйрәме булды.

## «ТУГАНЛЫК ТАҢНАРЫ»

Рязань шәһәрендә С. Есенин исемендәге китап сөючеләр клубында СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән «Туганлык таңнары» исемле китап күргәзмәсе оештырылды. Анда башка тугандаш әдәбият үрнәкләре белән рәттән татар язучыларының китапларына да зур урын бирелгән.

## ЯНКА КУПАЛАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН

Күп милләтле совет әдәбияты күренекле белорус шагыйре Янка Купаланың тууына 90 ел тулу көнен киң итеп билгеләп үтте. Бу уңай белән Минск шәһәрендә үткәрелгән тантаналы җыелышка Татарстаннан вәкил булып шагыйрь Зәки Нури катнашты. Ул Белоруссия җәмәгатьчелегенә Казанда яңа төзелгән урамнарның берсенә Янка Купала исеме бирелүе һәм Бөек Ватан сугышы чорында 1941—1942 елларда Янка Купала яшәгән Печище эшчеләр поселогында (Югары Ослан районы) шагыйрьнең тормышына һәм иҗади эшчәнлегенә багышланган мемориаль бүлмә ачылачагы турында Татарстан хөкүмәте карарын белдерде.

## БАКУДА ТАТАР СӘНГАТЕ КИЧӘСЕ

Баку шәһәрендәге Орджоникидзе исемендәге Культура сараеның татар үзешчән сәнгать коллективы СССРның төзелүенә 50 ел тулу уңае белән татар сәнгате кичәсе үткәрде. Күп санлы тамашачылар үзешчәннәр башкаруында композиторларыбыз һәм язучыларыбыз әсәрләрен, татар халык иҗаты үрнәкләрен яратып тыңладылар.

# Укучыларыбыз игътибарына

Журнал редакциясенә көн саен дистәләрчә хатлар килеп тора. Хат авторларының күбесе «Казан утлары»ның чираттагы санында басылган әсәрләргә карата үз күңелләрендә туган уй-фикерләрен, теләк-тәкъдимнәрен язып җибәрәләр. Шулай итеп, алар редакция хезмәткәрләренә һәм әсәрләре журналда басылган язучыларга хәл кадәренчә ярдәм күрсәтергә тырышалар. Редакция мондый хатларны куанып, көтеп ала.

Әмма, редакция һәм язучылар өчен бик кадерле һәм файдалы булган менә шушындый хатлар белән беррәттән, бүтән мәсьәләләргә кагылышлы хатлар да шактый күп була. Ул хатларның эчтәлеге нигездә өч сорауга кайтып кала:

1. «Казан утлары»на язылмакчы идем, ләкин, андый журналны белмибез, дип яздырмадылар. Аңа ничек язылырга була соң?

2. «Казан утлары»ның фәлән санын китермәделәр. Почтага барып сораган идем, без берни дә белмибез, безгә килгәне юк, редакциядән сорап яз, диделәр. Нигә миңа журнал җибәрмисез?

3. Татар язучыларының китапларын укырга телим. Әмма мин яшәгән җирдә аларны табып булмый. Шуңа күрә сездән үтенеп сорыйм, миңа фәлән язучының китабын җибәрә алмассызмы?

Хәзер, газета-журналларга язылу барган көннәрдә, менә шушы мәсьәләләрне ачыклауны үтенеп язган хатлар аеруча күбәйде. Хат белән генә җавап биреп бетерү мөмкин булмаганлыктан, без ул хатларның авторларына журнал аша аңлатма бирүне кирәк дип таптык.

Иң элек шуны басым ясап әйтеп үтик: «Казан утлары»на СССРның теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин. Ул — Бөтенсоюз журналлар каталогына 73210 номерлы индекс белән кертелгән журнал. Шул индексны әйтсәгез, сезне журналга һичнинди тоткарлыксыз яздырырлар. Тик моны озакка сузмыйча, подписка кампаниясе башланган көннәрдә үк эшләп калырга кирәк.

Әгәр журналның берәр саны килми калса, сез аны редакциядән түгел, бәлки үзегездән подписка алган элемтә бүлеге хезмәткәрләреннән таләп итегез. Алар бу мәсьәләне юллап бирергә бурычлы кешеләр. Тагын да ачыграк итеп әйтсәк, алар менә болай эшләргә тиеш: журналның кайсы саны килми калуын әйтеп һәм сезнең подписка квитанциягезнең номерын күрсәтеп, Казандагы газета-журналлар экспедициясенә (адресы: г. Казань, ул. Баумана, 19, газетно-журнальный цех) мөрәҗәгать итәргә, журналны шуннан сорарга тиешләр. Ә редакция журналга подписка кабул итү белән дә, укучыларга журнал җибәрү белән дә шөгыльләнми.

Журнал редакциясенең шулай ук укучыларга китаплар җибәрергә дә мөмкинлеге юк. Ләкин сез, кадерле укучылар, татар язучыларының китапларын бер дә мәшәкатьсез генә үзегезнең өегезгә кайтарта аласыз. Аның өчен, укырга теләгән китабыгызның исемен һәм ул китапның авторын әйтеп, түбәндәге адрес буенча хат язып җибәрү генә кирәк:

*г. Казань, ул. Октябрьская, дом 18, магазин «Книга-почтой».*

**Редакциянең хатлар бүлеге мөдире**
**В. НУРУЛЛИН.**

*Хөрмәтле укучылар!*

1973 елның беренче санында Э. Касыймовның **«Һаваларда тургай»** романын баса башлыйбыз. Бу — «Томан аша» китабының икенче кисәге. Яшь язучы Х. Хәйруллин **«Канатлар талмасын»** дигән повестенда республикабыздагы иң алдынгы колхоз тормышын, бүгенге көннең үткен проблемаларын, төрле характерлы, төрле язмышлы кешеләрне сурәтли.

Шигърият дуслары Г. Афзалның **«Нигә төшкә керә ул таңнар»** дигән шигырьләр циклын, З. Насыйбуллин, К. Сибгатуллин шигырьләрен укырлар.

М. Зариповның **«Тылсым иясе»** дигән очеркы Түбән Кама эшчеләренә багышлана. В. Гудкова **«Гомер буе укытучы»** дигән очеркында философия фәннәре докторы Мансур Абдрахмановның тормыш юлын, фәндә ирешкән уңышларын сөйли.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Ш. Әхмәдуллинның **«Шигърият мәйданында сонетлар»** дигән мәкаләсен укырсыз.

Болардан тыш сәнгать мәсьәләләренә караган мәкаләләр, яңа китаплар, юмор-сатира, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210